ISSN 0206-4189
Индекс 73210

12+

# КАЗАН УТЛАРЫ

11.2014



№11 (1105) 2014

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВНЫҢ БИШЕНЧЕ ЧАКЫРЫЛЫШ ТР ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНЫҢ ИКЕНЧЕ УТЫРЫШЫНДА ҖИТКЕРГӘН ЕЛЛЫК ЮЛЛАМАСЫННАН



«Болгар» тарих-археология комплексы ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы һәйкәлләре исемлегенә кертелде. Бу — беренче Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең гаять зур казанышы.

Бик зур рәхмәт Сезгә!

Свияжск утрау-шәһәрчеге объектларына кагылышлы шундый ук эш башкарырга тиешбез.

ТӨРКСОЙ тарафыннан Казанның төрки дөнья мәдәни башкаласы дип игълан ителүе белән бәйле рәвештә республика башкаласында бик күп иҗади форумнар һәм чаралар уздырыла.

Казанның тарихи үзәген торгызу, мәдәни мирас объектларын төзекләндерү буенча күп эшләр башкарылды һәм башкарыла.

Мәдәниятнең барлык өстенлекле юнәлешләре буенча тулы бер программа чаралары комплексы кабул ителде.

Бу эшне без киләчәктә дә дәвам иттерәчәкбез.

Бай һәм матур телебез, мәдәниятебез һәм рухи хәзинәбез татар халкын берләштерә.

Монда «Татар иле», «Ана теле» һәм башка милли проектларның әһәмияте бик зур. Әлеге юнәлештә эшләүне дәвам иттерергә кирәк.

Илебездә 2015 ел — Әдәбият елы дип игълан ителде. Язучыларның, аеруча яшь авторларның иҗади үсеше өчен яна мөмкинлекләр булдырыга, балалар әдәбиятын һәм әдәбият-сәнгать өлкәсендә халыкара элемтәләрне үстерүгә юнәлтелгән проектларга ярдәм күрсәтүне кайгырту аеруча зарур.

Территорияләрне төзекләндерү һәм агач-үсемлекләр утырту мәсьәләләрен без республикабызда шулай ук өстенлекле дип билгеләдек һәм 2015 елны Парклар һәм скверлар елы дип игълан иттек. Шулай итеп без бу процесска гражданнарны, бизнесны һәм хакимият органнарын җәлеп итәбез.

*Казан, 9 октябрь, 2014*

КАЗАН УТЛАРЫ

www.kazanutlary.ru

ӘДӘБИ-НӘФИС һӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ һӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Рашат НИЗАМИ. Каләмемнең кипмәс карасы. *Шигырьләр.* ....3
Салават РӘХМӘТУЛЛА. Утырып уйланыр чак... *Шигырьләр.* ....54
Лениза ВӘЛИЕВА. Яшәү — мәйдан... *Шигырьләр.* ....84
Рифкать ХУҖИ. Бер кәнди цемент. *Хикәя.* ....88
Ленар ШӘЕХ. Үзгәрешләр — адым саен. *Шигырьләр.* ....91
Гөлнур ВАСЫЙЛОВА. Биюче Нәгыймә. *Хикәя.* ....182

КЫСКА БӘЯННАР КОНКУРСЫ

Зөлфәт ХӘКИМ. Сәер никрут. *Сатирик бәян.* ....8
Фәтхулла АБДУЛЛИН. Чүл бүресе. *Бәян.* ....58

ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР

Рәйсә ЮСУПОВА. Бүре елаган төндә... ....95

100нче бит: Зиннур МАНСУРОВ. Явыз Иван киңәше. *Шигырь.* ....100

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫННАН

ЧУЛПАН. Дала юлларыннан... *Шигырьләр.* ....101

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Заман шигъриятендә ил гаме. ....103

СӘНГАТЬ

Юныс САФИУЛЛИН. Рухландыручы *(Марсель Сәлимҗановның тууына 80 ел).* ....109
Ринат ТАҖЕТДИНОВ. Ул һаман безнең белән. ....113

ТАРИХ

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Талантлы тарихчы-романтик ядкаре. ....115

ЮБИЛЕЙЛАР

Традицияләргә тугры калып... *(«Түгәрәк өстәл»).* ....126
Лирон ХӘМИДУЛЛИН. Милләтнең йөз аклыгы сагында. ....138
Ривкат ЮСУПОВ. Яңа биеклекләр яуларга... ....149

ДИН һӘМ ТОРМЫШ

Тәлгат хаҗи НӘҖМЕТДИН. Изге сәфәр җинел гамәл түгел. *Хаҗнамә.* ....155

ХӘТЕР

Рауль МИР-ХӘЙДӘРОВ. Шуның белән шул... вокзалдан язам. *Мемуарлар.* ....170
Әлфия ШАМОВА. Сезнең язмыш сугыш уты белән үрелгән. ....175

Кайтаваз: Сорауларга җавап эзләгәндә... *(Рашат Низаминың Ренат Хариска җавап хаты).* ....178

Шаян сәхифә: Уены-чыны бергә. *(Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде.)* ....185

Мәкаль өмәсе. ....188

«Казан утлары» архивыннан. *(Сәхифәне Равил ФӘЙЗУЛЛИН әзерләде.)* ....136

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ
НАЦИОНАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Гамәлгә куючы —
«Татмедиа»
ачык акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*

**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Нурия Беломоина**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(җаваплы сәркатип)*
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Әлфәт Закирҗанов, Камил Кәримов, Вакыйф Нуриев, Ләйсән Солтанова.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров, Флёра Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир — 222-05-50 (өст. 1618).*
*Җаваплы сәркатип, компьютер үзәге — 222-09-83 (өст. 1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (өст. 1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (өст. 1267).*
: **Факс** — (843) *222-09-83 (өст. 1612).*

: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 30.10.2014, график буенча 30.10.2014.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-2895. Тираж 3300.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс: 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2014 ел



Рашат
Низами

## КАЛӘМЕМНЕҢ КИПМӘС КАРАСЫ

### Шәфталу

Йөрим гүя ожмах бакчасында:
Жимеш арты жимеш тезелгән.
Чү! Монысы... ә монысы аның
Кай агачтан икән өзелгән?

«Персик», диләр. Бабалары аның
Персиядә, бәлки, үскәндер.
Бу дөньяда жимеш кенә түгел,
Кешеләр дә хәтта... бердәнбер.

«Пескәй» дигән рифма колагымда,
Чын татарча әйтсәк — шәфталу.
...Ир-затларга талант бирелгәндер, —
Хатын-кызга карап таң калу!

Шәфталуны тешләп карасаммы —
Шул сурәте күздән жуелмас:
Мәмрәп пешкән үзегеннән аның
Килеп чыга... кара чуерташ.

Сак бул, егет!
Ожмах бакчасында
Сөю ташларына юлыксаң.
Мәхәббәтнең күге генә биек,
Чынбарлыкта кайчак юл кысан.

Кемдер оча парлап, канатланып.
Ялгызларга, әйтче, кем юлдаш?
Сөюнен дә ерак почмагында
Тып-тын посып ята чуерташ...

---

Рашат НИЗАМИ (1950) — *шагыйрь, прозаик, публицист; «Яралы керпе», Фәрит Яруллин турындагы «Ут һәм жыр» дигән роман-хроника, «Сөйдәшнең соңгы елы» исемле кыйсса һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

## Минем урманым

Орларында уйный төлке, киек,
Имәннәрнең очы, ай-һай, биек:
Чайкалышып торган минутларда
Тиеп-тиеп китә болытларга.

Эләктерәм диеп кояш нурын,
Суза үлән нәни яфракчыгын.
Сыенган да усак кочагына,
Баскан миләш аяк очларына.

Биек абагалар һәм үләннәр
Бер-беренә килеп сөялгәннәр.
Күзгә бәрелеп тормаса да гәрчә —
Яши, сулый монда һәрбер нәрсә.

Син мактаган сазлы әрәмәдә
Бар микән соң чикерткәләр җыры?
Биредәге чыршы төн эченнән
Таңга каршы очып чыга туры!

## Теләченең олы юлында

Көмеш атын җитәкләгән егет,
Сукмаклары илтә инешкә.
Канатлы ат канатланып атлый
Хәтта йөгәнләгән килеш тә!..

Ат эчерә егет, ат сугара,
Барыр юлы ерак, күрәсең.
Юлдашыдыр, ахры — ярга басып,
Сулар эчә ап-ак күгәрчен.

Дулкын өстендәге очкыннарны
Сөзеп кенә эчә аткае.
...Кереп тулыр атның күзләренә
Алсуланып таңнар атканы.

Атны егет үзе дагалаган:
Ташка бассаң — чыксын ялкыны!
Алып чыкса алып чыгар аны
Шушы аты еллар аркылы...

## Күперләр

Җитәкләшеп уздык күпердән.
Сулар ага... Үлән күпергән.

Тирә-юньдә көмеш яктылык!
Болыт тора күктә — тап булып.

Каеннардан аклык түгелгән.
Уздык сөю дигән күпердән.

Мәхәббәттән Ай да исерде —
Ялгызлыгын искә төшерде.

Еллар ага... Вакыт картая.
Без барабыз икән кай таба?

Каләмемнең кипмәс карасы, —
Сүзләр сүзгә тора карашып.

Насыйп булсын гарше кичләрдә
Сират юлын бергә кичәргә...

## Тагын бер кат гомер турында

I

Вакыт дигән канатлы ат
Җилдерә, оча гына!
Нарасый булып тамганбыз
Әнкәйләр кочагына...

II

Атлый торгач дөньялыкның
Ай-кояшлы ягына, —
Атылып килеп кергәнбез
Мәхәббәт учагына...

III

Кая киткән гайрәтле чак?
Шәм эреп ага, сына.
Килә дә төртелә кеше
Әҗәлнең чалгысына...

## Төнге яңгыр

Шыбыр-шыбыр...
Төнге янгыр ява,
Кара шәүләләрне камчылап.
Пыялага килеп бәрелә дә
Тәрәзәдә үлә тамчылар.

Берни әйтми һәм сөйләшми янгыр,
Тылсым белән бары пышылдый...
Янгыр жепләренә тотынышып,
Жир белән күк бергә кушылды.

Дөнья дымык... Бер дә рәхәт түгел
Төнге юлда йөргән мәчегә.
Йолдызларны каплап китә янгыр,
Йолдыз булып үзе чәчелә.

Ераклардан бер-бер хәбәр микән
Сынып калган яшен яктысы?
Төн саташа... Кызны көтеп тора
Мәхәббәтнең иң-иң татлысы...

Төнге янгыр! Караңгыга түгел,
Таңга таба китеп барышың.
Офыкларда чигеп калдырасың
Яшеннәрнең утлы сагышын.

Табигатьнең көтеп алганы син,
Ерак әле салкын кышларга.
Уйна, янгыр, берәм-берәм басып
Ак-каралы клавишаларга!

## Заман сурәтләре

Юлга чыгам. Офыкларым —
Яки төнгә,
Яки таңга әверелә.
Шаулый гомер. Фасылларым —
Йә янгырга,
йә буранга әверелә.

Җандаш эзлим. Мәхәббәтем —
Ал чәчкәгә,
Йә нәфрәткә әверелә.

Шигырь язам. Әйтер сүзем —
Йә икмәккә,
Яки ташка әверелә.

... Замананың һәр сурәте —
Әнә шулай
Кереп тула бәгыремә!

## Чүкеч җыры

*Түбән Камадагы*
*нәкышче Александр Ивановка*

Тимер белән чүкеч очрашканда,
Өр-яңа моң, якты җыр туа.
Гап-гади бер калай кисәгеннән
Сәнгать ясый ала виртуоз.

Тукай язган әкият геройлары
Диварларга күчкән, күр әле:
Кама яктан килеп житкән безгә
Су анасы белән Шүрәле.

Әй, зәркәнче дустым, терелткәнсең
Тимер кадәр тимер кисәген.
Тагын кайсы татар әкиятләрен
Җанландыру синең исәбең?

Талант ягын Ходай биргән сиңа,
Ә тырышлык инде — үзеңнән.
Сүзләр генә түгел, чүкеч җыры
Могжизага әверелә
Уза алса энә күзеннән...

## Тормыш грамматикасы

«Күп нокта»лар белән чуарланган
Гомеремнең кайбер көннәре.
Кайчагында, үчекләгән сыман,
Суза язмыш салкын мендәрен.

«Өтер» куям — уйлар чуалганда,
Ярты юлда — җөмләм өзелә.
Туктап-туктап һаман алга барам
Хакыйкатьнең карап күзенә.

Вакыт ага. Гамәл дәфтәрендә
Сызылып кала гомер язмасы.
Тик бер теләк: ап-ак битләренә
Соң «нокта»ны кую язмасын!

## Язның беренче көне

Күр: тамчылар сикерде язга таба!
Кереп тулды күкрәкләргә саф һава.

Кинәт күкләр һич көтмәстән абынды, —
Кар өстендә күпме йолдыз кабынды!

Ак кар ява — чәчәк ата офыклар,
Җыру суза кыектагы чыпчыклар.

Чыпчыкның да, язларның да үз җыры,
Күр, өзелде салкын кышның зынҗыры!..

Өр-яңа көн күзен кысып елмая —
Безгә дигән язлар балкый дөньяда!

... Бер нәрсәдән һәр таң саен куркамын:
Атмас микән аучы егет... кыр казын?

## Астрономия

Тәүлек буе парад ясый Кояш —
Сигез планетасын җитәкләп.
Галәмдәге меңәрләгән сорау
Тартып тора безне итәктән...

## «Держава»га бер сүз

Рельсларны тимер тутык баскан:
Күргән алар — бозын, янгырын...
Рәсәй әгәр чын держава икән, —
Торгызыгыз черек БАМ юлын!



Зөлфәт
Хәким

# СӘЕР НИКРУТ

САТИРИК БӘЯН

## I

Еллар узган саен Татарстанда хәрби хезмәткә яраклы призывниклар саны кими барды. Унсигез-егерме яшьлек үсмерләрнең бер өлеше хәрби хезмәткә яраксыз дигән кәгазь-документ юнәтеп армиягә бармый калса, икенче өлеше шундый ук ярлыкны «тиешле кеше»гә ришвәт биреп солдат булудан котыла башлады.

Соңгы вакытта Россия армиясенең шәхси составын нигездә үсмерләрнең өченче төре – ялган справкалар ясарга мөмкинлекләре булмаган гади кешеләрнең, взятка бирергә акчасы булмаган ярлы халыкның малайлары тәшкил итә иде.

Шулай да яшьләр арасында үз теләкләре белән хәрби хезмәткә омтылучылар да юк түгел.

Каенсар авылында шундый бер малай үзенә унсигез яше тулганны зарыгып көтте – аның армиягә барып, кулына корал алып, илгә хезмәт итү теләге бик көчле иде. Аларның нәселендәге һәр татар егете солдат булып, Ватан сагында һичшиксез хезмәт итеп кайтырга тиеш дигән эчке ышануны бернинди заман үзгәрешләре чалшайтырлык түгел иде.

Булат сигезенче класстан соң ук военкомат тарафыннан беренче повестканы көтә башлады. Әмма мәктәпне тәмамлагач та, унсигезе тулгач та, аннан соң тагын берничә ел үтеп киткәч тә аны армиягә чакыручы булмады.

Беркөнне әтисе Раиф егерме бер яше тулган улына:

– Военкоматка үзең барып кайт, – диде. – Үзләре, тора салып, армиягә призывниклар житми, дип лаф оралар... Нишләп сине чакырмыйлар икән?!

Булатка повестка килмәүнең сәбәбе гап-гади иде. Хәрби комиссариат бинасында ремонт булды. Күп елларга сузылган ватып-җимереп янадан төзү дәверендә булачак солдат Хәсәнов Булат Раиф улы теркәлгән кәгазьләр чүп-чар арасында югалды.

Дөрес, берничә ел узгач, аның документлары иске папкалар арасыннан килеп чыкты чыгуын, ләкин аны военкоматка хәтта чакыртып та тормадылар. Аның турында: «Барыбер нинди дә булса чире бардыр, «не годен»дыр, югыйсә монарчы армиягә китми ятмас иде, мөгаен, берәр кешесе бардыр, йә чирледер, йә инде берәрсенә түләгәндер...» – дип уйладылар.

Әмма беркөнне көтелмәгән, алай гына да түгел, тетрәндергеч вакыйга N каласындагы хәрби комиссариатны һушсыз калдырды. Әлеге дә баягы үсмер

егет үзе военкоматка килеп керде дә коридорда очраган өлкән лейтенантка армиягә китәргә теләвен әйтте.

Авыл малайларына хас каушауны көчкә жинеп, егетебез берничә минут эчендә хасил булган комиссия каршына килеп басты.

Кин жилкәле, уртачадан калкурак гәүдәле, эре сөякле егетне жентекләп күзәттеләр. Каршыларында кара чәчле, кара кашлы, чәй төсендәге күзләреннән ихласлыгы күренеп торган чибәр егет басып тора. Анын кылыч борыны, ихтыяр көчен күрсәтә торган нык ияге комиссия составындагы өч хатынның игътибарын аеруча жәлеп итте. Үзенең шушы чын ирләрчә кыяфәтенә, буй-сынына тәнгәл килми торган, авыл егетләренә хас оялчанлык, юашлыкка охшаган сабырлык та бар иде анарда.

— Нишләп мине һаман чакырмыйсыз? — диде ул, комиссия әгъзаларынын кайсысына карарга белмичә. — Нишләп мина һаман повестка юк?! Мина бит инде егерме бер яшь.

Яшьләрнең күбесе әллә нинди ысуллар белән, алдап, хәйләләп, күп-күп акча түли-түли, армия хезмәтеннән котылу юлын эзләгәндә, берәүнен солдат булырга омтылуы комиссия өчен гайре табигый хәл иде.

— Армиягә барасын киләмени? — дип сорадылар егеттән, анын ихласлыгына һич кенә дә ышанмыйча.

— Сон, яше житкәч һәрбер егет солдатта булып кайтырга тиеш бит инде, — диде авыл малае.

Комиссия әгъзалары, үзара мыр-мыр килеп алдылар. Аларнын кайсысы кызыксынып, сәерсенеп, көлемсерәп, ә кайсысы кызганып кабул итте малайнын теләген. Әмма аларны бер уртак хис какшамас комиссия итеп тотып тора иде, бу — үсмердән шикләнү, ана ышанмау.

— Төнлә астына симисенмени син? — дип кызыксынды берсе.

— Юк, — диде егет, бу сорауга бераз үпкәләп.

— Колагын да әйбәт ишетәме?

— Әйе, колакларым да үз урынында.

— Син, нәрсә, төнлә саташып, йокыдан уянмаган килеш, урамнарга чыгып китмисенмени?

— Юк, мин бик каты йоклыйм. Саташу түгел, хәтта төшләрне дә сирәк күрәм. Мин бит эштән бик нык арып кайтам. Шулай булгач, нишләп саташып урамнарга чыгып йөрим ди инде!

Комиссиянен шиге артканнан-арта барды.

— Таныш врачларыгыз юкмыни? — дип сорады комиссиядән берәү.

— Бар, — диде хәрби кием киярга теләүче егет. — Әнкәйнен абыйсы район поликлиникасында терапевт булып эшли.

Комиссия әгъзалары өнсез калды. Карале моны! Абыйсы табиб була торып та ялган справкалар ясатмый! Бигрәк сәер кеше басып тора каршыларында! Әгъзалар янә үзара пыш-пыш килеп алдылар. Ата-анасынын военкомга «төртергә» акчалары юктыр дигән нәтижә ясадылар.

— Сезнен гаиләгез матди яктан хәлсездер инде, авыл жирендә акча юк бит, — дигәнне ишеткәч, егет тирән горурлык белән сөйли башлады:

— Аллага шөкер, акчабыз житәрлек. Әти балта остасы. Авылдан ерак түгел, урман буенда яна йортлар сала. Заказлардан арынган юк. Ә мин — анын ярдәмчесе. Бик шәп түлиләр безгә, чөнки әти бик оста плотник. Армиядә хезмәт итеп кайткач та, Алла боерган булса, әти белән балта эшендә эшләячәкмен. Мин балта эшен бик яратам.

— Ник армиягә барырга телисен сон син? — дигәч, егет гап-гади итеп жавап бирде:

— Илне кемдер сакларга тиештер бит инде. Армиядә кемдер хезмәт итәргә тиеш!

Комиссиядәгеләр үзе теләп армиягә атлыгучы егетләрне соңгы тапкыр кайчан күргәннәрен хәтерләмәгәнгә беркавым кинәшләшкәннән соң, бертавыштан: «Бу малай точно җүләр!» — дигән нәтиҗәгә килделәр.

Егет карышып карады:

— Мин сау-сәламәт! Зиһенем дә чалыш түгел! Мин хезмәт итеп кайтырга тиеш!

— Акылга зәгыйфь кешене хәрби хезмәткә алмыйбыз, — дип җавап бирделәр аңа. — Ничек инде тилегә ышанып утлы корал тапшырасың! Ил сагында дөрес психикалы егетләр торырга тиеш!

Авыл егетен нык рәнҗетте болар. Аның кыза башлаганын чамалагач, полиция чакыртып, унбиш тәүлеккә утыртабыз дип куркыттылар.

Һәм берни аңламый каңгыраеп калган егетне, «не годен» дигән карар белән, авылына кайтарып җибәрделәр.

## II

Өенә кайтып, ата-анасына, калада көллияттә укучы сеңлесенә гаҗәпләнеп, рәнҗеп кат-кат сөйләгәннән соң, анасы белән сеңлесе: «Төкер армияләренә!» — диделәр. Атасы исә чәй пешерә торган чәйгүн хәтле йодрыгы белән өстәлгә сугып: «Җүләр түгеллегенә справка алып бар син аларга!» — диде.

Андый справканы алып булыр микән дигәч, терапевт абыйсына барырга тәкъдим иттеләр: «Габделхәй абыең абруйлы табиб, психбольницадагы врачларны яхшы беләдер. Шалтыратып справка бирүләрен сорар.»

Боларның нәселләре әшнәлек-кодалык, блат белән яшәргә күнекмәгән иде. Шулай да армиягә барырга теләгән егетнең ярдәм сорап туганына мөрәҗәгать итүе йөзгә кызыллык китерә торган нәрсә түгел дип уйладылар.

Габделхәй медицинада инде утыз биш ел эшләгән чын табиб иде. Белеме, сәләте, тәҗрибәсе буенча гына түгел, кешелеклелеге, намуслылыгы, гаделлеге белән аерылып тора иде ул башкалардан, бигрәк тә яшь буын табибларыннан. Ул беркайчан да үзенең эш урынын кесә калынайту өчен файдаланмады, үз эшен нык яратты һәм авыруларны Гиппократ кушканча карады, дәвалады. Медицинадагы ришвәтчелек, кодалык-әшнәлек, оятсыз рәвештә карьера ясау кебек яман хәлләрне күреп тиздән үзе авыруга әйләнер, мөгаен. Ул көрәшеп карады, бүлнистәге ямьсез күренешләргә, чын табибның йөзенә кызыллык китерә торган вакыйгаларга каршы үзенчә көрәш игълан итте. Әмма аны баш врачтан алып бүлнис капкасы янында маңкасын агызып торган сакчыга кадәр анларга гына түгел, хәтта тыңларга да теләмәделәр. Киресенчә, бүлнис хезмәткәрләренең акчалата, күчтәнәчләтә ришвәт алуларына каршы баш күтәргән сәер терапевтның эшеннән гаеп эзләргә тотындылар, аны төрлечә кыса башладылар, хәтта кайбер авыруларны аның эшеннән канәгатьсезлек белдерергә котырттылар.

Булат килгән көнне Габделхәй бөтенләй кәефсез иде, аның үзенең дә эшен ташлап бу пычраклыктан читкәрәк китәсе килә иде. Сеңлесенең улын ул бик ярата, аның армиягә барырга теләвенә сөенә, горурлана, әмма ничек ярдәм итә алсын соң ул аңа? Булат психоневрологик диспансердан үзенең җүләр түгеллеген раслый торган справка алырга тели, шул үтенеч белән аңа, Габделхәйгә, анасының абыйсына килгән.

Ләкин психушкадагы хәлләр бу бүлнискә караганда хөртирәк ләбаса. Габделхәй анда мәңге шалтыратмаячак, гәрчә туганына ярдәм итү теләге көчле булса да.

Ул башта, кызып китеп, армиягә бармас өчен ниләр эшләгәннәрен, нинди справкалар ясауларын нәфрәтләнеп сөйләде.

Психушкада эшләүче персоналны яхшы белгәнгә күрә, ул анда шалтыратудан баш тартты һәм плимәннигенә анда барып йөрмәскә тәкъдим итте:

— Анда табибларның яшь буыны килде, аларда иман да юк, белем дә юк, — диде күпне күргән терапевт.

— Миңа аларның иманнары да, белемнәре дә кирәкми, мина жүләр түгеллегемә справка гына кирәк, — дип үзенекен тукыды Булат.

— Алар синнән умырып акча сораячак. Мин, гап-гади врач, аларның хезмәткәре түгел, алар белән таныш түгел. Дөресен әйткәндә, үзләрен беләсем дә килми. Шалтыратмыйм мин анда, гафу ит. Ә медкомиссияне бездә үтәрсен. Заключениене үзем язып бирермен.

— Психикам дөрес дигән кәгазь булмагач, монда медкомиссия үтүдән ни файда?

— Военкоматта берәр тузга язмаган сүз әйттеңме әллә соң син?

— Юк.

— Алайса, нигә син тиле дип кайтарып җибәрделәр соң алар?

— Нишләп һаман армиягә алмыйсыз, мина бит инде егерме бер яшь, дидем.

— Аңлашылды. Алар өчен бик сирәк һәм сәер күренеш шул бу — үзе килеп армиягә алыгыз дигән кешедән шикләнерләр дә.

Авылдагы вакыйгаларны, өйдәгеләрнең хәл-әхвәлләрен тәмләп сөйләшкәннән соң, Булат, абыйсына һич кенә дә ачу-үпкә белдермичә, аны дөрес аңлап, үзе психоневрологик диспансерга юл тотты. Чөнки справка барыбер кирәк, алай гына түгел, бик тә кирәк иде. Шул справканың юклыгы гына Булатны солдат булудан мәхрүм итеп тора бит.

## III

Булат психоневрологик диспансерның тимер ишеген ярты сәгать чамасы дөбердәтте. Монда «тихий час» иде, шуннан файдаланып, дежур хатын белән әле яңа гына эшли башлаган яшь санитар, иске җиһазлар саклана торган бүлмәгә кереп, саргаеп беткән иске матраста ыңгырашып яталар иде. Психушкага керергә теләүченең ишек шакуы аларга ишетелмәде, алар фәкать үзләренең йөрәк тибешләрен генә ишетәләр иде бу вакытта.

Үтеп баручылар тирләп-пешеп жан-фәрманга психлар бүлнисенең ишеген дыңгырдатучы егеткә сәерсенеп карадылар. Гадәттә моннан ничек чыгып качарга белмиләр, ә бу тырышып-тырмашып шунда керергә маташа.

Ниһаять, эчке яктан ямьсез тавыш ишетелде.

— Кем дөбердәтә ишекне?!

Бу пациентларга аш өләшүче Сәгүдә иде. Фляжкаларны ташучы килергә тиеш, шуңа аска төшкән иде ул.

— Ачыгыз, зинһар! — дип ялварды Булат. — Минем психиатрны күрәсем килә.

— Хәзер тихий час, — диде Сәгүдә. — Пациентларга укол кадалган, йоклыйлар. Медперсонал да кайсы кайда. Баш врач Казаннан кайтып житмәде әле.

— Миңа справка кирәк иде.

— Нинди справка?

— Жүләр түгел дигән справка кирәк.

— Монда, киресенчә, жүләрлеккә справка юнәтергә киләләр.

— Мин үз акылымда, миңа башка төрле справка кирәк.

— Ничә ел шушында эшләп, үземә дә ала алган юк әле бер справка да — ни тегендиен, ни мондыен.

Хатынның бу сүзләре инде каяндыр еракта тоныкк кына булып ишетелде, ул өске катка менеп китте бугай.

Егет беркавым шәһәр буйлап йөрде. Аппетиты булмаган килеш, кафетерийга кереп, теләр-теләмәс кенә ике пәрәмәч ашады. Пәрәмәчнең икесе дә ашказанына төшеп кадалганнан соң ярты сәгать чамасы вакыт узгач, аның саруы кайный башлады. Тәмам шәлперәеп, ул янә психушка ишеге төбенә килде.

Затлы машина килеп туктады. Утыз-утыз биш яшьләрдәге ир-егет машинадан чыкты да, май азгынын жиле кебек жинеллек белән шатырдап бикләнгән ишеккә таба юнәлде.

— Гафу итегез, сез табиб түгелме?

— Әйе, мин психиатр, — диде машинадан чыккан кеше, чалбар кесәсеннән ачкыч алып. Ул үз ачкычы белән Булат шул гомердән бирле дыңгырдаткан ишекне ачты һәм борылып сорады. — Ни йомыш?

— Миңа справка кирәк.

Психиатр шундук:

— Кер, — диде.

Кабинетка кергәч, Булат барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

Врач аның авызын ачтырып телен карады, ата-анасының нинди чирләре барлыгын сорады. Ике як нәсел дә сау-сәламәт икәнне белгәч, психиатр һава торышы үзгәргәндә, Ай тулган төннәрдә егетнең нинди дискомфортлар кичерүе белән кызыксынды.

— Военкоматта мыскыл итүләрен бернәрсә белән дә чагыштыра торган түгел, — диде егет. — Нык рәнжеттеләр мине анда.

— Баш врачны көтәргә кирәк, — диде психиатр. — Мондый үтенеч белән монарчы беркемнең дә килгәне юк.

Шулвакыт ак халатлы бер кыз кереп баш врачның кайтканын хәбәр итте.

Психоневрология диспансерының житәкчесе Ашанов егетне игътибар белән тыңлады. Аның армиягә атлыгуының сәбәбен ачыклауны табиб мондый сорау белән башлады:

— Сөйгән ярың бармы?

— Бар.

— Кем ул?

— Күрше авыл кызы. Шәфкыя исемле.

— Бәлки, аның белән араларыгыз бозылгандыр да шуңа күрә, кайнарланып, китәргә карар кылгансыңдыр?

— Юк, аның белән безнең аралар әйбәт. Ул мине армиядән көтәргә әзер.

— Бәлки, атаң-анаң белән конфликтың бардыр?

— Нишләп мин әти-әни белән конфликтка керим ди! Безнең гаиләдә ул яктан тәртип.

— Кемгәдер ачу итеп армиягә олагырга телисеңме әллә?

— Армиягә кемгәдер ачу итеп баралар димени? Мин, егет кеше — солдатта булырга тиеш!

— Бәлки, синең дошманнарың бардыр?

— Юк.

— Берәрсе янамыймы?

— Беркем дә янамый.

— Сугышканың бардыр бит?

— Тугызынчы класста укыганда Чатан Хәниф белән сугышканыек, ике көннән дуслаштык.

— Бәлки, ул синнән үч алмакчыдыр, ә син качмакчы буласыңдыр?

— Беренчедән, мин анардан көчлерәк, икенчедән, ул хәзер Камчаткада яши, килки балыгын юдыру баржасында эшли. Беркемнән дә качмыйм мин.

— Бәлки, шулай да кан дошманың бардыр? Шуна армиягә барып котылырга телисеңдер...

— Минем дошманнарым юк.

— Алайса, кемнән качарга маташасың соң син?

— Беркемнән дә качмыйм! — диде Булат кайнарланып. — Нинди кеше соң сез! Ватанны кемдер сакларга тиештер бит! Күпме кеше төрле ысуллар белән армиягә барудан качып, котылып йөри...

Әйе, баш психиатр моны бик яхшы белә. Күпме чиновникның, күпме түрәнең, күпме блатнойның, күпме байның улларын армиягә алмасыннар өчен авыру дигән заключение ясады ул, күпме ялган справка эшләп бирде, күпмесен «недееспособный» дип пенсия дә ясаттырды әле. Күпмесен төрмәдән коткарып калды!

— Сәер, бик сәер, — диде Ашанов. — Сөенәсе урынга кайгырып йөрисең...

— Нишләп военкоматта тиле диюләренә сөенергә тиеш ди мин?!

— Тапканың аптырар сәбәп. Кайда норма тәмамлана, кайдан тайпылыш башлана — әлегә медицина фәне белми. Кем тиле, кем үз акылында — моны үлчи торган бизмән дә, үлчәү тасмасы да юк.

— Сезне үз акылыгызда түгел дисәләр, ачуыгыз килмәс идемени?

— Димәк, син военкомат комиссиясенә үпкәләп, аларга үзеңнең нормаль кеше икәнеңне исбатларга тырышасың? Миңа аңлашыла синең комплексың.

— Мин армиягә барырга тиеш! — диде Булат гасабиланып. — Бу һәр сәламәт егетнең бурычы. Сез — баш врач, минем башым дөрес эшләгәнне күрәсездер бит?

— Димәк, сиңа справка кирәк? — диде психиатр чак кына ишетелерлек итеп.

— Әйе, миңа җүләр түгеллегемне исбатлый торган кәгазь кирәк.

Баш табиб өстәлендәге кәгазьләрне актарган булып:

— Ни... Андый справкалар биргәнебез юк... Бирергә була... Түләүле була инде ул... — диде.

— Күпме түләргә кирәк?

— Соң... күпме дип... аның төгәл тарифлары юк инде дә ни...

— Нишләп сез сәламәт кешенең сәламәтлеген раслый торган документ өчен акча сорыйсыз? — диде Булат.

— Син үзең монда килдең бит, — диде табиб тыныч кына.

— Әйе, үзем.

— Армиягә китәргә син ыргыласыңмы?

— Әйе, мин.

Психиатр егетнең йөзенә туп-туры карады.

— Патриотизм чирең бу дәрәҗәдә тирән тамыр җәйгән икән, илле мең акчаңны бирәсең дә, мин сиңа психодиспансерда учётта тормаганыңа справка язып бирәм.

— Нишләп мин ул справка өчен түләргә тиеш? — дип җикерде Булат. — Мин бит болай да монда учётта тормыйм.

Ашанов көрсенүдә арткарак каерылып:

— Болай акыллы кешегә охшагансың, — диде. — Ләкин психикаңда чалышлык бар.

— Нинди чалышлык? — диде Булат кинәт сагаеп.

— Чамадан тыш патриотизм.

Егет тагын кызып китте:

— Нишләп чамадан тыш булсын! Мин дә ил сагында хезмәт итмәсәм, башкалар да качып йөрсә, кем хезмәт итәр соң анда?

— Нишләп бу кадәре гиперсоциальный соң син?

— Нишләп сез, минем тиле түгеллегемне белгән килеш, шуны раслар өчен акча сорыйсыз?

— Справка кирәк, диденме?

— Әйе.

— Кирәк булса түлисең, кирәк булмаса түләмисең.

— Гиппократ антын хәтерлисезме? – диде Булат усал тавыш белән.

— Гиппократ антында призывниклар белән нинди мөнәсәбәттә булу хакында бер сүз дә юк. – Психиатрның тавышында усаллык сизелде. — Артык акыллыланма, бездә артык акыллылар болай да күп ята. Синең армиягә омтылуың миндә беләсеңме нинди шикле уй тудырды...

— Нинди?

Ашанов алга таба иелебрәк:

— Син гомосексуалист түгелме? – диде.

Булат корт чаккандай сикереп торды.

— Кабахәт! – дип кычкырды ул баш табибка. — Военкоматта «тиле» диделәр, син мине «зәңгәр» дисең... Үтерәм!

Булат сул кулы белән Ашановны түшеннән йомарлап тотты, уң кулы белән сугарга кизәнде, психиатр башын читкә алып калды, йодрык аның колагына ышкылып кына узды.

— Җибәр! Психушкада узачак гомерең! – дип кычкырды баш психиатр.

— Хайван! – дип акырды Булат, психиатрның бугазын буып. – Бирермен мин сиңа «зәңгәр»!

Психиатр белән авыл малае өстәл аша якалашканда санитарлар атылып керделәр һәм... алга таба Булатның нинди хәлдә калганын, аны кая урнаштырганнарын укучы инде чамалыйдыр.

## IV

Дүрт кешелек палатада инде өч пациент бар иде. Аларның берсе сары чәчле, какча гәүдәле, илледән узган агай, тәрәзә янындагы караватта чалкан ятып түшәмгә текәлгән. Аның янәшәсендәге караватта кырык яшьләрдәге киң җилкәле кеше, көрәктәй куллары белән башын кысып, торымнан-торымга ыңгырашып утыра. Өченче караватта озын чәчле берәү йөзтүбән капланган, аның тәбәнәк буйлы икәне генә абайланды.

Кыска балаклы, кыска җиңле буй-буй киеме аңкыткан хлор исеннән чыраен сытып, Булат ишек янындагы буш караватка утырды. Палатадагы куе сасы һава аның тын юлына аркылы килде, ул шундук сулышы ешайганны тойды. Башын тотып утыручы ыңгырашып куйды. Чалкан ятучы торып Булат янына килде.

Янак сөякләре чыгып торган сары чырайлы бу кешене бернинди гримсыз, махсус киемсез хәзер үк берәр куркыныч фильмда төшерерлек иде.

— Син кем? – диде ул.

— Беркем дә түгел, — диде Булат.

— Андый диагноз буламыни?

— Минем бернинди диагнозым да юк.

— Ничек инде диагнозсыз сине монда кертеп яптылар? – дип гаҗәпләнде псих.

Булатның монда ничек килеп эләгүен сөйләргә теләге дә, хәле дә юк иде. Ул үпкәсенә һава тутырырга тырышып озын сулыш алды һәм:

— Җүләр түгел мин, — дип кенә әйтә алды.

— Ә нишләп соң монда килеп эләктең?

— Мин барыбер акыллы икәнемне исбатлыйм.

— Ай-һай, белмим... — диде агай һәм үзенең караватына барып утырды. — Монда җүләр икәнне исбатлау да авыр әле, ә син акыллы икәненне исбатларга маташасың... Белмим, белмим...

Палатага кертер алдыннан кадалган укол отыры Булатның аңын томалады, күзләре әлҗе-мелҗе килә башлады һәм ул, яны белән авып, түшәсез йокыга талды.

Күпмедер вакыт йоклагач, Булат палатадагы шау-шудан уянды.

Тумбочка өстенә кырые китек тәлинкә белән ботка китереп куйганнар, әмма Булатның тамагыннан ашау үтәрлек түгел иде.

Ул өч палатадашның сөхбәт кылуларын тыңлап ятты.

Тәрәзә янындагы карават иясе, кәкре таякны хәтерләткән кулын болгый-болгый, аңлатырга тырышып чәрелдәде:

— Ленинны мавзолейдан чыгарып ташламыйча, карабодай ярмасының бәясе төшмәячәк!

— Ленин анда кайчаннан бирле ята, шул вакыт эчендә бәяләр әллә нишләп бетте, — диде Булат кергәндә башын кысып утырган пациент карлыккан тавыш белән. — Ленинның монда ни катнашы бар. Мине Египеттагы хәлләр борчый. Тыныч кына яшәргә язмаган микәнни безгә? Ливияне кара син... Муаммар Каддафины ник үтерергә иде инде! Ливия элек-электән бәрбәрләр кулында. Кайчан тыныч яши башларбыз икән? — Ул бәхетсезлегенең сәбәбен дә әйтеп бирде: — 1905 елны поп Гапон алдаганнан соң бер рәтле тормыш күргәнебез юк.

Бу кешенең тәне тутырук татуировкалар, гәүдәсенең кием капламаган урыннары зәп-зәңгәр бизәкле булып тора иде, хәтта муенында да яшькелт-зәңгәр елан уратылып ясалган иде. Аның сирәк чәче чәчкә охшамаган, башында йон үскән сыман иде. Маңгаендагы җөе, сугудан кәкрәеп калган борыны, тәнендәге «галерея»сы белән бергә, аның күпне күргән зат икәнен күрсәтеп тора иде. Тозлы лайлада тынгысызлыктан бертуктаусыз әйләнеп торган төссез кечкенә күзләре орбитадан гына түгел, палатадан чыгып чиксез галәмгә чыгып очар сыман иде.

Булат янындагы озын, чем-кара чәчле, күмер төсендәге күзле утыз яшьләрдәге ир-егет тә уянган иде, ул баздан ишетелгән сыман тоньк кына тавыш белән үз фикерен әйтте:

— Гитлерның әбисе мишәр булган. Анасы ягыннан. Ана ягы чыгыш буенча Чирмешәннән икән. — Ул күз алмаларын кинәйтеп өстә куйды. — Бик күп талантлар чыкты Чирмешәннән.

Әңгәмә бер-берсенә бәйле генә түгел, бөтенләй якын булмаган темаларга бик озак дәвам итте.

Тәрәзә янындагы пациент кешенең маймылдан яралмаганына шик белдергәч, палатада талаш купты.

— Синең чыраеңны күргәч, Чарльз Дарвин теориясенә мин ышана башлыйм, — диде татуировкалы агай. — Әмма дөрес түгел! Нишләп кеше маймылдан ялрсын!

— Маймылдан, маймылдан! — диде озын чәчлесе. — Бананны яратып ашыйбыз бит.

— Гафу ит, Эдик, мин банан яратмыйм! — диде татуировкалы псих, озын чәчле Эдикка ямьсез караш ташлап.

— Син банан яратмыйсың дип кешелек дөньясы Дарвин теориясеннән баш тартсынмыни? — диде какча гәүдәлесе чәнечкеле тавыш белән һәм, Булатның уянганын абайлап, җәһәт кенә аның аяк очына килеп утырды:

— Мин Әхәт абыең булам. Тарих укытучысы. Син каршы түгелме маймылдан яралганыбызга?

— Белмим.

— Бик сәер җавап. Нишләп соң сине бу палатага, укымышлы кешеләр янына яткырдылар?

— Белмим.

— Бик авыр икән синең белән сөйләшүе, — диде Әхәт, салкын елмаеп. — Җайсыз кеше син. Шул җайсыз булганың өчен яптылармы монда?

— Юк, җүләр түгеллегемә справка сораганым өчен.

— Исемең бармы синең?

— Булат.

— Булат энем, сиңа нигә андый справка? — диде Әхәт зур кызыксыну белән.

Булат, башын стена ягына борып:

— Военкоматка тапшырыр өчен, — диде.

— Ә военкоматка нигә кирәк андый справка?

— Мине никтер армиягә алмыйлар.

«Армия» сүзен ишеткәч, палатада кешелек дөньясындагы сугышлар тарихы буенча кайнар бәхәс купты.

Шыр сөяктән генә торган Әхәт, татуировкалы пациентка иелеп, төкерекләрен чәчә-чәчә аңлатырга маташты:

— Нәби әфәнде! Безнең эрага кадәр 1294 елны Рамзес Икенче хеттларны җиңалмады! Шуны беләсеңме син?

— Нишләп белмәскә! — диде Нәби әфәнде, бер дә исе китмичә. — Кадеш каласын алырга аның көче җитмәде, чөнки ул вакытта әле Калашников автоматы юк иде.

Калашников удмуртмы, урысмы, татармы дип шактый вакыт тарткалашканнан соң, Александр Македонский малайлар яраткан дигән нәтиҗәгә килеп, алар Урта гасырларга күчтеләр дә, шуннан римлеләрнең кавалерия тактикасына һуннар ничек тәэсир иткәнен кузгатып алдылар. Шул ук вакытта һуннарның атларына көтүлекләр җитмәгәнен, кыш көннәре фураж булмавын да искә төшерделәр һәм XX гасырның егерме беренче елындагы ачлыкта кем гаепле икәнне билгели алмыйча иза чиктеләр.

Булат бу тирән мәгънәле дискуссиядә катнашмады, тыңлап кына ятты. Бик күп нәрсә мәгълүм булды аңа кешелек тарихыннан. Мәсәлән, 1221 елны, Хорезм шахы үлгәч, Джебе белән Субудай Кавказ аша Көньяк Европага керергә Чыңгызханнан рөхсәт алганнар икән — моны Булат белми иде. Монголларның 40 меңлек гаскәре, Азәрбайҗан аша үтеп, Көнчыгыш Әрмәнстанда Аракс елгасы буенда кыш чыкканнары да мәгълүм түгел иде аңа.

«Елга», «кыш» сүзләре бәхәсчеләрне Татарстан балыкчыларының ел саен язгы ташкын вакытында боз белән агып китүләрен искәртеп үтәргә этәрде. Бүгенге көн балыкчыларыннан соң алар унөченче гасырда Чуд күлендә Александр Невский батырып үтергән немес рыцарьларын хәтердә калкыттылар һәм, басып, аларны бер минутлык тынлык белән искә алдылар.

Аннары алар, немес дигәннән, кинәт Гитлерны каргарга тотындылар һәм аның анасы ягыннан әбисе Аксубайдандыр дигән шикле фикергә килеп, бөтенләй көтмәгәндә Россия белән Төркия сугышына күчтеләр. 1853нче елның 4 октябрендә Гомәр паша җитәкчелегендәге төрек армиясенең Дунайны кичеп чыгуы пациентларны Чапаев батып үлгәнме, юкмы дигән бәхәскә алып кереп батырды.

Суда бату темасы аларны 1904-1905 елгы рус-япон сугышына экскурс ясатты. Америка тарафыннан Хиросима белән Нагасаки калаларына атом бомбалары ташланганга күрә, японнарга пациентлар ачу сакламыйча, Карфаген темасына күчеп, Ганнибалның хаталарын анализладылар. Ул вакытта Дзержинский әле тумаган, шуңа күрә римлеләрнең шпионнарын Карфагенда тоту мөмкин

булмаган дигән фикер белән барысы да килештеләр. Шуннан соң Германиянең абверына күчмәү мөмкин түгел иде. Гудерианның трактор йөртергә СССРда укыганын адмирал Канарис белмәде микәнни дигән сорау барысын да аптырашта калдырды.

Озакка сузылмады аларның аптыравы, ике санитарны ияртеп медсестра керде һәм тиешле уколларны кадап чыкты. Уколдан соң Гудерианның әбисе Чистайданмы, Азнакайданмы дигән сорауны күтәрделәр, әмма җавап табалмыйча йокыга талдылар.

Көн саен бер үк тәртип кабатлана: йокыдан уянып, ясалган укол шаукымыннан баш бераз арынгач, палатада янә аяусыз бәхәс-ызгыш куба, әмма озакка сузылмый — йә солы боткасын ашарга кирәк була, йә табиблар обход ясый. Шулай итеп талашырга вакыт аз кала һәм тарихи-сәяси-фәлсәфи конфликтның иң кызган урынында чираттагы укол чуарланып беткән күт битенә килеп кадала да палатада кабер тынлыгы урнаша.

## V

Беренче көннәрдә Булат, тавыш куптарып, диспансердан чыгаруларын таләп итте. Моның өчен аны ике дозалы укол кадыйбыз дип куркыттылар. Үзенең җүләр түгеллеген коридорга чыгып кычкырып игълан итүенә дә беркем шаккатмады, чөнки монда барысы да диярлек үзләрен акыллы дип саныйлар иде.

Көннән-көн Булатның, уколлар тәэсирендә, апатиясе арта барды. Ул инде телефоннан шалтыратырга рөхсәт итүләрен дә сорамый башлады, врачларның кереп аны дикъкать белән тыңлауларын да үтенмәс булды, ни военкоматта, ни монда аны дөрес аңламадылар диюдән дә туктады. Баш врачны күреп сөйләшү теләге исә тормышка ашмас хыялга әверелде. Баш психиатр даими рәвештә үз урынында түгел иде — йә ул командировкада, йә Казанда конференциядә, йә Мәскәүдә квалификация күтәрү курсларында, йә чит илдә ялда, йә яңа җиһазлар юнәтү эше белән беркем белми торган тарафларда йөри.

Әлбәттә, Булат үзенең сүренкеләнеп баруын эчке сиземләү белән чамалады. Тагын берәр атна бу уколларны, шушы даруларны кабул итсә, монда күптән ятучы пациентлар сыман башын чак кына кыңгыр салып, селәгәен авыз кырыеннан түшенә агызып, стенага ышкылып көннәр буе коридорның бер башыннан икенчесенә артсыз тапочкалы аякларын сөйрәп йөричәк.

Бирешергә ярамый!

...Беркөнне ул, калган көчен җыеп, йокы белән көрәшә-көрәшә, атасына хат язды. Ничек килеп эләгүен, баш психиатр белән әңгәмәне тәфсилләп язарга вакыт та, хәле дә юк иде. Конвертсыз хатны бөкләп куен кесәсенә тыккач, ул саклык белән генә палатадан чыгып, аш өләшә торган буфет янына барды. УАЗ-«буханка» машинасы белән бүлнискә аш ташучы шофёр Газиз аш бүлүче Сәгүдәне бер кулы белән кочып, икенчесе белән аның чиләк-чиләк олы имиләрен камыр изгәндәй әвәләп маташа иде. Карап торуга әле кырыкка җитмәгән түгәрәк хатын әллә рәхәтлектән, әллә кытыгы килгәннән чырык-чырык көлеп, бөрешергә теләгәндәй боргалана, ә яшь ир-егетнең планнары, ахрысы, зурдан иде, аның хатынны буфет түрендәге иске диванга таба чигендерергә тырышканы аңлашылды.

Монда башка вакытта керергә, бәлки, мөмкинлек тә булмас дип, Булат эндәшергә җөрьәт итте:

— Исәнмесез.

Сәгүдә тиз генә шофёр кочагыннан шуып чыкты да, чәчен төзәткәләп, имиләрен үз урынына кайтарырга ниятләгәндәй куллары белән күкрәген капшап, юылмаган савыт-саба өелгән озын өстәл башындагы шкаф артына посты.

Үз яшеннән олырак күренгән Газиз таушалган чыраен Булатка борды:

— Ашыйсың киләме әллә?

— Юк, рәхмәт, безне әле яңа гына ашаттылар. Минем сезгә үтенечем бар. – Сәгүдә ишетмәсен өчен ул пышылдауга күчте. – Мин сезгә аннары түләрмен... Минем хәзер үзем белән акчам юк... Мин авыру түгел... Мин монда армиягә барырга теләгәнем өчен килеп эләктем...

— Армиягә барырга теләгәч, синең урын шушында инде, брат, — диде Газиз. — Мин анда ике ел хезмәт иткән кеше. Монда армиягә караганда лутчырак.

— Ярар, анысы сезнең фикер... Мин әтигә хат яздым. Адресыбызны хат азагында язып куйдым. Алла хакы өчен, конвертка салып, адресны язып, хатымны авылыма җибәрегез. Чыккач, мин сезгә түләрмен.

Газиз, хатны алып, Булатның гозерен үтәргә вәгъдә бирде.

Коридорга чыккач Булат буфетның ишеген йозакка бикләгәннәрен ишетте һәм эчтән Сәгүдәнең чыркылдаганы колагына чалынды — анда «мәхәббәт» дәвам итте.

Булат палатага кереп ятты да, хатның тизрәк атасына барып җитүен Ходайдан сорап, йокыга китте.

## VI

Әмма хатны әтисенә алып укырга насыйп булмады. Булат язган хат хәтта психоневрология диспансерыннан да чыкмады.

Бүлнискә әчегән кәбестәле аш ташучы Газиз баш психиатрның агенты иде. Баш врачның Согуд Гарәбстанында ял итеп кайтканнан соң беренче эш көнендә үк Газиз хатны аның өстәленә кертеп салды.

Булатка шул ук көнне укол дозасын икеләтә арттырдылар.

Икенче көнне тәҗрибә уртаклашу кысаларында Татарстанның төрле районнарыннан психиатрлар килде. Кунакларны иң нык кызыксындырган пациент, әлбәттә, Булат иде. Аңа төрле сораулар бирделәр, Булат аларның барысына да нормаль кешеләргә хас акыл белән дөрес җавап бирде. Бу табибларны сокландырды. Һәм, ниһаять, аның армиягә атлыгуын үз колаклары белән ишеткәч, Булатның психик чалышлыгы тирәнгә кергән һәм алга таба да артырга мөмкин дигән нәтиҗә ясадылар.

Палатадагы башка авырулар белән дә сөйләштеләр. Әхәт аларның һәрбер соравына җавап биргәннән соң берәр тарихи вакыйганы котылгысыз рәвештә койрыкка бәйләп куйды. Соңгы сорау мондый булды:

— Сезнең нинди хыялыгыз бар?

Тарихчының хыяллары күп иде. Ул шуларның үзе өчен иң мөһимен ярып салды:

— 1940 елны Троцкийның башына ледоруб белән суктылар. Шул ледоруб Россиягә кайтырга тиеш. Чөнки аның составын тикшерергә кирәк. Троцкийны үтергән бозваткычның нинди металлдан эшләнгәнен белми торып, без торак-коммуналь сферадагы тарифларны контрольдә тота алмаячакбыз.

Бозваткыч буенча запрос ясарга вәгъдә биреп, врачлар Нәби белән дә әңгәмә корырга маташтылар, әмма барып чыкмады. Аларның үзара бу пациентның уголовник икәнен, берничә «ходка» ясавын пышылдап кына әйтсәләр дә, Нәби моны ишетеп кинәт кызып китте. Ул Казаннан килгән чандыр гәүдәле психиатрны халатының түше турыннан йомарлап тотты. Психиатрның бөтен өс киеме бугазы астына җыерылып менде һәм аның беләкләре, аяк балтырлары шәрә калды. Куркудан йөрәге ярылыр дәрәҗәгә житкән табибны Нәби алтмышынчы еллар мәктәбендәге кыңгырау шикелле чылтыратырга тотынгач, комиссия әгъзалары, тиз арада йөгереп килеп җиткән санитарлар ярдәмендә, бәгырь ярасы ялкынсынган пациентны урынына яткырдылар.

— Без бит сезнең турыда бер авыр сүз дә әйтмәдек, — диделәр ана.

— Мин уголовник түгел! — дип кычкырды Нәби яткан урыныннан.

— Юк, юк, сез уголовник түгел. Сез бик әйбәт кеше, — диделәр ана.

Эдикка чират житте. Ул сорауларның берсенә дә дөрес җавап бирә алмады.

— Сезгә ничә яшь? — дип сорагач, утыз яшьлек компьютерщик:

— Алтмыш сигез, — дип җавап бирде.

Нишләп нәкъ менә алтмыш сигез икәне белән кызыксынып тормадылар, исемен сорадылар:

— Исемегез ничек?

— Әйтеп була торган исем даими исем була алмый, — диде Эдик идәнгә карап. — Исемне әйтеп булса, димәк, ул чын исем түгел.

— Хәзер ничәнче ел, беләсезме?

— Белүче кеше әйтми, әйтүче кеше белми, — дип җавап бирде Эдик.

Тәҗрибә уртаклашырга килгән бер юан психиатр пациентны аркасыннан сөеп:

— Сез Дао динен тотасыз икән, — диде. — Даосизм иң борынгы диннәрнең берсе.

Эдик башын күтәреп табибка карады һәм аның борын кырыендагы коңгырт сары минен күреп чыраен сытты.

— Бигрәк ямьсез син, — диде ул табибка.

Психиатрлар чыгып киткәч, пациентларга укол кададылар.

Берничә сәгатьтән уянгач, Булат шактый вакыт кайда икәнлеген аңышмыйча ятты. Шулчакны ул үзенең психушкага кадәр яшәлгән егерме бер ел гомереннән каядыр чит-ят тарафка китеп барганын тойды, гүя үткәннәр белән элемтәдә тотучы җепләр тартылып менә-менә өзелергә тора иде.

Үзәгендә тамыр җәеп килгән битарафлык, инде күпмедер дәрәҗәдә тынычландырып, буйсынырга этәрде, әмма Булат чынбарлыктан аерылу куркынычыннан да арынмаган һәм каршы торырга, көрәшергә ихтыяҗны тәмам җуймаган иде әле.

Шул ук көнне палатада чыккан сугыш аны коткарды дип әйтсән дә, мөгаен, ялгыш булмас.

Нәби, караватында башын куллары белән кысып әкрен генә як-якка чайкала, Эдик үз караватында аяк бармакларын иснәп утыра иде. Әхәт, гадәттәгечә, палатаны тарихи сәяхәткә кузгалырга чакырды.

— Шунысы сәер, — дип башлады ул сүзен, — Византия императоры Феодосий Икенченең аттан егылып төшеп үлгәне тарихчыларга мәгълүм, ә биядән егылып төшкәнме, айгырданмы, алашаданмы, анысын беркем әйтә алмый.

Хәтта больничтә дә үзе турында «уголовник» диюләре Нәбине бик нык рәнҗеткән иде. Ул торымнан-торымга, сүгенеп, шуны кузгатты. Үзенең бер гаепсезгә әллә ничә тапкыр төрмәләрдә утыруын, гаделлекнең беркайчан да булмаячагын кат-кат палатадашларына тәкрарлады.

Әхәт Феодосийның аттан егылуын әйткәннән соң Нәбинең тарихтан туйганы аңлашылды. Эдик виртуаль дөньяда яшәргә күнеккән, ул тарихчының сөйләгәннәрен тыңласа да, илтифатсыз мөнәсәбәттә кала белә иде. Булат та инде тарихи лекцияләрдән туярга өлгерде, ләкин шул ук вакытта аңа тарихчының сөйләгәннәре кызык иде.

Әхәт сөйләвен дәвам итте:

— Алаша дигәннән, авылыбызның атбагары Вәдүт абыйның уртанчы кызы белән без бер класста укыдык. Абыйсы сугышып төрмәгә утырды...

Нәкъ менә «төрмәгә утырды» дигән сүзләр Нәбинең җан җәрәхәтенә тупас тарттырылган икенче сортлы тоз булып сибелде. Ул караватыннан атылып торды һәм тарих укытучысына аты-юлы белән сүгенеп акырды:

— ...мамыни синен Феодосиен!!! На х... мина синең Вәдүтең! Троцкий, Македонский, Ганнибал... Берәркайчан туктыйсыңмы син, юкмы ... чәйнәүдән?!

— Мин бит тарихи вакыйгаларны сезне агарту ниятеннән сөйлим, — диде Әхәт, күршесенең ярсуына шаккатып.

— Хәзер мин сине үзем агартам, падла!

Әхәтне сугып аударгач, Нәби Эдик янына томырылды. Тегесе куркып одеял астына качкан иде.

— Выходи, сука! — дип боерды ана Нәби.

Эдикның калтыранган куллары одеялны ачты һәм аның күз яшьләреннән бүлнис идәнен юа торган швабра сыман лыч булган чырае калыкты:

— Мина тимә-ә-ә, — дип улады ул.

Әхәтнең хәтерендә сакланган бөтендөнья сугышлары рәтендә палатадагы бу сугыш та урын алыр, мөгаен. Тарих укытучысы арттан килеп Нәбинең өстенә ташланды. Нәби физик яктан көчле иде шул, тарихчыны ул бик җайлы гына итеп егып салды. Эдик һичшиксез Әхәт яклы иде, шуна күрә ул да Нәбинең җилкәсенә сикерергә кирәк дип тапты. Әмма кин җилкәдә озак асылынып тора алмады, Нәби аның эченә терсәге белән төртергә җаен китерде. Эдик эчен тотып идәнгә егылганда Әхәт, өненә килеп, Нәбинең аякларын кочаклады — уголовникны ятkatканнан түгел, шулай итеп аны егарга маташты ул. Булдыра алмагач, аптыраганнан, ул аның сыйрагына тешләрен батырды. Нәби аны йодрыклары белән тояргә тотынды. Булат сугышта катнашмаса да, вакыт-вакыт аваз салып карады: «Нәби абый, ярарыгыз инде, кыйнамагыз инде, сугышмагыз инде!» Ләкин егетнең үтенече беркемгә дә ишетелмәде, Нәби сүгенә-сүгенә Әхәт белән Эдикны дөмбәсләвен дәвам итте.

Алты санитар берьюлы атылып килеп керделәр һәм шуның аркасында гына палатада сугыш фаҗига белән тәмамланмады. Нәбинең кулларына наручниклар кигерделәр, Әхәтнең өстенә нindидер сәер күлмәк индерелде, Эдикка исә өлкән санитарның бер кычкыруы да житте — ул азәрбайҗаннар сата торган кара җимеш сыман учка сыярлык булып бөреште һәм аларның өчесен дә алып чыгып киттеләр.

## VII

Берничә сәгать вакыт узгач, Нәбине ике санитар кире палатага алып керде һәм тыныч кына ятарга боердылар. Ул инде суынган, тик шулай да әле тәгаен тынычланып җитмәгән иде. Аңа сөйләшергә кеше кирәк иде, ул караватында утырган жиреннән Булатка таба борылды:

— Йокламыйсыңмы?

— Юк, — диде Булат. — Озакламый укол кадаячаклар, шуннан соң тагын йокларга туры килә инде.

— Син чынлап та армиягә барырга хыялланасыңмы?

— Әйе. Ләкин күнелем сизә, мондагы уколлар белән мине «не годен» итеп калдырырлар, ахрысы.

— Син әйбәт егеткә охшагансың. Күренеп тора — авыл малае, тегендә-монда тыгылмыйсың... Монда яткан козёллар шикелле әләкче түгел.

— Алар кая соң?

— Аларны, миннән куркып, башка палатага урнаштырдылар. Син миннән куркасыңмы?

— Юк. Мин бит сина бер начарлык та эшләмәдем, шулай булгач, ник куркыйм.

— Маладис егет син!

Нәби маладис дип Булатка ихластан әйтте. Чөнки санитарлар, табиблар кереп Булаттан: «Әхәт белән Эдикны Нәби ни өчен кыйнады?» дип сорагач, Булат: «Нәби беркемне дә кыйнамады», — диде һәм палатадагы сугыш турында анардан бер сүз дә әйттерә алмадылар. Төрмәләрне күргән Нәбигә Булатның егетлеге ошады.

— Теге козёлларны үтерергә кирәк, — дип дәвам итте Нәби кыжравын. — Аның Әхәте стукач. Акылдан язган тарих укытучысы ул. Беләсеңме, нишләп җүләрләнгән ул? Хатыны белән аерылышкач бу фатирсыз калган. Шуннан моның шалашы кыегайган да, тәмам ычкынып, урамда гайбәт чәйнәп йөри башлаган. Ни туганы, ни дуслары юк. Янына беркем килми. Ә Эдик — педик. Утызга житкән инде, һаман компьютер уеннарыннан арына алмый. Экранга карап утыра торгач, тилергән. Аның янына үзе сыман яшелле-зәңгәрле әкәүләр килә — бөтенесе нечкә билле, боргаланып-сыргаланып сөйләшәләр. Тфу, б..., пычрак, авызларын себерием!

— Син, Нәби абый, тарихны бик яхшы беләсең, акыллы кеше икәнең күренеп тора, юк-барга игътибар итмә инде.

— Нишләп юк-бар булсын! Туйдым икесеннән дә. Тарихка килгәндә, мин менә бу мудак укытучының шушы палатада укыган лекцияләрен тыңлап өйрәндем. Ничәмә айдан бирле, көн саен, сәгатьләр буе тарихны сөйли бит, денсез... Ирексездән хәзер бөтендөнья тарихын су урынына эчәм! Булды, житте, туйдым! Мин бит җүләр булып кыланып кына ятам. Шуңа күрә алар сыман тилене уйнап, аралашкан булып, тыңлаган, бәхәсләшкән булып ятам. Туйдым, гарык булдым! Ненавижу!

— Син соң нишләп җүләр булып кыланасың?

— Тагын төрмәгә утыртмасыннар өчен акча түләп, шушында кереп яттым. Төрмәләрдән дә туйдым. Миңа монда урнашырга Тәхлия апа ярдәм итте. Ишеткәнең бардыр — күрәзәче, сихерче ул.

— Әйе, әйе, ишеткәнем бар.

— Вәт, ул минем апам — әнкәйнең сеңлесе ул. Мин аның плимәнниге инде, вупшем.

— Син төрмәдә ничә тапкыр утырдың соң?

— Дүрт тапкыр гына.

— Нәрсә өчен?

— Дүртесендә дә ни за что утырдым. Вак-төяк әйбер урлап. Беренчесендә шәһәр мунчасыннан ундүрт бәйләм каен себеркесе урлап тотылдым.

— Нигә кирәк булды сиңа ундүрт себерке?

— Үземә түгел. Тәхлия апа сорады — им-том итүдә кулланырга.

— Икенче тапкыр нәрсә урладың?

— Пекарняга грузчик булып урнашкач, яшертен генә, койма астыннан урамнан үтеп баручыларга ярты бәясенә яңа пешкән ипи сата идек.

— Ә өченче тапкыр?

— Кер бавында эленеп торган джинсы чалбарны алып киткәнием... Ул кешенеке булып чыкты. Дүртенчесендә азык-төлек базасында грузчик булып эшләгәндә эләктерделәр. Базадан ерак түгел йөк машинасыннан бер коробка замороженный минтай төшеп калган. Шуны алып кайтып бара идем, эләктереп алдылар. Мин минтай балыгын бик ярата идем. Хәзер инде, киресенчә, күрү белән саруым кайный башлый.

— Җүләр булмагач, ничек курыкмыйча уколлар кадаттырып ятасың? Сәламәтлекне бетерә бит ул.

— Сиңа серемне ачам инде, син ышанычлы кешегә охшагансың. Миңа буш

укол кадыйлар, ягъни шприцта препарат юк. Шуның өчен мин алдан акча түләп куйдым инде. Укол калаган булалар да, мин башкалар белән бергә йоклаганга сабышып ятам. Башкалар уянгач, мин дә торып утырам. Шулай озак ятарга да риза мин, тик менә бу идиот Әхәт кенә желеккә үтте. Җүләр булып кыланам дип аның белән көн саен тарихта казынырга туры килә. Надоел, падла!

— Синен эшләр хөрти түгел икән бит. Ә мине бу уколлар бетерер, ахрысы.

— Син укол кадаучыларга акча төрт, яныңа буш шприц белән керерләр.

— Минем акчам юк бит. Синен юкмы соң?

— Бар.

— Бурычка биреп тор әле, зинһар. Мин сина аннары түләрмен.

Нәби Булатка ярдәм итәргә булды — трусигы эченә махсус тегелгән кесәсеннән алып ана акча бирде.

## VIII

Укол каламасыннар өчен Булат көн саен мен сум түли башлады.

Берничә көн уколсыз яткач, башы яхшырак эшли башлаганны тойды ул.

Ләкин Нәбигә түлисе акчанын суммасы биш меңгә житте, ә Булатны коткарырга атасы килми дә килми. Болай бит ул бурычка кереп батарга да мөмкин.

Беркөнне монаеп тимер рәшәткәле тәрәзәдән урамны күзәтеп утырганда ул авылдашын күреп алды.

Күгәрчен Мөхетдине сәвит чорында ындыр табагынын житәкчесе иде. Ил таркалгач, колхозлар, совхозлар бетте, аннары Каенсар авылы тирәсендә нишләптер иген үстерми башладылар. Хәзер Каенсар басулары җәй көне ямьсез төс белән тирә-якка шом таратып җәйрәп ята. Шулай итеп, Күгәрчен Мөхетдиненә базар икътисады бернинди файда алып килмәде, киресенчә, аны эшсез калдырды. Коммунизм буласына кайчандыр нык ышанган бу кәмит кыяфәтле кеше үз эшен яратып башкара иде, ындыр табагында тәртип булсын өчен жанын фида кылырга да әзер иде ул. Тәбәнәк буйлы, кысык күзле, кызыл чырайлы, гел кызу-кызу атлап йөрүче Күгәрчен Мөхетдиненен бөтен яшәү мәгънәсе ындыр табагында иде. Алай гына да түгел, иген урып-жыю чорында бөтен галәм ындыр табагы тирәсендә әйләнергә тиеш дип саный иде ул. Анын хәтта кушаматы да ындыр табагындагы кошлар белән бәйле. Бодай өеменнән кошларны куганда, ул агач көрәк белән сугып бер күгәрченне каты жәрәхәтли. Шул яраланган кошны ике учына алып ул ярты көн амбарда елап утыра. Күгәрченне өенә алып кайта. Медпунктка фельдшер Әлфидә янына алып төшә. Күгәрчен исән кала. Шуннан аны Күгәрчен Мөхетдине ди башлыйлар. Аны күгәрчен жанлы булганы өчен генә түгел, тырыш, эшчән, авыл өчен, ындыр табагы өчен жан атып йөргәнгә ихтирам итәләр иде. Анын ел саен сабантуйда жырлавы да авылдашларнын күнеленә хуш килә. Ындыр табагындагы сушилка моторы чыгарган чытырдыклы тавыш белән жырлый Күгәрчен Мөхетдине. Гәрчә тавышы жанга ятыш булмаса да, анын жырлавында мон бар. Ул шул кадәре тырышып жырлый ки, хәтта жыр тәмамлангач үзенең жырлавыннан үзе елап ала. Кемдер анын жырлавын яратып кул чаба, кемгәдер анын үзен тотышы кәмит тоела, кемдер беркемгә, бернигә карамыйча үз монынын стихиясенә чумучыны күзәтеп ләззәт ала, кемдер рәхәтләнеп анардан көлә. Ә Күгәрчен Мөхетдине исә елга бер тапкыр сабантуйда жырлауны үзенең изге бурычы дип саный. Анын чыннан да жырын башкарганда беркемдә, бернидә ригаясе юк, ул ашлыкны урып-жыю сезонынннан сон отчёт биргән шикелле, елга бер тапкыр авылдашлары алдында күнелендәге «уборка» буенча рухи жавап тота иде.

Ил таркалганнан соң да инде егерме ел вакыт үтеп китте. Ил дә юк, шул илне туйдырам дип җәй буе тузан куптарган ындыр табагы да юк. Елга бер тапкыр гына сабантуйда һаман әле Күгәрчен Мөхетдиненең җыры игеннәр шаулавын, кошлар сайравын, ындыр табагындагы ак яулыклы кызлар көлгәнне, ашлык өемнәренең дулкын-дулкын булып яшәеш океанына агылуын онытгырмас өчен сикрап чыга.

Булат палата тәрәзәсенең форточкасын ачты.

— Мөхетдин абый!

Үз исемен ишетеп агай як-ягына карады. Колагыма ишетелгәндәй булгандыр гына дип уйлады ул һәм атлавын дәвам итте.

— Мөхетдин абый! Өскә кара, мин өченче катта.

Ниһаять, авылдашы тавышның каян ишетелгәнен аңлады. Әмма кем эндәшкәнен күрерлек түгел, кояш яктысына каршы тора иде ул.

— Бу мин — Булат. Раиф малае.

— Бәрәч, Булат, нишлисең монда? — диде Мөхетдин, аптырап. — Бүлнис түгелме соң бу?

— Бүлнис кенә түгел, коточкыч бүлнис бу. Җүләрләр бүлнисе бу, Мөхетдин абый.

— Син соң монда ничек килеп эләктең?

— Мине монда көчләп тоталар. Бүген авылга кайтасыңмы?

— Кайтмый, кая барыйм мин?

— Әтигә кайтып әйт, справка сорагач мине психушкага яптылар. Тизрәк килеп коткарсын.

— Сине нишләп монда яптылар соң? Син бит чирлегә охшамаган идең.

— Аңлата башласам озакка китә. Син хәзер үк авылга кайтып китәсеңме?

— Мин теш куйдырырга килдем. Монда теш куймыйлармы соң?

— Юк, монда, киресенчә, тешне сугып коялар, — дип кычкырды Нәби дә, форточкага таба муенын сузып. — Бар, тизрәк кит моннан!

— Мин куркудан узган инде, — диде Мөхетдин. — Минем сугып төшерерлек тешләрем калмады. — Башта теш врачына күренәм инде. Стоматологияне моннан ерак түгел диделәр. Бик кыйммәт ди теш куйдыруы. Съемный протез куйдырам, арзанракка төшәчәк ди. Җайсыздыр инде ул. Съемный протез белән җырлап була микән?

Нәбинең соңгы вакытта нервысы нык какшаган иде. Ул форточкага башын тыгып:

— Хәзер үзе җырлый торган протезлар да бар, — диде.

— Кит аннан! — дип шаккатты Мөхетдин.

— Бер генә житешсезлеге бар ди — кайвакыт тик торганда да кычкырып җырлап җибәрә икән.

— Юк, андые кирәк түгел, — диде Мөхетдин.

— Син, агай, бар, тизрәк авызыңны врачка күрсәт тә, авылга кайтып, Булатның атасын алып кил. Алайса егетне харап итәләр монда.

## IX

Булат югалгач, анасы чирләп урын өстенә ауды, сеңлесе кайтып анасы янына сузылып ятты.

Раиф, калага барып, Габделхәйдән Булатның справка алырга киткәнен белгәч, психоневрологик диспансерга шалтыратты. Андый пациент бездә юк, улыгыз бездә ятмый, дип җавап бирделәр. Сәбәбе гап-гади — телефоннан җавап биргән дежур врачның өстәлендә яткан авырулар исемлегенә Булатның фамилиясен кертергә онытканнар иде.

Раиф белән Габдехәй каладагы туганнарына, Булатның мәктәптә бергә укыган дусларына, милициягә, моргка һәм тагын әллә кайларга шалтыраттылар. Булатны таба алмадылар.

Раиф иртәгәсе көнне полициягә барып гариза язармын дип кичкырын авылга кайтып китте. Өйдән аның каршысына хатыны белән кызы йөгереп чыктылар. Икесе дә шат. Кыз белән ана бертавыштан:

— Булатыбыз исән! — дип кычкырдылар.

— Кайттымыни?

— Юк, психушкада ул, — диде ана, күз яшьләре аша елмаеп. — Күгәрчен Мөхетдине кайтып әйтте.

... Раиф таң тишегеннән психоневрологик диспансерга барып баш психиатрның эшкә килгәнен көтте. Бәхетенә күрә, табиб беркая да китмәгән иде, сәгать тугызынчы ун минутта аның машинасы бүлнис төбенә килеп туктады. Раиф исәнләшеп тә тормады:

— Минем улым Хасанов Булатны нишләп монда тотасыз? — дип сорады.

— Ә кайда тотарга тиеш без аны? — дип сорау белән җавап бирде эскулап. Кабинетка кергәч, ул ата кешегә улының үзен ничек тотуын, аңа нинди диагноз куелуын, егетнең психикасы ни халәттә икәнлеген тәфсилләп, латин терминнарын катыштырып аңлатып бирде.

Раифка ничек кенә булса да бу тынчу, караңгы, сасы бинадан улын коткарырга кирәк иде.

Ул психиатрга утыз мең акча түләде.

— Ярар, — диде баш врач. — Бүген үк улыгызны чыгарабыз.

— Аның акылы үз урынында икәнне раслый торган справка кирәк. Ул бит монда җүләр түгеллеккә справка сорап килгән иде.

— Ул бит инде хәзер бездә учётта, — диде табиб, ике кулын ике якка җәеп.

— Нишләп инде сау-сәламәт кешене учётка куйдыгыз! Снимать итегез!

Баш психиатр: мөмкин түгел, учёттан төшерер өчен комиссия кирәк, тегебу, дип ык-мык килгәч, Раиф тагын егерме мең бирергә мәҗбүр булды.

Психитр акчаны алгач, акланып:

— Сез мине дөрес аңлагыз. Учётка кую-снимать итү бик четерекле процесс, — диде. — Җайлы нәрсә түгел ул. Улыңның психик халәте монда килгәндә бик мөшкел иде. Бик агрессив иде ул. Ә хәзер аны учёттан төшереп мин үземне күпмедер дәрәҗәдә куркыныч астына куям. Моны бит югары инстанцияләргә, хокук саклау органнарына әләкләүләре ихтимал. Минем үземнең агентларым гына түгел, мина каршы эшләүче шпионнар да җитәрлек монда.

Балта остасыннан алган акчаны аклар өчен шушы сүзләр җитәр дип уйлады психиатр һәм эшкә нокта куярга ашыкты.

...Шулай итеп, Булатны учёттан төшереп, акылдан язучылар исемлегеннән сызып ташладылар һәм бүлнистән якты дөньяга чыгардылар. Ә менә военкоматка илтеп бирер өчен бернинди справка да бирмәделәр. «Бездән беркайчан да военкоматка мин җүләр түгел дигән справка алып барганнары юк», — диделәр.

Тагын акча өстәргә кирәктер дип уйлады Раиф һәм кинәт аның күңеле ярсый башлады. Ни өчен, нишләп шушылай мескенләнәләр соң алар? Бу психиатрга ни өчен акча түләде соң ул? Илле менне алыр өчен балта тотып ай буе эшләргә кирәк. Ярар, калалып китсен илле мене. Нишләп армиягә барырга теләгән егетне болай мыскыл итәләр соң? Булат кәҗүнний киемнәрне тапшырып үзенекен кигән арада Раиф нишләргә белми бүлнис ишеге төбендә әрле-бирле йөрде.

— Милициягә барыйк, — диде ул, малае чыгып тирән сулыш алгач.

— Әллә башта военкоматка барып карыйкмы? — диде Булат. — Мина бит

«снят с учёта в психоневрологическом диспансере» дигән кәгазь бирделәр. Димәк, мин авыру түгел дигән сүз бит инде бу.

...Әмма юкка вакыт әрәм итеп йөргәннәр икән.

Комиссиядә катнашкан майорны табып, аңа справканы күрсәттеләр. Майор шадра чыраена елмаю сыман төс чыгарып справканы кире бирде:

— Димәк, чүтеки учётта булгансың икән бит, — диде ул чәнчүле тавыш белән. — Теге вакытта сине военкоматтан тикмәгә тиле дип кайтарып җибәрмәгәннәр.

Аңлашылды.

Улы янында моңарчы бер тапкыр да ямьсез сүз әйтмәгән Раиф аты-юлы белән аркылы-торкылы китереп сүгенеп эчен бушатты да:

— Киттек полициягә! — диде.

## X

Башы алдан пеләшләнә башлаган утыз-утыз биш яшьләрдәге капитан, урта бармагы белән компьютер төймәләренә, кайнар әйбергә кагылырга курыккан сыман, саклык белән генә төртә-төртә, нәрсәдер язып утыра иде. Аның күзен чекрәйтеп экранга каравын, аннары тагын зур тырышлык белән аерым-аерым хәрефләрне җыюын күргәч, аның язганы беркайчан дөнья күрмәс һәм аның карамагындагы уголовный эш ачылмыйча ябылыр да, җинаятьче ирektә калыр дип уйларлык иде.

Раиф белән Булат кереп исәнләшкәч тә капитан мыш-мыш килеп компьютер белән бәйләнышын дәвам итте. Тагын берничә кат сәламләгәч кенә полицейский бетчәле чыраен борып боларга игътибар юнәлтте.

Ата белән улның зарларын тыңлагач, капитан минут ярым чамасы бер сүз дәшми каршысында утыручыларга карап торды.

Ниһаять, ул Раифка мөрәҗәгать итте:

— Ник армиягә атлыга соң ул?

— Кемдер хезмәт итәргә тиеш бит, — диде ата кеше. — Күпме үсмер егет армиягә бармас өчен хәйлә таба, чирлегә сабыша, төрле ысуллар белән кача, котыла...

— Аңсын да беләбез, — диде капитан, сагаеп. — Тик менә болай өзгәләнеп солдат булырга тырышучыны әле моңарчы күргәнем юк иде.

— Минем солдат буласым килә, — дип, Булат сүзгә кушылды. — Бу һәр ир баланың бурычы.

Телевизордан көн саен ишетелә торган тәче патриотик сүзләрне гап-гади авыл кешеләренең монда кабатлап утырулары капитанның күнелендәге шикне көчәйтеп җибәрде.

Аның аптырашта калуын шәйләп, Раиф:

— Военкоматка тәэсир итә алмасагыз, психодиспансерга бәлки сүзегез үтәр? — диде һәм Булатны анда яткырганнарын сөйләп бирде.

Атаның сөйләгәнен тыңлаганнан соң, капитан:

— Баш психиатр өстеннән гариза язасызмы соң? — дип сорады.

— Юк, юк, кеше өстеннән жалу язу, кешене судка бирү безнең нәселдә булган нәрсә түгел, — диде Раиф. — Аларга берәр ничек справка бирергә куша алмассызмы икән...

— Нинди справка?

— Җүләр түгел дигән конкрет документ.

— Безнең андый полномочиебез юк. — Капитан Булатка дикъкать белән карады. — Бәлки, чынлап та улыгыз бераз нидер... Тегенди-мондый процесслар яз-көз көчәя бит... Хәзер как раз март азагы...

Ата белән малай, берсен-берсе бүлә-бүлә, инде бер сөйләгән аһ-зарларны тагын аңлатырга тырыштылар.

— Монда ачу килер урын бар, әлбәттә, — диде капитан, Булатка сынаулы караш ташлап. — Военкоматтан тиле дип борып кайтарганнар... психушкага баргач тотып яткырганнар... учётка куйганнар...

Булат баш психиатр белән булган әңгәмәне, ни өчен кызып киткәнен, барысын да бәйнә-бәйнә тагын кабатлап сөйләргә мәҗбүр булды.

— Учёттан снимать иттеләр бит инде! — дип тәмамлады ул сүзен.

Капитан тәрәзәдән тышка карап:

— Шулай да армиягә болай атлыгуың бик сәер... — диде.

— Хәрби хезмәткә тартылуда нинди сәерлек бар? — диде атасы. — Киресенчә, армиягә барырга теләмәү сәер саналырга тиеш.

Капитан үз заманының кешесе иде шул. Ул бөтен нәрсәнең асты өскә килгән, барлык кыйммәтләрнең полюслары алышынган чорда яши иде. Гадел, намуслы кешенең бүгенге көндә абруе юк. Алай булырга тиеш түгел, киресенчә булырга тиеш икәнне беләләр шикелле, ләкин чынбарлыкта елгыр, алдакчы, хәйләкәр, комсыз, рәхимсез кешеләр өстен хәзер. Кешене кеше иткән төшенчәләргә таянып яшәүче мескен хәлдә булган җәмгыятьтә законнар үтәлүен таләп итү көлке санала. Акча, мал, байлык түгел, ә кешенең күңеле, аның үзәгендәге дөнья кыйммәткә ия дисәң сине мыскыл итәләр. Ә инде туган як, туган ил, бурыч, намус дип сүз катсаң, сиңа тилегә караган сыман карыйлар.

Капитан аталы-уллы балта осталарына:

— Нәрсә дә булса уйлап табарбыз, проблемагызны хәл итәргә тырышырбыз, — дип вәгъдә бирде. Һәм, никтер, өстәп куйды: — Барыгыз, авылыгызга кайтып мунча керегез. — Күрәсең, бу бетчәле полицейский авыл мунчасын бик сагынган иде.

Алар чыгып киткәч, капитан тиз генә телефон номерын җыйды.

— Алло! Нихәл, Садриев! Каенсар авылы синең участоктамы? Миңа кереп чыгалмассың микән?

...Садриев — базык гәүдәле участковый, эссе булмаса да гел тирләп йөрүче зат — дүрт авылның участковые булып хезмәт итә иде. Инде иллегә җитеп килсә дә майор званиесен һаман алуга ирешмәде әле. Ул званиегә моннан берничә ел элек инде документлар да әзерләнгән иде, вәләкин авылларның берсендә булган вакыйга аны бу бәхеттән мәхрүм итте. Яңа клубны ачарга килгән Казан вәкиленең машинасын үгез сөзгән. Ике кыш чыккан яшь үгез иномарканың арткы фарасын ваткач, авыл халкының шатлыклы игътибары клуб ачылу тантанасыннан үгез-иномарка вакыйгасына юнәлде.

Тәнен язсын өчен ишегалдына чыгарылган үгезнең ирекә сусавы көчле һәм аңа бу тар мәйдан түгел, чын кинлек кирәк иде. Ярым черек койманы берничә тапкыр йөгереп килеп сөзгәч, такталар сынып-ватылып үгез сыярлык ара хасил булды. Ә көтмәгәндә азатлыкка ирешү теләсә кайсы хайванны исертә. Койрыгын чәнчеп, тибенеп, сөзеп, ямьсез тавыш белән мөгрәп авыл урамнарын айкаганнан соң, аның нәфрәте үзәктә яңа төзелгән клуб каршындагы нимес машинасына юнәлде.

Машинаны сөзгәннән соң үгезне бөтен авыл белән чолгап куалый торгач, абзарга куып кертүгә ирештеләр һәм аны хөкүмәт вәкиленә каршы теракт эшләүдә гаепләделәр. Үгез, хайван булу сәбәпле, җәзага тартыла алмый, аның урынына хуҗасы җавап бирергә тиеш иде.

Участковый киңәше буенча үгезне күрше районның берданбер фермерына саттылар. «Акчаны тотмагыз, җыеп куегыз, аны җәрәхәтләнгән машинаны төзекләндерер өчен хөкүмәт вәкиленә тапшырырга кирәк булыр», — диде участковый.

Ярты елдан артык вакыт узды, машинаны үгез сөзү буенча Казаннан шалтыратучы да, кәгазь-мазар җибәрүче дә булмады. Садриев Казанга үзе шалтыратты. Ә Казанда инде бу вакыйганы да, ачылган яңа клубны да, авылның үзен дә онытканнар икән.

Садриев үгез хуҗасына: «Мин Казанга шалтыратып эшне җайга салдым — сине җавапка тартмаячаклар»,— диде. Үгез хуҗасы шатлыгыннан башта биш минут чамасы тып-тын гына елады. Елаудан туктагач, Садриев аңа: «Үгез саткан акчаңның яртысын эшне кузгаттырмаган кешегә түләргә кирәк, — диде. — Син миңа акчаңны бир, үзем аңа киләсе атнада тапшырырмын».

Үгез хуҗасы берсүзсез участковыйга акча бирде. Әмма шул көнне үк кичкә таба җирле үзидарә башлыгына, ягъни авыл җитәкчесенә, тынычландырыр өчен, Казаннан шалтыраттылар. «Машинаны үгез сөзгәнгә кайгырып ятмагыз анда. Машинаны төзекләндерделәр, ул вакыйганы күптән оныттылар инде», — диделәр. Җирле үзидарә башлыгы адым саен акча белән, ит-сөт-май белән барысын да җайлап-майлап яшәгәнгә күрә, участковыйга биргән акчаны азсынганнардыр, үгез саткан акчаны тулаем участковыйга бирергә кирәктер дип уйлады. Һәм бу хакта Казаннан шалтыратучы белән киңәшләште. Телефон линиясенең Казан очыннан ярсулы дулкын килеп авыл җитәкчесен коендырды: «Ни сөйлисез сез! Нинди акча?! Сездән акча сораучы юк бит. Сез участковыйга акча бирдегезмени? Үгез хуҗасын да, хәтта үгезнең үзен дә гаепләүче юк! Биргән акчагызны участковыйдан кире алыгыз. Сезне үгезегез өчен түгел, взятка биргәнегез өчен җавапка тартып була хәзер!»

Аннары район үзәгенә дә шалтыраттылар Казаннан.

Капитан Садриевны чак кына эшеннән алмадылар. Җитәкчеләргә ярый белгәнгә аны полициядә калдырдылар, ләкин майор званиесенә тутырылган документларга йөреш бирелмәде.

Бу вакыйгадан башка да Садриев майор званиесенә лаеклы түгел иде бугай. Шәһәр янында булганга күрә, аның участогына кергән авылларда заманча җинаятьләр тамыр җәйде. Яңа төзелгән коттеджлар тирәсендә утлы корал тотучылар да бар. Караклыкны әйткән дә юк инде. Ә яшьләрнең үзара сугышулары гадәти күренешкә әйләнде. Хатын-кызны көчләү очраклары ешайды.

Әйе, җинаятьләр еш булып тора Садриев участогында. Әмма аларның бик азы ачыла. Кайберләрен ачкач, тизрәк ябарга кирәк була — берәр «блатной»ның малаен, йә биек урындагы кешенең малаен, нинди җинаять кылса да, төрмәгә утыртып булмый бит инде.

Ул исереп аунап яткан сәрхушләрне генә отделга алып барып яба, йорт тирәсендәге чүп-чар өчен штраф сала — шулай итеп кенә үзенең полиция киемен киеп йөрүен аклый. Хөкемнән акча түләп котылучылар күп. Садриевка гына түгел, ришвәтне уголовный розыскка да бирәләр, следовательләргә дә төртәләр, прокуратураны да «майлыйлар». Кайвакыт өстән теге яки бу җинаятькә нинди караш булырга тиеш икәнне алдан әйтеп куялар, эшне нинди юнәлештән җибәрергә икәнне өйрәтәләр.

Кайчандыр хөкемгә тартылып инде төрмәдә утырып чыккан кешеләргә башкалар кылган җинаятьләрне тагу очраклары күбәйде — кайсысын куркытып, кайсысын алга таба хокук саклау органнары аңа карата миһербанлы булыр дип юмалап.

...Ике капитан, ачылмаган эшләрне актарып, Садриев участогындагы җинаятьләрне барлап утырганнан соң, Булат нинди дә булса җинаять кылгандыр да, шуңа күрә тизрәк армиягә китеп җәзадан котылырга телидер дигән уртак фикергә килделәр.

## XI

Булатны милициягә кат-кат чакырып бимазаладылар. Башта аңа авыл артындагы инеш буенда төзелүче коттеджлан такта урлауны сылтамакчы булдылар. Атаң да, үзең дә — балта осталары, сез тактага битараф түгел, — дигән фикер белән егетне тикшереп теңкәсенә тиделәр. Аннары аңа күрше авылдагы жирле үзидарә башлыгының кызын көчләүне үз өстенә алырга куштылар. Шул арада көчләүчене тоттылар һәм Булатка ачылмаган бүтән эшне тагарга тотындылар. Бу тирәдә наркотик таратуда катнашканыңны таныйсаң, төрмәгә утыртмыйбыз, условно гына бирәбез, срогын тәмамлангач армиягә китәргә ярдәм итәрбез, диделәр.

— Мин бер гаепсез кеше! – дип кычкырды Булат ачыргаланып. – Мине, сау-сәламәт килеш, психушкада яткырдылар, бездән баш психиатр ришвәт алды...

Психиатрга взятка биргәнне ычкындыргач, Булатны:

— Взятканы бирүче өчен дә статья бар, — дип куркыттылар.

Улын көнаралаш чакырып, янап, куркытып, төрле эшләр тагарга маташкач, Раиф полициягә дә түләргә кирәк икәнне аңлады.

Ике капитанның һәр икесенә егермешәр мең акча түләгәч, Булатка полиция тарафыннан берниди дәгъва калмады.

Жайлы гына егерме мең кесәсенә кергәч, Садриевның тар күңеле ничектер киңәебрәк китте. Аннары, балта остасының нәселе әдәпле, хезмәт сөючән икәнне тирә-якта белмәгән кеше юк. Садриев боларга үзенчә ярдәм итеп карарга булды. Аның район прокуратурасында ерак туганы эшли иде. Шуның аша Булатны армиягә озатып булмас микән дигән уйга килде.

...Садриев Булатны гел елмаеп утыра торган кырык-кырык биш яшьләрдәге кеше бүлмәсенә алып керде. Сыек кына мыек, стена сәгатенең циферблаты кебек түгәрәк чырай, шул чырайга Ходай тарафыннан саранлык белән генә урнаштырылган почык борын, чепи күз, крекер печеньесенә охшаган ике колак, бер уч арыш саламын хәтерләткән чәч, тар гына җилкә, нәзек бармаклы ике кул, өстәл астына сузылган ике аяк – болар, эчке органнар һәм башындагы уйлары белән бергә Ярмиев фамилияле прокуратура хезмәткәрен тәшкил итәләр иде.

Кабинетта Булатны гына калдырырга кушкач, участковый үз эшләре белән каядыр китеп барды, Раиф улын коридордагы эскәмиядә утырып көтә калды.

Якты йөзле булса да, сөйләшү манерасы, сораулары салкын вә кискен иде Ярмиевнен.

Булат сөйләгәннәрне тыңлаганнан соң, ул:

— Бик сәер — нишләп участковый синнән котылырга тели икән? – дип уйга калды. — Син хулиганмы?

— Юк, — диде бала чагында да кеше бакчасыннан алма урламаган егет. – Хулиганланып йөрергә вакытым юк минем. Без әти белән көн саен балта эшендә.

Ярмиев озын-озак итеп хәзерге заманның терроризм заманы икәнне, илдә антитеррор халәте игълан ителгәнне сөйләде һәм Булатка турыдан-туры үзенең коточкыч шиген белдерде:

— Армиягә нинди максат белән барырга талпынасың икән син? – диде ул усал тавыш белән, әмма мөлаем маскасын чыраеннан салмыйча гына. – Автоматтан атарга өйрәнергә телисенме? Хәрби фәнне өйрәнеп терактларда кулланырга өметләнмисең микән? Синең белән прокуратура шөгыльләнәчәк. Без сина шушы арада повестка җибәрербез.

Булат өнсез калды. Башына утын яра торган агач тукмак белән суктылармыни

– ул аяк табаннарын идәннән шудырып әкрен генә коридорга чыкты һәм шунда гына атасының коридорда көтеп утыруын исенә төшерде.

Улы калтырана-калтырана әңгәмәнең эчтәлеген аңлаткач, Раиф озак уйлап тормады, шундук тәкъдим итте:

– Булат, улым! Әйдә, бу кәҗә күте төсле ачык чырайлы Ярмиевкә акча түлик тә... Кирәк түгел военкоматы да, армиясе дә, медицинасы да, полициясе дә, прокуратурасы да! Йөрмә, улым, үзеңне үзең букка батырып!

Булат Ярмиевкә егерме биш мең акча кертеп бирде. Акча кергән сөенечтән Ярмиевнең мәңге якты чырае чак кына монсуланып китте – яшәешнең гүзәллеген адәм баласын аңлатып булмый торган моңга манчый, бик рәхәт чакларда кешегә шатлык белән бергә дөньяга рәхмәт йөзеннән бәхетле монаю хас.

Акчаны өстәл тартмасына тыгып куюу белән, Ярмиев:

– Хәзер үк военкоматка шалтыратам, – диде. – Үзләре армиядән косить итәләр, призывниклар житми дип зарланалар, ә үзләре... – Ул телефон трубкасын алгач, Булат:

– Кирәкми, – диде.

– Нәрсә кирәкми? – диде Ярмиев, елмаю киңлегән чак кына тарайтып.

– Минем армиягә барасым килми башлады.

– Ничек инде синең армиягә барасың килми?!

– Гайрәтемне чигерделәр.

Ярмиевнең бите елмайса да, күзләре усал төс белән елтырап куйды:

– Алай ярамый, алай ярамый. Болай да призывниклар житми, күпме үсмер армиядән косить итеп йөри. Синең кебек егет тә бармаса армиягә, илне кем саклар?!

– Соң, мин бит кайчаннан бирле барысына да шуны аңлатырга тырышам! Әүзем, хезмәт итәсе урынга, йә психушкада ятам, йә полиция бүлегендә аңлатма язам, йә прокуратурада...

Ул сүзен әйтеп бетермәде, Ярмиев аны бүлеп:

– Прокуратурага килеп дөрес эшләдең. Хәзер мин военкоматка шалтыратам, – диде һәм нәзек бармагы белән төймәләргә нәзакәтлек белән басып телефон номерын жыйды.

Телефон линиясенең теге очыннан жавап ишетелгәч, Ярмиевнең чырае елмаюдан язгы күл сыман жәелде.

– Сәләхетдинов! Мотыйк Махмутович! Сәлам! Бу прокуратурадан Ярмиев борчый сезне.

Булат аларның ярты сәгать чамасы сөйләшкәннәрен тыңлап утырырга мәжбүр булды. Ниһаять, әңгәмә кирәкле агымнан китте:

– Мотыйк Махмутович! Монда бер егетне армиягә алмагансыз. Хасанов Булат Раифович. Аның хезмәт итәсе килә. Нишләп алмыйсыз? – Сәбәбен ишеткәч, Ярмиев кет-кет көлеп куйды. – Үземнең дә шигем бар, мин дә аптырадым. Шулай да, призывниклар житмәгән заманда, армиядән яшьләр баш тартканда бу егетне армиягә алырга кирәктер. Әйе... әйе... Алайса, мин аны хәзер сезгә жибәрәм.

Ул трубканы куеп, Булатка:

– Бар военкоматка, – диде. – Хезмәт ит Ватанга.

– Анда ничәнче кабинетка керим? – дип сорады Булат.

– Дежурныйга әйтерсең: Мотыйк Махмутович Сәләхетдиновка, диярсең. Кая керергә икәнне күрсәтерләр.

Раиф, эше күп булу сәбәпле, авылга кайтып китәргә ашыкты, ә Булат, инде ниһаять армиягә алырлар дигән өмет белән, военкоматка юнәлде.

## XII

— Солдат буласың киләме? — диде Сәләхетдинов, тау хәтле гәүдәсен креслосының аркасына терәп.

— Күптәннән инде, — диде Булат. — Армиягә барырга теләүчеләр соңгы вакытта булмагач, минем чын күңелдән хезмәт итәсе килүемә ышанмыйлар.

Военкоматның эшләрен һәрвакыт чынбарлыкка туры килмәгән алдаулар белән яктыртып күрсәтү Мотыйк Махмутовичның канына сеңгән иде.

— Беренчедән, армиягә барырга теләүчеләр юк диюен дөрес түгел.

Икенчедән, синең ихластан илгә хәрби хезмәт күрсәтергә ыргылуыңны шәхсән үзем биш куллап хуплыйм. Ничек инде армиягә барырга теләүчеләр булмасын! — Ул, гадәттәгечә, ялганлый башлады. — Бүгенге көндә гаскәрләрнең кайбер төренә шул кадәре күп призывник атлыга. Конкурс шул кадәр зур — бер урынга алты кеше.

Булат бу сүзләрнең ялган икәнен чамаласа да, бәхәсләшергә базмады.

— Мине бу яз призывында аласызмы армиягә? — диде ул инде тукмак борынлы абзый читкә типмәс дигән өмет белән.

— Карарга кирәк. Буш урын калды микән...

— Ни дигән сүз бу? — диде Булат, кызып китүдән үзен көчкә тыеп. — Ел саен призывниклар житми... Әллә нинди ысуллар белән хезмәт итүдән качалар... Кача алмаганнарының сәламәтлеге юк... Моны бөтен кеше белә бит инде.

— Ил дә башка, армиясе дә башка хәзер, — диде Сәләхетдинов тирән сулап. Сулышы шул кадәр тирән булды ки, кабинетның ярты һавасы аның бугазына суырылып кереп киткәндәй булды. — Бөтен нәрсәнең асты өскә килде. Адым саен түләргә кирәк...

Инде тик торганда, бер кирәкмәгәнгә акча түләп туйган егет:

— Мин тагын кемгәдер түләргә тиешмени әле?! — дип жикеренде.

— Бу призывта, урын тапсам түләргә кирәк булачак, — диде Мотыйк Махмутович егетнең йөзенә карамаска тырышып.

Булат түзмәде, шаркылдап көлеп жибәрде. Һәм ишекне шапылдатып чыгып китте.

... Моны авылга кайтып сөйләгәч, өйдәгеләр дә рәхәтләнеп көлделәр. Малайларны армиягә жибәрмәс өчен ришвәт алучылар армиягә барырга теләүчеләрдән дә акча сорыйлар икән. Армиядән котылыр өчен дә түләргә кирәк! Барасың килсә дә түләргә тиешсең!

— Күпме түләргә була! — диде гаилә башлыгы. — Нишләде бу ил?!

Егерменче гасырның житмешенче еллар азагында сәвит Армиясендә ике ел хезмәт иткән Раиф өчен улының күңелсез хәлдә калуы бик аянычлы күренеш иде.

— Казанга бар! — диде ул. — Иртәгә үк юлга кузгал! Татарстанның иң өлкән военкомын күреп барысын да сөйләп бир.

## XIII

Район үзәгеннән Казанга автобусның тагын өч сәгатьтән китәсен белгәч, Булат сөенде, чөнки Нәбигә түлисе әҗәтен апасы Тәхлиягә кертеп чыгарга вакыты кала иде.

Тәхлия шәһәр читенең шәхси йортлардан торган өлешендә матур гына яшәп ята. Күрәзәчелек, им-том ише нәрсәләргә гомерен багышлап ул балаларын да аякка бастырды, иренең вафатыннан соң да ким-хур булмады, киресенчә, үзе генә калгач, аның сихер-михер эше чәчәк атты. Тәхлиянең даны районнан чыгып, Татарстан чикләрен узып, хәтта Мари жирләренә генә дә сыймыйча, Мәскәү астына кадәр барып житкән иде, ә көннең чыгышына таба карасаң, Урал тауларының артында да аның турында ишеткәннәре бар икән.

Булат кергәндә Тәхлия, өстәлгә терсәкләре белән таянып, тәрәзәдән төшкән яктыда бармакларын төкерекли-төкерекли акча санап утыра иде. Түрдәге киштәдә әллә нинди сәякләр, кечкенә банкалар, таш кисәкләре, ниндидер төргәкләр тезелгән. Стена буендагы артсыз урындыкта таз белән су тора. Өй эчендәге дымлы жылылык тәнгә дә, сулышка да рәхәт түгел иде, күрәсең, әле яна гына карчык нидер кайнаткан булган.

Булат исәнләшкәч, Тәхлия сискәнеп китте һәм акчаны тиз генә өстәл тартмасына шудырып куйды.

Егет тагын бер тапкыр исәнләште:

— Исәнме, Тәхлия апа.

— Уф, котымны алдын, — диде Тәхлия. – Исәнме. – Ул шактый вакыт егетне болай да кысык күзләрен челәйтеп күз карашы белән «капшады».

— Вакытын бик тыгыз түгелме?

Тәхлия барып стенадагы төймәгә басты. Түшәмгә эленгән люстра шикелле түгәрәк нәрсә саран гына яктылыгын өй эченә сирпеде.

Тәхлия инде алтмыштан узган, әмма әле житмешкә барып житмәгән, кечкенә буйлы, шома чырайлы карчык иде. Анын кысык күзләренен карашын анларлык түгел, бөтен халәтен үзен тотышы белән карлыккан тавышыннан чамалап була. Почык борыны астында олы авыз булганга, ул мультфильм персонажына охшаган, ләкин ярты минут аралашканнан сон анын житди, көчле һәм кирәк булса жанынны суырып алырга сәләтле сихерче иканенә һәркем ышана иде. Кигән күлмәге, күлмәк өстендәге кофтасы, аягындагы башмагы – барысы да сирәк очрый торган чуар төстә һәм, аны күптән белүчеләр әйтүенчә, ул гомер буе шундый кием кия, имеш.

— Вакытнын тыгызлыгын-бушлыгын кем үлчәгән, — диде сихерче, сулы таз янындагы махсус урындыкка утыргач. — Тыгыз булса да, буш булса да, һәрбер кеше билгеле бер вакыт арасына сыя инде ул, беркая киталмый. – Ни йомыш?

— Синен бертуган апаннын улы Нәби белән без психушкада бер палатада яттык...

Шул вакытны Тәхлиянен өстәлдә яткан кесә телефоны жыр белән зенгелдәде: «...Девочкой своею ты меня назови, а потом обними, а потом обмани...»

Тәхлия трубканы алып колагына куйды:

— Алло! Әйе. Исәнмесез, Гимран Гильманович! Сез суган суына бер кашык борчак салып унике көн тотыгыз. Юк, суыткычта түгел, тәрәзә төбендә генә. Сасысын, сасысын, анын шул сасуы кирәк тә инде. Эчәргә кирәк, эчәргә. Булыша, булыша. Как рукой снимет. Миндә ул сыекчанын әзере бар. Флаконы өч йөз унике сум. Әйе, килеп алыгыз. Ярар. Сау булыгыз, Гимран Гильманович.

Тәхлия, телефонын кофта кесәсенә тыгып, Булатка анлатты:

— Гимран Гильманович – үзәк базар директорынын урынбасары. Ул көн саен аракы эчә торган кеше. Махмырдан иртән теш чистарта башлагач, укшыта дип килгән. Мин тәкъдим иткән сыекчаны эчкәч, ул теш чистартканчы ук косачак. Тагын нәрсә эшләтә алам инде мин аны.

Булат әле һаман бусагадан ары китмәгән иде, Тәхлия ана ишарәләп буш урындыкка утырырга кушты.

— Без Нәби абый белән бер палатада ятадек, — диде Булат. – Мин анардан әжәткә сигез мен акча алып торган идем.

Тәхлия кинәт авызын ямьсез итеп жәеп елап жибәрде.

— Жан көеге бит ул! Апамны картайтып гүргә кертте! Кабахәт! Адәм актыгы!

Булат сихерчсенең болай өзгәләнүен котмәгән иде.

— Алай начар кешегә охшамаган ул үзе, — дигән булды. — Нәби абый ул ярдәмчел... Хәзер тарихны яхшы белә...

Булатның бу сүзләре карчыкка унай тәэсир итте — кинәт елаудан туктады. Булат шуны сизеп алды — елаганда Тәхлиянең күзләре аз гына да дымланмаган, күз яшьләрен түкмичә генә илаулаган икән. Плимәнниге турында моңарчы бер жылы сүз дә ишеткәне булмаганга күрә Тәхлиянең күңеле йомшарып китте.

— Болай күңеле әйбәт аның үзенең. Чалыш юлларда йөрсә дә, адәм рәтле тормыш белән яшәрдәй кеше. Менә дигән гаилә корырлыгы бар. Мозгасының бер урынында нәрсәнедер үзгәртсәң...

— Сез бит данлыклы сихерче. Нәби абыйны гына урынына утыртырга сәләтегез житмимени?

— Мин үзе дәваланырга теләүчеләрне генә дәвалый алам. — Аның йөзе тагын карангыланды, авызы тагын жәелде. — Бәреп кенә үтерәсе бар аны, кабахәтне! Дүрт тапкыр төрмәдә утырды. Мин коткармасам, инде ундүрт тапкыр утырган булыр иде. Бу юлысы, аптырагач, тиләләр бүлнисенә яткырдым, юкса тагын төрмәгә тыгып куялар иде үзен.

Бурычын түләгәч, Булат чыгып китәргә ашыкмады, чөнки аның Тәхлиядән үзенең киләчәген сорыйсы килде. Армиягә юк-бар мәшәкатьләрдән, урынсыз-кирәксез матавыклардан башка гына китәр өчен нишләргә кирәк икәнне дә әйтмәсме дип өметләнде ул.

Үзенең проблемаларын кыскача гына әйтим дип авызын ачуы булды, Тәхлиянең телефоны жырлап жибәрде: «... Девочкой своею ты меня назови, а потом обними, а потом обмани...»

Багучы трубканы колагына куеп:

— Алло! — диде. — Мин бит икенче көнне үк төзәлә димәдем. Карга каурыен дуңгыз маена манып сыпырдыңмы? Ничек инде карга каурыен табалмыйсың син? Татарстанда каргадан күбрәк кош юк. Бездә дуңгыз өстендә дуңгыз. Табалмасаң, миндә бар. Бер каурый йөз кырык алты сум тора. Дуңгыз маен ике йөз ун сумга бирәм. Килеп ал.

Булат үзенең соңгы вакытта нинди көтелмәгән матавыкка дучар булуын, армиядә хезмәт итәргә хыяллануын, бу юлында аңа нинди киртәләр куелуын һәм, ниһаять, менә хәзер иганә сорап Казанга барырга жыенуын бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

— Армиягә алырлар микән мине? — дип сорады ул бәянын тәмамлагач.

Тәхлия, сулгарак янтаеп, яньчелгән тазындагы суга карады. Һәм таздагы судан аңа Булатның һичшиксез солдат булачагы күренде.

— Син армиягә быел ук китәсең, — диде ул егетне сөендереп.

Ләкин шундук Тәхлиянең военкоматта эшләмәвен искә төшереп, Булат:

— Моның өчен нишләргә тиеш соң мин? — дип сорады.

Шулвакыт йорт каршына салам эскерте хәтле затлы машина килеп туктады һәм ырымчы өенә егерме биш яшьләрдәге кыз килеп керде.

— Исәнмесез, — диде кыз.

— Исән, — диде карчык коры гына.

Утырып килгән машинасыннан, кигән киеменнән, анкыган хушбуй исләреннән бу кызның бай икәнлеге аңлашылды.

— Сез хәзер занята бугай... башка вакытта килимме? — диде кыз каушап.

— Миндә башка вакытта да кеше булачак, — диде карчык. — Моннан кеше өзелми. Нинди проблемаң бар? Курыкма, сөйлә. Бу — үзебезнең кеше.

Плимәнниге белән психушкада бергә яткан егет Тәхлия өчен якын кеше иде.

— Сез багучы апамы?

— Булсам ни. Утыр.

Булат, торып, кызга урын бирде, үзе түрдәге буш урындыкка барып утырды.

— Минем исемем Румия. Тәхлия апа, мина сезнен кинәшегез кирәк. Минем сөйгән кешем, ирем дип әйтсәң дә була... Фаяз исемле ул... Без бала чактан ук бергә... Ләкин мин гел шикләнеп, көнләшеп яшим. Бик яратам мин аны. Ул кызлар күзенен явын ала торган егет, бәлки, шунадыр. Аннары мин ырымнарга бик ышанам, сонгы вакытта һәрнәрсәдә нинди дә булса билге күреп кайгыга батам.

— Акчаң күп булса да мәхәббәт кирәк икән... — диде Тәхлия, төрттереп.

— Яратам мин аны, — диде Румия газаплы тавыш белән.

— Мина туп-туры кара әле, — диде сихерче ике учы белән кызнын сагыштан саргайган йөзен үзенә таба борып. — Әһә... — Карчык үзенен иске тазына күз салды. — Фаяз синен кешең түгел. Сина башка кеше кирәк — солидный кеше кирәк сина.

— Мин Фаязны бик яратам бит.

— Яраткач, нәрсә борчый соң сине? Яратмау начар. Яраткач бик әйбәт. Мина бер зур нәчәлник килде дә: «Секретаршама гашыйк булдым, нишлим?» — диде. Уйлап кара — гашыйк булган да, нишлим дип сорый. Гашыйк булгансын икән, рәхәтләнеп ярат! — Ул Булатка таба борылды. — Мәсәлән, печ итәсен килсә, син бит нишлим икән — печ итәсем килә дип сорамыйсын. Барып печ итәсен, шулаймы?

— Шулай, — диде Булат.

Егет сәгатенә карады — автобуска әле тагын ике сәгать вакыт бар иде, шулай да ул карчыкның тизрәк кызны чыгарып җибәрүен теләде. Ачуны китереп, тагын Тәхлиянен телефоны үзенен җырын сузды: «... Девочкой своею ты меня назови, а потом обними, а потом обмани...»

— Алло! — диде Тәхлия трубкага. — Малаенны армиягә алалар? Мин аны астына сия торган итә алам, но аннары сими торган итеп булмавы ихтимал. Әллә армиягә барып кайтсынмы? Тагын нишләтеп була дип... Җүләр дип справка эшләтергә мөмкин. Синен малаен җүләр дип справканы бирергә тиешләр. Тулы түгел бит синен малаен. Сон, тиле булмаса, машиналардан магнитола урлап йөрер идемени ул! Ярар, ярар, алып кил малаенны, берәр нәрсә уйлап чыгарырбыз. — Карчык телефонын сүндереп кесәсенә тыкты. — Армиягә малайларын җибәрмәс өчен әллә ниләргә баралар, ай-яй.

— Минем Фаязым хезмәт итте, ике ел, — диде егетен бер секундка да башыннан чыгармаган Румия.

— Узган атнада транспорт хуҗалыгыннан баш механик килгән, — диде Тәхлия елмаеп. — Малаемны армиягә алмасыннар өчен күзләрен бераз кылыйландыра алмыйсынмы, ди. — Тәхлия «хый-хый-хый» итеп көлеп куйды. — Вакытлыча гына, аннары турайтырлык итеп кенә ди. Бәясен әйткәнием, үзенен күзләре кылыйланды тегенен. Хый-хый-хый-хый.

— Мин Фаязым белән булмаячакмынмыни?

— Синен Фаязын шушы мескен Җир шарыннан ары беркая да киталмый, — диде карчык, кинәт житдиләнеп. — Син, танышырга телим дип, гәҗиткә игълан бир. Аңа ачу итү дә була, аны һәм үзенне сынау да була. Бәлки шәбрәк кеше белән танышырсын. — Ул таздагы суга иелеп карады. — Игъланны бүген үк бирсән, бер атна-ун көннән сина хәрби формадан бер бик мощный ир кеше киләчәк — менә таздан күренеп тора.

Румия үрелеп тазга карамакчы булды:

— Кая... — Ана бөтен киләчәге шул иске таздан күренер сыман иде.

— Карама тазга, аны мин генә күрәм, — диде Тәхлия кызны җинел генә иненнән этеп.

— Хәрби кеше дисезме?

— Әйе. Исемен дә әйтә алам — Нәби.

— Нәби... — диде Румия үзалдына.

Булат түземсезлек белән кызның тизрәк чыгып китүен теләп утырды.

Шул вакытны тагын телефон үзенең уйнашчылар җыры белән зынларга тотынды: «...Девочкой своею ты меня назови, а потом обними, а потом обмани...»

— О-о-о, Паромон Петрович! — диде Тәхлия карлыккан тавышын ягымлылык белән берникадәр майлап. — Скульке лит, скульке зим! Да, Паромон Петрович, я живая... А шту?.. В бүлнисе лижали?.. Паромон Петрович, я же ни сказала поши слюнасын пить... Натирать дигәнием бит... Ну кто стакан поши слюнасын пьет... Ну что вы, Паромон Петрович! Мозоли надо был натирать... А вы пили... Паромон Петрович! Паромон Петрович! — Карчык борын тишекләрен кинәйтеп кулындагы телефонына карап торды. — Ташлады трубкасын, мудак! Син Паромон Петровичны беләсенме?

— Юк, — диде кыз, Паромонны белмәгәнгә үзен гаепле тоеп. — Кем соң ул?

— Кызыл Чишмә урман хуҗалыгының директоры. Аягының һәр бармагында сөял. Поши селәгәен сыларга кушканыем. Тирә-ягында поши күп булгач, күп итеп җыйган да эчкән. Ике ай инфекционныйда ятып чыккан. Урысча дөрес анлата алмаганмындыр инде. Мин бит урысча начар сөйләшәм. Татарча мин любой кешене өч тәнкәгә сатып җибәрә алам, ә урысча... Ярар, хрен с ним. Паромон Петровичлар күп алар дөньяда. Барысыннан да курка башласаң... Мин куркудан узган инде. Тәк! Урыс әйтмешли, вернемся к нашим баранам. Танышулар бүлегендә игълан бирәсең дә, эше бетте кодагый! Аңладыңмы?

— Куркам мин, — диде кыз еламсырап.

— Бу дөньяда бер генә көн дә курыкмыйча тору мөмкин түгел, — диде Тәхлия шомлы тавыш белән.

Шуннан соң ул Румиягә бер уч балык кылчыкларын чүпрәккә төреп бирде дә, шуның өчен ике йөз сум һәм сеанс өчен мен ярым акча алды. Ул биргән кылчык гади кылчык түгел, ә кабисә елында язгы ташу вакытында Кама елгасында черпак белән тотылган табан балыгыныкы ди. Ә сеансның бәясе мен, чөнки легендар таздагы судан карау шуннан да кимрәк булалмый икән. Бу кылчыкларны сөйгәне яши торган йорт тирәли сибеп кенә чыгасы бар ди һәм язмышлар Кама елгасы сыман ышанычлы агым белән китәчәк, имеш.

Румия чыгып киткәч, Булат карчык янына килеп утырды.

— Тәхлия апа, миңа нишләргә?

— Монда район үзәгендә мескенләнеп йөрмә. Казанга барырга җыенгансың икән, бик хуп, шунда юл тот.

— Армиягә алалар диден мине...

— Быел ук китәсең. Түлке хәзер барып Казан военкоматына керергә кирәк. Син анда үз ходың белән барып керсән, мондагы шикелле эт типкесендә йөртеп, акчанны суырып, ыштансыз калдырачаклар һәм күтенә тибеп кайтарып җибәрәчәкләр. Анда син берәр зур кеше аша керергә тиеш — хакимият кешесе, бай бизнесмен, криминаль авторитет, депутат, республика җитәкчесенен берәр туганы яки берәр мөфти — шундыйларның берәрсе башта военкоматка шалтыратырга тиеш.

— Нишләп шулай бик катлаулы икән соң Татвоенкоматка керү? Мин бит армиядә хезмәт итәргә телим!

— Монда шул теләгенне тормышка ашырырга маташкансың бит инде, нәрсә килеп чыкты соң? Ә Казанда мондагыдан күп мәртәбә зуррак михнәтләр күрүең ихтимал. Казанда берәр блатной кешең бармы?

— Юк шул, — диде Булат, авыр сулап. — Синең берәр абруйлы танышың юкмы соң анда?

— Бар да, ни ул...

— Мин сиңа түләрмен, Тәхлия апа...

— Узган атнада бер депутат килгәние. Атабаев. Ишеткәнең юкмы?

— Юк.

— Хатыным читтә нитә бугай... хыянәт итә, ахрысы, ди. Тәхлия апа, минем шик-шөбһәләрем урынлымы, ди. Аның килеп керүен күрсәң әле син. Телевизордан чыгыш ясаганда чәчрәп тора, ә монда кергәндә инештән еракта су күрми үскән каз бәбкәсе сыман шәлперәйгән. Югыйсә тау хәтле иномаркада шәхси шоферы белән килгән, үзеннән затлы әдикалун исләре аңкып тора, но күнелендә сумала кайный, җаны тынычсыз түгел депутатыбызның. Хатыным хыянәт итә микән дигәч, мин дөресен әйттем: хатыныңны синнән башка да басалар, хатының тугры түгел, дидем. Ышанырга мы-юкмы дип күзен шакаена кадәре акайтып утыргач, мин депутатка әйттем: «Әнә пекарняның завхозы да ышанмыйдырые, дидем. Хатыным чалыш юлга басмады микән дип килгән. Хатыным йөрми микән дип сорасалар, мин һәрвакыт: «Кәнишне, йөри!» дип җавап бирәм. Чөнки хатыны йөрмәсә, андый сорау белән килмәс иде, шулаймы? Шул ук көнне пекарня завхозы хатынының строительный вагоннан прораб белән чыгып килүен күргән. «Кем белән хыянәт итә икән минә хатыным?» — дип сорый депутат миннән. Йортым каршында торган машина янында тәмәке тартып әрле-бирле йөрүче шофёрын күргәч, депутатның хатыны кем белән йөргәнне шундук әйтеп тә бирдем. Депутатның чырае йодрык хәтле генә калды, хәле бетеп бик озак дәшми утырды. Мин хәзер нишлим ди... Авылга кайтып түбәдән сәнәккә сикер, мәйтәм. Син әллә нинди ямьсез тонда сөйләшәсең, ди бу миңа. Миңа көненә күпме кеше мөрәҗәгать итә, мәйтәм. Мин ЗАГСтагы администратор шикелле ясалма ягымлылык белән сөйләшеп утыралмыйм. «Нужәли минем водитель хатынымны каезлап йөри икән?» ди бу миңа. Һичшиксез шул, дидем. Бу юлысы мин тазга да карап тормадым. Соң, Булат энем, ул хәзер генә башланган хәл түгел бит. Элек-электән шәхси водительләр начальникларнең, депутатларның хатыннарын сөеп йөргәннәр — таздагы суга карамасаң да аңлашыла, шофёрны күрү дә җитә.

Булат күрәзәчегә сокланып карады.

— Син карап торуга гап-гади апа... Ничек алдан күрә аласың соң?..

Тәхлия киштәдәге препаратларын җайлаштырып тезәргә тотынды.

— Яшелчә базасында эшләгәндә черек помидор ашап агуланганыем, — диде ул моңсу тавыш белән. — Шуннан ошбу сәләтләрем ачылды.

— Тәхлия апа, алайса минем проблемам белән шул депутатка мөрәҗәгать итеп кара әле.

— Хәзер, — диде Тәхлия, юеш кулын чүпрәккә сөртеп. — Ул миңа бик рәхмәтле. Хыянәт иттерми торган үлән җыелмалары бирдем мин аңа. Хатыны сизмәгәндә ашына салырга.

— Ә теге водителен нишләткән?

— Нишләтсен ул аны. Эшеннән куган. Шофёры башка хәзер. Машинасының багажнигындагы почмакка тыгарга бер әйбер дә бирдем — анысы яна шофёр моның хатынына кызыкмасын өчен.

Тәхлия тәрәзә янына барып телефонында депутатның номерын җыйды.

— Алло! Гаяз Сираевич! Хәерле көн! Әйе, мин бу, Тәхлия апаң. Хәлләрегез

ничек? Ярыйсымы... Бик әйбәт. Үземнең элеккечә, бер көн эшсез утырганым юк. Безнең халык шундый бит инде ул — патша вакыты булса да, коммунистлар килсә дә, янадан мәчетләр төзесәләр дә барыбер минем ише сихерче-көрәзәчеләр кирәк. Сезнең дә эш күпмени? Мәскәү кушканны гына эшләп утыргач, сезнең анда эшләр беткәндер инде дигәнием... Шаярам, шаярам, Гаяз Сираевич! Минем сиңа бер үтенечем бар. Янымда бер бик шәп егет утыра — балта остасы. Аның атасы да тирә-якта дан казанган столяр. Менә шул егет армиягә китә алмый иза чигә. Ярдәм италмассын микән? Юк, юк, сау-сәламәт! Бозлавык көнне тауга каршы сыер этәрдәй егет. Ник дәшмисең? Курыкма! Синең теге водителең шикелле бозык егет түгел, авыл малае, тәртипле гаиләдән... Аннары, хатынын сиңа хәзер хыянәт итмәячәк инде... Кабул итеп, ярдәм күрсәт, зинһар. Ул бүген Казанга автобус белән килә... Ярый, рәхмәт сиңа, Гаяз Сираевич! Проблемаларың булса, озакка сузмыйча шалтырат. Сау булып тор!

Тәхлия Булатка депутатның телефон номерын биреп:

— Казанга барып җитү белән шалтырат, машинасы килеп алыр, — диде.

Булат депутатның телефон номерын үзенең телефонына язып алды һәм Тәхлиягә ярдәме өчен биш мең акча тапшырып:

— Армиягә китәргә повестка алсам, тагын биш мең китерермен, — дип вәгъдә бирде.

## XIV

Атабаев Гаяз Сираевич елгыр кеше иде. Ул гомер буе яраклаша белде. Гади, намуслы кешеләрдән аермалы буларак, табигать тарафыннан аңа җилнең кайчан, кайдан, кая таба искәнен сизүче ниндидер (үзе дә белми торган) өстәмә бер орган да бирелгән иде. Дәүләт предприятиесенең директоры да ул, төзелеш материалларын сату-алу фирмалары белән дә җитәкчелек итә, хатынына, ике малаена рәсмиләштерелгән бизнесы да бар. Акчасы да, абруе да җитәрлек шикелле Атабаевның. Әмма ике малае да кыек юлга кереп, кынгыр эшләр белән матавыклангалап тора, алар кайгысы чигә тирәсендәге чәчен ньк агартты, өстәвенә хатыны да хыянәт итеп, башкалар белән чуалып алды, анысы йөрәккә каты яра булып уелды. Дөрес, Гаяз Сираевич үзе дә хатын-кызны читтә ньк каезлый, ләкин хатынының читтә башкалар белән йөрүен үзең кызлар өстендә үлсән дә кабул итеп булмый шул.

Булат автобустан төшү белән Атабаевка шалтыратты. Егерме минут үтте микән, Булатны алырга тау хәтле машина килеп җитте.

Депутатның шоферы Мәхмүт — түгәрәк йөзле, боз төсендәге зәңгәрлек белән генә бераз буялган зур күзле, һава торышы нинди булуга карамастан даими рәвештә чак кына елмаеп торучы кырык яшьтәге ир — Булат аның якташы икәнне белгәч (күрше районнан иде ул), туганын очраткан сыман шатланды. Булатны ул депутатның Казаннан биш чакрым чамасы читтәрәк урнашкан посёлоктагы тыштан зиннәтле, ләкин эчендә әле төзелеп бетмәгән коттеджына алып килде.

Аларны хуҗа үзе — Гаяз Сираевич каршы алды.

Кыяфәтенең җитдилеген арттырыр өчен борын тишекләрен киеренкелек белән киңәйтеп сөйләшә торган депутат илледән узган адәм баласы иде. Чыраеннан, тән төзелешеннән, мышнавыннан аның тәмле ашаганы, җәяү йөрмәгәне аңлашыла. Үзен татар дип санаса да, ул мукшы чырайлы, саргылт чәчле, дуңгызныкы кебек сары керфекле иде. Шул сары чәчле булганга күрә генә соңгы вакытта хатынының хыянәт итүеннән һәм улларының пүтсезлегеннән чәченең чигә тирәсендә агаруы алай бигүк күзгә ташланмый, моны ул үзе көзгедән генә күрә ала иде.

Гаяз Сираевичны беркемнен дә кәчтүм-галстуксыз һәм түшендәге

«депутатский значок»сыз күргәне юк. Шушы формадан башка аның абруе мизгел эчендә гаип булырга мөмкин дип уйлый микән, кешеләр арасында шушы кием, шушы значок белән генә өстен була аласын дип инанганмы.

Кичкә кырын, хатыныннан аулакта, төзелеп бетмәгән коттеджның кухнясына ул дусларын, таныш-белешләрен, татар халкының танылган шәхесләрен алып кайтып затлы аракы эчә-эчә гәп куертырга ярата. Монда көнаралаш салмыш баштан фәлсәфә корган булып, ил проблемалары буенча бәхәсләшеп, милләт, киләчәк, тарих турында төне буе сөйләшеп утыралар.

Булатның исәнләшүенә җавап итеп ул юка иреннәре арасыннан салкын гына:

— Исәнме, — диде.

Булат хуҗаның кечкенә соры күзләренә туры карый алмады. Бу караште сынау да, ышанмау да, бераз җирәнү дә бар шикелле иде.

Төзелеп бетмәгән коттеджның кухнясы әзер иде инде — монда яшәр өчен кайбер шартлар: җиһазлар, электр җылыткыч, киң диван, телевизор, савыт-саба, газ плитәсе һәм башка кирәк-ярак бар иде. Мунча иң алдан, коттеджның нигезе салына башлаганда ук төзелгән һәм ул үзенең туры вазифаларын күптән үти иде. Башкаланың үзәгендәге өч йөз квадрат метрлы фатирдан мунчага Атабаевның гаиләсе атнага бер тапкыр йөри, ә депутат үзе көнаралаш диярлек йә коллегалары белән, йә сөяркәләре белән мунчага килеп китәргә җай таба иде.

Гаяз Сираевич Булатны тыңлаганнан соң:

— Менә шушы кухняда йокларсың, — диде. — Җылыткычны кайчан кирәк, шунда кабыз. Мунчаны теләсә кайчан ягып кер. Суыткычта ашарга бар. Ризык беткән саен водителем ташып торыр. Телевизор эшли... Минем сина үтенечем бар... Коттедж эчен нарат рейкалар белән тышлап чыгарга кирәк... Син бит балта остасы. Шуны эшләп бир әле мина. Хәзер безнең сессия. Сессия тәмамлангач, мин военкоматка берәр кешемне җибәрермен, мәсьәләңне хәл итәрләр. Үземә бару килешмәс, чөнки мин әле күптән түгел генә ике малаемны да армиягә җибәрмәс өчен шул тирәдә йөрдем. Үземнең малайларым урынына сине җибәрергә телим дип уйлаулары ихтимал.

— Бәлки, сез шалтыратырсыз да военкоматка, үзем барырмын?

— Юк, башта синең үзенә барырга ярамый. Сине егерме бер яшенә кадәр үзен военкоматка бармаганың өчен җавапка тартулары ихтимал. Саклык кирәк... Бер ун көннән мин анда берәр кешене юлларммын.

«Җавапка тартулары ихтимал» дигән сүзләр Булатны нык куркытты. Үз районында, бәлки, бу сүзләр каты тәэсир итмәс иде, ә монда исә, Казанның үзендә сүзне болай гына әйтмиләрдер бит.

## XV

Булат җиң сызганып эшкә тотынды. Нарат такталарыннан, ерактан кайтартылган булганга һәм складларда озак аунап яту сәбәпле, бала чактан ук аңга-канга сеңгән хуш исләр килмәсә дә, агач эше аны тынычландырды, хәтердә сабый чакның якты мизгелләрен калкытты, әтисе, әнисе, сеңлесе, сөйгән кызы, авыл янындагы болыннар, болыннан соң калыккан урман — барысы да могҗизалы фильм булып башында кат-кат әйләнде.

Көн артыннан көн үтте. Булат эшне яратып эшләде. Ул көн саен кичкырын мунча ягып керә. Мәхмүт, алдан Булатның ни ашарга теләгәнен сорап, ризык ташый. Якташының талымсызлыгына ул шаккатты. Мәхмүт үзе дә авыл малае, әмма башка нәселдән, аннары, «зур» кешеләрнең шоферы булып эшләп, үзе дә сизмәстән тәмле тамакка әйләнгән иде.

Мәхмүт белән Булат дуслашып киттеләр. Мәхмүт гаҗәеп кызык кеше икән.

Мангае тар булса да (аның куе коңгырт чәченнән кашларына кадәр ара бик кыска) үз ягына башы шәп эшли. Аның әнкәсе ягыннан туганнары барысы да хәлле кешеләр — урта дәрәҗәдәге житәкчеләр, эшмәкәрләр, хәтта бер абыйсы республика масштабындагы зур чиновник иде. Әнкәсе гади авыл кешесенә чыгып гап-гади дүрт бала тапкан, апалары кайсы кая кияүгә чыгып таралганнар. Ә Мәхмүт шофёрга укыганнан соң, өйләнеп, Сургут якларына акча эшләргә чыгып киткән булган. Шунда ике баласы туган, шактый акча эшләгән, әмма 1991 елны аның бөтен акчасы яна. Шуннан соң ул гаиләсе белән Казанга кайта һәм монда аңа югары урында утыручы абыйсы зур ярдәм күрсәтә — фатир сатып алырга акча бирә, бер завод директорының шофёры итеп урнаштыра. Завод директорының машинада шатыр-шотыр кикерүенә түзә алмыйча, ул аннан китә һәм аны абыйсы Госсоветка депутат йөртергә урнаштыра. Шулай итеп Мәхмүт Атабаевны йөртә башлый. Атабаев «жилле» булмаса да, Мәхмүт анардан да туярга өлгергән иде инде.

Мәктәптә икелегә укыган булса да, Мәхмүт депутатларны, аларның үзара мөнәсәбәтләрен, яшәү рәвешләрен аңлау һәм дөрес анализлау сәләтенә ия иде һәм аларның ваемсызлыгын, юк-барга акча туздыруларын, балда-майда йөзүләрен жай чыккан саен сөйләп ул Булатны шаккатырды.

— Минем шеф йөз егерме меңлек кәчтүм алды, чегы һаман машина бардачогында, — диде ул чәй эчеп утырганда.

— Синең үзеңә дә абыең жайлы гына фатирлык акча биргән бит, — диде Булат.

— Минем гаиләм бар! Минем авыр хезмәт белән эшләгән акчам янды.

— Анысын аңлыйм. Фатирлык акчаны болай гына бирүе кызык, димәк, абыең да шулар даирәсеннән.

Мәхмүт туганының да карьерист-аферист икәнен белә. Ләкин ярдәм иткән кеше турында кыек-мыек сүз әйтергә генә теле әйләнми торды.

Мәхмүт тә үз дәрәҗәсендә елгырлыкка ия, аңарда да карьера ясаган туганнарыныкы шикелле сыйфатлар чагыла. Кемгәдер документларга кул куярга булышу дисеңме, фәлән-фәләнеч секретареның яисә тән сакчысының телефон номерын табып бирү дисеңме... Атабаев шофёрының үтенечләренә беркайчан да игътибарсыз калмый, аның юл кагыйдәләрен бозуга да, жай чыккан саен вак-төяк урлаштыруына да күз йома. Мәсәлән, Мәхмүт, аяк астыннан тимерчыбык сузып, спидометрны кызурак әйләндерә торган жайланма тоташтыра да бензин өчен бухгалтериядән артык акча ала. Моны күргәч Атабаев рәхәтләнеп көлде дә:

— Ну, малай, кайлардан уйлап чыгарасыз мондый нәрсәләрне! — дип кенә куйды.

— Кем ничек булдыра, шулай яши инде, — диде Мәхмүт, тирән сулыш алып. Тирән сулап куюы аның тормыш авырлыгыннан түгел, ә киресенчә, агымга эләгә белүеннән канәгатьләнү, үзенең булдыклылыгы өчен горурлык хисеннән иде.

Тирәнрәк уйлап баксаң, Атабаевларга һәм аларның кучерлары булып хезмәт итүче Мәхмүт ишеләргә тормышның авырлыгы жиңел яшәргә мөмкинлек бирә. Менә шундый парадокс.

Шуңа күрә, түрәләрдән, яшәешнең тискәре якларыннан чирканып сөйләшсә дә, асылда ул канәгать, ә зарлануы аның күбрәк тагы да рәхәтрәк яшисе килүдән иде.

Мәхмүт, эчкән чәйдән чак кына бүртебрәк киткән чыраен учы белән сыпырып куйгач, елмаеп дәвам итте:

— Чиновникларның талауларыннан, кысуларыннан, взяткалардан тәмам туйган бер эшмәкәр миңа әйтә: — Шәхсән үземнең ришвәтче булмаган

чиновникны очратканым юк әле, ди. Теләсә кайсы чиновникны сатып алырга мөмкин, ди. Моны мин ул әйтмәсә дә беләм.

Булат энем, бизнесменнарның, должностьтагы блатнойларның кесәсендә яки барсеткасында һәрвакыт берничә ясалма удостоверение йөри.

Берсендә хәтта «Служба безопасности президента» дип язылганы да бар – банкеттан соң исерек баштан мактанып күрсәтте. Властьның кайсырак даирәләрендә ясала икән андый таныклыклар, кемнәр ясап сата икән ул документларны – мин чамалыйм. Кайбер таныклыкны күргәч таң каласың – аның белән теләсә кая керергә мөмкин. Алар ярдәмендә сине бер генә «гаишник» та, бер генә полицейский да тоткарларга, тикшерергә җөрьәт итмәс. Бизнесменнарны аңларга була – аларга яшәргә, исән калырга, башлаган эшләрен дәвам иттерергә кирәк. Аларны адым саен талыйлар, шуңа күрә ясалма таныклыклар аларга саклану чарасы буларак кирәктер. Шунсы ачуны китерә – түрәләр инде бит болай да акчаларын кая куярга белмиләр, өстәвенә эштән соң да, үз машиналары була торып, служебный машина белән тегендә-монда чабалар. Шофёр эш сәгатеннән соң да «шеф»нең хатынын фитнес-клубка алып барырга, балаларын мәктәптән алып кайтырга тиеш; фәлән районнан тёщасын калага китерергә, хатынының двоюродный сеңлесен РКБга илтеп куярга тиеш, һәр атнаның азагында нәчәлникнең туган авылына кайтып банка-банка тозлы кыяр-помидор ташырга тиеш. Түрә йөрткән шофёрларны җыеп, барысын да сөйләтсәң, халык акылдан язар иде.

— Беркөнне телевизордан Татарстан түрәләренең еллык доходларын ишетеп-күреп таң калдым, — диде Булат. — Бер чиновникның еллык доходы йөз кырык миллион диделәр. Нигә икән аңа ул хәтле акча?

Мәхмүт якташының самимилегеннән көлеп җибәрде.

— Әле ул хисапка алынганы гына. — Налоговыйлар, башкалар белмәгәне күпмедер! Савалар илне. Товар житештереп түгел. Җир астының табигать байлыгы хисабына җируют. Ә менә аларның малайлары армиягә бармый, киресенчә, төрле юллар белән качалар. Бер чиновникның гына малае армиядә икәнне беләм мин. Анысын да гел атасы шалтыратып контрольдә тотып тора. Алар илне имәләр, ә үзләре шул илгә хезмәт итәргә теләмиләр.

— Ә мин барыбер армиягә барам, — диде Булат.

— Үзең беләсеңдер, — диде Мәхмүт кул селтәп.

Булат якташына сокланып карады. Гади генә авыл малае, югары белеме дә юк... Депутатны йөртә, киеме затлы... Акыллы сүзләр сөйли... Туганы фатир сатып алып биргән...

— Үзеңнең берәр нәчәлник буласың килмиме? – диде Булат. — Сине шефың, яисә туганың берәр институтка кертә аладыр.

— Дипломны укып тормыйча гына да сатып алырга мөмкин. Җитәкче булып эшли алмам мин, чөнки язуым хаталы. Мәктәптә дә көчкә укыдым. Кирәк түгел! Әллә җитәкчеләргә, чиновникларга рәхәт дисеңме син? Рәхәтлекне ничек, нәрсәдә тоярга өйрәнәсең бит... Чиновникларның кайвакыт мескенләнүләрен, өстә утыручылар алдында түбәнсенүләрен, тәлинкә тотуларын күрсәң син! Алар бит көн саен урын өчен калтырап яши. Аларның өстәгеләр белән телефоннан сөйләшүләрен ишетсәң... Элекке «шеф»ым бер тапкыр президент аппаратыннан кем беләндер сөйләшкәндә куркып астына җибәргән иде. Хәлләр бетте утыргычны чистартып. Ул бит затлы коньяк, кыйммәтле виски эчә, ә андый эчемлектән соң исне бетерүе ай-һай авыр, малай. Ацетон да алмый. Утыргычны алыштырырга туры килде. Дөресен әйткәндә, кайвакыт карап-карап йөрим дә, үзем дә берәр нәчәлник булып эшли алырмын шикелле тоела.

Илдәге гаделсезлек, коррупция, түрәләрнең, чиновникларның комсызлыгы,

вәхшилеге, фәхешлеге хакында тагын мисаллар китергәннән соң ул фатирлык акча бүләк иткән бай туганын да берникадәр тәнкыйтьләп алды.

— Ә беләсеңме, нишләп ул тәк-томалдан гына миңа фатир алырга ярдәм итте? Безнең Татарстанда, Башкортстанда туганнарыбызны санап бетерерлек түгел. Һәрберсенең машинасы бар. Җай чыккан саен гел Казанга кунакка киләләр. Күбесенчә мондагы бай туганнарыбызга килергә тырышалар инде алар. Менә бу туганым хәзер үзенә килгән һәрбер кунакны төн кунарга миңа җибәрә. Аның янына килгән һәрбер кеше хәзер бездә ята. Нык яратканнан ярдәм иткән дип уйласаң, ялгышасың. Минем фатир хәзер аңа килгән кунаклар өчен кунакханә ролен үти. Отказ бирә алмыйм, чөнки фатир аның акчасына алынган.

Депутатның хатыны турында да сүз чыкты. Роза (хатынның исеме шулай) турында сөйләгәндә Мәхмүтнең күзләре мутланды, тавышы эротик төсмер алды. Сүзаралаш Розаның чибәр икәнлеген кабатлый-кабатлый, Мәхмүт депутат гаиләсендәге хыянәтләр, скандаллар турында да берничә фикер әйтеп үтте.

— Гаяз Сираевич көнләшә, шуңа күрә мин аның янында Розага карарга да куркам, — диде Мәхмүт. — Шәп хатын ул. Читтә гулять итсә дә, күңеле якты бугай аның. Хәер, андый хатыннарның күңеле якты була инде аларның. Ә Атабаев үзе кеше түгел! Монда озак эшләмим мин.

Чыгып киткәндә ул Булатның авырткан җиренә басып тагын бер тапкыр:

— Ни калган сиңа ул армиядә?! — диде.

Ә Булат, депутатның тизрәк военкомат эшен җайга салуын көтеп, коттедж эчен нарат такталар белән каплавын дәвам итте.

## XVI

Дәүләт советының сессиясе тәмамлангач, Булат инде сөенгән иде. Менә Гаяз Сираевич шушы көннәрдә военкомат белән элемтәгә керер дә язгы призыв белән армиягә китү насыйп булыр дип уйлады ул. Коттедж эчендә дә эш тәмамланып килә, йокы бүлмәсен һәм холлны гына рейкалар белән бизисе калды.

Әмма икенче көнне Атабаев бик эшлекле кыяфәт белән коттеджга килеп, Булатның хезмәтенә күз салганнан соң, үзенең тиз генә командировкага барып кайтырга тиешлеген әйтте.

— Мин анда бер атнадан да озак булмам, борчылма, кайткач проблеманны хәл итәрмен, — диде депутат.

Булат:

— Берәр кешегезгә кушып калдырмыйсызмы соң военкоматка барырга, — дип карады.

— Юк, юк, әле мин кемне җибәрергә дә белмим. Кайткач, кайткач...

Сак эш итәргә кирәк. Нишләп депутат шөгыльләнә бу призывник эше белән дигән сораулары туачак, әллә нинди шик-шөбһәләре уяначак... Кайткач, җайлап-майлап кына... Как раз такталарны да кагып бетерәсең.

Ул көнне, кәефе кырылу сәбәпле, Булат ял итәргә булды. Мәхмүт ашарга алып килгәч, аңа бераз аракы эчәсе килүен әйтте. Мәхмүтнең дә, «шеф»ны командировкага озату хөрмәтеннән, тамак чылату теләге юк түгел иде.

— Машинаны шушында калдырып, такси белән кайтып китәрмен, — диде ул.

— Монда гына кунып калсаң да була, — диде Булат. — Кухняның идәне җылы, матраслар бар.

— Юк, юк, хатын башны ашаячак. Хәзер икебезгә бер яртыны сындырабыз да, такси чакырып кайтып китәм.

Депутатның суыткычында, шкафында спиртлы эчемлекләр күп иде. Якташлар рәхәтләнеп ашадылар, эчтеләр.

Мәхмүт исергәч ачыктан-ачык Атабаевның начар кеше икәнен әйтеп салды:

— Саран ул! Влачка ирешкән кешеләр барысы да саран булалар. Шул саран, комсыз булганга күрә влачка үрмәлиләр дә инде алар. Аның сине күбрәк эшләтәсе килә. Ул бит күрә — синең кулың алтын, тырышып эшлисең. Армиягә китәргә бәлки ярдәм итәр ул сиңа, но түлке башта сине ишәк урынына эшләтәчәк, менә күрерсең. Ник атлыгасың син ул армиягә?!

Төн уртасына кадәр шактый салып, тормыштан зарланып, шул ук вакытта тормышның рәхәт якларын да искә алып, түрәләрне, депутатларны сүккәннән соң, Мәхмүт такси белән кайтып китте. Булат телевизорны кабызып диванга ятты, әмма экрандагы чит ил киносы аны кызыксындырмады, ул үзенең уйларына бирелде.

Коттедж ишегалдына машина кереп туктаганны ишеткәч, ул башта Мәхмүт кире килде микән әллә дип уйлаган иде. Кырыклар тирәсендәге чибәр хатын килеп кергәч, ул аптырап китте.

— Мин Роза, — диде хатын, егетне башыннан аягына кадәр күз карашы белән «капшап». — Гаяз Сираевичның хатыны.

— Булат, — диде егет чак кына башын иеп.

Роза коттедж буйлап Булатның эшен күзәтеп чыкты.

— Симпатично, симпатично сделано, — диде ул егеткә текәлеп карап. — Мин мунча керергә килдем.

— Мунча эсседер әле ул, — диде Булат. — Мин көн уртасында яккан идем.

— Мин юынып чыгам, — диде хатын серле тавыш белән.

Ярты сәгатьтән Роза, чәчәкләр белән чуарланган халат киеп, башына саргылт тастымал урап мунчадан чыкты. Берничә минут ишегалдында күктәге йолдызларга карый-карый саф һава сулаганнан соң ул Булатны нык каушатып кухняда пәйда булды. Хатыннан килгән хуш исләр көчле дулкын булып бөркелеп егетне башыннан аягына кадәр коендырды.

— Чәй эчәсезме? — диде Булат.

— Юк, мин шампан шәрабе эчәм, — диде Роза һәм бардан бер шешә шампан шәрабен алды. — Син дә бар, юынып чык.

Булат кып-кызыл булды — миннән тир исе киләдер дип уйлады ул һәм сикереп торып мунчага йөгерде.

Аның юынып чыгуына Роза өстәлгә ризыклар турап, салатлар ясап куйган иде.

— Син нәрсә эчәсең? — дип сорады ул мунча эсселегенә караганда күбрәк каушап, оялып кызарган егеттән.

— Су, — диде Булат.

Роза көлеп җибәрде.

— Утыр. Оялма. Бераз ак аракы эч.

Роза бәллүр рюмкага аракы салып Булат алдына куйды, үзенең фужерына шәраб салды.

— Танышуыбыз хөрмәтенә, — диде хатын фужерын күтәреп.

Чәкештереп эчкәннән соң Роза егетнең күзләренә туры карап:

— Син армиягә барырга телисеңме? — диде.

— Әйе, — диде Булат, үзен ничек тотарга белмичә. Ул кинәт шешәне алып рюмкасына үзе аракы салды. Аннары беравык уйланып торганнан соң, Розаның фужерына шәраб агызды. — Әйдәгез, — диде ул тизрәк каушавын җиңәргә теләп.

Розага егетнең оялчанлыгы ошады.

— Нәрсә өчен эчәбез? — диде ул, фужерын тотып.

— Белмим, — диде Булат.

— Синең алтын кулларың өчен эчик, — диде тәҗрибәле хатын егетнең кыюлыгын уятыр өчен.

— Сез бик чибәр, — диде Булат хатынның җылы сүзенә җавап итеп.

— Чын әйтәсенме? — дип пышылдады хатын, чак кына иеленкерәп.

— Чын әйтәм.

— Син чынлап та армиягә китәргә хыялланасыңмы?

— Әйе.

— Син тилеме әллә?

— Юк, тиле түгел.

— Бар, диванга утыр, — дип пышылдады хатын.

Булат буйсынып диванга барып утырды.

Роза халатын салды. Каршында анадан-тума басып торган хатынны күреп, Булатның йөрәге бугаз төбенә таба күчеп кушаяклап тибә башлады. Кырык яшьтә булса да Розаның буй-сыны шәп иде. Шуңа күрә аз гына да читенсенмичә шәрәтән калды да инде ул. Роза белә — бер генә ир кеше дә аны ошатмый калмас, бер генә ир-егет тә аны кочагына алудан баш тартмас.

Роза өчен иренә хыянәт итү гадәти хәл булса, Булатның үзеннән егерме яшькә олырак хатын белән җенси мөнәсәбәткә керүе беренче тапкыр иде.

Менә бу столяр ичмаса, дип уйлады Роза.

Соңыннан Булат ана сокланып туймады — янында өлкән яшьтәге хатын түгел, яшәүнең ин рәхәт мизгелләрен бүләк итә торган илаһи зат ята иде.

Бераз ял иткәч, Роза егетне иреннәренең читеннән үбеп:

— Ты прелесть! — диде. — Әйдә, мунчага.

Мунчага кереп житкәнче үк Булатның янә дәрте уянды. Чибәрлеген, табигый сихерен һаман җуймаган хатынны тагын изәсе килде аның. Һәм мунча өйалдындагы диванда Роза икенче тапкыр балта остасының кочагында эреде.

Мунча өйалдындагы ыңгырашулардан, хатынның чинап, кычкырып куюларыннан тирә-яктагы этләр өрергә тотынды.

Юынганнан соң коттеджга кереп тамак чылаткач, Булат хатынны үзе күтәреп алып диванга яткырды. Егетнең кайнар иреннәре хатынның муеннарын өтеп алды. Роза оеп күзен йомды:

— Нәрсә калган сиңа армиядә? — дип пышылдады ул. — Ник анда барырга тырышасың син?

Булат җавап бирмәде, еш-еш сулап хатынны иреннәреннән, күзләреннән, чәчләреннән үпте.

— Барма армиягә, — дип ыңгырашты Роза.

— Егет кеше хезмәт итәргә тиеш, — диде егет, хатынның сәвит чорындагы биш тиен акча кадәр ими башларын үбеп.

— С ума сошёл, — диде хатын еламсырак тавыш белән. — Мне так хорошо никогда не было. Ты самый лучший. Ы-ы-ы-ы... Не ходи в армию... Ы-ы-ы...

Булат ир назына мәңге туймаган хатынны яшь егетләргә хас кайнарлык белән әвәләде, изде.

Бу юлысы алар юынып та тормадылар, кочаклашып йокыга талдылар.

Иртәнге якта Роза аны иреннәреннән үбеп уятты.

Булат күзен ачкач, Роза кичәге сүзләрен кабатлады:

— Китмә армиягә. Нигә кирәк сиңа служба?

— Мин армиядә хезмәт итеп кайтырга тиеш.

— Дурачок, ой, дурачок! Нигә сиңа армия? Син монда кирәк! Җүләр!

Булат хатынны кочагына алды.

Ничек диван чыдыйдыр мондый мәхәббәткә!

Шушы төндә Роза үзен унсигез яшьлек кыздай хис итте. Аның Булатны беркая җибәрәсе, үзенең дә мондый җылы, көчле кочактан беркая китәсе килмәде. Ләкин, нишлисең бит, шулай да Мәхмүт-мазар монда килеп кергәнче, китәргә кирәк иде.

Розаның машинасы борылыш артында юк булгач, Булат Мәхмүткә шалтыратты.

Мәхмүт ярты сәгатьтән килеп җитте һәм Булат аңа барысын да сөйләде.

— Бик яхшы булган, — диде Мәхмүт.

— Нәрсәсе яхшы инде?! Бер дә яхшы түгел. Мина моннан кичекмәстән китәргә кирәк.

— Ник куркасың? Аны шеф сизмәячәк тә.

— Ничектер, эч поша, үземнең монда бер минутка да каласым килми.

— Гаяз Сираевич кайтып военкомат юлын җайласын иде.

— Монда аның агач эше муеннан. Шуны эшләп бетермичә мина ярдәм итмәс ул.

— Мин сиңа баштук шулай дигән идем, — диде Мәхмүт.

— Үзем военкоматка саклык белән генә кереп карыйм әле. Барып чыкмаса авылга кайтып китәм. Мина берничә көн кунарга урын кирәк, — дип уйга калды Булат.

— Әйдә, бездә кунарсың. Минем өч бүлмәле фатир, урын табарбыз. Малай белән кыз берничә көн бер спальняда йоклап торырлар.

— Түлке минем кайда икәнне Гаяз Сираевичка әйтмәссең, яме.

— Ярар. Авылына кайтып киткәндер, диярмен.

Шулай итеп, Булат Атабаев ыстанын ташлап Мәхмүтләргә күчеп китте.

## XVII

Шул ук көнне кичкә таба депутат Атабаев Гаяз Сираевич Казанга кайтты. Алдан хәбәр бирмичә кайтуы хатынын берәрсе белән тотмаммы дигән уй-нияттән иде. Ул Казан үзәгендәге фатирына кайтып кергәндә хатыны, әле ятарга иртә булса да, йокыга талып, Каенсар авылының балта остасы Булатны төшендә күрә-күрә татлы саташу кичереп ята иде.

Хатынының өйдә булуын, аның үзе генә икәнен күреп, Атабаев тынычланды һәм Булатның кичә-бүген эшләгән эшен тикшерергә дип коттеджга китте.

Анда балта остасын тапмагач, телефоны җавап бирмәгәч, ул Мәхмүткә шалтыратты. Мүхмүт Булатның кайда икәнен белмим дип ялганлады.

Җомга көн иде. Үзенә ял ясарга уйлагандыр, берәр театрга, йә концертка киткәндер дип уйлады депутат.

Шимбә көнне дә Булат күренмәде, телефоны да һаман җавап бирмәде. Булатның коттеджда бер әйберсе дә юк икәнне күргәч, депутатның күнеле сизде — качкан ахрысы бу егет.

Атабаевның мондый оста эшчене тиз генә ычкындырасы килмәде. Ничек булса да табып аны кире монда китерергә кирәк дигән карарга килде ул.

Һәм якшәмбе көнне кичкә таба полициягә барып гариза язды.

Дүшәмбе көнне иртүк Мәхмүт белән Булат, иртәнге ашны ашап, стоянкага машинаны алырга киттеләр. Мәхмүт аны военкоматка илтеп куярга тиеш иде.

Стоянканың биек стенасына эленгән «Их разыскивает полиция» дигән такта турына җиткәч, Мәхмүт, фотоларга күз салып, кинәт туктады.

— Кара әле, Булат, син түгелме соң бу? — диде ул, җиде-сигез нурсыз чырай эленгән тактага якынрак килеп. — Син бит бу!

Булат үзен шундук таныды.

— «...Караклыкта гаепләнә...» — дип укыды ул фото астындагы язуны һәм телсез калды.

— Атабаевның бирәр нәрсәсен чәлдергәниең мәллә?

— Юк. Әллә белде микән?.. Хатынына үрелгәнгә ачу итеп язды микәнни?

— Белмим.

— Минем фотоны каян алды икән соң ул? Мин бит үзем белән бер сурәтемне дә алып килмәгәнием, монда да фотога төшкәнем булмады.

— Сине Атабаев төшергән, — диде Мәхмүт.

— Каян беләсең?

— Ул коттеджында эшләүчеләрнең барысын да яшертен генә фотога төшереп ала — на всякий случай.

Булат үзенең фотосын күреп бер шаккатты, астындагы караклыкта гаепләп язылган сүзләрне укып икенче кат тетрәнде. Ә инде үзенең фотосы белән янәшә N психоневрологик диспансерында бергә яткан Нәбинең шадра чыраен күргәч, ул уйлау сәләтен бер мәлгә бөтенләй җуеп торды.

Булат шундук Тәхлиягә шалтыратырга булды. Тәхлия аны игътибар белән тыңлады. Булат барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Урын-җир өстендәге җенси мөнәсәбәтләр хакында да, нечкәлекләренә кермичә генә, сихерчегә җиткерде ул.

Тәхлия игътибар белән тыңлагач, аңа: «Әгәр әйбер урламагансың икән, сразы полициягә бар», — диде.

Булат полиция бүлегенә барып үзенең сурәтен урамдагы тактада күрүен әйтте.

«Сез депутат Атабаевның коттеджыннан әйбер урлауда гаепләнәсез!» — диделәр аңа һәм тынчу камерага ябып куйдылар.

Камерага кереп күз ияләшкәч анда унбишләп кеше ятканы абайланды. Почмактагы шконкадан бик тә таныш тавыш ишетеде. Шул урында ярымтүгәрәк ясап биш-алты кеше җыелган, алар сөйләүчене йотлыгып тыңлыйлар иде.

Таныш тавыш тарихи вакыйганы бәян итә иде. Сүз Пугачёв восстаниесе хакында бара, Булат кергәндә Пугачёв гаскәрләре әле генә Җаек шәһәрен алганнар иде. Булат су мичкәсе янындагы буш шконкага урнашкан арада 1773 елның сентябре җитте һәм баш күтәрүчеләр ике мең биш йөзлек отряд белән Оренбург каласын камап алдылар. Аннары камерадагы җан ияләре 1773 елның декабрь аенда Пугачёвның инде утыз меңлек гаскәре, сиксән алты пушкасы булганын мәгълүм кылдылар. 1774 елның февралендә Пугачёвның Чиләбене алуына камерадашлар бигүк аптырамадылар, ә менә аның 1774 елның июлендә Казанны алуын ишеткәч, үзара быр-быр килеп гөжләп алган булдылар.

— Пугачёв милләте буенча татар булган, — дип дәвам итте сөйләүче. — Иманым камил, чөнки нәкъ шуңа охшаган вертухай эшли «четверка»да — ул чеп-чи татар, хәтта урысча да начар сөйләшә.

— Ә Пугачёвның төс-кыяфәтен син каян беләсең? — дип сорадылар «лектор»дан.

— Миңа вертухайның чыраен белү дә җиткән, — диде таныш тавыш. — Әшәке кешеләр минем өчен барысы да бертөсле.

— Пугачёв әшәке кеше булганмыни? — дигән сорауга сөйләүче:

— Җаек буеннан әйбәт кеше чыга алмый, — дип җавап бирде «лектор». — Беләсезме, Җаек казакларының абҗур командалары татар авылларына килеп ниләр кылганнарын?! Шуңа күрә мин Пугачёв восстаниесен яратмыйм. Асылда ул восстание милли хәрәкәт булганга гына мин аны кабул итәм. — Кристияннәрнең баш күтәрүе — урыс тарафыннан җәберләнгән милләтләрнең көрәше икәнне игълан иткәч, «лектор» су сорады. Аңа әлюмин кружка белән су китерделәр.

Булат, әлбәттә, Нәбине таныды. N диспансерында Әхәттән тарих фәнен отып калган Нәби камерадагыларны үзенең белеме белән инде таң калдырырга өлгергән иде.

Нәби белән Булат шул Пугачёв чорыннан ук таныш булган кешеләр сыман каты иттереп кочаклашып күрештеләр. Нәби шундук янәшәдәге шконкадан сугыша-сугыша мангае сыдырылып-җөйләнеп беткән бер үсмерне башка урынга күчереп, анда Булатны урнаштырды.

Алар бу очрашуга икесе дә куандылар, гәрчә камерада очрашу шатлыклы күренеш булмаса да.

Башта Булат үзенең тарихын сөйләде.

Нәбине егетнең күргән михнәтләре түгел, аның һаман армиягә атлыгуы нык гаҗәпкә калдырды, хәтта бераз ачуын китерде.

— Армиягә барырга теләп инде төрмәгә таба барасың түгелме! — диде ул.

Аннары Нәби үзенең ничек монда килеп эләгүен сөйләде.

— Румия исемле егерме биш яшьлек бер бай хатын Тәхлия апага бергә яши торган ирен көнләве, аны ничек ярату хакында сөйләргә килгән. Ә мин Тәхлия апага берәр бай, чибәр, яшь хатын килсә, мине шунын белән берәр ничек кавыштыр дигәниием. Румия үзенең киләчәген сорагач, Тәхлия апа тазга караган да, сиңа башка кеше кирәк, дигән. Гәҗиткә игълан бирергә кушкан һәм, тагын тазга күз салып, игълан буенча синең янына бик шәп ир-егет киләчәк — военный, дигән. Язмышын шуның белән бәйләнәчәк тә, гүрләргә кергәнче шуның белән бергә буласың, дигән. Румия игълан биргән, бу турыда Тәхлия апа үзе шалтыратып белешкән. Икенче көнне үк мин гарнизонный магазиннан «капитан второго ранга» формасын сатып алдым да сигез бәйләм каен себеркесе зурлыгындагы чәчәк букеты алып Румиянең адресы белән киттем. Кыяфәтемне күрсәң... Кием минем размердан ике размерга кечерәк иде, җиннәр, балаклар кыска. Кырык бишенче размер аяк киеме киям, ә гарнизонный магазинда иң зурысы кырык икенче иде. Нүжәли безнең капитаннар шундый бәләкәй халык икән?! Бардым. Таныштык. Үзем белән алып килгән шампанскийны ачтык, мин эчтем, ул эчмәде. Миннән сразы шикләнде ул. Кочаклый башлаган идем, этеп җибәрде. Үҗәтләнеп чишендермәкче идем, яңагыма чапты. Обидно. Капитан второго ранга башым белән... Мин гафу үтенгән булдым. Ул елап ванна бүлмәсенә кереп бикләнде. Мин бераз уйланып утырганнан соң, шкаф тартмаларын тиз генә актарып, андагы алтын чылбырны күреп, алып кесәмә тыктым. Ишек катыннан кычкырып саубуллаштым да чыгып киттем. Атна-ун көн узгач, бергә зонада утырган дустымны күрергә дип Казанга килгәниием, автовокзалда ук кулга алдылар. Ул алтын чылбыр Румия өчен бик кадерле нәрсә икән — сөйгән яры бүләк иткән булган. Гариза язган. Шампан шешәсендә минем бармак эзләре калган. Ә минем, төрмәдә утырган кеше булгач, бармак эзләрем полициядә саклана. Мин икәнне сразы белгәннәр, сукалар!

## XVIII

Атабаевка полициядән шалтыратып Булатны тотуларын шул көнне үк хәбәр иттеләр.

Кояш Казан каласының Киров районы артына батып маташкан вакытта депутат полиция бүлегенә кереп бара иде инде.

Депутатка Булатның паспортын, телефонын, алмаш-тилмәш трусигы белән ике пар носкиен, өстендәге кулмәген юганда киеп торыр өчен үзе белән йөрткән иске күлмәген тапшырдылар. Атабаев паспорт белән телефонны үзенең кесәсенә тыгып, калган милкен Булатка бирде һәм аны үз машинасына

утыртып коттеджына алып китте. Ул эш машинасы белән түгел, үзенеке белән килгән һәм үзе рульдә иде.

— Гафу ит, мин сине табар өчен караклыкта гаепләп гариза яздым, — диде ул юлга кузгалгач.

Булат тынгысыз халәттә депутат алга таба ни әйтәсен көтеп утырды.

— Мин сиңа армиягә китәргә ярдәм итәм. Эшне эшләп бетер инде.

— Армиягә барасым килми, — дигән булды. Булат, башын аска иеп. — Ял итәсем килә. Хәл алгач военкоматка барырмын.

— Мин сине аннары берәр санаторийга урнаштырырмын.

— Авылыма кайтып, кулыма балта тотып, әти белән эшләп онытыласым килә. Шуннан да рәхәтрәк ял булырга мөмкин түгел.

— Мин сиңа акчалата түләрмен.

— Булды, түләде инде хатының, — дип ычкындырды Булат, нишләптер бу минутларда депутатның шикләнүеннән, сизенүеннән курыкмыйча.

— Күпме бирде? — дип кызыксынды депутат хатыны акча түләгәндер дип уйлап.

— Житәрлек... — диде Булат һәм башын борып машина тәрәзәсе артында әлҗе-мелҗе килгән башкала күренешләрен игътибарсыз гына күзәтә башлады.

Хатынының, ана әйтмичә генә, эшче белән расчёт ясавына Атабаевның ачуы килде. Коттеджга кайткач, ул хатынына шалтыратты:

— Карале, Роза, син Булатка түләгәнсең икән... — диде ул, ачуын яшермичә.

Иренең тавыш төсмерен ишеткәч, Роза коелып инде. Сизенгән бугай дип уйлады ул.

— Син Булатка түләгәнсең икән! — дип кабатлап җикерде депутат. — Күпме бирдең син аңа?

Соңгы вакытта допрослардан, иренең көнләшүеннән туйган хатын сораунын мәгънәсен турыдан-туры аңлады, ягъни иренә Булат сөйләгәндер дип уйлады һәм шундук хәйлә белән үзен сакламакчы булды.

— Мин аңа бирмәдем... Мин аңа бирми идем... — диде хатын еламсырап. — Ул бит мине көчләде.

Депутат һушсыз калды.

— Нишләде? — диде ул, аңышмыйча.

— Көчләде ул мине! — дип акырып еларга тотынды телефон.

## XIX

Атабаев Гаяз Сираевич тавыш куптармаска булды. Оятка калу бик җиңел ул. Инде көнләшеп, гауга куптарып, казынып, төпченеп хатынны оялтырга тырышуда мәгънә юк.

Булат: «Көчләмәдем», — ди. Хатын: «Көчләде», — ди.

Депутат, Тәхлиягә шалтыратып, таздан карарга кушты. Тәхлия кешеләрнең катлаулы язмышларыннан яньчелеп беткән иске тазына хәтта карап та тормады:

— Юк, хатының үзе биргән, — диде. — Хатының гаепле. Егеткә тимә. Теге мин биргән үләннәрне хатыныңның ашына саласыңмы соң син?

— Соңгы атнада салмаганием, — диде Гаяз Сираевич, уфтанып.

— Так а что ты хочешь! — дип урысчага күчте никтер Тәхлия. — Кәнишне башкалар белән чуалыр.

Үләннәрне даими рәвештә салам дисә, Тәхлия аңа аларны янартырга кирәк дияр иде. Атна-ун көн салмадым дигәч, Тәхлиягә акланырга җайлы булды.

— Мин бит сиңа шундый шәп нәрсә бирдем, — диде ул шелтәле тавыш белән. — Тагын бирермен. Гел салып торырга кирәк. Раз инде хатының шундый икән.

Хатының б... булганга гаепне кешедән эзләмә инде син. Шундый күренекле башың белән кайчаннан бирле юньле хатын таба алмыйсың.

Дөрес сүзгә җавап юк. Депутат дәшмәде. Тәхлия, паузадан файдаланып, үзенең гозерен әйтте:

— Анда минем плимәннигем полициядә ята. Чыгар аны, зинһар.

— Ярар, чыгарырмын, — дип вәгъдә бирде депутат.

Атабаевка Тәхлия бик кирәк кеше. Иң авыр чакларда, бигрәк тә интим мәсьәләләр буенча, ул коллегаларына да түгел, җитәкчеләргә дә түгел, үзе салдырган мәчеттәге муллага да түгел, ә Тәхлиягә мөрәҗәгать итә. Аллага мөрәҗәгать иткәч ана күктән җавап ишетелми. Ә Тәхлиягә телефоннан шалтыратып була, һәр сорауга шундук җавап аласың, тынычландыра белә. Тиздән яна сайлаулар, ул вакытта да сихерче карчык кирәк — кем өстеннән компромат юнәтергә, кемнең нишләргә җыенуын белергә, кайсы кандидатның нинди проблемалары бар, кайсысының баласы наркоман, кайсысыныкы җинаятьче, кайсысында нинди чир бар, кемнең хатыны кем белән хыянәт итә — боларның барысын да Тәхлия белеп тора. Кайчандыр коммунист булган, дөньялар үзгәргәч авылында мәчет салдырган Атабаев Аллага үзенә кирәк чакта гына ышана иде. Алланың үзенә карата мөгамәләсендә аның уйлары икеле-микеле, чөнки аның белән күзгә-күз карап сөйләшергә мөмкинлек юк. Ә Тәхлия белән алай сөйләшергә мөмкин, хәтта аны тотып карарга да була.

Депутат белән саубуллашканнан соң, Тәхлия, тәрәзә яктысында урындыкка утырып, сөяккә җеп урарга тотынды.

Өйгә кемдер кергәнне сизгәч, ул утны кабызды. Бусагада болганчык суда чирканчык алырга җөрьәт итмәүче турист сыман шомраеп ир кеше басып тора иде.

— Исәнмесез! Мин Булатның әтисе Раиф булам, — диде ул.

— Исәнме. Утыр. Минем синең турыда бик күп ишеткәнем бар. Син тирә-якка даны таралган балта остасы.

— Булат соңгы көннәрдә шалтыратмый, — диде Раиф, карчык күрсәткән урындыкка утырып. — Ә без шалтыраткач җавап бирми.

Тәхлия, гадәттәгечә, таздагы сугап карап:

— Борчылма, — диде. — Малаең исән-сау. Ул армиягә китәчәк. Ләкин аның язмышын үз агымына куярга ярамый. Кул кушырып утырмагыз, улыгызның киләчәгенә йогынты ясарга тырышыгыз.

— Мин шәхсән нишләргә тиеш?

— Хәзер әйтәм, — диде карчык, тазына карап.

Раиф Тәхлия турында күптән белә, аның бөтен дөньяга танылган тазы турында да бик күп риваятьләр ишеткәне бар. Ул үрелеп тазга күз салды.

— Син тазыңдагы суны алыштырасыңмы соң? — диде ул, чыраен сытып.

— Ә ник аны алыштырасың? — дип җавап бирде сихерче. — Данлыклы столяр булганың өчен генә бу соравыңны гафу итәм.

Шулчакны Тәхлиянең телефоны зеңгелдәде: «... Девочкой своею ты меня назови, а потом обними, а потом обмани...»

— Алло! — диде карчык телефонын колагына куеп. — Исәнмесез, Земфира Зиннатовна! Соңгы вакытта ирегез кыйный? Ну, монда бер бик шәп чара бар. Исерек чагында, йокыга киткәч, чыраена чүпрәк ябасыз да балта түтәсе белән шакылдатып берне бирәсез. Кыйнамасын дисез бит. Алайса, мина килегез. Мин сезгә бер сыекча бирермен, ашына салырсыз. Парализовать итә. Кыйнамасын дисез бит. Бигрәк кызык кеше сез, Земфира Зиннатовна! Үлмәсен дә, парализованный да булмасын, кыйнамасын да. Көнче кеше кыйнаудан туктамаячак инде ул. Куллары йөрми торган итеп була, андый препаратым да

бар минем. Земфира Зиннатовна! Кыйнамасын дисез бит! — Тәхлия трубканы колагыннан алып яман әшәке итеп сүгенде. Аннары: — Ташлады телефонны, тавык баш! — диде. — Земфира Зиннатовна шәһәр хакимиятендә бүлек житәкчесе булып эшли. Ире — панельле йортлар төзү идарәсендә нәчәлник урынбасары. Нәрсәдә тукталдык әле без?

— Абруйлы столяр булганым өчен генә гафу итәсең таздагы су турында сораганымны.

Тәхлия тагын тазына карады да:

— Дүрт яшьлек чуртан балыгының кылчыгын арыслан ялының кылы белән урап кызыл чүпрәккә төреп мендәрең астына куй, — диде.

— Каян белим мин чуртанга ничә яшь икәнне! Арысланның ялын каян табыйм!

— Миндә әзере бар ул нәрсәнең. Нибары ике йөз илле сум.

— Кирәкми.

— Аңладым. Син хорафатчан түгел. Үзеңә кара. Ну барыбер мин сиңа булдыра алганча ярдәм итәчәкмен.

Тәхлиянең телефоны тагын жырлап жибәрде: «... Девочкой своею ты меня назови, а потом обними, а потом обмани...»

— Алло! Юк, кызың болай гына укырга керә алмаячак. Акчаны күп түләргә кирәк. Юк, булмый. Синең кызың шулхәтле тупой. Минем им-томнарымның бер файдасы да булмаячак. Ник үпкәлисең мина?.. Минем кызым түгел бит, синең кызың тупой. Кемгә күпме түләргә икәнне әйтә алам, анысы пажалысты. Тәмәке дә тартамыни кызың? Ничек ташлатыргамы?.. Бәреп үтерсәң, тартмаячак. Шаярам, шаярам. Анысы проблема түгел. Аның тәмәке тартуын ташлатып була. Кәжә бугын янгыр суы белән болгатасың да, тәмәке тартасы килгәч, ярты стакан эчерәсең. Шуннан соң көне буе тәмәке тарту түгел, яшисе килми йөриячәк. Сау бул! — Тәхлия, телефонын сүндергәч, Раифка аңлатты: — «Комфорт» дигән управляющая компаниянең директоры бу. Кызы тәртипсез, интегәләр. Үзе бандит булгач, баласы юньле булмас инде.

Тәхлиягә тагын шалтыраттылар. Тәхлия, телефонын колакка куйгач, мыскыллы тавыш белән:

— Ирең читкә йөри?! — диде. — Көнләшү бар инде ул... Син генә көнләшәсеңмени... Йөрмәсен дисәң, мине тыңла. Күгәрчен тәпиен элеп киптерәсең дә, машинасының задний мостындагы сапунны төбеннән үк борып алып, шундагы майга саласың. Боларны ничек эшлим дип?.. Кипкән күгәрчен тәпие бар миндә. Өч йөз сум. Задний мостка минем кешеләрем салырлар — ансы ике мең сум, чөнки опасно. Әй бу мәхәббәтләр, көнләшүләр... Кеше шунсыз яши алмый инде, күрәсең. Син беркайчан көнләшмә. Бүген син аны яратасың, иртәгә күралмавың мөмкин. Бүген сиңа рәхәт, иртәгә читен булуы ихтимал. Дөнья ул һәрвакыт бер алдын, бер артын күрсәтә. — Шушы сүзләр белән карчык телефонын сүндерде. — Шәһәр поликлиникасының баш бухгалтеры зарлана, ире гулять итә. Ире «горгаз»да нәчәлник булып эшли. — Тәхлия кофта кесәсеннән кулъяулык алып борынын сеңгерде. Аның борын сеңгерүеннән меңләгән кешенең үткәннәрен, бүгенгесен, киләчәген үзенә сыйдырган иске таз зыңгылдап куйды, ә эчендәге суы шактый вакыт дерелдәп торды. — Баш исән булсын, шулай бит, Раиф.

— Әлбәттә, — диде Раиф, баш исәнлеген хуплап.

Әңгәмәне янә телефон жыры бүлде: «...Девочкой своею ты меня назови, а потом обними, а потом обмани...»

— Алло! — диде сихерче трубкага. — Ярдәм итмәде? Алайса наркологияга алып барыгыз! Синең малаең наркоман булганга мин гаепле түгел! Төрле чак

була... Мәсәлән, беркөнне мин таздагы суга уксусны күбрәк салганмын. Ну, ул бит инде минем төп эшемә хилафлык китерә торган нәрсә түгел. Минем сыекчам ярдәм итмәгән икән, димәк, ул мин аңламый торган көчле наркотиклар куллана. – Тәхлия кинәт кызып китте. — Син миңа угрожать итмә! Мин синең ишеләрне үз гомеремдә күп күрдем. Юньле кеше булсаң, синең малаең наркоман булмас иде. Синең исполкомда эшләвеңә төкерәм мин! Миңа Казаннан, Уфадан, Нижгардан әллә кемнәр килә! Пошёл ты! – Тәхлия телефонын сүндерде. — Исполкомда эшли, имеш. Житәкчеләребезнең малайлары наркоман булганга да мине гаепләргә маташалар.

— Сиңа шул хәтле күп кеше ышана! – диде Раиф шаккатып.

— Алданасы килгәннәрне алдыйм мин, — диде Тәхлия ачыктан-ачык. — Кешеләрнең алданасы килә. Алар үзләре уйлап чыгара минем ишеләрне. Мин булмасам, башка берәүдән багучы ясарлар иде. Мин кешеләрнең хорафатчанлыгыннан файдаланып тамагымны туйдыручы гына.

Тагын телефон жырлап жибәрде: «...Девочкой своею ты меня назови, а потом обними, а потом обмани...»

— Алло! Мин сиңа әйттем бит – наркологиягә барыгыз! – дип кычкырды Тәхлия телефоннан. — Син миңа угрожать итмә! Башымнан бер чәч бөртеге генә төшсен, мин сиңа устрою птичий базар. Мәетеңне унбиш ел эзләячәкләр, козёл! Шалтыратма монда бүтән!

Тәхлия телефонын сүндергәч, Раиф гажәпләнеп:

— Син ничек алар белән курыкмыйча сөйләшәсең? – диде.

Тәхлиянең ярсуы кыяфәтенә чыкса да, шул ук вакытта аның беркемнән курыкмый торган зат икәне, эчендә беркем сындыра алмый торган умырткасы барлыгы күренеп тора иде.

— Мин аларның барысының да кыңгыр якларын беләм, — диде ул кинәт тынычланып. — Шуңа күрә мин аларның иманнарын кия алам. Ә син, Раиф, бер дә борчылма. Улың Атабаевта. Гаяз Татвоенкомат белән сөйләшә алмаса, башка берәр зур кешегә кушармын.

Раиф им-том, сихер-михер кәсебенә шикләнеп, хәтта бераз жирәнеп караса да, шул ук вакытта Тәхлиянең ихтирамга лаек кеше икәнен сизде. Тәхлия үзен хөрмәт иттерә белә торган кеше иде.

Раиф тагын ихластан гажәпләнүен, соклануын белдерде:

— Әллә нинди абруйлы кешеләр белән таныш син!

— Нинди абруйлы кешеләр белән?! – диде Тәхлия, көлемсерәп. — Мәсәлән, ул Атабаев абруйлымы?! Хатыны башкаларга биргәч, аны абруйлы дип буламы?! Ничек инде ул абруйлы кеше булсын, раз хатынын башкалар манчып йөри!

— Ярар, анысы аларның гаилә фажигасе инде ул.

— Раиф, бер дә борчылма, мин улыңны ташламам. Раз инде алай бик телисез икән, армиягә алдыртам мин аны. Минем шуның өчен сиңа бер үтенечем бар. Минем мунча түбәсе искерде. Ябып бирмәссеңме икән?

— Ябармын, — диде Раиф.

## XX

Атабаев Булатка паспортын, телефонын бирде дә, йөзенә туры карамыйча гына:

— Бар! Бүтән күземә күренмә! – диде.

Коттедж белән Казан арасын Булат рәхәтләнеп саф һава сулый-сулый, телефонындагы «непринятые вызовы» бүлегенә жыелган номерларга жавап бирә-бирә узды. Аның телефоны жавап бирелмәгән номерлар белән чуарланып беткән иде. Арада Нәбинең номерын да күреп, ул аңа шалтыратты. Нәбинең

азат ителүен белгәч, Булат бик сөенде. Кунар урын кирәклеген әйткәч, Нәби ана Ирек мәйданындагы Ленин һәйкәле янына килергә кушты.

Очрашкач, алар Хөкүмәт йорты янындагы кафетерийга кереп тамак ялгадылар.

— Бу кафетерий Хөкүмәт йорты янында гына югыйсә, нишләп мондый тәмсез ризык саталар соң монда? — диде Булат, кәкрәеп каткан тавык канатын кимереп.

— Монда Дом правительстводан беркемнең дә кереп караганы юктыр. Аларның ашказанына мондый ризык ярамый. Мин хәзер сине зонада бергә утырган дустым янына алып барам. Ул хәзер бик зур кеше. Сәүдә үзәгенең генераль директоры. Бәлки, военкоматта да берәр дусты бардыр. Миңа Казанда эш табармын дигәние ул. Казанда яшәргә телим.

Сәүдә үзәгенең генераль директоры Вафин Гата Каюмович бик эшлекле кыяфәтле булса да, зонада бергә утырган әшнәсен шактый җылы каршы алды. Аның ял итү бүлмәсендә секретарь кыз чәй әзерләде. Булат анламый торган жаргон телендә ике зонадаш башларыннан узганны искә төшереп көлешеп тә алдылар, караңгыланып та куйдылар. Директор, Нәбине һаман вак караклык белән шөгыльләнүе өчен битәрләп алганнан соң, төрле документлар белән тегендә-монда йөрү өчен курьер итеп эшкә алырмын диде. Җинел машинада шофёр кырыенда папка тотып утыруын күз алдына китереп, Нәби бик сөенде.

Нәби Булатның проблемасын да сөйләп бирде һәм аңа да ярдәм сорады.

Гата Каюмович:

— Туганыңмы әллә? — дигәч, Нәби:

— Юк, җүләрләр йортында бергә яттык, — диде.

Вафин соңгы ике елда гына да утыз дүрт кешенең малаена армиядән котылырга ярдәм иткән булган, шуңа күрә Булатның проблемасы белән военкоматка барудан баш тартты.

— Чакырмаганнар бит, ник йөрисең үзеңә бәла эзләп! — дип ачуланды ул Булатны. — Армиядә рәхәт дип беләсеңме әллә? Армиягә атлыга торган заманмыни?!

— Мин дә аңа әллә ничә тапкыр әйттем инде, — диде Нәби.

Гата Каюмович Булатка кер порошоклары саклана торган складта кунарга рөхсәт итте.

Курьер булып урнашыр алдыннан Нәби Nга кайтып килергә җыенды.

Булатның нык кайгыруын күреп, ул көтмәгәндә мондый тәкъдим ясады:

— Әйдә, мин хәрби комиссариатка барып сөйләшеп карыйм әле. Синең фамилияңне, адресыңны әйтмәм. Ерактан башлармын. N военкоматында бер егетне армиягә алмыйлар, диярмен. Армиягә бармаса, ул миңа минем шикелле булачак дип беләкләремдәге, аякларымдагы татуировкаларны күрсәтермен. Җилкәмне күрсәтсәм, алар бөтенләй һушсыз калачак. Ә N га иртәгә кайтып китәрмен.

Соныннан Нәби военкоматка ник барганына үкенде. Аңа бик усал бер хатын:

— Ул егет синең шикелле уголовниктыр, шуңа күрә алмыйлардыр армиягә! — диде. — Полициягә тапшырганчы ычкын моннан! Пошёл вон!

Нәби ачудан икенче көнне көтмичә шул ук көнне кич белән такси тотып Nга кайтып китте. Булат анардан, Тәхлия апага аннары кертеп бирермен дип, әҗәткә акча алып калды.

Булат Мәхмүткә шалтыратып алга таба нишлим икән дип киңәш сорыйсы итте. Мәхмүт исә аңа яман усал итеп җавап бирде:

— ... военкоматыңны!

Розаны тиешле дәрәҗәдә күзәтмәгәне һәм Булатның кочагына керергә юл куйганы өчен, уяулыгын юк дип, аны Атабаев эшеннән куган иде.

Булат Мәхмүт алдында үзен бик гаепле хис итте. Ул аны ничек тынычландырырга да белмәде.

— Гаяз Сираевич бераздан тынычланыр, аннары әйбәтләп сөйләшеп карарсың, — дигәч, Мәхмүт:

— ...Атабаевынны! — диде. — Эштән куылуым факт буларак кына борчый мине. Атабаевта мин үзем дә озак эшләргә җыенмый идем. Мине әле беркайчан эштән куганнары юк, гел үзем китә торганием. Шунсы аяныч!

Аккумуляторы утыру сәбәпле, телефон сүнде, шуның белән элемтә дә өзелде.

Булат Мәхмүткә инде бүтән беркайчан да шалтыратмады.

Склад идәнен җыештыручы Рәкыйга апа иске диванда йоклап яткан кешене күргәч башта котсыз калды. Швабра сабы белән төртеп уяткач, Булат үзенең кем икәнен әйтте. Апа идән юган арада армиягә китә алмавын да сөйләп бирде. Рәкыйга апа, швабрасын идәнгә ташлап, Булат янына диванга килеп утырды.

— Нишләп синең армиягә барасың килә? — диде ул шаккатып. — Минем малаемны алдылар. Коткарып булмады. — Апа еларга тотынды. — Күршеләрем акча түләп малайларын җибәрмәделәр. Минем андый акчам юк шул. Гади кешеләрнең улларын алалар шул армиягә. Хәллерәкләр коткаралар малайларын. Ул армиядәге хәлләрне ишеткәнем бар. Берүк исән-сау калсын инде балакаем, берүкләр исән-сау кайтсын, җаныкаем!

Әмма Булатның армиягә барырга теләвен дөньяның барлык идән юучылары җыелып хор белән елаган сурәттә дә сүндерерлек түгел иде. Төнлә аның башына бер уй килде — Рәкыйга апа вонкоматка барып сөйләшсә, бәлки аны армиягә алырлар? Аның малаен алганнар, улы хезмәт итә, димәк, ул сорагач, Булатның солдат булырга теләве ихластан икәненә ышанырга тиешләр.

Икенче көнне Булат Рәкыйга апага өч мең акча бирде, швабрасын алды һәм идәненне үзем юармын дип, хәрби комиссариатка барырга кушты.

Рәкыйга апа коридорда очраган кешеләрдән: «Армиягә китәргә теләүче кеше бар, кемгә мөрәҗәгать итим?» — дип сорагач, ана кайсы ишектән керергә кирәк икәнне күрсәттеләр.

Кечкенә тәрәзәдә урта яшьләрдәге хатынның пудралы чырае күренде.

Рәкыйга сүзне, никтер, үзенең улыннан башлады:

— Күптән түгел улым армиягә киткәние...

Шулай дию булды, тәрәзәнең капкачы шапылдап ябылды. Рәкыйга улы турында да әйтеп бетерергә өлгермәде, Булат хакында да бер сүз ката алмый калды. Тәрәзә артында утыручы хатын: «Бу апа малаемны армиядә җәберлиләр дип зарланырга килгәндер...» дип уйлады, шуңа күрә тыңлап та тормады.

Рәкыйга коридорга чыгып як-ягына карады. Ул кәгазьләр тотып коридор буйлап әкрен генә килүче ир кешегә мөрәҗәгать итте:

— Мин бер егетне армиягә алыгыз дип килдем.

— Үзеннең малаеңмы? — дип сорады военкомат хезмәткәре, туктамыйча гына.

Апа аңа ияреп:

— Юк, минеке хезмәт итә инде, — диде. — Монысы минеке түгел.

— Кем малае соң ул?

— N районыннан. Бик әйбәт егет.

— Әйбәт булгач ник аны армиягә олактырмакчы буласың?

Апаның мондый сорауларга җавап бирергә хәле юк иде. Монда аны тыңларга да, аңларга да теләүче юк икәнне сизде ул.

Военкомат хезмәткәре исә: «Бу апа, үзенең малае хезмәт иткәч, башкалар да хезмәт итсен дигән ачу белән, армиягә китмәгән малайны җибәрергә тели, — дип уйлады. — Берәр дошманының малаедыр бәлки...»

Рәкыйга, туктап, коридорда калды, хезмәткәр ишекләрнең берсен ачып күздән югалды.

## XXI

Булат гәҗит-журналлар нәшриятына барып карады. Кайсы редакциягә керсә дә, анын теләген сәерсенеп, шикләнеп, көлеп, хәтта бераз куркып кабул иттеләр. Һәрбер редакциядә кемнен дә булса улы, туганының улы, дустының улы, йә ришвәт биреп, йә ялган справкалар ясатып армиягә алудан качкан иде. Шуда күрә Булатнын бу проблемасы турында беркемнең мәкалә язарга теләге булмады.

Татар телендә чыга торган «зур» гәҗитнең баш мөхәррире үзенең шәүләсеннән дә куркып йөрүче кеше иде.

— Сина бәлки армиядән качып йөрүче булып кыланырга кирәктер, — диде күптән түгел энесенең малаен армия хезмәтеннән йолып калыр өчен РКБдагы дус табибы аша «не годен» дигән бәяләмә юнәткән баш мөхәррир.

— Ничек инде мин армиядән качып йөрүче булып кылана алыйм?! — диде Булат.

— Шул чагында үзләре сине җәһәннәм тишегеннән эзләп табачаклар.

— Төрмәгә утыртып куйсалар? — диде Булат.

— Төрмәдә безнең армиягә караганда читенрәк дип уйлысыңмы? — диде баш мөхәррир. — Син тып-тын гына авылыңда яшәп ят. Үзенә үзең кайгы эзләп, кычытмаган җиреңне кашып йөрмә.

Булат кер юу порошоклары арасында бик озак уйланып ятканнан соң, үзе хәрби комиссариатка шалтыратырга булды. Үзенең хәлен анлаткач, тегендә шалтырат, фәлән-фәләнечкә мөрәҗәгать ит дип, аны бер-бер артлы җиде-сигез номерны җыярга мәҗбүр иттеләр.

Ниһаять, көр тавышлы ир кеше, моны тыңлагач:

— Повесткалар килгән булгандыр бит сина? — диде.

— Килмәде! — диде Булат җан ачысы белән.

— Этого не может быть! — дип җикерде көр тавышлы кеше, урыс теленең авыл татарына тәэсире каты икәнне белеп. — Ты отлынивал от армии!!!

Булат телефонын сүндерде.

Ул әкрен генә Казан урамы буйлап атлады.

«Нишләп болай соң бу? — дигән сорау чыңлады анын башында. — Мин тормышны, илдәге хәлләрне белмим, анламыйм микәнни? Атам-анам, туган җирем, сенлем, сөйгән кызым, урман-болыннар, елгалар-күлләр, нарат исле такталар — менә шул безнең ил, безнең яшәеш дип йөргәнмен. Тормыш катлаулырак һәм башкачарак икән бит. Һәркем үзен генә кайгырта, үз кесәсе, үз бүксәсе турында уйлый барысы да. Ә уртак нәрсәбез бар соң? Безне нәрсә берләштереп тота? Байлык, мал артыннан чабудагы бәйләнешләрме? Минем солдат булырга теләвемнән барысы да көлә. Минем илгә хезмәт итүемә барысы да аптырый. Барысы да мине җүләр ди. Бигрәк сәер бит. Мин, атам-анам, сенлем, сөйгән ярым — шушы ил кешеләреме? Мин анламый торган һәм мине анламаучы психиатрлар, полиция, прокуратура хезмәткәрләре, депутатлар — без яши торган ил кешеләреме? Бәлки алар балда-майда йөзгән иксез-чиксез илгә хезмәт итү чынлап та зур мәртәбә түгелдер?.. Бәлки мин, киресенчә, үземнең «кечкенә» һәм бөек Ватанымны шушы кешеләрдән сакларга тиешмендер? Куркыныч

уйлар килә, куркыныч! Барыбер мин солдат булырга тиеш! Үзем өчен, атам өчен, авылдашларым өчен! Солдатта булдыңмы? — дип сорасалар, «Әлбәттә!» — дип җавап бирергә язсын!»

## XXII

Ходай ишетте Булатның теләген.

N каласындагы военкоматта кискен үзгәрешләр булды. Кайсыдыр призывникның ата-анасы куптарган җәнҗал район военкоматының астын өскә китерде. Анда яңа җитәкче килгәч, төрле вакытта югалган документлар, кәгазьләр табылды. Бәлки, табылмаган да булыр иде, әмма район военкоматын игътибар үзәгенә куйдылар.

Булатка, язгы призывка чакырып, повестка килде.

Балтасын бүрәнәгә чабып куеп, ул сөенә-сөенә район үзә генә юл тотты.

Военкоматтагы яңа кешеләр аңа:

— Егерме бер яшенә җиткәненне көтмичә үзең килергә идең, — дип чак кына шелтә белдерделәр.

Булат акланырга теләмәде. Ул, йә тагын дөрес аңламаслар дип куркып, армиягә китәр өчен нинди михнәтләр күргәнен сөйләмәде һәм басып торган урыныннан кымшанмыйча бары тик торымнан торымга күндәм тавыш белән:

— Гафу итегез, — дип кат-кат кабатлады.

Әллә ниләр әйтсеннәр, теләсә ничек битәрләсеннәр, армиягә генә алсыннар!

Сау-сәламәт, физик яктан нык булганга, Булатны десант гаскәренә алдылар.

...Йөз егерме солдат йоклап яткан казарманы җан өзгеч тавыш дер селкетте:

— Рота, подъем!

Төнлә килгән яңа солдатка отделение командиры сержант Тарасов йокыдан айнымаган чыраен җыерып озак карап торды.

— Фамилия? — диде ул, ниһаять.

— Хасанов.

— Туган елың?

— 1992.

— Нишләп өч елга соңга калып алдылар?

— Мине бөтенләй алырга теләмәгәннәр иде әле. Армиягә алыгыз дип ялынып йөри-йөри чак кына акылдан язмадым.

Сәер солдат килде дигән хәбәр бөтен ротага минуты белән таралды.

Иртәнге аштан соң, аны, чолгап алып, армиягә ничек китә алмый җәфа чиккәнен, повестка килгәч ничек сөенүен сөйләттеләр һәм тыңлаганнан соң аңа бертавыштан диярлек:

— Җүләр! — диделәр.



Салават
Рәхмәтулла

## УТЫРЫП УЙЛАНЫР ЧАК...

### Солтанморат

Их! Юлларның юктыр якыннары[1],
Авылыма илткән юл сыман:
Ашкынулар —
Һаман «ул чактагы»,
Сагынулар —
Һаман «шул» сыман!

Солтанморат! Яшьлек илләремнән
Син тагын да мине бер урат,
Хыялларда урат:
Солтанморат,
Үзем кайтыр идем —
Бик ерак...

Хыялларда урат
Төннәрендә
Ин чибәре белән кызынның:
Гармун сузсам —
Тәрәзәдән чыгар,
күлмәгенең киеп кызылын...

Кулъяулыгын — Галиябану сыман! —
Бүләк итәр мина — «Хәлил»гә...
Исмәгыйль дә булса —
Атар иде!..
...Башкалары килә хәтергә.

Төнге...
Тангы тәрәзәләренә
Кемнәр генә тагын килмәгән?!. —

[1] Якын – бу очракта, кадерле, үз.

Салават РӘХМӘТУЛЛА (1942) – *Башкортстанда яшәүче татар шагыйре, татар һәм башкорт телләрендә дөнья күргән бернечә китап авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.*

Галиябану өчен Хәлил — үлгән,
Мин...
Яшимен әле — үлмәгән...

Хәлил булмасам да,
Миңа (миңа!) — Галиябану —
Һаман «ул» сыман!..
...Эх, юлларның юктыр ераклары,
Сөйгәннәргә илткән юл сыман...

## Дуслык турында

...Бигрәк дус без табыннарда
Бәхетләр теләшкәндә.
Тик... калҗалар «җитми» безгә
Калҗалар өләшкәндә.

Борын-борыннардан килә
Дусны санлау йоласы.
Ник әле? Ник әле безгә
«Һәм башкалар» буласы?!

«Без — дуслар!» диюләр генә
Дуслыкка нигез түгел:
Ә ник «милли мәсьәлә»дә
Хокуклар тигез түгел?!.

Әллә ниләр чыгар сыман,
Төрттереп «кызып» кара,
Намус саклау чиген дә бит
Сабырлык узып бара...

Дуслык билгеләнми фәкать
«Дежурный тост»лар белән.
Корьән дә куша дусларча
Яшәргә дуслар белән!

«Дуслар» дип, күзләр кысышмыйк,
Тамаклар кырып-кырып:
Кирәкми дуслык, үзара
Тигезлек булмый торып!..

## Колын

*Балачак дустыма*

...Кешнәп — авыл яңгыратты,
Тузан туздырып чапты:
Әнкәсеннән торып калган —
Исеннән барып тапты.

Басуда икән әнкәсе,
Салам җыялар икән:
Зур-зур күбәләрне тартып,
Эскерт куялар икән...

...Иркәләнергә дә була,
Әнкәй ял иткән чакта:
«Үс, улым!» — дип яши ана,
«Үс, колын!» — дидер ат та...

Зур булсак, тартышыр идек —
Йөкләре авыр бугай...
...Балачак: әтиләр — яуда,
Хәбәрләре дә юк, әй...

***

*Мондый илне нинди ният белән*
*Бар иткәннәр, шайтан алгыры!..*
З.Мансуров

«Илмени бу?!.
«Ил» дигән сүз сиңа
Исем өчен генә тагылган», —
Шушы фикер әллә кайчаннардан
Күңелемә минем ягылган.

«Илмени — бу?!.
Илләр — болаймыни?!.
Илләр — башка (белдек сон(ы)рак...):
Патшалары — патша! Башкалары —
Алары да! — адәм сынлырак...»

«Илмени — бу?!.» — Шушы көфер фикер
Ничә еллар чыкмый күңелдән...
...Гомер буе шушы илдә яшим:
Һич китәсем килми бу илдән...

***

Сату-сатылу заманы!
...Яшәешкә күз салчы:
Шагыйрь — акыл көчен сата,
Аяк көчен — футболчы...

Шагыйрьне кемнәр таныр соң?!
Футболчыны — мир таныр! —
Шагыйрь — һаман да хәерче,
Футболчы — миллионер!..

## Думада

...Еллар — Думада эш кайный
(Тагын кайда кайнасын?!):
Дума кадәр дума булгач,
Эшләр — мөһим: аңла син.

Иң мөһимнәрдән мөһиме —
Халыкка арт бормаска:
Аңа... хәмер каптырмаска!
Тәмәке тарттырмаска!..

***

«Җир шарының алтыдан бер
Өлеше» идек берчак!
«Сигездән бер»гә калдык бит:
Моңланыр-сызланыр чак...

«Әллә ничәдән бер»гә дә
Калырбыз сыман берчак:
Ятып елар чак житкәнче,
утырып уйланыр чак...

***

Чит дөньялардан киләләр
Яңа «күк җисемнәре»:
«НЛО», дибез,
Аларның
Ничек чын исемнәре?

Белмибез һәм,
Һәм белә дә
Алмабызмы икән без?
Без аларга — кеше микән?
Һаман... маймыл микән без?!.

***

*Бер күземне бирәм күзсезгә:*
*Бер күз җитә миңа — юньсезгә...*
Г.Латыйп

Бер кулымны мин кулсызга бирәм,
Булыр сынар аяк белән дә:
Бер аякны аяксызга бирәм —
Йөреп булыр таяк белән дә.

Бер күз, бер кул һәм бер аяк белән
Яшәү авыр булыр — яшермим.
...Башым — бирәү! Башсыз нишләрмен мин? —
Беркемгә дә шуңа баш бирмим!

***

«...Эш хакларын арттырабыз!..»
«Пенсия арттырабыз!..» —
Ә ... сумалар кулга кергәч,
Аптыраплар торабыз.

«Арттырулары» — һаман шул
Балыкчы ялганнары:
Эләккәннәр — ыбыр-чыбыр,
Зур — төшеп калганнары...

***

...Авылдан мин:
Һаман салам
Урлыйсы килә — кайтып.
Рестораннарга керсәм дә,
Ашыйсым килә... катык!..



Фәтхулла
Абдуллин

# ЧҮЛ БҮРЕСЕ

БӘЯН

Сиксән биш яшен тутырып килгән Хисами карт, әбәт вакыты житкәнне чамалап, көч-хәл белән картлар йортының баскыч култыксаларына тотынып менеп килә иде, якташы Мәрзияне очратты. Карчык, исәнләшергә дә онытып, аңа шатлыклы хәбәр житкерде.

— Хисаметдин абзый, сөенче! Ике көннән оныгың Алмазның туе! Чакырмый калмаслар. Әзерләнеп тор! – диде. Үзенең балалары булмаса да, карчык юк-юк та Казлы Куакка кайтып, чыбык очы туганнарында кунак булып килә. Авыл хәлләрен ул белә дә белә инде.

Аның сүзләре дөнья белән алыш-бирешне өзеп барган картның күңелен алгысытып жибәрде, тоныкланып барган күзләрендә өмет чаткылары кабынды. Карт, үз колакларына үзе ышанмагандай, телгә килде:

— Ә? Ни диден? Чынмы?

— Чын, Хисаметдин абзый, чын! Алдасам, ике күзем чәчрәп чыксын менә!

«Теленә тилчә чыккыры!» дип куйды карт күңеленнән генә. Яшь чакта да шулай усал, телчән иде. Тешләре төшеп беткән, һаман шул «пычак тел Мәрзия» булып калган. Юк, ул аңа тамчы да үпкәләмәде. Сөлектәй кызларга насыйп ярларның яу кырында ятып калулары аркасында сазаган кыз булып гомер кичергән карчыкка ничек үпкәлисең инде?! Киресенчә, ул аңа рәхмәтләр генә укыды. «Һе, әзерләнеп тор!» диме? Әллә соң... Әллә... Ул бөгәрләнеп беткән чалбарын, сидрәгән күлмәген үтүкләтте, сакал-мыегын тәртипкә китерде. Карчыкның тешсез авызын мимылдатып әйткән сүзләре аны шулай канатландырган иде. Балаларының өчәү икәнен белә Хисами, ә оныклары ничәү икән? Белми. Теге чакта сорый алмый калды шул. Күрәсе иде шуларны бер генә мәртәбә булса да, күрәсе иде. Кемгә охшаганнар икән? Кайда эшлиләр микән? Ходаем, картайган көнемдә мине бу бәхеттән мәхрүм итмәсәң иде. Ул малай чакта әнисе өйрәткән догаларны исенә төшерергә тырышып карады. Әмма, чуала башлаган хәтер аларны бер жепкә тезәргә ирек бирмәде. Алай да ул үзенең баш кода булып түр башында утыруын, аңа кадер-хөрмәт күрсәтүләрен күз алдына китереп татлы уйларга чумды. Ә бәлки әле кунаклар гына түгел, Гөлмәрьям дә, балалар да жылы сүз әйтер?.. Юк, монда – картлар йортында да рәнжетмиләр анысы. Вакытында ашаталар, вакытында урын-жирне алыштыралар. Баш очында радио сөйләп тора. Теләсәң, телевизор

карый аласын. Тагын ни кирәк? Ә шулай да бу гына аз, бик аз... Барыбер дә нидер житми адәм баласына...

Хатын-кыз ул ничек тә бирешми: үзенә шөгыль таба. Кайсысы китап укый, кайсысы яшьлек мәхәббәтен сагынып, үзе «шагыйрь»гә әйләнә. Янсә, кырыкмаса кырык төрле сәбәп табып, жылы өеннән куып чыгарган миһербансыз баласының баласына жылы оекбашлар бәйли.

Ничек вакыт үткәрергә белми, тегендә барып, монда сугылып йөргән ялгыз картларның хәле авыр. Аларның күз карашында ук тел белән генә әйтеп-аңлатып булмый торган монсулык... жирсү... үкенеч... ләгънәт... каргыш... тагын әллә ниләр бар...

Көткән кешегә минуты ай, сәгате ел... Хисами картка ике көн ике ел сыман тоелды. Кулыннан килсә, жир шарын зыр-зыр әйләндереп ике тәүлекне ике минут эчендә үткәреп жибәрер иде дә бит. Андый кодрәткә кем ия булсын? Беләсе иде аны алырга нинди машина жибәрерләр икән? «Жигули»-фәлән генәме, әллә тагын да кәттәрәген, «Джип» дигәненме? (Аларның хәлле тормышларын карт үз күзләре белән күрде. Ихаталарында тагын әллә нинди, ул белмәгән берничә жинел машина бар. Хәтта — нигә саклый торганнардыр — бер почмакка поскан «Запорожец» та аның күзенә чалынган иде). Һи-и, «Джип» дигәне дә булса! Аның чит ил машинасына утырып чыгып китүен күреп, үзе шикелле ялгыз картлар көнләшеп, күзләрен яндырып озатып калырлар инде. Көнләшәләр икән, көнләшсеннәр әйдә. Ана карап кына Хисаметдиннең мыек очы да селкенмәс. Күрсеннәр иде әле алар «Беженец бабай»ның кем икәнен! Юкса, кайбер әче телләләре ана Хисаметдин бабай дип түгел, ә «Беженец бабай», янсә «Үзбәк бабай» (Үзбәкстаннан кайткан ич) дип кенә эндәшкән булалар. Әйтерсең, аның ата-анасы кушкан исеме юк.

Менә, ниһаять, Хисами картның тыны белән суырып алырдай булып көткән көне килеп житте. Ул үткән төнне әллә йоклады, әллә... кичтән әз генә черем итеп алыйм дип яткан иде. Булмады. Башында кайнаган каршылыклы хисләр өермәсе ана тынгылык бирмәде. Ул үзен давыл вакытында диңгез дулкыннары арасында калган каек хәлендә хис итте. Икеләнү... шикләнү... күңеленең кайсыдыр почмагыннан ымсындырып баш калкыткан өметләнү белән тулы уйлар өермәсе аны бер ярдан икенче ярга чөйде. Ул керфек тә какмый таң аттырды. Хисами картның ничек кенә булса да... Һич югы бер генә сәгатькә булса да туйда буласы, кадерле кунак булып түр башында утырасы, балаларының, оныкларының бәхетле елмайган йөзләрен күрәсе килә иде. Туйдагы гармун тавышлары, шатлыклы авазлар, туганнарның бер-берсенә ихлас күңелдән әйткән жылы сүзләре, изге теләкләре, яшьләрнең юктан гына да чыркылдап көлеп жибәрүләре бәлки әле Гөлмәрьямнең дә боз булып каткан бәгырен жебетер, күңелендә тамчы каләре генә булса да миһербан уятыр... Һич югы, бер-ике генә авыз булса да жылы сүз әйтер? Юк, Гөлмәрьям аны башта эт итеп сугәр...

— И-их, Хисаметдин, Хисаметдин, яшь чакта ничек әтәчләнеп йөргән идең. Ә хәзер, күр әнә, ничек йоны йолкынган өтек бер йолкышка әйләнгәнсең, — дияр. — Сабыйларыңны ятим итеп рәхәт күрдеңме? Яшь хатын белән яшәп бәхетле булдыңмы? — дияр. Катырак әйтсә дә, Хисами үпкәләмәс иде. Шуннан соң гына ул аның күз яшьләре белән мөлдерәмә тулган карашыннан йомшарып. — Картайган көнеңдә йөрмә болай дуадак каз шикелле ялгызың каңгырып. Үзебездә генә кал, — дисә, Хисаметдиннең башы күккә тияр иде. Аның өчен ул көн күк капусы ачылган көнгә тиң булыр иде. Әйе, булыр иде... иде дә бит...

Ни үкенеч, арада хыянәт... ятимлек... мохтажлык... күз яшьләре... моң-зар белән тулы еллар (айлар гына түгел!)... еллар ята. И-их, заяга үткән гомерне кире кайтарып булса икән. Юк шул, юк! Башыңны ташка бәрә-бәрә ялварсаң да, файдасыз.

Үткән гомер кире кайтмый
Сулар үргә акса да,

– дип жырлыйлар шул. Юк, Хисаминың заяга үткән гомерне түгел, ә Гөлмәрьям белән бергә яшәгән елларны кайтарасы килә. Шул еллар чылбырын өзелгән жиреннән ялгап дәвам итәсе килә. Ни дисәң дә, тугыз ел бергә яшәделәр ич. Йорт-кура житкерделәр. Балалары булды. Ә-әй, ул яшь чаклар... Дуамал чаклар... Картаймыш көнендә искә төшерүе дә авыр...

***

... Сугышка 1944 елның ахырында гына китсә дә, күкрәгеn орден-медальләр белән бизәп 1948 елның жәендә туган нигезенә исән-сау кайтып ирешкән Хисами кич клубка килеп кергәч, яшьләр «ah!» иткән иде. Өрлектәй ир-егетләр яу кырында ятып калган еллар... Егетләрнең «дефицит», алтын бәясенә торган чагы. Хисами авылның кайсы гына чибәренә күз кысса да, жавапсыз калмас иде. Гүәрдин кебек егеткә кияүгә чыгарга бишкуллап риза булырлар иде. Ә аның күзе күбәләктәй әле тегендә, әле монда очынып йөрүче, унжиде яше тулып килгән Гөлмәрьямгә төбәлгән иде. Тик дөнья син уйлаганча гына түгәрәк түгел шул. Аның шау чәчәктә утырган болыннары, челтерәп аккан чишмәләре генә түгел, кыялы таулары, чытырманлы урманнары, ярсып аккан ташкын сулы дәрьялары да бар. Хисами никадәр генә тасма телләнеп караса да, Гөлмәрьям аны якын жибәрмәде, якты чырай күрсәтмәде. Ә Хисами аның саен үжәтләнде. Кич клубта парлы уеннар башландымы, күзләрен мут уйнатып, аңа чат ябыша. Киләшчә сыман куллары белән эләктереп ала да, әрсезләнеп кочаклый башлый, йоклап торсаң, «ә» дигәнче гәүдәсенә сылап та куя. Оялмый да, әле ихахайлап көлгән була. Ә үзеннән тәмәке исе аңкып тора. Әйтерсең, ул биш ел хезмәт итеп түгел, биш ел тәмәке фабрикасында эшләп кайткан. Тәмәке исенә аракы, йә әче бал исе дә өстәлсә, тач «сасы көзән»гә әйләнә. Янында озаграк басып торсаң, сасы ис киемгә сеңә. Тәмәке исен өнәми Гөлмәрьям. Әйтә торгач, Мәгъфуржанны тәмәкедән биздергән иде. Әтисе дә фронтка киткәнче тәмәке тартмады. Сугыш мәхшәрендә нишләгәндер, Гөлмәрьям анысын белми. Ә менә үле хәбәре килгәнен яхшы хәтерли. Дүртенче сыйныфта укучы Гөлмәрьям дә ул хәбәрне авыр кичерде. Шулай да йортка кара кайгы китергән ул шомлы хәбәрне әнисеннән дә авыр кичергән кеше дөньяда булмагандыр. Ул көнне әнисенең йорт эшләренә кулы ятмады. Өйгә бер керде, бер чыкты. Каралты-кура тирәсендә ангы-минге килеп буталып йөрде, нидер эшләмәкче булып сарайдан сәнәк алып чыга да, бераз уйланып торганнан соң, кабат сарайга кереп көрәк күтәреп чыга. Аны кулында әйләндерә-әйләндерә карый, нәрсәсендер ошатмый кабат сарайга кереп китә. Ул көнне кичке савымны да, елый-елый, дүртенче сыйныфта укучы Гөлмәрьям сауды. Әнисе икенче, өченче көнне дә шул халәтеннән айный алмады. Атна-ун көн үтмәгәндер, ахыр чиктә аны паралич сукты: урын өстенә калды. Кавырсыны да катмаган Гөлмәрьям менә ничә ел инде ялгызы хужалыкны тартып бара: мал-туар карый, әнисен тәрбияли...

Ә Хисаминың үз туксаны туксан. Өзми дә куймый, күргән саен аңа бәйләнә. Гөлмәрьям ничәнче тапкыр инде:

— Хисами абый, минем егетем бар. Яренгә кайта. Сиңа миннән башка да авылда кызлар житәрлек, – дип карады. Юк кына бит...

— Ә кайтмаса? Яренгә вдруг сугыш чыкса, нишләрсең? Тагын биш ел көтәрсеңме?

— Сугыш бетте инде, Хисами абый. Безнекеләр Гитлерны дөмектереп кайттылар.

— Без дә шулай уйлаган идек тә бит, көзгә японнар белән сугыш башланды.

— Аларны да җиңделәр бит.

— Һе, а вдруг Кытай безгә каршы сугыш башласа? Хисами Гөлмәрьямнең ни әйтергә белми торганын күреп дәртләнеп китте. — Һе, Кытай башласамы? Теге ничек әле, җыры да бар түгелме соң? —Хисами кайчандыр ишеткән такмагын, бутала-бутала булса да, ерып чыкты:

Кытай, диләр, Кытай, диләр,
Кытай кузгала, диләр.
Кытай кузгалган чагында,
Кызлар да калмый, диләр.

Һәм ул, күрденме абзанны, дигән кыяфәттә кулындагы чыбыгы белән чажлатып хром итегенең кунычына сугып алды.

— Менә шулай ул кысык күзләргә ышансаң. Ул чагында синең Мәгъфүрҗаның әллә кайта, әллә юк!

Гөлмәрьямнең йөрәген нидер чәнчеп алгандай булды. Ул, ихтыярсыздан ыңгырашып, сулкылдап куйды.

— Тәүбә диген, Хисами абый. Андый сүзне авызыңнан җил алсын.

Авылда шулай бит инде. Төнлә басу капкасы шыгырдап куйса да, иртәнгә мәгълүм була. Хисаминың кыланышын күреп торган авылдашлары, туган-тумачалары аны айнытырга, дәртен сүндерергә тырышып карадылар.

— Энем, өйләнү — ата-баба йоласы. Бик хуп! Тик, син, Гөлмәрьямгә кагылма инде, яме. Аның вәгъдәләшкән егете Мәгъфүрҗан киләсе елга хезмәтен тутырып кайта. Менә өч ел инде алар кавышу минутларын көтеп яшиләр. Адәм әйтеп, адәм ышанмас: сагынуларын басар өчендер инде, көн аралаш хат алышып торалар. Таһир белән Зөһрә дә ул кадәр яратышмагандыр. Ә сиңа кыз-кыркын буа буарлык! Теләгәнең сайлап ал. Гөрләтеп туй итәрбез!

Хисаминың күзе тонган, акылы томаланган иде. Ул туганнарының киңәшенә дә, өлкәннәрнең шелтәсенә дә колак салмады. Төннәр буе йокламый планнар корды. Максаты: урлап, яисә берәр этлек эшләп булса да Гөлмәрьямне үзенеке итү! Кич клубта аның җырлаганын да ишеткәч, егет өнсез калды. Булса да булыр икән бу кадәр дә моңлы тавыш! Талга кунып сайраган сандугач диярсең! Хисаминың үз гомерендә бу кадәр сихри, юк, илаһи моң белән җырлаган кешене күргәне дә, очратканы да булмады. Җырның сүзләре дә гади генә инде югыйсә:

Ак күгәрчен дә гөрли,
Күк күгәрчен дә гөрли;
Атасыз балалар үлми –
Дөнья рәхәтен күрми.

Кызның җилкәсенә төшкән толымнары сизелер-сизелмәс кенә тирбәлеп-тирбәлеп ала. Әйтерсең, алар моң дингезендә чайкала...

Сугыш... Сугыштан соңгы еллар авырлыгын үз җилкәсендә күтәргән апалар, яшьлек елларын сугыш сөреме каплаган үсмерләр, итәк тулы бала белән тол калып ачы хәсрәт кичергән җиңгиләр әсәренеп, тын алырга да куркып Гөлмәрьямне тыңлыйлар. Кызның күкрәгеннән саркып чыккан моң аларның йөрәкләрен сулкылдата, бәгырьләрен айкап ала. Ихтыярсыздан, күзләр яшькә чылана.

Ул керсез күз яшьләрен тыярга маташу файдасыз. Алар алма битләр буйлап тәгәрәпме тәгәриләр. Кемнәрдер үзеннән алда утырган тамашачының аркасына

ышыкланып мышык-мышык елый. Ай яктысында чигелгән кулъяулыклар берара чыланган керфекләр тирәсендә тирбәлә...

Жыр тәмамлана. Халык гөрләтеп кул чаба. Тамашачы Гөлмәрьямне сәхнәдән җибәрми.

— Тагын берне җырла инде, сеңлем!

— Тагын берне!

Авылдашларның сүзен ничек аяк астына салып таптыйсың инде. Ничек аларның гозерен үтәмисең? «Ай-яй, кыланышы! Ялындырган була инде. Әллә кем булган!» —дисәләр ояты ни тора! Тагын җырлый Гөлмәрьям:

Агыйделләрдә ак томан,
Ак томан төтен сыман;
Икәү булмый, берәү була
Йөзне саргайта торган.

Халык һаман тынмый. Сорый. Үтенә. Тамашачыларның кул чаба-чаба уч төпләре кызып чыккан. Хәзер ул утырган җиреннән аякларын тыпырдата.

— Тагын берне!

— Берне генә!

Гөлмәрьямнең җырга-моңга һәвәслеген дә белеп алгач, Хисаминың үҗәтлегенә үзсүзлеге дә өстәлде. Юк, ул аны нииндидер маңка малай Мәгъфүрҗанга бирәме соң?! Беркайчан да! Кайтып арага керә башласа, куркытыр, алай да тыңламаса тукмап ташлар. Немецларның иманын укытып, йорт-җирләрен пыран-заран китереп кайткан солдат ул Хисами абзаң.

...Шулай бервакыт, немецларның үз җиренә кергәч бер авыл өчен аяусыз сугышканнары әле дә хәтерендә. Немецлар никадәр генә көчле каршылык күрсәтсәләр дә, ахыр чиктә чигенергә мәҗбүр булдылар. Кайбер торак пунктларда совет солдатларын:

— O-o, kamrad! Kommen nach Hause! Fleisch essen und Snaps trinken![1]— дип каршы алсалар, монда немец солдатлары гына түгел, бер адәм заты да калмаган. Күрәсең, авыл халкы да чигенгән солдатлар белән киткән иде.

Немецлар йорт-җирләрен шул кадәр тәфсилләп, матурлап төзегәннәр.

Андагы чисталык-пөхтәлеккә исең китәр. Абзар тулы мал-туар. Кош-кортлар берни булмагандай җим эзләп тибенә. Сарай эчендә качып-посып калган немец солдаты юкмы дип, тикшереп йөргәндә Хисаминың колагына каяндыр «чи-чи» килгән тавыш чалынды. Якынрак килеп караса, тубал тулы яна гына күкәйдән тишелеп чыккан, сары йомгак шикелле сап-сары чебиләр! Алар, пилоткасына кызыл йолдыз кадаган кешене күргәч, нинди бәндә икән бу дигәндәй, башларын кыйгайта-кыйгайта Хисамига текәлделәр. Аннары тагын да көчлерәк «чи-чи» килергә тотындылар. Күрәсең, ашарга, яисә эчәргә су сорыйлар иде бу гөнаһсыз җан ияләре. Хисами автоматын иңбашына элеп берсен кулына алды. Үзе йомшак, үзе җып-җылы бу нарасый җан иясе югалып калмады, нәни генә томшыгы белән Хисаминың уч төбен чукып-чукып алды. «Кая җимен?» дигән булгандыр инде үзенчә. Алдында бернинди дә ризык күрмәгәч, төймә кебек елтыр күзләрен Хисамига төбәп, кабат «чи-чи» килергә тотынды.

Ул арада каяндыр командирлары килеп чыкты.

— Чего смотришь? Рассыпай их на землю и топчи! Это же фашистская тварь!

Офицер тонган күзләре белән тирә-якны айкап чыкты.

— Ломай всё подряд!

[1] (нем.) О-о, иптәш! Әйдә өйгә керегез. Ит ашарсыз, аракы белән сыйларбыз.

Командирлары әмер бирде дә, күздән югалды. Хисами, ике дә уйламый тубалны күтәреп бер якка ыргытты. Сары йомгакларның берничәсе генә хәлнең хәтәрлеген чамалап качып котылды. Каралты-кураның асты-өскә килде...

Менә шулай. Ә монда бер Мәгъфүржанны сындыру аңа берни түгел.

Хисами Гөлмәрьямне урламакчы да булган иде (безнең татарда юк әйбер түгел). Ә кая алып кайтасың? Өйдә бер өер бала-чага (әтисе инвалид – сугышка алынмады). Бер почмакка чаршау корып булса да йоклар иден, йортлары да алты почмаклы түгел, дүрт почмаклы әтәм-сәтәм генә. Ишле гаиләгә өстенә кыш көне сарык бәрәннәре дә өстәлә. Анда ничек килен төшерәсең? Шул бераз төрле этлек эшләсән генә инде. Ә аңысына бисмилла әйтү кирәк түгел. Андый эшләргә оста Хисами. Булдыра. Тәҗрибәсе бар...

***

... Польша җирендә булды бу хәл. Бер чибәр генә санитарка кызга күзе төште Хисаминың. Җаен табып сөйләшеп тә карады: унай җавап кына ала алмады. Дәрт иткән – морадына җиткән ди. Зур гына бер хуторны немецлардан азат итәргә кирәк иде. Ышыкланып һөҗүм итәргә якын-тирәдә агач заты юк. Бомба төшеп чокыр-чакыр ясап бетергән кыр аша үтәргә кирәк. Солдатлар чалгы белән печән чапкандагы кебек кырылачак та кырылачак инде. Немецлар безнекеләрне күрү белән пулемётлардан ут ачты. Кемнәрдер яраланып-канга батып, кемнәрдер шундук мәңгелеккә егылды. Алар артыннан килүче санитарка кызлар иелә-иелә, кайчагында шуышып ярдәм сорап кычкырган яралылар янына ашыгалар. Сугыш кыры – шахмат уены түгел. Командирлар күпме генә аяусыз сүгенә-сүгенә «Вперёд!» дип кычкырсалар да, нәтиҗә күренмәде. Никадәр солдат шушы хутор өчен башларын салды. Дошманның чигенергә исәбе юк иде. Ахыр чиктә, резервта калган Хисамилар ротасын да һөҗүмгә күтәрделәр. Шулчак Хисами күзе төшкән санитарка кызны шәйләп алды. Чүгәләп утырган кыз әле генә кемгәдер ярдәм иткән иде булса кирәк, санитар сумкасын төреп маташа иде. Беркадәр ара киткәч, Хисами артына борылып карады. Кыз да күпмедер ара калдырып аларга ияргән иде. Немецлар безнекеләрне шәйләп тагын да көчлерәк ут ачты. Алгы сафта баручы солдатлар берәм-берәм түмгәккә абынган шикелле сөрлегеп ауды. Тирән генә бер чокыр яныннан үткәндә сызгырып очкан пуляларның берсе Хисаминың колак яфрагын «чеметеп» узды. «Фронтовой сто грамм» белән кайнарланган кан аның яңагы буйлап агып төште, гимнастёркасын чылатты. Хисами кинәт кенә «ай-вай» килеп, ыңгырашып егылды... Тәгәрәп чокырга ук төшеп китте. Бу хәлне күреп алган санитарка да яралы солдатка ярдәм итмәкче булып аның артыннан чокырга сикерде.

– Что с вами? Где ваша рана?

«Яраланган» Хисами санитарка кыз якынлашуга аны бөтереп алды да, өстенә менеп ятты. Бер кулы белән кызның авызын томалады, каударланып икенче кулы белән итәген күтәрде...

...Хисами хайвани теләген канәгатьләндергәч, кызның маңгаена автомат көпшәсен терәде:

– Будешь жаловаться! Застрелю!

Әгәр кыз чәрелди башласа, Хисами ике дә уйламый тәтегә басмакчы иде. Туплар гөрселдәгән, берөзлексез автоматлар тырылдаган сугыш кырында бер автомат тавышына кем игътибар итсен? Бичара кыз аның миһербансыз, ерткычныкыдай явыз чыраена күз сирпеп алу белән коелып төште.

– Вот, крест! Ей богу, не буду!

Хисами, кыз чукына-чукына ант иткәч кенә, автоматын читкә борды...

...Туган авылын яу кыры түгел. Хисаминың кулында автоматы да юк. Булса да алай пырдымсыз кылана алмыйсың.

Бирәм дигән колына — чыгарып куяр юлына, ди. Хисами кибет тирәсендә кәефләнеп, тәмәке пыскыта-пыскыта жай гына атлап килә иде, бәләкәй арба белән урманнан утын алып кайтучы Зариф очрады. Үсмер егет ялгызы гына яши (әтисе сугышта хәбәрсез югалды, әнисе кар астында калган башак ашап бер ел элек вафат булды), акылга зәгыйфьрәк булса да, бакча тутырып бәрәңге утырта, тавыклар асрый. Аның өчен шунысы жайлы: күрше авылда сельпо бар. Ул күкәй сатып көн күрә. Акылы сай булгач, аны «Давай налог түлә!», «Заемга язып!» дип тинтерәтмиләр. Хисамның күнеле күтәренке иде. Ул егетне мактарга, үсендереп салпы ягына салам кыстырырга тотынды.

— Шәп имән утыннары икән. Каян кистең боларны?

— Козгын-тау итәгеннән.

— Тагын калдымы соң әле? — (Әйтерсең урманда утын беткән).

— Һи-и, муре! — (море инде анынча). — Чытырманлык аркылы чыгасы түлке. Менә... — Ул сыдырылып-тырналып беткән кул аркасын Хисамига күрсәтте.

— Бияләй кияргә иде.

— Юк бит.

— Миндә ике пар трофей бияләй бар иде бугай әле. Бер парын сиңа бирермен. Миннән бүләк булыр.

Трофей дигән сүзнең ни икәнен анламаса да, бүләк дигән сүзне ишеткәч, Зарифның авызы колагына житте.

— Һе, рәхмәт инде!

— Бүләк алгач әйтерсең рәхмәтеңне.

— Син немецларны жиңеп кайткан әйбәт кеше бит, Хисами абый. Алдамассың инде.

Хисами үз итеп, жинелчә генә егетнең инбашына сугып алды.

— Нишләп алдыйм инде мин сине. Теләсәң, ул шыгырдап торган өр-яңа күн бияләйләрне мин сиңа бүген үк китереп бирәм.

— Карале, Хисами абый, түлке нишләп син немецларны жиңгәч тә кайтмадың?

— Плен төшкән немецларны сакладым.

— Ә нишләп сакладың соң аларны, атып үтереп кенә бетермәдең? Мылтыгың юк идемени?

— Зарифжан энем, аларны бит карап торып эшләтергә кирәк иде. Жимерелгән шәһәрләрне төзетергә кирәк иде. Анладыңмы?

— Анладым инде. Анладым. Ул шәһәргә мине дә алып барырсың әле бер, яме.

— Ярар, ярар, обязательно алып барырмын. Теләсәң урнаштырып та кайтырмын. Шунда яшәрсең. — «Сары йорт»та дип әйтеп бетермәде Хисами. Зариф ризалашса, аның хәйран төзек йорт-жире каласын, даулашып йөрергә туган-тумачасы юк икәнен дә чамалаган иде. — Шәһәрдә болай интегеп бәләкәй арба тартып утынга барасы юк.

Зариф кискен генә башын чайкарга тотынды.

— Ю-ук, калмыйм мин анда, калмыйм. Монда Актүшне кем ашатыр? — Һәм ул аягы тирәсендә сырпаланган этенең башыннан сыйпап алды. Эт тә жавапсыз калмады — койрыгын болгый-болгый хужасының кулын ялап алды.

Утыннар өелеп бетте. Эш тәмамланды. Хисами куен кесәсеннән бер ярты аракы чыгарды.

— Арыгансыңдыр. Әйдә, оешкан каннар таралсын әле.

Зарифжан бу юлы бәхәсләшеп тормады. Өйгә керделәр. Өстәл янында ике ир-ат озак кына гәпләшеп, чөкердәшеп утырды. Уртак фикергә килгәннәрдер, ахырдан кул сугышып аерылыштылар.

***

Хисами икенче көнне кич клубка барырга чыккан Гөлмәрьямне Зарифлар капкасы төбендә көтеп алды.

– Матурым, Зариф абыеңа нидер булган. Урыныннан кузгала алмый ята. Бер-бер хәл булмады микән? Әйдә, кереп карыйк әле. Кичә бәләкәй арба белән урманнан алагаем төяп имән утыны алып кайткан булган икән дә, көч килде микән, бүген менә тора алмый ята, мескенкәй.

Гөлмәрьям жилкапка аша ихатага күз салды. Сарай янындагы утынлыкта, чыннан да, туралмаган утын өемнәре ята иде.

– Мин фельдшер түгел бит, Хисами абый. Сания апаны чакырыгыз.

– Хәзер соң бит инде. Эш сәгате беткәч кешегә әйтүе дә кыен. Мужыт йокларга яткандыр. Сине жырга-биюгә генә түгел, им-томга да һәвәс диләр бит. Әйдә, кереп кара инде.

– Нинди им-том булсын инде, Ходаем. Киселгән ярага үги ана яфрагы ябарга кирәген, эче киткән кешегә шомырт суы эчертергә кирәген бар кеше дә белә инде. Басуда бер-бер хәл булса, арада иң яше булгач, апалар мине йөгертәләр. Шул гына.

– Шулай да синең кулың килешә диләр бит.

Зарифжан – авылның бер гарибе. Кермәсә, рәнжеше төшәр. Чарасыз керергә мәжбүр булды Гөлмәрьям.Исәбе: егетне күреп чыгарга да, хәле чыннан да авыр булса, Сания апаларның өе клубтан ерак түгел, кереп әйтер.

Зариф сәкедә юрганга төренеп ята. Калын гына сөлге белән башын бәйләгән. Үзе бертуктаусыз ыңгыраша. Ыңгырашуының ата-анасы юк. Әллә елый шунда, әллә көлә? Белмәссең?

Өйдәге шапшаклыкка игътибар итми мөмкин түгел иде. Ничә ел себерке, мунчала күрмәгән идәнгә лакашып каткан пычракны хет көрәк белән кырып ал.

Зарифның хәлен белергә дә, тизрәк чыгып китәргә иде кызның исәбе. Ул аңа якынрак килде.

– Ни булды сиңа, Зарифжан? Кайсы төшең авырта?

«Авыру» Зариф Гөлмәрьям аның янына якынлашуга жәһәт кенә өстендәге юрганын алып атты, сикереп торды, берни булмагандай:

– Бүген алдау көне! Алдау көне! Алдадым! Алдадым! – дип, кычкырып көләргә тотынды. Кыз «Алдау көне беренче апрельдә бит, Зарифжан. Соңга калгансың» дип әйтмәкче иде, ул арада Зариф ушада яткан күн бияләйне эләктереп чыгып та китте. Гөлмәрьям ни әйтергә белми Хисамига текәлде. Ул егетләрнең кыланышын шаяртулары дип уйлаган иде.

– Нинди кәмит бу, Хисами абый?

Хисами кызга җавап биреп тормады, көрәктәй куллары белән кызны эләктереп алды, кочаклап үбәргә омтылды. Аның тыны кайнарланган, үзе еш-еш сулыш ала. Кызның битенә аракы исе белән буталган сасы тәмәке исе бөркелде. Ул, ихтыярсыздан, башын читкә борды.

– Хисами абый, жибәр! Бүген безнең репетиция!

– Нинди репетиция? Син болай да сандугач кебек сайрыйсың, матурым!

Гөлмәрьям берара Хисамидан ычкынып ишеккә ташланган иде, ул тыштан бикле булып чыкты. Кыз шунда гына Хисами оештырган спектакльнең асылын аңлап алды.

– Хисами абый, яхшылык белән чыгармасаң, тәрәзәне ватам. Каравыл кычкырам!

Егет кызны кабат эләктереп алды, шашып үбәргә тотынды һәм ... әле генә «чирле» Зариф яткан ятакка сөйрәде. Ул үзен тыеп торырлык халәттә түгел иде.

– Синдәй чибәр кызны суырып үпмәсәң гөнаһ булыр. Курыкма, матуркаем, барысы да әйбәт булыр. Хисами абыеңның тәҗрибәсе зур аның...

– Хисами абый, җибәр! Мин сиңа уйнашчы түгел!

– Беләм! Уйнашчы түгел икәнеңне беләм. Бер күрүдә үк ошаттым мин сине. Миңа тормыш итәргә синдәй хатын кирәк.

Ул инде әрсезләнеп кызның күкрәгенә үрелде.

– Минем егетем бар! Кагылма миңа!

– Ә мин сине беркемгә дә бирмим!

Кыз чәбәләнде, бөтен көчен җыеп каршы торды, ахыр чиктә ярсып еларга тотынды.

– Хисами абый, шул чаклы миһербансыз булма. Авыру әнием хакына рәнҗетмә мине! Зинһар, чыгарып җибәр!

– Курыкма, матурым, берәр җае табылыр. Мужыт ул да безнең белән яшәр.

Бу минутта кыз авыру әнисе турында да, егете турында да уйлап алды. Мужыт диме? Юк, ул беркайчан да, үлсә дә әнисен ташламаячак, Мәгъфүрҗанга да хыянәт итмәс. Гөлмәрьям Хисаминың оятсызланып көлмәк итәген күтәрә башлаган кулын тешләп алды. Егет корт чаккандай, кискен генә кулын тартып алды һәм ачуына буылып кызның яңагына китереп чапты. Гөлмәрьямнең күз алдыннан бер мизгелгә Хисаминың чүл бүреседәй явызланып өлгергән чырае югалды. Аның урынына гөлт итеп ут көлтәсе кабынды.

Егет өйдәге бердәнбер урындыкны тибеп очырды.

– Менә, нәрсә, чибәркәй, йә үзең риза булып миңа кияүгә чыгасың, йә булмаса, мин сине иртәнгә кадәр тотам да, кешеләр көтү куганда җилтерәтеп урамга алып чыгам. Кичә миңа ябышып кияүгә чыккан иде, чиләк төбе тишек икән, кеше калдыгы миңа кирәк түгел дип, тузанга төртеп егам.

Гөлмәрьям бу кадәр астыртын мәкерлекне уена да китермәгән иде. Ул башын күтәреп Хисамига карады — чынлап сөйлиме бу явыз? Егетнең чыраенда миһербан әсәре юк иде. Кыз бу мизгелдә аны чүл бүресенә охшатты. Гомергомергә калдык-постык, сасыган үләксә белән тукланган чүл бүресе көче житкәннәргә шулай шәфкатьсез кылана диләр. Йа, Алла! Хисами аны шулай мәсхәрә итсә, нишләрсен? Оятын кая куярсын? Кыз кешегә монысы тагын да хәтәррәк! Мәгъфүрҗан да нахак сүзгә ышанып аннан йөз чөерсә?! Кеше калдыгы миңа кирәк түгел дисә, нишләрсен? Хет, суга ташлан! Агымсу үзеңне дә, бар булган кайгы-хәсрәтләреңне дә агызып ала да китә, җайлы ич. Ярар, ул үзе бу мәсхәрәдән котылыр, ә әнисе кем кулына калыр? Кем аны тәрбияләр? Кыз, кырау суккан чәчәк кебек, сыгылып төште... Ярсып үксергә тотынды. Ул язмышы белән ялгызы торып калды...

– Фашист! Миһербансыз!

... Кыз мәхәббәтенең сихри көннәрен, тылсымлы төннәрен көтеп ала алмады. Таң әтәчләре кычкырганда аның чәчәге тапталган, намусы тапланган иде. Ул авыру әнисен кызганып, Хисаминың явызлыгын сөйләп тормады, җан сызлавы белән бергә эченә йотты...

– Шулай килеп чыкты инде, әнкәй. Ачуланма инде...

Туй ясап мәшәкатьләнмәделәр, сугыштан соңгы ачлык-ялангачлыкта ул турыда кем уйласын? Кияү белән кәләшкә Хисамиларның өендә урын юк та юк инде. Гөлмәрьямнәр йортында көн күрә башладылар. Хисами өчен бу йортка кергән шикелле тоелса да, Гөлмәрьямгә әнисен тәрбияләргә кулай иде. Бәләкәй генә кысан өйдә берсенә дә рәхәт түгел. Ни дисәң дә, яңа өйләнешкән парлар... Яшь чак, дәртле чак... Хисами дәртләнеп хатынын кочаклый башласа, Гөлмәрьям:

— Әни ишетә бит. Сабыр ит инде. Йоклап китсен, — дип иренен дәртен тыя. Андый чакта Хисаминың сикереп торып карчыкны ботарлап ташлыйсы килә. Ни өчен өйләнде соң ул? Хатынын кочакларга тилмереп ятар өченмени?..

***

Без йоклый дип, вакыт йокламый. Сәгать телләре бер җайга текелдәп минутларны-секундларны санап кына тора. Мәгъфүрҗан да хезмәтен артыгы белән тутырып, исән-сау әйләнеп кайтты. Бу хәбәрне ишеткәч тә, Гөлмәрьям кибеткә тозга китте. Өйдә тоз беткәнгә түгел, кибеткә барганда Мәгъфүрҗаннар турыннан үтәсе! Аның читтән генә булса да моряк тельняшкасы кигән, бескозырка тасмаларын җилфердәтеп, ихаталарында йөргән Мәгъфүрҗанны күрәсе, һич югы, тавышын гына булса да ишетәсе килә иде. Алар турыннан үткәндә ул адымнарын әкренәйтте, колакларын сагайтты. Әмма өйдә халык күп иде, ахры, сагынганнардыр инде: күрше-күлән, туган-тумача җыелгандыр. Гөлдер-гөлдер сөйләшкәннәре, көтмәгәндә кумәкләшеп көлеп җибәргәннәре ишетелә. Арада кайсысы Мәгъфүрҗан тавышы — белә алмады. Тәрәзә төбен тутырган яран гөлләре балкып, өлге пыялалары шатлыклы авазлардан зеңгелдәп калды.

Ә шулай да, бердәнбер көнне язмыш аларны барыбер очраштырды...

Өске әрәмә янындагы басуда эшләп йөргән Гөлмәрьям, хатыннар кайсы кая күләгә ясап, төшке ялга туктагач, баласын имезергә авылга йөгерде. Аның сөт белән тулган күкрәге сулкылдап авырта башлаган иде инде. Кызы — Гөлмәрьямнең беренче сабые. Ярый әле әнисе янында. Авырыбрак торса да бала тәрбияләү дәресләрен ул аңа өйрәтә. Гөлмәрьям эштә чакта да сабые әнисе карамагында: юешләнгән чүпрәкләрен алыштыра, елый башласа, имезлек каптыра. Сабый әчкелтем ипи исе килеп торган имезлекне суыра-суыра йоклап китә. Ана сөтен берни дә алыштыра алмый шул инде. Бераздан сабый тагын уяна, тагын елый башлый. Үткән ел гына кырык бер яшен тутырган «әбисе» бишектә «ыгы-ыгы» килеп яткан оныкчыгын юата башлый.

— Хәзер әниең кайтыр, бәбкәм, әз генә сабыр ит инде. Әнә күрәсеңме, кояш төшлеккә җитеп килә.

Казлы Куак авылы урманга бай. Иген басулары арасында да төрле зурлыктагы әрәмәләр, як-ягын чикләвек, миләш, балан, камырлык куаклары каплаган чокырлар бар. Авыл белән Өске әрәмә арасында гына да алар дүртәү. Халык телендә Беренче... Икенче... Өченче... Дүртенче чокыр дип йөртелсәләр дә, аларны үзәнлекләр дисәң, дөресрәк тә булыр әле. Ул чокырларның яры да сөзәк, тирәнлеге дә дүрт-биш метрдан артмый торгандыр. Әнә шул сөзәк ярдан төшкәч, илле-алтмыш адымнар чамасы киңлектәге үзәнлек. Үзәнлекнең нәкъ уртасыннан чишмәләрдән саркып чыккан салкын су ага. Ул корылык килгән елларны да кипми. Шуңа күрә җәяүлеләр өчен генә түгел, җигүле атлар да үтеп йөрерлек итеп салынган. Бәләкәй генә күпере бар. Агымның як-ягында куе булып үлән үсә. Авыл халкы печәнлек чабып кинәнә. Чакрымнарга сузылган дүрт үзәнлек, Типтәр әрәмәсенә җитәрәк, кул чугындагы бармаклар беләзеккә җитеп кушылган шикелле кушылып, тирән генә чокырга әйләнә. Хәзер аның суын да, авыз тутырып, инеш дияргә була инде.

Гөлмәрьям Дүртенче чокырның ярыннан төшеп, күперчеккә җитәрәк, каршысына килгән Мәгъфүрҗанны күреп алды. Егет балтасын биленә кыстырмаган, йөзен аска каратып, уң җилкәсенә салган да әкрен генә атлап килә. Ул, Гөлмәрьямне күргәч, адымын тагын да әкренәйтте, күпергә кергәч, бөтенләй туктап калды. Гөлмәрьям дә күпергә керде, Мәгъфүрҗанга җитәрәк ул да туктап калды. Хәзер бер-берсен үлеп яраткан, җанымның яртысы дип

хыялланып йөргән гашыйкларның берсе шушы атлап кына чыгарлык инешнең бер ярында, икенчесе — икенче ярында, шагыйрьләрчә әйтсәк, язмышлар ярында, кул сузымында гына басып торалар.

— Кая ашыга бу чибәр кыз? Танцыга түгелдер ич?

Гөлмәрьямнең Мәгъфүрҗанны күрүгә, йөрәге күкрәк читлеген ватардай булып тибә башлаган иде инде. Ул аның сүзләрен үзен мыскыллау шикеллерәк кабул итте. Берара, ни дип җавап бирергә белми, сүзсез торды. Аның битләре кызышып чыкты. Шулай да сабыр булырга тырышты.

— Исән-сау гына йөреп кайттыңмы, Мәгъфүрҗан?

— Күрәсең ич, исән-сау.

Егетнең җавабы да төксе килеп чыкты. Гөлмәрьям, әңгәмәне ничек дәвам итәргә белми, унайсызланып калды. Кузгалып китәргә омтылса да, тәгаен бер карарга килә алмаган кеше сыман, бер урында таптанып алды.

— Балта күтәреп, кая юл тоттың болай?

— Чалгы сабына элмәгә Өске әрәмәгә барам. Элегрәк анда зифа буйлы кызлар кебек төз элмәләр үсә торган иде.

— Нишләп еракка барасың? Беренче чокырда да күп бит алар.

— Зифа буйлыларын без юкта кырып бетергәннәр. Кәкре-бөкреләре, ботаклылары гына калган. Алары мина кирәкми.

Егет бу юлы да сүзен киная белән әйтте. Гөлмәрьям Мәгъфүрҗанның күзенә туры карарга оялды, унайсызланды. Шулай да, тәвәккәлләп, кыяр-кыймас кына аның йөзенә күзен сирпеп алды. Сүзләре төксерәк булса да, егетнең чыраенда явызлык чалымнары юк, элеккегечә ягымлы елмайган. Күзләрендә генә сәер моңсулык сизелә иде. Егет, көтмәгәндә балтасын бер якка ыргытып, Гөлмәрьямнең беләгеннән тотып алды.

— Гөлмәрьям, җан кисәгем, нишләдең син, ә? Нишләдең? Нигә дип, мине шул сасыган кәҗә тәкәсенә алмаштырдың, ә?

— Юк, алыштырмадым. Син әле дә йөрәгемнең түрендә, Мәгъфүрҗан!

Егет салмак кына башын чайкап алды.

— Ай-һай, ай-һай! Ышануы кыен. Шулай ике кешене берьюлы сыйдыра ала торган куш йөрәкле кызлар барын белми идем.

Гөлмәрьям кыюлана төште. Искә төшерү никадәр авыр дисәң дә, булган хәлне Мәгъфүрҗанга аңлатырга кирәк бит инде. Юкса, гомер буе аңа рәнҗеп йөрүе бар.

— Юк! Хисамига минем йөрәгемдә урын юк. Булмаячак та! Тик нишлим, хәзер ул минем тормышымда бар. Уртак балабыз бар.

Мәгъфүрҗан көчле куллары белән Гөлмәрьямнең иңбашларыннан тотып алды.

— Сөеклем, син бит мина нинди матур хатлар яза идең. Вәгъдәләр бирешкән идек. Синең ул вәгъдәләрең сабый баланы куандырган сабын куыгы гына булдымыни, ә, Гөлмәрьям? Бер ел калгач, ник көтмәдең? Ник сабыр итмәдең? Әнә ишетәсенме, күрәсеңме, менә бу инешләр дә, сабыр гына челтер-челтер серләшеп ага торгач, бергә кушылалар. Ә нигә син шушы бәләкәй генә инешләрдән үрнәк алмадың?

Гөлмәрьям, ниһаять, башып күтәреп, Мәгъфүрҗанның күзләренә текәлде. Егетнең теле үкенү, үпкә сүзләре тезсә дә, күзләреннән ягымлы җан җылысы бөркелә иде. Сөйләмичә ярамый. Янадан мондый форсат әллә була, әллә юк дип уйлады ул.

— Хисами мине Зарифҗаннарга хәйләләп алып керде, төлке!

— Нинди төлке? Сасы көзән ул!

— Әгәр мина кияүгә чыкмасаң, адәм рисваена калдырам дип куркытты. Син дә, аның нахак гайбәтенә ышанып, миннән йөз чөерерсең дип курыктым.

Мәгъфүрҗан, ялварган кешедәй, кулларын күтәреп, күкләргә төбәде, аннары, шапылдатып, ботына сугып алды.

— Йа Аллам! Алай да курыккан, болай да курыккан, ә! Элек син алай куркак түгел идең бит, Гөлмәрьям. Кешеләр күнеленә шом салып, Шарлама башындагы улаган бүреләрдән дә курыкмый торган идең бит син! Әйдә, барып карыйк әле, ничек улый икән алар, дип, мине әйдәкли торган идең. Ә мин сиңа, бүреләр төннәрен күккә, тулган айга карап улыйлар, ауга чыгарга иптәшләрен җыялар, дип аңлата торган идем. Хәтерлисеңме шуларны?

— Әйе, хәтерлим.

— Чын бүредән курыкмаган кыз чүл бүресеннән шүрләп калган, ә!

— Ул чагында минем янымда син бар идең бит, Мәгъфүрҗан! Ә монда мин явызлык каршында япа-ялгыз калдым... тышкы яктан ишек бикле булгач... чарасыз калдым...

Гөлмәрьям башын түбән иде. Ул сүзен дәвам итәрлек халәттә түгел иде инде, үксеп, егетнең күкрәгенә капланды...

— Кичерә алсаң, кичер мине, сөеклем! Мөгаен, барысына да мин үзем гаепледер...

Мәгъфүрҗан, шуны гына көтеп торгандай, аны күкрәгенә кысты... шашып үбәргә тотынды...

Гөлмәрьям карышып тормады, бу минутларда ул барына да риза иде...

— Җанкисәгем, төкер шул сасы көзәнгә. Әйдә кавышыйк. Гөрләтеп яшәрбез.

— Соң инде, Мәгъфүрҗан, соң! Үпкәләмә, бәгърем, гафу ит! Кызым әтиледән әтисез булып үсмәсен инде. Ятимлек ачысын үзем кичергәннәр дә җиткән. Юк, баштан ашкан.

— Курыкма! Ант итеп әйтәм, балаңны үгисетмәм.

Гөлмәрьям, «юк» дигәнне аңлатып, әкрен генә башын чайкап алды.

— Үпкәләмә, бәгърем, гафу ит!..

Гашыйклар озак юана алмадылар. Өске әрәмә ягыннан атлы арба тавышы ишетелде. Арба келтерәве, доп-доп баскан тояк тавышы якынайганнан якынайды. Мәгъфүрҗан сөйгәнен тагын бер тапкыр суырып үпте дә, балтасын биленә кыстырып, үз юлына китеп барды.

Татлы очрашу мизгелләре кавышу китермәсә дә, гашыйклар күңелендә сүнмәс хатирә булып мәңгелеккә сеңеп калды...

Җигүле ат Гөлмәрьямне үзәнлектән күтәрелгәч кенә куып җитте. Үрәчәле арбада күршеләре Фәтхелислам агай утыра. Ул, юл сабып читкә чыккан Гөлмәрьяне күргәч, чөңгереп, атын туктатты.

— Тпру, малкай!

Агай арбасына яңа чапкан печән салган. Чалгысын арбаның артына аска, ялгыш киселмәслек итеп печәнгә батырган иде.

— Әйдә, кызым, утыр!

Гөлмәрьям җәһәт кенә арбага сикерде. Мизгел эчендә аны яңа чапкан печән исе чолгап алды. Исенә исерерсең, валлаһи! Аның күңеле күтәрелеп китте. Туры бия Фәтхелислам агай дилбегә кагуга тагын үз көенә әкрен генә теркелди башлады.

— Бу вакытта каян кайтып киләсең, кызым?

— Өске әрәмә янындагы басудан. Кешеләр төшке ашка туктагач, мин көн саен шулай бала имезергә кайтам бит, Фәтхелислам абзый, — ул чеметеп кенә күлмәгенең күкрәк турын күтәргәндәй итте. — Менә бит, күлмәгем лыч, сөткә тыгып алган кебек булды. Хет сыгып ал.

— Ә-ә, әйе шул. Карале, гел онытып торам икән бит, әй. Менә хәтер диген инде, ә!

Агай, әле генә каршысына очрап, үзен сәламләп узган Мәгъфүрҗанның тельняшка күкрәге дә юешләнгәнен абайлап алган иде. Әмма ул турыда сүз куертып тормады. Сөйгәнен сагынып кайткан егет аны кочагына алып кыскан иде шул. Озак итеп, яратып кыскан иде. Йөрәк түреннән ургып чыккан кайнар мәхәббәт хисләренә күкрәк сөте дә өстәлер дип, кем уйлаган...

— Фәтхелислам абзый, ә үзең каян кайтып киләсең?

— Мунчала күленнән. Суы саекканмы, бүртеп чыкканнармы, җебетергә салган кабыкларым өскә калыккан. Менә шуларның өстенә имән түмәрләре салып кабат бастырдым.

Гөлмәрьям бер уч печәнне борынына якын китерде.

— Бигрәк хуш исле. Каян чабып алдың бу печәнне, Фәтхелислам абзый? Исе әллә каян аңкып тора.

— Мунчала күле яныннан инде. Күл тирәли куаклык булса да, ачык урыннары да бар бит. Шуннан чаптым. Безнең сыер ике бозау китерде бит быел. Менә, бозауларга булыр дидем инде. Алар бит яңа чапкан печән ярата.

Гөлмәрьям учындагы дымлы печән белән бөтен битен каплады. Исен мәңгелеккә сеңдереп калдырырга теләгәндәй, тагын бер тапкыр озак итеп, күкрәген тутырып сулады...

***

Илленче еллар житте. Мыекбай Сталиннан соң властька утырган Маленков, рәхмәт яугыры, ил халкын шатландырып, байтак кына салымнарны бетерде, әйбер бәяләрен төшерде. Авызын ачса үпкәсе күренеп торган җир кешесенә сулыш алырга ирек бирде.

Хисамины бригадир итеп куйдылар. Ул партиягә керде. Хуҗалыкта гына бер кадак та какмады. Хатыны ава башлаган читән турында сүз кушса:

— Бүген партсобрание! — дип, яисә, ачыктан-ачык: — Минем ихата түгел. Хәбәрсез югалганнар да кайта. Сөләй Әмәтенә (Гөлмәрьямнең әтисе Әхмәтнең исемен бозып әйтә инде) каралты-кура әзерләп торасым юк әле, — дип, кесәсеннән тәмәке янчыгын алып, өйдән чыгып китү җаен карады. Җыелышларда теле телгә йокмаган, кирәксә-кирәкмәсә дә «Без — фронтовиклар!» дип күкрәк кагарга яраткан Хисамины тора-бара МТСка тракторчылар бригадиры итеп алдылар. Ниһаять, йорт салырга җир кишәрлеге бирделәр. Икесенең эшләгәне, ихатадагы мал-туар бары да йортка китеп барды.

***

Хатыны авырга узган саен ир бала көтте Хисами. Үзе төсле кара күзле, кара чәчле нәсел дәвамчысы булуын бик теләсә дә, бер-бер артлы әниләренә охшаган өч кыз тугач, ирнең тәмам кәефе кырылды. Салгалап кайтулары ешайды. Һәм аңа сонарып кайтулар да өстәлде...

Гөлмәрьям дүртенчегә авырга узган елны, ниһаять, яңа өйгә күченделәр. Гөлмәрьям өчен ул көн — олы бәйрәм булды. И, аның шул чактагы ике басасы урынга бер басып, канатланып йөрүләре! Ул нарат исе аңкып торган яңа йортка йөгерә-йөгерә әйбер ташыды, кайсын кая урнаштырды. Аяк астында буталып йөргән кызларының аркаларыннан сөеп үтәргә дә җай тапты. Болытлы, пыскак көн аңа язгы көннән дә яктырак, җылырак булып тоелды. Ул көн күк капусы ачылган көнгә тиң булгандыр! Гөлмәрьямнен үз гомерендә мондый бәхетле мизгелләр кичергәне булды микән? Булса да сирәк булгандыр.

Әнисе генә яңа өйгә күченергә теләмәде.

— Аллага шөкер, әкренләп булса да үз йомышларыма йөри башладым инде.

Оныклар минем янга кунарга килер, — дип, сылтау тапты. Ә асылда, кызы белән кияве арасына кара елан кергәнен күңеле сизгән иде...

Яна йортка күченеп бер ай яшәделәр микән, Хисами бөтенләй бәйдән ычкынды. Юк-бар сәбәп табып, көн дә хатынына бәйләнде. Бусы нигә болай түгел дә, тегесе нигә тегеләй түгел? Ачуы килгән чак булса, сорап тормый сугып та җибәрә. Әнә бит, бүген дә, сонарып кайтты да, ишектән керүгә:

— Юган керләреңне нигә тузанлы киртәгә эленң? — дип акырырга тотынды.

— Карачкы шикелле торма юлда! — дип каршысына килгән хатынын тупас кына этеп җибәрде. Гәрчә, Хисаминың май таплары тигән (механизаторлар янында йөри ич) спецовкалары, чалбарлары гына ихата арасындагы киртәдә эленеп тора, юылган керләрнең калганнары бауда җилферди югыйсә.

— Хисами, әкрен! Нигә шул чаклы кычкырасың? Балаларны уятасың ич. Юылган керләр барысы да үз урынында. Киртәгә ни дә булса элгәнче башта юеш чүпрәк белән мин аның тузанын сөртеп алам. Ә синең ул спецовкаларың авыр, бауны сыгып төшерә.

— Һы, авыр имеш!.. Ә мин сезгә акча булсын дип, шул авыр спецовкаларны көне буе киеп йөрим, беләңме?

Акча турында сүз чыккач, Гөлмәрьям бу юлы телен тешләп кала алмады. Күпме генә сакласаң да, чуан бер тулышып тишелергә тиеш бит инде.

— Һи-и, акча дип... ул акчаның ни ... яртысы гына өйгә кайта ич. Яртысы кая югала торгандыр? Белмим. Синең мут күз Хөршидән дә акча ярата, сельпо эшчеләренә зарплата түләгәндә тиеннәрен булса да үзендә калдыра диләр. Шул сөйрәлчектән калганы гына өйгә кайта торгандыр инде.

Иренең күрше авылдагы сельпода эшләүче Хөршидә исемле хатын белән чуалуын Гөлмәрьямгә күптән җиткергәннәр иде инде. Ул балалары хакына ничарадан бичара тешен кысып түзеп тора иде.

Турысын әйткән туганына ярамаган ди. Ир яткан җиреннән сикереп торды.

— Ах, син, кипкән балык! Әле синең телең дә бармыни? Күрсәтермен мин сиңа сөйрәлчекне! — Ул котырынып хатынын кыйнарга тотынды. Берничә мәртәбә сугып екты. Эченә типте...

Икенче көнне Гөлмәрьямнең баласы төште. Ул бу юлы малай алып кайтырга тиеш булган икән.

Хисами тукмалудан күз төпләре күгәргән, баласы төшүдән хәле китеп караватта яткан хатыныннан гафу үтенәсе, «хәлең ничек?» дип сорыйсы урында, эштән кайтып керү белән ашарга даулый башлады.

— Кая, ашарга бармы?

Гөлмәрьям җавап бирмәде, хәлсез генә ыңгырашып куйды.

Ир кабат бүксәсен киереп, үзе бер чынаяк чәйгә тилмереп яткан хатынына акырды.

— Ашарга бармы дим мин сиңа!

— Хөршидәң сыйламадымыни?

— Син әле һаман телләшәсеңме?

— Юк, дөресен генә әйтәм.

Ир ачуына буылып ишекле-түрле йөренде.

— Ул гөнаһсыз сабыйның гәүдәсен күмәргә кирәк бит инде, Хисами. Күршеләргә кереп сөйләш. Кабер казырга...

Хисами аны ярты сүздә бүлде.

— Ул минеке түгел! Оеткысын кем салган, шул күмсен көчегенне! Ул минеке түгел. Басуда берәр чирләшкә әвәләгән аны. Шуңа оешып җитмәгән. Минекеләр вакыты җиткәч кенә туды.

Гөлмәрьям үз колакларына үзе ышанмады. Ничә ел бергә яшәгән, бер табактан ашаган иреннән нахак сүз ишетермен дип уена да китермәгән иде. Анын аны томаланды. Битләре кабынып китәрдәй булып кызышты. Ул, берара авызын ачкан килеш, ни дияргә белми торды. Авырлык белән булса да торып утырды. Чынлап сөйлиме бу явыз, әллә шаяртамы? Хатын башын күтәреп иренен йөзенә текәлде. Юк, Хисами шаяртмый иде. Аның иреннәре кысылган, күзләре чүл бүресенекедәй усаллык белән яна, аларда рәхим-шәфкатьнең чалымы да юк иде.

Гөлмәрьямнең йөрәген нидер чәнчеп алгандай булды. Ире белән телләшеп торырга анын хәле дә, теләге дә юк иде. Шулай да нахак яла ягып анын йөрәген яралаган иргә әйтергә теләгән рәнжү сүзләренең бер өлеше анын бәгыреннән саркып чыкты.

— Син... Син... туачак сабыеннын жанын кыйдын. Ана жан кергән иде бит инде. Сине Алланын каты каһәре тотсын! Бала чырае күрергә тилмереп яшә! Минем гөнаһсыз күз яшьләрем тотсын!

Хатын үксеп караватына капланды.

Бу вакытта Хисаминың инвалид әтисе бакыйлыкка күчкән иде инде. Әнисе тезләнеп елый-елый Гөлмәрьямнән гафу үтенде.

— Килен, булдыра алсаң гафу ит инде син безне. Ул баланың колагын бора-бора без тәрбияли алмаганбыздыр. Без гаепледер.

Бианасынын кешелеклелеген, миһербанлылыгын белгән Гөлмәрьям хәлсез куллары белән аны тезләнгән жиреннән күтәрде.

— Юк, әнкәй, сез гаепле түгелдер. Сугышта ул шулай кансызга әйләнгәндер.

— Атта да бар, тәртәдә дә бар дигәндәй, килен синең сүзең дә дөрестер. Алай да кем баласы, дигән сүз дә бар бит әле. Нишләтәсен, әтиләре дә, мәрхүмкәй, гариплеге өстенә балаларга йомшаграк булды шул. Берәр ярамаган эшләрен сизеп тирги башласам да ярар инде, Гөлзифа, балаларга каты бәрелмә инде син, дип мине гел тыеп килде. Ә безнең Хисаметдин, әтисенең йомшаклыгын сизеп алгач, тыңлаусызга әйләнде. Авылның тәртипсез малае Ирнис тирәсендә бөтерелде. Тәмәке тартырга өйрәнде. Колхозның тавык фермасыннан йомырка урлап папирос сатып ала торганнарые. Ирнис белән икесе урманда кош ояларын туздырып йөрделәр. Болында йомран ояларына су тутырып интектерделәр. Ул мескен жан ияләренең тончыгып үлмәс өчен ояларыннан порхылдап килеп чыгуларыннан үзләренә кызык таптылар...

Күрше-күлән кабер казып, нарасый булырга өлгермәгән гөнаһсыз жан иясенең жансыз гәүдәсен гүргә индерде. Авылдашлар Хисамидан бу кадәр миһербансызлык көтмәгәннәр иде. Өлкәннәрнең сүзе дә бер тирәдәрәк булды.

— Яхшыдан яман туган нәрсә. Аллаһы Тәгалә жәзасын бирер әле. Бирми калмас...

— Әйе, теге дөньяда булса да жәзасын алыр.

— Юк, андый кабахәтләр дөньялыкта ук жәзасын алып китә, Фәтхелислам абзый. Әнә, мәчет манараларын кискән ахмакларны гына күр син. Шуларның берәрсе рәхәт күрдеме? Юк! Кайсы кайда эт типкесендә тилмереп йөрде. Туган илен дә кайтып күрә алмады. Барысын да Алланың каһәре тотты. Менә, күрерсез, Хисамины да бер китереп тота ул...

***

Атна ун көн үтте микән, тракторчыларга өләшәсе хезмәт хакын югалтып кайтты Хисами. Әллә исерек баштан төшереп калдырган, әллә теге мут күз Хөршидәнең кулы уйнаган? МТСтан кайтышлый янына сугылып, күнелен

күреп, бер яртыны «бөкләп» чыккан иде. Хисами бөтен ачуын хатыныннан алды. Ишектән керә-керешкә, сабыйларның төнге чүлмәген тибеп очырды, котырынып хатынына ябышты.

– Акчаны син урлап яшергәнсең! Давай, бир!

– Соң, Алла колы, МТСтан акча алып кайтып килешең генә ләбаса. Синең хезмәт хакы өләшәсенне мин кайлардан белим, ә?! – Гөлмәрьям бу юлы нахак сүзләрне күтәрә алмады – анын җуйды...

***

Югалган акчаны, өй борынча йөреп-теләнеп дигәндәй, әҗәткә алып түләделәр. Күзгә унышка өмет баглады Гөлмәрьям. Шөкер, соңгы вакытта хезмәт көненә азмы-күпме түли башладылар. Ир кисәгә дә үз гаебен танып читтә калмас.

Гөлмәрьям монысы хатын-кыз эше, ә монысы ир-ат эше дип тормый, хуҗалыктагы бар эшне сөреп эшли – чәче белән җир генә себерми. Бәйләнерлек урын да юк инде югыйсә. Иренең һаман сөяркәсе артыннан чабуына ачуы килә. Ничек биздерергә генә белми.

– Син ул Хөршидә янына йөрүдән кайчан туктыйсың инде? Оят бит! Урамга чыгар хәл юк, сине сөйлиләр. Мине эт итеп сүгәләр. Ир бирмәк, җан бирмәк, эчеңдә җаның юктыр синең, диләр.

Хисами ашап утырган җиреннән кашыгын ташлап, кискен генә тәлинкәсен этеп җибәрде. Кайнар шулпа ашъяулыкка түгелде. Сикереп торды. Хатынын җилтерәтеп күзгә каршына китереп бастырды.

– Синең берәр вакыт күзгегә караганың бармы?

Ир Гөлмәрьямнең иягеннән эләктереп башын өскә күтәрде.

– Кара! Кипкән балык бит син! Шыр сөяк! Юк, карачкы син! Карачкы! Бакча карачкысы! – Ул үзенең Хөршидә белән булган мажараларын яшереп тә маташмады. – Хөршидә – вот это, да! Аның белән йоклаганда түшәк тә кирәк түгел, беләнме? Ә син – кипкән балык! Шыр сөяк!

– Карачкы булмый нишлисең. Мин Хөршидә кебек бизәнеп-төзәнеп, җылы бүлмәдә чүт төймәләре генә тартып утырмыйм бит. Ул хуҗалыктагы мал-туарны кем карый соң? Кыш җитсә, көн дә терлек астын чистартырга кирәк.

***

Хисами уракка төшәр алдыннан бер атна өйгә кайтмады. Район зур, эш күп. Техникасы да ватылырга тора. Уракка төшкәч комбайннар ватылып ятса нишләрсең? Ни дип җавап бирерсең? Вакытында карамагансыз диячәкләр. Райкомга чакырып утлы табага бастырсалар бөтенләй эш харап! Андый чакта ак эт бәласе кара эткә – таякның юан башы Гөлмәрьям җилкәсенә төшәчәк. Һи-и, ул кайтса да, ни балаларга көн юк, ни үзенә. Болай тынычрак та әле. Сабыйлары әтиледән әтисез булмасын дип, тешен кысып түзә инде Гөлмәрьям. Авырып егылмасын гына. Соңгы айлардагы тавыш-гаугадан, нахак сүзләрдән саулыгы да бик нык какшады. Элекке чибәрлегенең дә сөлдәре генә калды. Сәхнәгә чыкмаганына да бишбылтыр.

***

Ә бердәнбер көнне... уйламаганда-көтмәгәндә Гөлмәрьямнәр капка төбенә җигүле карт алаша килеп туктады. Арбадан эреле-ваклы биш бала җиргә сибелде. Дилбегәне, ни өчендер, төенчекләр өстендә утырган ир-ат түгел, кырык биш яшьләр тирәсендәге хатын тоткан иде. Гөлмәрьям эшнең нидә икәнен ир-атның

сынар җине җилдә җилфердәгәч кенә абайлап алды. Ир-ат сүзгә саран булса, хатын, киресенчә, телчән булып чыкты. Ул дилбегәне җәһәт кенә койма башына элде дә, тәтелдәргә, сорау арты сорау яудырырга тотынды.

– Хисамилар өе шушы буламы? Сөбханалла, ярыйсы гына күренә бу йорт! – Ничек ярыйсы булмасын инде?! Гөлмәрьямнәр аны, мәңгелеккә булмаса да, гомерлеккә булсын дип салдылар ич. Авыздан өзә-өзә булса да.

– Бәхетле нигез булсын! Әйдәгез, балакайларым, өйгә буш кул белән кермәгез! Төенчекләрне алыгыз! Хәерле сәгатьтә!

Гөлмәрьям аларның юлына аркылы төште.

– Апа, туктагыз әле! Сез кемнәр буласыз соң? Каян килдегез? Нишләп йөрисез безнең ихатада?

Шатлыгы ташып чыккан хатын шунда гына үзенең хатасын аңлап алды: бәй, үзе белән таныштырмаган икән ич.

– Ә-ә, сеңлем, исәнме! Фәхринур апаң булам мин. Әйдә, күрешик. Син йортны пөхтәләп, карап тоткансың икән, рәхмәт яугыры! Хисамины әйтәм, бигрәкләр дә әйбәт кеше икән. Хатыныма бу якның һавасы килешми дип, Ташкентка күчеп китте. Йорт-җирен дә арзан гына бәягә сатты. Балаларым бәхетенә булгандыр инде...

– Ничек сатты? Кемгә сатты?

– Безгә сатты. – Хатын җәһәт кенә арбада яткан бәләкәй сумкадан бер төргәк кәгазь тартып чыгарды.– Ышанмасаң, менә, сеңлем, кара! Менә дугувыр кәгазьләре, кәпитәнсәләр... Дүкәмитләрдә авыл сәвитенен дә пичәте бар. Сеңлем, монда барысы да тәртиптә. Ул – сатучы, без – алучы. Бу йортка хәзер без хуҗа.

Гөлмәрьямнең башына күсәк белән ордылармыни! Ул ни әйтергә белми баскан урынында тораташтай катып калды. Әйткәннәр иде шул – Хисаминың кемнәргәдер йортларын күрсәтеп йөргәнен, әйткәннәр иде. Гөлмәрьям аларның сүзенә игътибар гына итмәгән иде. Дөресрәге, ире кемнәрдер алдында: менә мин сарай кебек нинди йорт житкердем, дип мактана торгандыр дип кенә уйлаган иде. Ялгышкан, бик нык ялгышкан икән. Хатасын соңарып кына аңлады. Йорт Хисами исемендә иде шул. Хәзер, инде терсәк якын булса да, тешләп булмый. Үткән эш тә кире кайтмый, үкен, үл, ела... Бу минутларда йөрәк түреннән сулкылдап чыккан чиксез рәнжү... чамасыз үпкә... үкенү... ачы нәфрәт... әйтеп-аңлатып булмый торган тагын әллә нинди хисләр өермәсе Гөлмәрьямнең бәгырен телгәләде. Үз гомерендә иреннән бер авыз җылы сүз ишетмәсә дә, язмышы белән килешеп, аның тупаслыгына күнегеп беткән Гөлмәрьям Хисамидан бу кадәр миһербансызлыкны көтмәгән иде. Берсе ыштансыз, берсе күлмәксез сабыйларын «эһ» тә итми ташлап китәр дип уена да китермәгән иде. Хәер, ул өчесенең берсен генә булса да алдына утыртып сөйгәнен, үчтеки-үчтеки итеп кулында чөеп уйнатканын, күкрәгенә кысып яратканын хәтерләми Гөлмәрьям. Бала җанлы булмады шул аның ире, булмады. Бала яратмаган, бала кадере белмәгән кешегә аларны ташлап китүе дә берни түгелдер. Юкса, кошлар булып кошлар да бит, балалары канат яргач кына... Юк, юк, кошлар – изге җан. Аларга тел-теш тидерсәң Алланың каһәре төшәр. Аю, бүре кебек ерткыч җанварлар да балаларын ташламый. Кыргый хайваннар да мондый кыргыйлык эшләми. Ә кешеләр?! Кешеләр бер-берсен кыерсыту, нахакка рәнҗетү, юк-бар сәбәп табып сугышлар чыгару, солдат киеме кигән кемнәрнеңдер балаларын кыру өчен яратылганнар микән соң әллә? Алай булса нигә кирәк булган аларны үрчетү? Йа, Алла! Нинди гөнаһларым өчен бирден миңа бу җәһәннәм газапларын? Сабыр канатларым гына сынмаса ярар иде. Аның күз аллары караңгыланды. (Көн чалт аяз иде югыйсә).

Томан эләпәсе аша Фәхринурның тавышы һаваны ярып узды.

— Сеңлем, сез Хисаминың кеме соң? Туган-тумачасымы? Әллә берәр игелекле күршесеме?

Бәхетленең шатлыгы бәхетсезнең кайгысын каплаган иде. Шулай булмаса, бу хатын чырае качкан Гөлмәрьямнең кемлеген йөзенә күз төшереп алу белән аңларга, һич югы, чамаларга тиеш иде. Юк шул, юк. Бу минутта Гөлмәрьям кемгәдер җавап бирерлек халәттә түгел иде. Аның өчен, әйтерсең, дөньяның ае да, кояшы да сүнде. Ул, киселгән үләндәй, җиргә ауды. Су бөркеделәр. Хатын алай да аңына килмәде. Күрше Фәтхелислам агай тиз генә ат җигеп, һушсыз яткан хатынны район үзәгенә хастаханәгә алып китте...

Гөлмәрьям атна буе үлем белән яшәү арасында тартышты. Кем кемне?.. Ул аякка басып туган авылына кайтканда күрше-күлән балаларны, барлы-юклы йорт җиһазларын әнисенең кыйшайган йортына күчергәннәр иде инде. Ә йөрәк бөрөзлексез әрнеде дә әрнеде. Ачлыкка түзүе бик авыр, ә җан сызлавы аннан да хәтәррәк, үлчәүгә сыймас.

***

Авыл... Авыл халкы... Нинди генә дәһшәтләр, нинди генә афәтләр кичерсә дә авыл булып кала. Намуслылык, итагатьлелек, миһербанлылык, ярдәмчеллек (һәй, санап бетерерлекме?)... тагын бик күп, берсеннән-берсе яхшы сыйфатлар хас авыл кешесенә. Халык авыз иҗатында да шәһәргә караганда авыл турында җырлар, бәетләр, табышмаклар, мәкаль-әйтемнәр һичшиксез күбрәк. Дөрес, зимагурлар, Казан, Оренбур, Уфа, Чиләбе калалары да җырларга кергән аңысы. Әмма аларның барысын бергә җыйсаң да, авыл турындагы җырларның чирегенә калэр дә юктыр.

Гөлмәрьям савыга төшкәч, авылдашларның күбесе киңәш бирде:

— Җибәп торма! Иренне дә, силсәвит секретарен да судка бир! Тиешен каерып ал!

— Без шаһит булып барырбыз!

— Закун балалар ягында!..

Тик Гөлмәрьямнең иреннән гайрәте чиккән иде инде. Ул тагын тешен кысып түзде. Уйласаң, бәлки ул үзе дә гаепледер. Йорт Хисами исемендә. Шулай булгач, закон да аның ягындадыр инде. Аннан соң бит әле Хисамины каян эзләп табасың да, судка ничек китертәсең? Судка килә калса да, аның юха елан кебек боргалануын, оятсыз чыраен күрәсе килми. Ул кабахәтнең эче тулы мәкер. Әллә нинди этлек уйлап чыгарып, аның үзен гаепләп куюы да бар. Закон җил тегермәненең канаты шикелле, кая борсаң, шунда борыла диләр. Бәладән баш-аяк! Кирәге юк! Поты бер тиен! Ходай ташламаса — эт ашамас. Менә, кызларын-багалмаларын аякка бастырасы бар.

***

Хисами йорт саткан акчаны кесәсенә салып, сөяркәсе белән Ташкенттан ерак түгел бер совхозга барып урнашты. Ташкент, растан да, «город хлебный» икән. Бирердәге муллыкка аларның исләре китте. Безнең төбәктә халык көчкә-көчкә генә очын-очка ялгап яшәсә, Үзбәкстанда кешеләр балда-майда йөзәләр. Ашарга җаның ни тели, шул бар: төрледән-төрле ризыклар белән кибет киштәләре сыгылып тора. Кием-салым кибетенә керсәң дә шул ук хәл. Безнең якта колхозчы мескен бәләкәй арба белән печән ташый-ташый мал асрап көзге сугымда эче-башы белән генә юанса, ите-түшкәсе белән чутсыз-чамасыз салымнар, кәнсәләргә чакыртып өстәл суга-суга көчләп яздырган заемнар түләргә китеп бара. Монда эчәк юып мәшәкатьләнмиләр дә — чыгарып кына ыргыталар. Чөнки адым саен дүкән-ит кибете. Бәясе дә, кем әйтмешли, шалкан

бәясе: килосы бер сум кырык-бер сум туксан тиен генә! Ул татлыдан-татлы кавын-карбызларның, өрек, шәфталу, йөзем жимешләренең хакы да тиеннәр генә. Менә кайда икән ул жирдәге жәннәт!

Район үзәге Янги-Йул кул сузымында гына. Хисами шундагы мамык эшкәртү заводына эшкә урнашты. Сату-алу тирәсендә тәжрибә туплаган Хөршидәгә сельпода хисапчы эшен ышанып тапшырдылар. Тору урыны да бик жиңел генә хәл ителде. Хөршидәнең бертуган апасы кияве белән байтактан монда яшиләр. Аларның саман сугып (салам белән балчык измәсеннән сугылган кирпеч) төзегән иркен йортында Хисамиларга да урын табылды. Дөнья түгәрәкләнде!

Килгән чорда күз күреме жиргә сузылган мамык плантацияләрен бәрәңге бакчасына охшатканнар иде. Мамык үсентеләренең сабагы да, күпмедер дәрәҗәдә яфрагы да бәрәңгене хәтерләтә. Колхоз басуында үскән мамык сабаклары да рәт-рәт буразна булып утыра. Тик аларны бәрәңге шикелле күмәсе юк. Үзбәкләр буразналарга арыктан су жибәреп сугаралар. Көз көне мамыклар өлгергәч, каплары ачыла. Өлгергән берен жыеп алырга кирәк. Аларны колхозчылар гына жыеп өлгерә алмый. Укучы балалар, студентлар беренче чирекне парта арасында түгел, куна-төнә ятып, мамык кырында үткәрәләр. Мамык эшкәртү заводларында да «урак өсте» башлана. Жыелган мамыкны эшкәртеп, төшеннән мамык мае ясыйлар, мамыгын эскерт-эскерт итеп өяләр. Күләме дә, үлчәме дә безнең яктагы салам эскертләреннән күпкә зуррак. Алар, офыктагы ак болытлардай, әллә каян күренеп тора.

Техника тирәсендә кайнаган Хисамины тора-бара механик итеп үрләттеләр. Дөрес, аның коммунист булуы да роль уйнады. Килгән мәлне ул мондагы коммунистларның холык-фигылен аңлый алмый аптырады. Алар жыелышларда оешма секретареның әйткәннәрен кулларын күкрәкләренә куеп:

– Хуп, мәйле, Иван Степанович! Бәжәрәмез! Кыламыз![2] – дип, берсүзсез жөпләп торалар. Ә жыелыштан чыгуга, бөтенләй капма-каршы гамәл кылалар. Коммунистлар идеологиясенә ихластан инанган Хисаминың шуңа эче поша. Ничек инде житди мәсьәләдә шулай икейөзле булып кыланырга? Ул соңгы жыелышта түзмәде, Казлы Куак авылындагы шикелле чәчрәп чыкты.

– Илдә коммунизм төзү өчен көрәш барганда кайбер коммунистлар үз мәнфәгатьләрен генә кайгырталар. Законга каршы килеп, хужалыкларында егермешәр-утызар баш куй асрыйлар, – диде. Кызып китеп: – Аларга партия сафларында урын булмаска тиеш,– дип, сүзен төгәлләде.

Жыелышны алып баручы фирка секретаре:

– Ә сезнең дәлилләрегез бармы?– дип мәсьәләне кабыргасы белән куйгач, Хисами кабат торып басты.

– Бар! Бригадир Дадабаев Баһадурның хужалыгында егермедән артык куй сарыгы бар. Йөзләгән кош-корт. Гектарга якын жимеш бакчасы! Хет бүген үк раскулачивай!

Хисами жыелышта утырган күп кенә партбилетлыларның да абзарлары тулы мал икәнен, кайбер район житәкчеләренең йөзләгән баш малларын ялчы малбагарлар тауда көтеп йөргәнен, ә Чимган тауларында меңәр баш куйлары, кымыз өчен асраган йөзәр баш бияләре, дөяләре, шәхси биләмәләре белән яшәүче байлар барын белсә, телен тешләп кенә утырыр иде дә бит. Юк, аңа ничек тә үзен күрсәтергә кирәк. Жыелышта Хисами сүзенә карап кына Баһадур Дадабаевны партиядән дә чыгармадылар, раскулачивать та итмәделәр, кисәтү белән генә чикләнделәр. Шулай булса да, Хисами тантана итте, аның сүзенә колак салдылар ич! Киләсе жыелышка тагын да саллырак фактлар табарга кирәк!

[2] (үзб.) Үтибез! Эшлибез!

***

Сонарып кына Үзбәкстанга да көз килде. Иртә-кич салкынча булса да, төш вакытында кояш кыздыра. Иртән киеп чыккан пиджәк артыкка әйләнә. Үзбәкләрнең рәхәт — алар җәйге челләдә дә, көзге яңгырлар яуганда да буй-буй тукымадан тегелгән чапан кия. Шушы юка гына итеп сырган якасыз чапан аларны җәйге челләдән дә, кышкы суыктан да саклый.

Октябрь бәйрәме якынлашып килгән көннәр. Шәһәрләр, кышлаклар бәйрәмгә әзерләнә. Өй түбәләренә «Яшәсен...», «Яшәсен...», «КПССка дан!» кебек шигарьләр язылган плакатлар элгәннәр. Кышлак советы, мәктәп, почта, колхоз идарәсе кебек хакимият биналарына икешәр-өчәр кызыл флаг кадаганнар. Бар җиһан кызыл тәскә чумган диярсең.

Кибеткә дип чыккан Хисами урамда Баһадурны очратты. Ул, берни булмагандай, үзе килеп күреште.

— Һә-ә, сәламәләйкум, Хисами әкә! Әхвәлләр кандай? Сез орышта булган адәм икәнсез, күү! Көн ыссык, әйдән бир пиала чәй дәмләп чыкамыз[3], — дип Хисамины чәйханәгә чакырды. Хисами үзбәкчә өйрәнә башлаган иде инде.

— Рәхмәт, Баһадур әкә! Мән дүкәнгә нан алырга чыгыпмән[4] — дип, аның тәкъдимен кире какты. Баһадур бирешә торганнардан түгел.

— Куй, дүкән ахшамга кадәр эшләйде күү. Киен керерсең. Чәйханәче Эргаш әкә палау кыламыз дипте. — Ул Хисамины ымсындырып бугазына чиртеп алды. — Гәпләшеп утырырбыз.

Сыйланырга яраткан Хисами мондый форсатны кулыннан ычкындырамы соң? Ул әдәп өчен генә Баһадурның тәкъдимен кире кагып маташса да, эченнән генә: «Әһә, минем белән хисаплаша башладыгызмы? Шулай ул!» — дип уйлап алды.

Чәйханәдә пылау әзерли торган казан, көлчә шәкелендәге нан пешерә торган мич — тандр җирдә булса, аяк бөкләп утыра торган дастархан арык өстенә юан-юан бүрәнәләр тезеп көйләнгән. Аста әкрен генә чурлап салкын су ага. Арык, чәйханә тирәсен каплап үскән агачларда кыр күгәрченнәре — мөчәләр гөрли. Рәхәт! Хисаминың күңеле күтәрелеп китте.

Чәйханә кунаклары җай гына һава торышы, дөнья хәлләре турында гәпләшеп утырдылар. Тора-бара мәҗлескә — Баһадурның танышлары иде булса кирәк — әзмәвердәй ике үзбәк егете дә килеп кушылды. Табын мул, аракы су кебек агып тора. Баһадур бармак шартлатуга, бушаган шешә урынына дастарханга икенчесе менеп «кунаклый». Үзбәкстан чәйханәләрендә хатын-кыз заты күрмәссең. Монда һәммәсен: пылавын да, чәен дә ир-атлар әзерли. Чәй эчеп утыручы клиентлар арасында да озын толымнар юк. Унар-уникешәр балалы гаиләдә аларга өйдә дә эш җитәрлек. Чәйханәләрдә тулысынча патриархат!

Мәҗлескә егетләр дә өстәлгәч, әңгәмә тагын да куерып, җанланып китте. Тавыш инде тамак төбеннән генә түгел, бөердән чыга.

Төрле мәзәкләр, ләтыйфәләр[5] сөйләнде. Коммунистлар турында сүз чыккач, фикерләр аерылды. Партиягә ихластан инанган Хисами бәхәсләшә башлады.

— Без коммунистлар партиясе җитәкчелегендә немец фашистларын җиңдек. Киләчәктә коммунистлар Үзбәкстанда, СССРда гына имәс, — ул колачын җәйде. Бөтен җир шарында хуҗа булачак, белдегезме? Менә сезнең кышлакта да партия оешмасы бар. Значит, монда да коммунистлар хуҗа.

Баһадур килешмәгәнен белдереп, кискен генә иреннәрен бер якка кыйшайтып, урт итен «чырт»латып алды. Бу теш арасыннан тын белән

[3] (үзб.) – Хәлләр ничек? Сез сугышта катнашкан кеше икәнсез бит!
[4] – (үзб.) Мин кибеткә ипи алырга гына чыккан идем.
[5] Ләтыйфә – мәзәк яки гыйбрәтле хәлләр турында ике-өч җөмләдән торган кыска гына вакыйга.

сыгылып чыккан аваз ризасызлыкны, «юк!» дигәнне аңлата иде. Аның чырае кырысланды.

— Э-э, Хисами әкә, дөрес гәпермәйсән кү![6] Безнең кышлыкта сән нугай татары да, ак колак[7] Иван Степанович та имәс, — ул йодрыгы белән җиңелчә генә күкрәгенә сугып алды. — Мән хуҗаин, төшенденме?

Хисаминың үзсүзлегенә аракы кайнарлыгы да өстәлгән иде. Ул кызып китте.

— Октябрь Революциясенә кырык ел тулып килә. Сез үзбәкләр һаман шуны аңламыйсыз! — Ул ике бармагын бөгеп арка терәп утырган агач кәүсәсен тукылдатып алды. — Шул кадәр надан булмагыз инде.

Сөйдергән дә — тел, биздергән дә — тел, ди. Ни сөйләгәненне, кайда һәм кемнәр белән утырганыңны чамаларга кирәк тә бит югыйсә. Үзбәкләр бакчасына ыргытылган таш янәшәсендә утырганнарның түтәленә дә килеп төште. Мәҗлестәш егетләр Хисаминың «эчкерсез» бәхәсенә бик тиз нокта куйды...

Ипигә дип чыккан Хисами буш кул белән һәм, өстәвенә, ике тешен югалтып кайтып керде. Бер теше авылда чагында ук «төшкән» иде инде...

...Гөлмәрьямгә өйләнгәненә елдан артык вакыт үтсә дә, Хисами кич клубка килеп яшьләр арасында болагайланып, буталып йөрүен ташламаган иде. Ул көнне дә оя тапмаган күке сыман анда-монда сугылып, кызларга бәйләнеп йөргән салмыш Хисамины яшьләр:

— Хисами абый, син болай да авылның иң чибәрен эләктерден бит инде. Ә үзең һаман кызлар тирәсендә чуаласың, — дип, оялтмакчы да булганнар иде. Кая ул? Әллә аңа әйттеләр, әллә бүтәнгә — ул кулын гына селтәде. Карлыккан тавышы белән җырларга маташты. Гармунчы бию көен уйный башлагач, әрсезләнеп, Мәгъфүрҗан белән сөйләшеп торган кызны биергә чакырды. Кыз ризалашмагач, көчләп кулыннан эләктереп алды, уртага сөйрәп алып чыкмакчы булды. Егет кызны яклап арага керде. Әче бал эчеп, ярыйсы ук «әчеп чыккан» Хисами, галәтенчә, һаваланып:

— Не мешай, маңка малай! — дип, кул аркасы белән генә (әйтерсең, өстәлдәге чебенне куа!) егетне этеп җибәрде.

Сөйгәнен тартып алган Хисамига булган ачуын эченә йотып йөргән Мәгъфүрҗанга үч алырга җай чыкты.

— Кем маңка малай? Минме?

Егет Хисаминың җавабын көтеп тормады, очып килеп боксёрларча кискен генә аның авызына тондырды. Ир гөрселдәп ауды, идән сайгаклары буйлап шуып китте... Сәхнә тактасына башы белән барып төртелде... Егет үрмәләп торып баскан, канлы төкрекләрен чәчә-чәчә сүгенгән Хисамига тагын берне өстәмәкче иде, кызлар арага керде.

Ул чагында Хисами «Син котырткансың аны!» дип, төшкән тешенең үчен бер яклаучысыз бичара Гөлмәрьямнән алды.

Ә монда кемне гаепләргә? Баһадур аңа тырнак белән дә чиртмәде. Тукмаган егетләрне ул белми, күргәне дә юк. Хисами бүген дә бар ачуын хатынынннан алмакчы булып, кайтып керүгә:

— Сельпога товар алырга килгән үзбәкләрне миңа каршы син котыртып җибәргәнсең! — дип хатынына җикерде, әтәчләнеп яңагына чабып та җибәрде. Хөршидә акырып еларга тотынды. Хөршидә Гөлмәрьям түгел. Еласа да, имән бармагын баш очында селки-селки тәтелдәде:

— Мин сине болай гына калдырмыйм!

— Життеме сиңа? Әллә тагын кирәкме?

---

[6] — (үзб.) дөрес сөйләмисең бит;

[7] Ак колак* — «чурка» дип кимсетүләренә каршы русларга үзбәкләр таккан кушамат.

– Иртәгә партком секретарена барам. Гариза язып иманынны укытам!

Партком сүзен ишетүгә Хисаминың хатынына сугарга күтәргән кулы һавада эленеп калды, уен эш түгел, партиядән чыгарсалар нишләрсең, эшеннән очырсалар кая барырсың? Тавышка Хөршидәнең апасы белән кияве йөгереп керде. Бажай чәче-башы тузган Хөршидәне күрүгә, Хисаминың үзен сугып екты. Типкәләргә тотынды. Төшкән тешкә сынган кабырга да өстәлде. Шушы хәлләрдән соң Хисами хатынына бүтән кул күтәрмәде. Киресенчә, ул исереп кайтса, өстенә атланып, Хөршидә аның үзен уклау белән ярды. Рольләр алышынды. Кәҗә мал түгел, бажай туган түгел шул инде. Соңгы вакытларда еш кына аның:

– Үзенә йорт салып керә алмаган нинди ир-ат инде ул? – дигәне колакка чалына башлады, авылда йорт салганын белә югыйсә. Хөршидәнең колагына да чүбек тыкмаган: андый «мактау» сүзләрен ул да ишетә. Ана да уңайсыз. Туганың булса да, өйдәш булып яшәү кемгә дә кыен. Шуннан соң алар тәвәккәлләп тотынгач, бер ел эчендә сеңлесенең йортына терәтеп саман кирпечтән өч бүлмәле йорт житкерделәр. Бер караганда мыжгак бажайның чәйнәнеп йөрүе әйбәт тә булды әле. Үз куышың булгач – рәхәт! Теләгән вакытта бикләп чыгып китәсең, теләгән вакытта кайтып керәсең. Сүз әйтүче юк. Ни өчен өч бүлмәле? Хөршидә малай алып кайтыр дип өметләнде Хисами. Тик, көтеп-көтеп тә өметләр акланмады: Хөршидә кысыр булып чыкты. Булмас иде – унжиде яшендә үк төшерде. Аннан соң да берничә тапкыр булды андый хәл. Белмәделәр генә. Мондый эшләрне тәжрибәле әби-сәбиләр эчкә йомды – читкә чыгармады. Хисами боларны каян белсен? Ул эчтән сызды. Бер-бер хәл булса, үзеннән битәр кешене гаепләргә күнеккәч, Гөлмәрьямне эт итеп сүкте. Шул кипкән тәренең каргышы төшкәндер. «Бала чырае күрмә! Нәселең корысын!» дип каргады бит, явыз. Ул гына гаепле.

Хисами балалары юклыкка борчылып:

– Әйдә, тикшеренеп карыйк әле, – дип, хатынына әйтеп, инәлеп тә карады. Хөршидәнең җавабы һәрчак бер булды:

– Больниска барып, оялмыйча, ир-ат врачлар алдында ыштан төшереп... күрсәтеп утырыр хәлем юк әле. Мужыт син үзең гаепледер.

– Миндә нинди гаеп булсын инде. Өч бала атасы лабаса мин.

Хисами тинтерәткәч, шулай да бер тапкыр чарасын күрде Хөршидә. Хисами да кара чутыр, сельпо шоферы да кара чутыр, эт тә белмәс дип, үзбәк Иркенгә «күз кыскан» иде, нәтиҗәсе генә булмады. Иркеннең хатыны тугыз айдан бишенче бәбиен алып кайтты. Ә Хөршидәдә тугыз айдан да, ун айдан соң да берни юк. Күршедәге үзбәкләрнең ихатасы тулы бала-чага. Балчык дувал[8] аркылы үзләре күренмәсәләр дә, чыр-чу килгәннәре ишетелә.

Уйныйлар, шаяралар, кечкенәләредер инде, елап та алалар. Шулай булса да әти-әниләренең әйткәнен тыңлыйлар, кушкан эшләрен эшләп тә куялар. Ул эшләсен, бу эшләсен, дип бәхәсләшеп тору юк.

Хисами ни эшләсә дә, берүзе. Кул астына керердәй кешесе юк. Чүл бүреседәй ялгыз. Өйдә дә тып-тын. Күңелне шомландыра торган ямансу тынлык. Кайчагында йөрәк сулкылдап, әрнеп куя. Күңелен үкенечле уйлар биләп ала. Далага чыгып борылып та карамый йөгерәсе, тауларга менеп качасы, югаласы килә. Никадәр генә уйламаска, онытырга тырышмасын, юк-юк та туган як та искә төшә. Казлы Куакка кайтып урманнарга керәсе, инеш буйларында йөрисе килә. Бигрәк тә кичке шәфәкъ батканда аның күңелен җирсү биләп ала.

[8] Дувал — (үзб.) балчык койма.

Агыйделгә басма итеп
Кемнәр салган чи киртә?
Чит илләрдә шунсы читен –
Сагындыра кич-иртә,

– дип шыншып та ала ул ялгыз калган минутларда.

Әмма... әмма ... Хәзер ни нәрсә, башыңны ташка орсаң да үткәнне кире кайтара алмыйсың. Казлы Куакка бик кайтыр иде дә бит. Юллар ябык, күперләр җимерелгән, кичүләрнең урыны билгесез. Язмышына буйсынып яши Хисами. Бар курыкканы: эзләп табып алиментка гына бирмәсеннәр! Ул чагында эшләр харап!

Хөршидә болай да: зарплатаңны яшереп калдырасың, уйнаштан туган (коммунист булгач никах укытмады) балаларына җибәрәсең, дип, колак итен ашый. Профсоюз, партия взносларына кадәр тикшереп тора.

***

Авылдашлары никадәр генә кыстаса-үгетләсә дә, Гөлмәрьям Хисамины судка бирмәде, алимент артыннан да йөрмәде. Бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр эшләде. Басудан кайткач, хуҗалыгында тир түкте. Утынын кисте, көрәк сабы сынса үзе саплады, ирләрдән калышмый печәнен чапты, чалгысын чүкеде. Исәя төшкәч, кызлары да кул астына керә башлады: яшелчәләргә су сибү, бәрәңге бакчасын утау, күмү эшләре алар җилкәсенә күчте. Тора-бара ялгыз карчыкларның бәрәңге бакчасында эшләп, үзләренә дәфтәр, каләм ише уку әсбаплары юнәтә башлагач, Гөлмәрьям сөенеп туя алмады. Ә инде урманнан шомырт, гөлҗимеш җыеп, киптереп, күрше авылдагы сельпога тапшырып үзләренә күлмәклек ситса да алып кайткач, Гөлмәрьямнең түбәсе күккә тиде. Ихтыярсыздан, күзләренә шатлык яшьләре бәреп чыкты. Яратып аркаларыннан сөйде.

– И-и, бәхетегез, тәүфыйгыгыз арткыры!

Шулчак кызларының кулларын күргәч, ананың йөрәге «жу» итеп китте, тәне чымырдап куйды:

– И-и, бәбекәйләрем, кулларыгыз песи тырнаган күк булган бит! – Ул үзенең кытыршы куллары белән сабыйларының тырналган бармакларын сыйпады, үбеп-үбеп алды, тылсымлы догалар укып өшкергән әбиләр шикелле, җылы тынын өрде.

Олы кызы, гаепле кеше сыман, акланып азапланды:

– Гөлҗимеш куагы энәле бит, әнкәй.

– Җитте! Урман дип бүтән авызыгызны да ачмыйсыз!

Гөлмәрьям кызларын кызганып берара урманга җибәрми башлаган иде дә, күңелләре күтәрелеп, канатланып киткән балалар барыбер җаен тапты. Әниләре иртүк торып тиз генә мал-туарын карый да, басуга китә. Ул басу капкасын чыгуга, кызлары урманга йөгерә. Хәзер алар гөлҗимеш җыйганда үзләре бәйләгән йон перчатка кияләр. Җыелган җимешләрен абзар түбәсендә киптерәләр.

Алланың биргәненә шөкер, Гөлмәрьямнең кызлары ялкау булмады. Алга таба да эшли-эшли укыдылар. Һөнәрле булдылар. Кыйшайган йорт урынына нарат бүрәнәләрдән яңасын житкереп кердeләр. Кызлар ата-ана йортында кунак кына. Кош балалары шикелле, канат яргач, очалар да китәләр. Гөлмәрьямнең кызлары да кияүгә чыгып берсеннән-берсе унган балалар үстерделәр. Әниләренең йөзенә кызыллык китермәделәр. Төп йортта төпчек кызлары белән яши Гөлмәрьям.

Үткән гомер – искән җилдәй сизелми дә. Инде оныкларны башлы-күзле итәргә вакыт җитеп килә. Ходай кушса, оныклары Алмаз ярәнгә (булачак килен институт тәмамлый) гаилә корырга ниятләп тора. Шул уңайдан җыелган «кинәшмә»гә, күз ачкысыз буран дип тормаганнар, хәбәр салу белән, кызлар,

кияүләр килеп тә житкәннәр. Аларның басса бакыр, типсә тимер өзәрдәй чаклары. Гөлмәрьям аларга карап сокланып туя алмый. Намаз саен аларга бәхетле, тигез тормыш теләп дога кыла.

Чү! Болдырда кемдер бар ахры? Гөлмәрьямнең колагына таякмы, агач аякмы тукылдаган тавыш ишетелде. Ул арада кемдер ишек шакыды.

— Хужалар өйдәме?

Хужаларның жавабын көтмәстән ишек ачылды. Өйгә салкын һава бәреп керде. Аннан соң бусагада таякка таянган сәләмә киемле бөкшәйгән карт пәйда булды.

— Керергә мөмкинме?

Өлкән кияү «Кергәнсең бит инде. Тагын ни кирәк?» димәкче иде, дәү әниләре (кияүләр Гөлмәрьямне шулай дип йөртә) өнәмәс дип, телен тешләде. Гөлмәрьям картны күрүгә нидер шәйләде. Тавышы мескен генә булып чыкса да таныш кебек иде. Хужалар бер мизгелгә тынып калдылар. Кем бу? Эт оясыннан чыкмаслык буранда ялгызы нишләп йөри? Ни өчен әле башка кешеләрнең ишеген түгел, авыл читендәге Гөлмәрьямнәр ишеген шакый? Кияүләрнең берсе телгә килде.

— Абзый, сезгә кем кирәк?

— Хисами мин, Хисами! — диде карт ниһаять.

Гөлмәрьям Хисаминың авылдагы туганнарына: «Ожмах икән монда, ожмах!» дип мактанып хат язганын ишеткән иде.

— Ожмах тормышын ташлап нишләп йөрисең соң әле син монда?

— И-и-и, нинди ожмах булсын инде! Тәмуг булды минем тормышым, Гөлмәрьям. Мин күргәнне эт тә күрмәс. Хәршидә үлде. Безнең йортның янкормасы гына ул дип, өйгә апасының балалары хужа булды. Үзебез салган йорт Хәршидә исемендә дә түгел иде ичмаса. Алар мине типкәләп куып чыгардылар. Хәзер кая барыйм? Ходай хакы өчен кумагыз инде мине. Бусагагызда булса да ятып үлим, — дип өзгәләнде Хисами. Кесәсеннән кулъяулык чыгарып яшьләнгән күзләрен сөртте. Бу минутта ул тулыланып, матураеп киткән Гөлмәрьямнең аякларын үбәргә әзер иде.

— Йолкыш эткә өйләнгәч гаиләң искә төштемени?

— Балалар хакына кичер мине, Гөлмәрьям.

— Ә син балалар хакын хакладыңмы соң? Өч бала белән ялгызымны калдырып качканыңны оныттыңмыни? Күңел өчен генә булса да берәр мәртәбә хат язып балаларыңның хәлен дә белмәдең ич син. Сукыр бер тиенлек тә ярдәм күрсәтмәдең. Минем хәер сорашыр дәрәжәгә житкән көннәрем булды. Балаларны ач тотмыйм дип ашатып, бер язда бәрәңге орлыгы да калмаган иде. Рәхмәт авылдашларга! Ярдәм иттеләр. Кем бер чиләк, кем ике чиләк бәрәңге китерде.

Бу вакытта инде өйләнеп, ике бала атасы булган Мәгъфүржанның да ярдәме турында ул бер сүз дә әйтмәде.

Тамашаны сүзсез генә күзәтеп торган кызларның өлкәне аваз салды.

— Әти, әти?! Кайчан миңа тәмле прәнник алып кайтасың дигәч, кукиш күрсәткән абзый шушымыни инде?

— Әйе, шул. Ул чагында «герой» иде бит ул. Әллә кем булып йөри иде. Ә хәзер, әнә, үзе сабый хәленә калган.

Итәк тулы бала белән ялгызын калдырып качкан, йөрәгенә төзәлмәс яра салган миһербансызга карата хатынның каны каткан иде. Аның йөрәк ярасын ачы күз яшьләре дә, еллар агышы да төзәтә алмады. Ни чәчсәң — шуны урырсың ди. Кызларның чыраенда да рәхим-шәфкать әсәре күренмәде.

Әңгәмәнең кая таба барганын төп йортта яшәүче төпчек кияү чамалады. Ул Хисамины житәкләп алып чыгып китте. Машинасына утыртып район үзәгенә юл тотты. Картлар йортында ут сүнмәгән иде әле. Ул кизү хезмәтен башкарган сестрага пулемёттан сиптергәндәй тезде.

– Сенлем, менә юлдан табып алдым. Катып үлә язган бит. Сугыш ветераны да икән. Үзе безнең як кешесе ди. Зинһар, берәр чарасын күрегез инде.

Төпчек кияү сестраның җавабын көтеп тормады, тиз генә чыгып та китте.

***

Өлкәннәр йорты житәкчесе миһербанлы ханым булып чыкты. Сабый хәленә калган Хисами картның хәлен аңлады. Хакимият органнары белән килешеп, ана урын бирде. Район үзәгендә урнашкан картлар йортында хәзер аның үз караваты, үз тумбочкасы, үз урындыгы бар... Тормышы «түгәрәк». Ярты ел инде ул биредә «рәхәт чигә»...

***

...Көтмәгәндә, уйламаганда Мәрзиянең «Оныгын Алмаз өйләнә! Чакырмый калмаслар!» дигән сүзе аны алгысытып җибәрде, картның күңелендә өмет чаткылары уянды. Аның бу халәте аяк атлап йөрүләрендә үк сизелә иде. Хәтта таянган таягы да гадәттәгедән көчлерәк тукылдады...

Ул әбәткә кадәр ишегалдында юанды. Менә килерләр, менә килерләр дип өметләнде. Туйдагы өстәлләр тулы сый-хөрмәтне, тәмле-тәмле ризыкларны күз алдына китереп, хәтта төшке ашка да бармады. Үзенең «Джип»машинасында жилдерәсен уйлап берара күңеле күтәрелеп китте. Икенде вакыты житкәндә дә аны сорап килүче күренмәгәч, картның күңеленә шик корты керде. Әллә соң... Бабаларын оныттылармы? Юк, юк, булмас! Туй мәшәкате белән башлары каткандыр. Килерләр дип үзен юатты. Берара капка төбенә чыгып арлы-бирле чапкан машиналарны күзәтеп утырды. Тик аларның берсе дә өлкәннәр йортына әйләнеп карамады. Әһ! Әнә теге «Джип» дигәне бу якка борыла түгелме соң? Сул яктагы бәләкәй лампочкасын кабызды! Ниһаять! Хисаминың йөрәге дөп-дөп тибәргә тотынды. Ул торып басты. Ычкынган төймәләрен эләктерде. Тик ... күзеннең явын алырдай елкылдап торган машина өлкәннәр йортына сәлам дә бирми узып китте. Ихатаны үткәч борылышка кереп күздән югалды. Хисами кабат урынына сеңде. Ул башын түбән иеп утырды. Уйларының очы-кырые гына юк иде. «Джип» машинасы шәп инде ул, каһәр. Тик ул кияү белән кәләштән бушамас шул. «Жигули» машинасы жибәрсәләр дә риза Хисами. Ул оешкан буыннар язылмасмы дип, берара койма буйлап арлы-бирле йөренде. Картның жегәре чамалы иде. Тез буыннары калтырый башлагач, кабат утыргычка килеп чүмәште. Күзләрен әлҗе-мөлҗе китереп кабат урам тулып жилдергән машиналарны күзәтергә тотынды. Машина йөртүчеләрнең күбесе борын асты да кипмәгән яшь-жилкенчәк. Кая ашыга торганнардыр, өстенә менәрдәй булып чабалар. Карт эченнән генә аларны эт итеп сүкте. Көн кичкә авышканда да аны сорап килүче күренмәде. Э-эх, «Запорожец» машинасы жибәрсәләр дә кош тоткан сабыйдай сөенер иде Хисами... Юк бит, юк. Күренми...

Кояш батты. Күктә шәфәкъ кызыллыгы сүнде. Шәфәкъ белән бергә Хисами картның өмете дә сүнде...

Күз алдында карачкыдай басып тормас өчен, ул бакча эчендәге куакларга таба юнәлде. Хәзер аның өчен кая барса да барыбер иде. Ул ихатаның бер почмагына – корыган ботаклар, чыбык-чабыклар, чүп-чар өемнәренә килеп чыкты. Кире борылмакчы булган иде, таянган таягына абынып чүп өемнәре өстенә егылды. Аның иреннәре чатнап кипкән, теле анкавына ябышкан иде. Карт кипкән телен көч-хәл белән әйләндереп:

— Миһербансызлар! Сараннар! Туй кадәр туйдан мәхрүм итмәсәгез булмагандыр. Бабагыз ашап бетерер дип курыккансыздыр, — дип үкседе. Аның тире белән сөяккә калган инбашлары дер-дер калтырый иде...

***

Кичке «обход» вакытында Хисами картның югалуы мәгълүм булды. Юрганы да иртән ничек өстеннән бер якка этәргән булса, шул килеш «чәбәләнеп» ята. Хезмәткәрләр өчен хәтере чуала башлаган картның урын-җирен җыештырмавы яңалык түгел, гәүдәсен көч-хәл белән сөйрәп йөрткән картның югалуы гаҗәп иде. Кая киткән? Нишләп йөри? Өлкәннәр йорты кырмыска оясына таяк тыккандагы хәлне хәтерләтте. Хезмәткәрләр, нишләргә белмичә, әле тегендә, әле монда тыз-быз йөрде. Тавышка хәллерәкләр дә бүлмәләреннән чыкканнар иде. Сораштыра, төпченә торгач, Хисаминың төшке ашка да килмәве, кичке ашта да күренмәве ачыкланды. Аның белән бер өстәлдә утыручы астматик бабай иҗек саен туктап сулыш ала-ала булса да, белгәннәрен «сөйләп» бирде.

— У-ул и-иртәнге чәй-не дә каядыр ашыккан ке-ше-дәй, кабалана-кабалана гына э-эч-те. Ә-әбәт ва-кытын-да кү-рен-мәде. Кич-ке а-ашка мин үзем дә ба-ра а-алмадым, — диде. Әби-сәбиләр ни әйтергә белми бер-берсенә карап аптырашып басып торалар. Смена өчен җаваплы шәфкать туташы мескен нишләргә белми коелып төшкән:

— Анкета кәгазьләрендә ул ялгыз дип, гаиләсе дә, балалары да юк дип күрсәтелгән. Аның алып китәр кешесе дә юк бит. Иртәгә мин нәрсә дип җавап бирермен инде, Ходаем, — дип өзгәләнде. Тавышка «тел бистәсе» Мәрзия әби дә чыккан иде. Ул:

— Ник булмасын? Бар! Бүген бит аның оныгы өйләнә. Мужыт шулар алып киткәндер, — диде.

Дежурга килгән санитарка ханым да:

— Әйтәм җирле, ике көн элек миннән күлмәк-чалбарларын үтүкләткән иде, — дип, Мәрзия әбинең сүзен җөпләде. Шаулаша торгач, аларның фаразына тагын бер дәлил өстәлде.

— Кемнедер көткәндәй капка төбендә утырып торганын мин дә күрдем, — дип сүз кыстырды сыңар күзен кара пәрдә белән каплаган бабай. — Хәзер бит урам тулы машина. Кемнең кая чапканын кем белә? Тим боли оныгының туе да булгач, выжлап килеп туктаганнардыр да, утыртып алып та киткәннәрдер.

Саңгырау күп ишетә, сукыр күп күрә, ди. Кизү хезмәткәрләр шуннан соң гына бераз тынычлангандай булдылар. Алар сөйләгәнчә булган очракта да гариза язылмаган, журналга теркәлмәгән. Димәк, карт «самовольничать» иткән — тәртип бозган булып чыга.

***

...Чүплектә, чүп-чар арасында аунап яткан Хисамины икенче көнне генә табып алдылар. Бу вакытта инде дөнья белән алыш-бирешне өзгән картның гәүдәсе таш булып каткан иде. Хисаминың авызы җим өмет итеп чыелдашкан кош балаларыныкы кебек ачык калган. Ул нәрсәдер әйтмәкче булганмы, бер йотым су сораганмы? Билгесез. Белсә дә, бер Ходай үзе генә белгәндер...



Лениза
Вәлиева

## ЯШӘҮ — МӘЙДАН...

* * *

Күзләрдән сирпелгән яктылык
Уелып күңелдә калырлык.
Билгесез, шик тулы бу халәт
Әллә төш, әллә соң чынбарлык?!

Чиксез күк — болытлар кәрваны,
Җаныма тоташкан дәвамы.
Ирендә — иртәнге чык тәме,
Үткәннең бүгенгә хәбәре.

Дөрләсен иң соңгы күперләр,
Атылсын күкрәктән күнелләр.
Ялкыннар көйдерә учларны —
Без чүгә торганнар түгелләр!

Ут аша сузыла кулга кул.
«Йөрәгең каршында тугры бул» —
Үземә бирелгән нәсыйхәт.
Хис — хужа, ә акыл — бәйсез кол.

Кайда, кем булсам да, барыбер
Кайтырмын әйләнеп сиңа, бел.
Кайтырмын, барыбер котәрсең —
Күңелне алдауның чиге бер!

Лениза ВӘЛИЕВА – *шагыйрә; «Диңгездә йолдыз коена» исемле китап авторы. Казанда яши.*

* * *

Ялларымны жилләр тарый,
Тоягымнан чыга ут.
Ярсып-шашып алга ыргылам,
Туктатырлык киртә юк.

Ефәк ялым, ай, елкылдый
Язгы кояш нурында.
Мин йөгерәм, шат уйнаклап,
Йолдыз чәчәм юлымда.

Майдай жылы саф һаваны
Күкрәгем белән ярам.
Офыкка тәгәри кояш,
Шәфәкъне иңләп барам.

Ялкаемны жилләр тарый,
Тоягымнан оча ут.
Яшәү — мәйдан.
Чын тулпарга
жиңүләрсез китү юк!

* * *

Бер йомарлам итеп учка төйнәп,
Күкрәгемә кысам хыялларны.
Бу — яу кыры, ә син, атсыз яугир,
Үтәрсеңме калку кыяларны,
Адашмыйча барып житәрсеңме
Исән-имин торткан максатыңа,
Калмассыңмы маяк табалмыйча,
Үтәлмичә юлның яртысын да?!
Чәчләремне артка сирпеп шулчак,
Шашып-ярсып көләр идем синнән.
Жиңәм, димә. Тормыш — хәтәр уен.
Кан тамчысы тамды хәнжәремнән.
Итәкләрне ялмый ялкын теле,
Һәр күзәнәк кыза кайнарыннан,
Бер гөнаһсыз сикереп чыгам димә
Дөрләп янган учак аймагыннан.
Тезгеннәрен бушат чаптарымның,
Томырылып күккә очсын фәләк.
Жир сулышы өтә күкрәгемне,
Офыкларда тибри алсу шәфәкъ.
Ай коенган дәрья куенында
Сафландыра гүя жан калыбын,
Төн жырына изри-изри тарыйм
Туарылган аргамагым ялын.
Аһәңнәре көйнең чыңлый канда,
Толымнардан тама дәрья суы.
Колагымда шаулый шанлы тарих.
Колчанымда — соңгы алып угы.
Йөгәненнән тотып акбүз атым,
Еллар, чорлар аша бар үтәсе.
Комга уелып кала безнең эзләр.
Офыкларны ялмый таң шәүләсе...

* * *

Уч төбендә — шадра киндер.
Яз сулышы — иренемдә.
Зинһар, дәшмә! Татлы тынлык
Хөкем итсен бу мизгелдә.
Буяу исе катыш сафлык...
Җил урала пәрдәләргә.
Бу — беренче Казан язы...
Ялкын тибри шәмдәлләрдә.
Бу бит тәүге тәкъдир язы...
Соры күздән торган еллар...
Тәрәзәдә — Казан күге —
Хәят күгем — ай, йолдызлар.
Күкрәгенә ятып төннең,
Тынлыйм әле тынлык шавын,
Җан яралган мәлдән барган
Аек акыл һәм хис явын.
Бу алышның дәвамы юк.
Шашындыра җиңү тәме,
(Кан-яшь аша килгәнгәме?!)
Ялкынлана гомер шәме.
Ин кыены — йодрык төйнәп
Буйсындыру үз-үзенне.
Ачык төсләр сайла, язмыш!
Учка җыям соң түземне.

Ялкын теле — тәрәзәндә...
Тыелып кына сызыла ал таң.
Ниләр сөйли җанлы киндер,
Күзләренә багып уйчан?!

* * *

Бу — апрель.
Җанымның тулышкан,
Чайпалып түгелер фасылы.
Бөрешкән күнелне эретер күзләрдә —
Яшәүнең асылы.
Соң түзем төйнәлгән учларда кайтаваз —
Җиңүнең хәбәре.
Күзләрдә — әллә яшь?!
Җанымның язмышка җиңелү әләме.

Бу — апрель.
Соң өмет кыллары, тартышып,
Киергән җәядә.
Бизмәнгә салынмый хәрабә бәһасе,
Үлчәнми бәядә.
Бушаган яу кыры —
Күңелдә кынына
Куелган соң кылыч.
Мөлдерәп, күкләргә төбәлгән караш та
Яңгырый ышаныч.

Бу — апрель...
Тезгеннәр бушаган жанымда
Уйнаклый яшь колын.
Томаннар пәрдәсен мәңгегә эретеп
Ачыла киң болын.

* * *

Лачыным очырдым чиксез күк куенына.
Аргамак атымны иярләп,
Артыннан омтылдым. Кин дала — тирә-юнь.
Ташкынны торалмыйм йөгәнләп.
Чәчләрем тарала искән жил көенә;
Бөтерә энжеләр биюе —
Тантана, пакь жиһан һәм апрель янгыры —
Илаһи дөреслек жинүе.
Калыбын тарсынып шашына тынмас жан:
Ашкынам язылган язмышка.
Ыргыла аргамак, ут чәчеп тояктан,
Чыкканын тойган күк узышка.
Йөземне иркәли әллә соң салкын яшь,
Янгырның кайнармы тамчысы?!
Зөләйха ядкәре кулымда — Йосыфның
Сулыштан ут кабар камчысы.

* * *

Өметләр, хыяллар дөньясын калдырып,
Ярсыган йөрәкне әрнетеп яндырып,
Йомарлап учларга ташыган хисләрне,
Дөрләтеп ялгызым үткәргән кичләрне,
Өр-яңа язмышка ашкынам, ашыгам.
Туктатам дип чыкма, үтенәм, каршыма.
Тәкъдиргә баш иеп яшәләр гомерләр,
Күңелдә сулырлар аталмый бар гөлләр,
Иреннәр елмаер «Нихәл, син?» дигәндә,
Язмышлар чатына ялгышып килгәндә.
Йөрәкләр, өзелеп, һаман да пышылдар,
Ә акыл әзерләр сөюгә агач дар...
...Мин күптән мин түгел: ят йөзләр, чит шәһәр...
Үземне табалмый түгелде соңгы хәл...

...Диварда — шәүләләр, бүлмәндә пыскый шәм.
Чиксезлек чигендә тик жансыз күләгәм...

Рифкать Хуҗи

# БЕР КӘНДИ[1] ЦЕМЕНТ

ХИКӘЯ

Әле кичә генә урамда алтын көз иде. Әбиләр чуагы. Ә төнлә ачы җил чыгып, алтын-кызыл яфракларны жиргә койды, авыр кара болытлардан бертуктаусыз салкын яңгыр сибәләде. Бер төн эчендә дөнья шулай танымаслык булып үзгәрде. Салкын юештә каралып калтыранган агачларга каравы кызганыч та, куркыныч та иде.

Һәмдия әби салкыннан калтыранып уянды. Инде сәгать бишләр тирәсе булса да, урам кап-караңгы иде. Киез-каталарын эзләп табып киде, сырмасын аркасына элде дә тизрәк мичтәге чыраларга ут үрләтеп җибәрде. Әмма берничә мизгелдән үк өй төтен белән тулды. Хәер, шулай буласы билгеле иде инде ул. Әле дә ничек урталай ярылмый диген бу мичне. Үзе белән бергә картайды бит инде. Көймәсе дә «менә төшәм, менә төшәм» дип кенә тора. Ел саен бөтен ярык-тишекләрен балчык белән сылап, аннары акбур белән агартып чыга иде. Иң мөһиме — чормадагы таш морҗаны яхшылап карарга кирәк. Анда ярык булдымы — тартмый да тартмый инде төтенне. Түбәгә менеп, цемент белән морҗа төпләрен дә сылап төшә иде. Югыйсә шуннан яңгыр-кар сулары аска агып, сылаган балчыкларны юа да төшерә. Юк шул, булмады быел — көзен озак кына авырып ятты. Бу мөһим эшләр эшләнмичә калды....

Ишекне дә ачып куеп карады Һәмдия әби — төтен генә өйдән чыкмады. Чыралар бик тиз янып бетте — ә өй эче күзгә күренеп салкыная башлады. Һәмдия әби пәлтәсен дә киеп алды. Шул чормага менеп, морҗа төпләрен сыламый булмас! Балчыгы бар барын, тик аңа азрак цемент кушарга кирәк. Югыйсә яңгыр балчыкны бик тиз юып төшерә. Булырга тиеш ансы да — улы Таһир бер капчык кайтарып киткән иде.

Абзар-кура тирәсенә чыгып эзләп караса да, һич кенә дә таба алмады Һәмдия әби шул цементны. Кибетендә дә юк бит аның ише әйбер! Хәер, авылдагы карт-корыга нигә хаҗәт ул?! Ә йорт-жир салучы хәлле кеше үзе алып кайта аны Казаннан. Һай, Аллаһының рәхмәте төшкере — «йорт салучы» дигәннән исенә төште әле... Сон, күрше Таһир да үткән атнада гына бер машина төяп кайтты бит шуны. Юк, өй салырга түгел — ике катлы таш коттеджына өч ел элек күченгән иде инде. Хәзер машиналарына гараж салырга җыенып йөргән чагы...

Һәмдия әби, бер кәнди алып, күрше Таһирларга юнәлде. Үз Таһиры кайтарган теге цементны тапкач та бурычын кертеп бирер анысы...

Күрше дигәч тә — ундагы өч, каршыдагы ике йорт күптән инде жансыз.

[1] Кәнди – тирән аш тәлинкәсе.

Рифкат ХУҖИ (Рифкат Хуҗиәхмәтов, 1958) – *галим, прозаик, Казан милли-тикшеренү технология университеты доценты. Казанда яши.*

Таһирларга килеп житкәнче дә дүрт йортнын аркылы такта кадакланган шомлы тәрәзәләре генә озата бара. Аяк асты тайгак, абына-сөртенә көч-хәл белән генә барып житте Һәмдия әби...

Таһир өстәл янында ялгызы гына чәй эчеп утыра иде. Хатыны сыерларын сава булыр, балалары торырга иртәрәк әле.

— Улым, моржа төбе сыларга азрак цимынт табылмасмы икән?

— Юк! — диде Таһир, башын да бормыйча.

«Ак» димәде, «кара» димәде Һәмдия әби. Тавыш-тынсыз гына ишек-капкаларын ачып, урамга чыкты. Шунда гына йөрәге чәнчеп алды да күз аллары карангыланып китте...

...Күзен ачса — урамда жылы, кояшлы май, имеш. Бөтен жирдә яшеллек, алмагачлар ап-ак чәчәктә утыра! Менә ул үзе — яшь, чибәр башлангыч сыйныфлар укытучысы — улы Таһирны житәкләп, капкадан чыгып килә. Сул як күршеләрнен дә, ун яктан да капкалар ачылып, һәрберсеннән үзендә сабак алучы сабыйлар күренә. Барысы да ана:

— Исәнмесез, Һәмдия апа! — дип елмая.

Әнә, Сафура апанын капкасыннан да, сенлесе Сажидәне житәкләп, тагын бер Таһир чыга.

— Исәнмесез, апа!

— Исәнме, Таһир улым!

...Һәмдия әби, аңына килеп, күзен ачты. Юк, урамда жылы май түгел, кара көз! Ул да яшь укытучы түгел — карт, хәлсез бер карчык... Мәктәпкә дә барышы түгел, жирдә аунап ята икән... Көч-хәл белән пычрак жирдән торып, әүпән-тәүпән үз өенә таба атлады ул. Буш кәнди капка төбендә аунап калды...

Күпме ятканын хәтерләми, шул арада салкын желегенә үтеп тә өлгергән икән. Бөтен гәүдәсе калтырана, самавырын куеп, кайнар чәй эчәргә дә рәте калмаган иде инде. Юеш, пычракка баткан сырмасын гына салды да урын өстенә ауды... һәм шул мизгелдә үк үтә дә бер рәхәтлеккә чумып, жинеләеп калды. Ягылмаган өй дә, юеш киемнәр, салкын түшәк тә эреп юкка чыктылар. Ярым уяу, ярым йокылы халәтендә тормыш юлы йомгагы кирегә сүтелә башлады Һәмдия әбинен. Тик, нигәдер анын күз алдында, беренче чиратта, күрше Таһир белән бәйле вакыйгалар гына калкып чыга торды...

...Әнә алар — ике күрше, ике Таһир, Һәмдия апа сыйныфында, иң алгы партада бергә утыралар. Ул аларнын икесенә дә «Улым!» дип эндәшә. Икесе дә яхшы укыйлар. Тик холык-фигыльләре — жир белән күк арасы, ничек дус яшиләрдер — аңлавы да читен. Үз Таһиры — эт борчасы инде менә — тиктормас, шаян, чая, гел хәрәкәттә булыр. Күрше Таһир — анын нәкъ киресе! Әтисез үскәнгәдер инде — гел боегып йөри. Уйнавын да күбесенчә сенлесе белән икәү генә уйныйлар. Урам балалары да аларны үз араларына кертергә бик теләми: «Барыгыз, китегез, сезнен белән уйнарга кызык түгел!» — диләр. Кайчакларда әле суккалап та алалар. Дәшми Таһир, башкалар кебек үзен яклап сугышмый да.

Ә бер тапкыр аны ярыйсы ук каты тукмап ташладылар. Шулар, арттагы партада утыручы Сафа малае белән Исмайныкылар инде. Контроль эшне күчертмәгән өчен. Аулак тыкрыкка очраклы рәвештә генә борылган иде Һәмдия апа. Ә анда... кара тузан эчендә ап-ак күлмәктән аунап ята малай, үзе күз яшьләренә буылып, үкси-үкси бер үк сүзләрне кабатлый:

— Әтием булсамы... Минем дә әти булсамы!..

Ну, эләкте инде тегеләргә дә! Бу вакыйгадан сон Таһирга берәү дә, бер генә тапкыр да чиртеп тә карамады хәтта.

Сафура апанын белем ягы чамалы иде, житмәсә үзе көне-төне эштә булыр. Һәмдия апа анын Таһиры белән Сажидәсен гел үзенә чакырып, дәрес

хәзерләргә булыша иде. Көчен, вакытын кызганмыйча. Өстәлдә булганы белән сыйламыйча чыгармас үзе. «Ятимнәргә акчалата ярдәм итәргә кирәк!» — дип, районлагы мәгариф бүлеге юлларын да әз таптамады. Кытлык заманасы бит — үз Таһирының әле өр-яңа диярлек өс-баш, аяк киемнәрен яхшылап юып-чистартып, гел Сафура апаларга кертеп килә торды.

Мәктәпне тәмамлагач та, армиядә ике Таһир бергә хезмәт итеп кайттылар. Сафура апа бик картайган иде, шуңа да аның Таһиры авылда торып калды. Күрше авыл кызына өйләнеп, матур гына гаилә корып җибәрде. Бер-бер артлы нарасыйлары туды. Тора-бара җиңел машина да алды. Хәзер инде ул боегып түгел, башын югары күтәреп, горур атлап йөри башлады. Машинасында «выжт» итеп, сәлам дә бирмичә үтеп китә.

Тыштан үзгәрсә дә, элеккечә үз эченә бикләнеп кала бирде Таһир. Бердәнбер якын кешесе — әтисе урынына калган олы абыйсы белән генә ачылып китеп аралаша иде ул. Абыйсы авылга кайтканда, бөтенләй икенче була — шат, көләч, ачык йөзле, барысына да булышырга әзер торучы мәрхәмәтле кешегә әйләнә. Тик, кырык яше дә тулыр-тулмас, китеп барды шул абыйсы... Шул чакта янә бер тапкыр Таһирның елаганын күрде Һәмдия апа. Малай чакта елаулар күп була ул. Ә менә ир уртасы булганнарны бары тик олы кайгы гына шулай өзгәләндерә торгандыр.

«Абыегыз вафат!» дигән телеграмманы кулына кысып тоткан килеш Һәмдия апасына төн уртасында килеп кергән иде Таһир.

— Ничек, ничек әйтим әнкәйгә бу турыда, апа? — дип, тыела алмыйча үкси-үкси елады ул мич артында.

...Бу хәбәрне ишеткәч, әнисе түшәккә егылды. Аны артык борчымас өчен, абыйсының өчен дә, җидесен дә Һәмдия апаларда үткәрделәр.

Олы улы кайгысыннан Сафура апа да озак тормады. Ярты ел дигәндә аны да җирләделәр.

Бу хәлләрдән соң Таһир бөтенләй үз эченә бикләнде. Хатынының туганнары белән болай да сирәк аралаша иде — хәзер инде бөтенләй юлны өзде. Авылдагы туганнары белән дә рәтләп сөйләшмәс булды. Хәер, бер карасаң — ул карт-коры, карчык-корчык белән ни турында гәпләшсен инде?!. Алай дисәң, бердәнбер сеңлесе Сәҗидә белән дә аралашмый диярлек. Коттедж салып керде, өй туе үткәрде. Әллә чакырмаган, әллә чакырып килмәгән, туйда сеңлесе күренмәде. Зиратта абыйсы белән әнисенең каберләрен чүп үләне баса, барып чистартмый Таһир. Сеңлесе җәйгә бер тапкыр кайтып, аларны утап чыга, утырып бер туйганчы елый да, бушанып калгач, абыйсына кереп тормыйча, Казанга китеп бара.

Һәмдия әби дә, тирә-күрше дә Таһирның капкасын ачмас булдылар. Ник кенә бу юлы шунда керәсе итте икән??? Һәмдия әби күзләрен тутырып ачты да... алар инде бүтән ябылмадылар...

«Нигә шушындый салкында төтене чыкмый моның?» — дип, каршыдагы күрше карчыгы икенче көнне генә керде...

Үлемтеккә дип сандыгында барысы да күптән хәзерләп куелган иде инде Һәмдия әбинең. Лапастагы ләхет такталарын да әйбәтләп-таслап өеп куйган булган. Алар янында торыпша белән капланган бер капчык цемент та бар иде...

Янгыр коеп торуга карамастан, зиратка бөтен авыл җыелды. Аларның яртысы диярлек Һәмдия ападан беренче сабак алган укучылар иде.

...Зираттан таралышучы халыкка пычрак чәчрәтеп, зур тизлектә йөк машинасы үтеп китте.

Күрше Таһир тагын каядыр ашыгып китеп бара иде...



Ленар
Шәех

# ҮЗГӘРЕШЛӘР – АДЫМ САЕН

* * *

— Күпне күргән татар аналары,
Кан-яшь түккән татар әбиләре,
Хәлегезне ничек жинеләйтим? –
Дисәм, сыкрый сугыш жөйләре.

Яшь-яшь көе, тормыш башлаганда,
Сөйгәненне сугыш кырында
Югалт та син... аннан мөмкинме соң
Уйлау якты тормыш турында?..

Мыек тибәргә дә өлгермәгән
Сабыенны тимер табутта
Кабул итеп ал да жиргә иңдер...
Киләчәкне ертып як утта.

Картаялмый калган балаларны,
Жан бәйләнгән сөйгән ярларны
Уйлыйм да мин, борчуларга калам,
Дога гына көтә. Алармы?..

Үткәннәрне актарыплар ташлап
Булмый икән, булмый... – салават!
Киләчәктән килә нәни сабый,
Янәшәдә бара бала-ат.

Күпне күргән татар әбиләре,
Кан-яшь түккән татар аналары
Гомер буйлап сыкрый-сыкрый барыр,
Төзәлалмас инде яралары...

Үлгәннәргә дога гына кирәк,
Искә алып тору вакыт-вакыт.
Беркайгысыз дәвер бер килер ул,
Сорап тормас, тормас ишек шакып!

Ленар ШӘЕХ (1982) – *шагыйрь; «Дүртенче кат... Бишенче кат...», «Җылытасы килә дөньяны!», «Алдамыйм!» һ.б. китаплар авторы. Татарстан Республикасының М.Җәлил исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

* * *

Шәһәр шаулый. Тормыш бара.
Кешеләре өер-өер,
Машиналар көтү-көтү...
Барысы — чын, кызык, сәер.

Ашыгалар кешеләр дә
Машинада, метросында.
Кайда акча койрык болгый,
Ябырыла бар да шунда.

Ә акчасыз яшәп булмый.
Һәр адымың, һәр сулышың
Акча сорый. — Рәхәтеме,
Михнәтеме бу тормышның?!

Күнелләрдә тынычлык юк,
Ышанычы бармы, белмим?..
Очын-очка ялгаучылар!
Сезне уйлыйм, жәллим... көлмим.

Чүпрәк янчык бушап тора,
Тулмаса да инде тулмый...
Шәһәр бит ул авыл түгел,
Күкрәк киереп сулап булмый.

Кайда урман, кайда болын,
Кайда бакча, ахыр чиктә?!.
Барысы таш, барысы туң,
Тимер ишек җиде биктә.

Шәһәр шаулый. Тормыш бара.
Тормышмы бу? Шулдыр, хаер.
Көтү-көтү еллар чаба,
Барысы — чын, моңсу, сәер.

## Февраль әллә яз аемы?..

Февраль әллә яз аемы?.. —
Хәтта мартны көтеп тормый,
Ярсый-ярсый тамчы тама,
Түбәдән кар урлый-урлый.

Шыпырт кына сулар ага,
Зур ташуга сәбәп булып.
Дөнья үзгәрә,
кышларның
Атналарын йолып-йолып.

Кышның чиге артка чигә,
Ул кысыла аның саен.
Табигатьне аңлап булмый,
Үзгәрешләр — адым саен.

Болай барса, ап-ак карлар
Төшкә керер, сагындырыр.
Кыш сиздерми китеп барыр,
Ул тиз килмәс – ялындырыр.

Кырлачлары, бураннары
Бүген генә ялыктыра...
Ә иртәгә хәбәр килсә:
«Быелга кыш калып тора!»

Февраль әллә яз аемы?.. –
Көнелләрне утка сала
Фасылларның чуалуы,
Үткәннен тоныклануы,
Гадәтләрнең югалуы.

* * *

Еллар оча, еллар оча,
Китап битен актаргандай
Язгы җилләр, җәйге җилләр.
Көн коела, ә тоела
Бер урында таптангандай.

Еллар үтә, еллар үтә,
Вакыт – чиге-чамасы юк,
Сузыла ул чиксезлеккә.
Бер кат тамган тамчының да
Кабат-кабат тамасы юк.

Еллар арта. Еллар артта
Ялтыр-йолтыр килеп кала
Сибелепләр-чәчелепләр.
Мизгелендә гүя очкын
Кабына да һәм югала.

Еллар оча, еллар оча,
Күзне ачып йомган кебек,
Ул шулай тоелган кебек.
Ерактагы эзне дингез
Дулкыннары юган кебек,
Алар арттан куган кебек.

* * *

Мәскәү урамнары буйлап
Атлап киләм озаклап.
Тырышсам-тырышмасам да
Китә алмыйм тиз атлап.

Бар нәрсә дә якын монда,
Шул ук вакытта чит тә.
Мәскәү – Казан, Казан – Мәскәү –
Икесе ике чиктә.

Мәскәүнең биек йортлары,
Иркен киң урамнары,
Метросы, Останкиносы,
Кызыл мәйдан аннары –

Барысы да горур, мәгърур –
Күңелне хисләндерә,
Шул ук вакыт шикләндерә,
Шатлыкны төсләндерә.

Башкала дисән, башкала!
Үсә, җәелә – чик юк.
Мәскәү – Мәскәү урынында,
Казанга җитми тик... юк!

Казандай кысылмаган шул,
Казандай басылмаган.
Кайчандыр дөрләп янса да,
Бирелмәгән, сынмаган.

Казан сынган, нишләтәсең,
Язмыштан узып булмый.
Үткәннәрне үлчәп була,
Анда кул сузып булмый.

Мәскәүдә татар эзләре
Бар алар... адым саен.
Кочагына сыендырган
Безне — үги малаен.

Мәскәү, Мәскәү! Якын да син,
Шул ук вакытта чит тә...
Икебез ике чиктә шул,
Икебез ике чиктә!..

## Авыл

*Хәлең ничек, авыл?*
Р.Фәйзуллин

Хәлең ничек, авыл? —

Бер җинел һәм авыр.
Урамнарда тынлык,
Күңелемдә — давыл.

Бакчаларда үлән.
Күптән күрше-күлән
Асрамый шул малны.
Гөрләп торган авыл
Бүген малсыз калды.

Кибет тулы ите,
Каймак, мае, сөте...
Нәрсә кирәк тагын?.. —
Фермаларда, әнә,
Түбәнәя савым.

Буш басулар да бар.
Нишләтәсең — базар!
Житештерү нигә
Кирәк икән безгә?..
Нидер ашыйбыз ла,
Нидер эчәбез лә...

Бәрәңге күп түгел,
Шулай да көр күңел —
Ашау... утыртырга...
Житә инде, житә, —
Күп кирәкми шуна...

Телевизор карый
Авыл халкы. Арый
Йөз каналны тыңлап. —
Күзләр кызарышкан,
Колак тора чыңлап.

Интернет бар — гөрли,
Беркем «эшсез» йөрми.
Телефоннар «тота». —
Авыл җанын шулай
Гамьсезлекме йота,
Мәнсезлекме йота?..

Дөрес, яшьләр калмый. —
Эшли армый-талмый
Кала тирәсендә...

Сорап кара, авыл
Кирәк түгел микән
Анда берәрсенә?..

...............................

...Жил токтасы — давыл.
Ил токтасы — авыл!
Шулай укмы соң ул
Хәтерләрдә генә,
Хатирәдә генә
Яшәп кала алыр?..

Рәйсә
Юсупова

# БҮРЕ ЕЛАГАН ТӨНДӘ...

...Ул чакыру көтте. Көтеп-көтеп тә килмәгәч, театрга үзе китте. Тик билетлар юк иде инде. «Урыннарны обком алды, — диде кассада утыручы хатын, — сатуга бер билет та бирмәделәр». Инде директор бүлмәсенең ишеген шакудан башка чара калмаган иде. Әмма аның юлына секретарь кыз аркылы төште: хуҗаның беркемне дә кабул итә алмавын, юбилей уңаеннан бик тә җитди җыелыш баруын бәйнә-бәйнә аңлатты. Көтеп утырырга ниятләгән Ханымга кисәтү дә ясады: ярамый! Аяк астында буталып йөрүчеләрне күрсә, хуҗа кызны эштән куачак икән.

Юк, бу ябь-яшь кызны эштән кудырасы килми иде Ханымның: «Әле биш көнләп вакыт бар, директорның бушрак чагын туры китерермен бер», — дип юана-юана ишеккә юнәлде. Әмма калган көннәрдә аны секретарь кыз бүлмәсенә дә үткәрмәделәр.

Ниһаять, театрның юбилей көне туды. Ана анда бармыйча, юбилей кичәсен күрмичә калу — үлем белән бер иде. Барачак ул кичәгә, барачак!.. Обком үзе билет таратып йөрмәс бит инде. Әйе, берәр җаваплы кешегә исемлек тоттырганнардыр да, кичәгә килүчеләрне шул барлый булыр.

Исемлекнең башында ук түгел микән әле аның исеме?!.

Президиум өстәленә утыртырга ниятләсәләр — сонару килешмәс, җыена башларга кирәк булыр. Тик менә... Көне-төне театр тирәсендә йөреп, зәвык белән киенү кирәклеге онытыла язган икән лә... Кара йон күлмәге бар барын. Тик аны кисә, мондый тантанага килешмәс шул. Ак челтәрле яка куйса, бала-чага сыман диярләр. Нечкә үкчәле кара туфлиенә озын кара юбкасы, затлы ак кофтасы бик килешле югыйсә... Шуны кияргә кирәктер, мөгаен... Энҗе-укалар белән чигелгән кара бәрхет калфак исә кырау кунган чәчен каплар. Кара пәлтәсенә киез кара эшләпәсе дә туры килеп тора. Җәй-көз кигән эшләпә булса соң! Кызыл роза чәчәкләрен сүтеп, мех кисәге белән бизәп була бит аны... Искергән кышкы пәлтә якасының бер чугы җитәр үзенә. Ул әле килешле генә ятыр эшләпәгә — ком төсендәге чәшке койрыгы...

Кыш уртасы димәссең, Ходайның рәхмәте, иртәдән бирле кояш елмая; димәк, көзге кием белән дә өшемәячәк ул, боерса, өшемәячәк. Ара да якын гына лабаса! Тыкрыктан урам буйлап күтәрелсә дә Горький урамына аяк басасы. Анда инде сине мәшһүр Камал театры каршылый...

...И хыял! И өмет! Ишек сакчысының көрәктәй кулы үзен читкә этәргәндә, Ханымның әлеге матур хыяллары чәлпәрәмә килде. Өмет чаткыларына бозлы су сипкәндәй, җаны өши башлады. Әмма аны театр ишеге янынннан еракка-рак алып ату мөмкин түгел иде инде. Үлсә үлә, тик ул бу кичәне күрергә тиеш! Әйе, тиеш!!! Шушы теләк, шушы өмет аны шушы яшькә, шушы көнгә хәтле яшәтмәдемени?!. Яшәвенең бөтен мәгънәсе театр булуы турында ул шушы

юбилей кичәсендә чыгыш ясарга, соңгы тапкыр тамашачыларына баш иярга хыялланмадымы?!. Әйе, керәчәк ул театрга, һичшиксез, керәчәк!.. Бәлки әле таныш артистлар да очрар? Алар аны, әлбәттә инде, үзләре белән иярттәчәкләр. Тик әнә ишектә торучы сакчы гына... Янәшәсендәге егеткә аны күрсәтә-күрсәтә нидер әйтә шикелле...

Ялгышмаган икән, ялгышмаган: алыптай егет үзен култыклап алды да искәанга килергә өлгергәнче урамга чыгарып та бастырды. Имән бармагы белән күккә ишарәләп: «Буран башланырга тора, өегезгә генә кайтасыгыз бар, апа», — дип тә өстәде.

Ханым башын күтәрде. Күк йөзе чыннан да карасу болытлар белән капланган иде. Әйтерсең лә алар җирне дә каплау өчен җай эзлиләр... Кичә башланырга ярты гына сәгать калып килә — түзәчәк ул буранга да, җил-давылга да түзәчәк...

Биткә беренче кар бөртекләре кунганда, театрга якынлашучы бер төркем күренде. Төркемгә Ханым да кушылды, ишеккә дә төркем уртасында якынлашты. Әмма шул ук көрәктәй кул аны читкә этәрде. Ә төркем-төркем килгән кешеләр исә, бәләкәй генә буйлы, чандыр гәүдәле бу Ханымны таптый язып, агылды да агылды.

Машиналарыннан төшкән түрәләр арасына да сыенмакчы иде. Кая ул: әллә каян гына пәйда булган соры киемле ир-егетләрнең терсәкләре янә аны читкә кысрыклады. Нәкъ шул мәлдә, әйе, әйе, ул аны, түрәләрне каршылап торучы якты йөзле директорны күрде. Күрде дә, бәләкәй куллары белән ишкәк ишкән хәрәкәтләр ясый-ясый, аңа якынлашмакчы итенде...

...Йа Хода! Ул — берүзе — урам уртасында басып тора түгелме?!.. Театр ишекләрен дә эчке яктан бикләп өлгергәннәр. Түрәләрне алып килгән машиналар да китеп беткән. Театр тирәли йөренгән соры киемлеләрне исәпкә алмаганда, ул — япа-ялгыз...

Пыяла кыйпылчыклары диярсең — битне кар яфраклары кисә. Керфекләрдән энҗе бозлар тәгәри. Ачы буранның хәерсез җиле куенга ук үрмәли. Эчке бер аваз йөрәккә дәшә: кайтырга кирәк! Кайтырга кирәк... Әмма ишеккә төбәлгән күзләр... Аларны аннан аерырмын димә!..

Чү! Елау авазымы?.. Әллә буран җиле шулай сызгырамы? Эт улыймы әллә, Ходаем?.. «У-у-у-у...» — Үкси ич ул, үкси: «У-у-у-у...»

Әрле-бирле йөренүче соры киемлеләрнең берсе икенчесенә: «Арча кырында бүре елый», — дип үтте. Бүре елый? Моның ише хәлне ишеткәне юк иде Ханымның. Хәерлегә булсын!..

«Хәерлегә»... Бүре өненнәнме, кычкырып әйтелгән шушы сүзеннәнме — Ханым айныгандай булды. Күз алдыннан, җанны телгәләп, янә бер-бер артлы сурәтләр узды. Түрә төркемнәре... Мәскәү кунаклары... Рәсемнәре гәзит-журнал битләрен тутырган хезмәт алдынгылары... Иңенә салган чәшке тунын иңбашын сикертеп кенә баш режиссёр кулына күчерүче, зур шөһрәт казанган актриса һәм... Һәм барлык өметне юкка чыгарып ераклашучы соңгы сурәт — атаклы артистлар — Ханымның үз шәкерте Мәрзия Миңлебаева һәм аның ире Фуат Халитов... Аһ, аларга якынлашып булсачы?!. Юк шул, юк. Көчле куллар аны һаман читкәрәк кысрыклый, һаман читкәрәк... Ул, ниһаять, кычкырып карады, тик тавышын үзе дә ишетмәде.

Туңган бармаклары белән чигәләрен кысып, Ханым ыңгыраша башлады... Асфальт бозына ышкылган тәгәрмәч сызгыруы аны саташу халәтеннән чынбарлыкка кайтарды. Почта машинасы! Котлау телеграммалары, тәгаен. Соңгы өмет, соңгы талпыну. Берни тоймас хәлгә җитеп өшегән аякларны кыймылдатып булса... Әйе, уң адымнан — театр ишеге. Ә ишектә әзмәвердәй

сакчы, һәр телеграмма өчен кул куячак ул. Эчкә үтәргә шушы мәл дә житә. Тик аяклары гына сынатмасын...

...Ханымның күзенә иң әүвәл президиум өстәле чалынды. Кызыл өстәл артында, обком, Югары Совет түрәләре янәшәсендә, ул — коңгырт-кара күзле актриса. Алар артындагы рәтләрдә дә, титул-дәрәҗәле ир-атлар арасында, хатын-кызлар күренгәли: өчәр мең литр сөт савучы геройлар, завод-фабрика алдынгылары...

Жылыдан колак яфраклары кызыша, сызлый башлады. Нотык сүзләре дә авырлык белән генә аңа ирешә. Чү! Театрның тәүге артистлары турында түгелме сүз?!.

— Профессиональ татар театрына нигез салучы, сәхнәдә гаҗәеп образлар тудыручы, театр сәнгатендә якты йолдыз булып янучы ике шәхесне — Габдулла Кариев һәм Сәхибжамал Гыйззәтуллина-Волжская исемнәрен атыйм мин бүген, — ди иде трибунадагы әфәнде. — Бөек Тукаебыз кояшка тиңләп: «Берсе уйный күк йөзендә, берсе уйный сәхнәдә», — дип мәдхия юллаган Сәхибжамал ханым шәхесенә аерым тукталасым килә минем. Ул — хатын-кызлардан беренче булып әле гасырыбыз башында ук сәхнәгә басучы һәм искиткеч осталык белән баш рольләрне уйнаучы, йөзек кашыдай артистка. Ул — үз акчасына артистларны ашатучы, киендерүче, акчасы беткәч, затлы киемнәрен, зиннәтле йөзек-беләзекләрен сату бәрабәренә театрны саклап калучы, театр дигән сәнгать аша татар халкын илебезнең бик күп почмакларында танытучы җитәкче. Ул — татар пьесалары белән беррәттән, татар халкы рухына туры китереп, рус һәм дөнья классикасын үз телебезгә тәрҗемә итеп сәхнәгә куючы режиссёр... Кариев турында да Кәрим Тинчуриннан остарак әйтү мөмкин түгел. Әйе, ул аны: «Беренче татар театрының юлбашчысы», — дип атый...

Кызганыч, бу бөек шәхесләр безнең шушы олы бәйрәмебезгә, мәртәбәле юбилеебызга кадәр яши алмадылар, тормыштан иртә киттеләр. Үз эшләренең чәчәк атуын күреп алар да куанырлар иде... Без хәзер аларны аяк өсте басып искә алыйк әле, иптәшләр!

Зал бер мәлгә тын калды. Кешеләр урыннарына да тын гына утырырга тырыштылар. Тик уртадагы рәтләрдән берәү генә һаман аягүрә иде. Һәм тын залны өн ярды: «Сәхибжамал ханымны тарих чүплегенә ыргытырга ашыкмагыз әле; ул — исән, ул калабыз Казанда яши!» Зал «аһ» итте. Президиумдагылар зал уртасына, күкрәген орден-медальләр бизәгән, таякка таянган чал чәчле иргә текәлделәр. Тик күркәм артистканың коңгырт-кара күзләренең угы гына иң арткы рәткә чүмәшкән Ханымга кадалды. Иреннәре дә янәшәсендәге түрә колагына нидер пышылдый башлады...

...Залда ут сүнде. Кичәнең икенче өлеше — «Зәңгәр шәл» спектакле башланган иде. Соңгы рәткә, Ханым урындыгына бер әфәнде иелде. «Сезне директор бүлмәсендә көтәләр», — диде ул, тирә-якка бик тә сәер караш ташлап. Жылы тоя башлаган аякларын көч-хәл белән өстерәгәндә: «Ниһаять! Гафу үтенәләрдер», дип уйлады Ханым. Әмма әфәнде аны директор бүлмәсенә түгел, урамга алып чыгып китте.

Урамда ике машина тора. Берсенә — «Милиция», икенчесенә «Ашыгыч ярдәм» сүзләре язылган. Соры киемле егет «Ашыгыч ярдәм» машинасы ягына этәрде. Ханымның йөрәге «жу» итте. Ул, машина ишегенә тотынып, буранлы күккә карады. Әллә Арча кыры тарафыннан, әллә күктән, бүре елавы ишетелде. Жанын «Песиләрем...» дигән уй телеп үтте.

Суыкта күшегеп утыручы песи балаларын кызганып, очраткан саен куенына тыгып алып кайта торган гадәте бар иде Ханымның. Песиләр җидәү булган иде инде... Гаиләсенә әйләнгән бу дусларына Ханым хәтта исемнәр дә кушты.

Ул үзе яраткан спектакль геройларыннан. Әйтик, Дездемона исеме назлы ак песигә эләкте. Дездемона янына башка песиләрне якын җибәрмәүче көнче каракае Отелло иде. Елгыры — Гайни, иркәсе — Галиябану, комсызы, сугыш чукмары — Исмәгыйль, чаясы — Мәйсәрә, кыюсызы Хәлил булды...

Иҗауда кадерле ирен җырләгәч, абруйлы түрәнең иркә хатыны булып яшәвенә нокта куеп, дүрт бүлмәле фатирын тота-каба Казанга — театрлы Казанына — ике бүлмәлегә алыштырган иде Ханым. Спектакльләргә йөрергә җинелрәк булыр дип, әле ул әнә шул ике бүлмәле фатирын да театрга якын гына урамдагы яртылаш җиргә күмелгән бер бүлмәгә алыштырды. Әмма аны туган каласында берәү дә көтмәгән икән... Көтмәсә соң, көндезләрен репетициягә барып утырудан да, кичләрен спектакль караудан да аны берәү дә тыймый ич.

Инде менә... үзен бу дөньяга бәйләп торган тылсым ишекләре ябык. Ябык!..

Машина ишеген атлаган мәлендә анын бөтен барлыгын бер генә уй биләде һәм җаны: «Песиләрем нишләр?!» — дип ыңгырашты... Ярый әле ялгашларын ризык белән тутырган иде. Ярый әле тәрәзә форточкасы ачык калды...

«Песиләрем», — дип пышылдады Ханым.

Әйе, ул — Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская — песиләренә кирәк иде. Кирәк иде...

---

## Автордан

Житмешенче еллар азагы. «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналында эшли башлаган чагым бу. Татарның һәм бөтен мөселман дөньясының беренче артисткасы хакында язар өчен аны белгән кешеләрне эзли башладым. Иң әүвәл, «Гөлҗамал» дигән, Сәхибҗамал апаның тормышын һәм артистлык эшчәнлеген чагылдырган драма иҗат иткән Нәкый ага Исәнбәтнең ишеген шакыдым.

— Очерк-истәлек, дисезме? Ай-яй авыр эшкә алынгансыз, ерып чыга алырсыз микән? — диде ул. — Сәхибҗамал ханымның соңгы еллардагы тормышы җиде кат йозакка бикләнгән... Театрга барып карагыз соң. Анын «Гөлҗамал» репетицияләренә (1963 ел. *Ред.*) килеп утыруын әйткәне бар Празатның. Бәлки, ул ни дә булса беләдер.

Празат Исәнбәт тә, Марсель Сәлимҗанов та бернинди мәгълүмат бирә алмадылар. Мәдәният министры Булат Гыйззәтуллин, атаклы актриса Фатыйма Ильская белән сөйләшүләрнен дә — ни гаҗәп — нәтиҗәсе булмады. («Бөек артистка театрда бер генә була ул», — диде мина Фатыйма апа.) Ниһаять, Шәүкәт абый Биктимеров:

— Сәхибҗамал апаның соңгы еллардагы тормышын Фуат абыйлар белә. Сәхибҗамал ханым әле Мәрзия Минлебаеваның остазы да булган, — дип сөендерде.

Икенче көнне үк мин Мәрзия Минлебаеваның кадерле кунагы идем инде. Шөкер, Фуат абый Халитов та өйдә. Ул, СССРның халык артисты, сөекле хатынының әле елый-елый, әле көлә-көлә сөйләвенә кинәнеп, тыйнак кына елмаеп утыра. Менә Мәрзия апаның мөлдерәмә күзләре иренен йөзендә тукталып калды.

— Карале, Фуат, Батыевның[1] сина төн уртасында телефоннан шалтыратып, Сәхибҗамал апаның җәсәден шул төн эчендә Казанга күчерергә кушканын әйт, җаным. «Мулла малае икәненне онытма!» — дип кисәткәнен дә әйт.

— Менә үзен үк әйтеп бирден бит инде, Марзуш.

Мин, гаҗиз калып, аларны бүлдердем:

— Гафу итегез, Сәхибҗамал апа Казан больницасында вафат булмадымыни ул?!

[1] Салих Батыев ул чакта Татарстан Югары Советы президиумы председателе. *Ред.*



— Юк, шалтыратып түрәләрне бимазалый дигән сылтау табып, Чистайга, «Авыру картлар йорты»на олактырганнар аны. Әнә шул йортта Фуатның кулына 1974 елның 6 апрелендә вафат булды дигән кәгазь дә тоттырганнар.

Мәрзия апа белән Фуат абыйның тынлый-тынлый, әнә шул кара төндә булган хәлләрне: сазлыкка охшаган ташландык кыр буйлап, жиргә кадалган таякларга беркетелгән уч төбе кадәр генә такталарны фонарь белән яктырта-яктырта, андагы саннарны кулларындагы дәфтәргә язылган саннар белән чагыштырып (исем-фамилияләрсез каберләр арасыннан!), бөек артистка каберен эзләп йөрүче ике шәүләне — «Авыру картлар йорты» башлыгын һәм Фуат абыйны күз алдына китереп, тетрәнеп куйдым.

Нигә кирәк булган соң бу эшне шулай ашыгып, бер төн эчендә башкару? Минем менә, «Мәскәүдән киләләр!» дип, культура эшлеклеләренең ут капкандай чабышулары хәтердә калган. (Мәдәният министрлыгында (1971-1976) эшләгән чагым иң.) Мондый хәл теге төн алдыннан булган дип фараз кылсак, бөтен нәрсә үз урынына утыра да куя. Мәскәүгә шундый данлы шәхеснең юкка чыгу хәбәре ирешкән булуы бар бит. Әлеге кара төнне сер итеп калдырырга теләү күренеп тора. Төнлә бөтен сазлы зиратны фонарь тотып нибары ике кеше айкасын инде![2]



Лемар ГОБӘЙДУЛЛИН фотолары

Әле, житмәсә, бу 1975 ел чынлыкта Сәхибжамал апаның юбилей елы да бит: 1885 елда туган ул. 1892дә туган дигән, күп басмаларга кергән, кабер ташына да уелган мәгълүмат дөрес түгел[3].

Шулай да, ярый булган әле бу төн. Юкса беркайчан да Сәхибжамал апабызның мәңгелек йорты Казанның Яңа бистә зиратында, Тукай янәшәсендә урын ала алмас иде. Хәтта аның кайчан үлгәнлеген дә, кабере кайдалыгын да белмәс идек...

...Шекспир трагедияләре дә күтәрә алмаслык мондый вәхшилек алдында — якты, затлы очерк язу хыялым чәлпәрәмә килде. Ә аның урынына кәгазьгә, күп еллардан соң, «Бүре елаган төндә» дигән тормышның үз хикәясе төште...

[2] Батыевның Фуат абыйны теге заманнарда кулга алынган мулла әтисе турында әйтеп кисәтеп куюы да тикмәгә түгел инде. *Ред.*

[3] Дөрес мәгълүмат 1999 елда чыккан «Татарский энциклопедический словарь»да күрсәтелгән. *Ред.*

## ЯВЫЗ ИВАН КИҢӘШЕ

*Ни бәла килде Казанның халкына?*
*Очрадылармы Ходайның каһренә?..*
*Габдулла Тукай*

**Өммәт рухын кирмән төсле тотар кала**
**күчә бара әллә кемнәр кулына.**
**Тәүге тапкыр «Мин!» дип әйткән хәләл ия**
**инде хәзер аслын җуйган кол гына.**

**Мәркәз буйлап әрсез кавем йөри һаман,**
**чабатасын эләр өчен түр эзләп.**
**Төрки йөзле шәһәр яме агып тора,**
**кан-яшь тулы Казансуда дерелдәп.**

**Илнең күпме фәрештәсе качып киткән –**
**һомай-кошлы капкаларны кем саклый?**
**Тәңре аңлар шундый телне яклый алмас**
**пайтәхеттә ана сөте коргаксый.**

**Монда иман алай зәгыйфь түгел әле,**
**Ислам үзе тамыр төрткән җир барга.**
**Аллаһ безгә куәт бирсен алгы көндә**
**югалганны берәмтекләп җыярга.**

**Үзебезгә тартып-тартып китерәбез**
**җәза итеп язган һәрбер казаны.**
**Явыз Иван ихлас киңәш бирер иде –**
**яулап алу кирәк безгә Казанны,**
**яулап алу кирәк безгә Казанны!..**

**Зиннур МАНСУРОВ**

*Күренекле үзбәк шагыйре Чулпан (Габделхәмит Сөләйман улы, 1897-1938) репрессия еллары корбаны була. 1917 елгы революциядән соң яңа чорга күчү фаҗигаләрен, каршылыкларын эзләнүле иҗатында ачык чагылдырган язучы озак еллар онытылуга дучар ителә. 1991 елда гына, иҗади мирас буларак, роман, пьеса, шигырьләрен туплаган «Янә алдым сазымны» исемле җыентыгы дөнья күрә. Без бу санда укучыларыбызга тәкъдим итә торган шигырьләр шул китаптан алып тәрҗемә ителде.*



Чулпан

## Дала юлларыннан...

Дала юлларыннан үтеп барамын,
Һәр яфрак — башыма, биткә жилпәзә...
Йомшак жил...
Йөземне аңа борганмын,
Житез, уйнак, жил күк хисләр дә...

Кечкенә арыкның нәни шарламасы
Назлы тавыш белән жырлап бирәдер:
«Әй тупас шәһәрнең жәнжал-гаугасы,
Дала юлында мин дә бар!» — диядер.

Дала юлларыннан, хистән тилергәндәй,
Иртәдән кичкәчә мин дә чабамын.
Риваятьтән сукбай — бөрәдәкләрдәй,
Кешесез жирләр эзләп барамын.

Аулак жирләрдә серләр әйтелде —
Гафләт йокысыннанмы уянып киттем?
Яңа ләззәтләр зәукы күңелгә тулды,
Аннан чиксез мәгънәләр хис иттем... —

Шарлама тавышы иркен шигыремә
Алтын канат куйды — әфсаналәрдән.
Алкышлар яуды гөл-лаләләрдән,
«Үзем»лек ят иде бу — торган жиремдә.

«Үзем»нән тыш бер дөньяны күрдем!..
Аның белән икәү без — агып барабыз.

Фанилыкны без егып барабыз,
Чын бергәлеккә юлымны бордым.

Шул мәлдә «үзлек»не дә жинеп барамын,
Дала юлларыннан үтеп барамын.

## Чәчәк

*Бер кичә истәлеге*

Яңа гына бөресеннән чыккан чәчәк
Биш-алты көн һәркем өчен тансык булыр.
«Бетте исе...», — дип ташласа берәр тинтәк,
Һәркем типсә, һәркем изсә — ул хаклыдыр.

Биш-алты көн күкрәкләрдә, горурланып,
«Мин гүзәлмен, йөземә бак!» дигән гөлне
Жиргә төшкәч, инде кара: сулып-корып
Үлем төсе кергән, сагына сахра-чүлне.

Әйтә кебек: «Әгәр сусыз чүл-далада
Гали бер гөл, иссез чәчәк булса идем! —
Өзеп ташламас иде бит бер адәм дә... —
Киң сахрада күкрәп үсеп сулса идем!

Һәр хаин кул мине жиргә атмас иде,
Һәрбер аяк күкрәгемә басмас иде!»

## Утлы су

Зур дингезнен дулкыннары бәгърендә
Йөз елларның каны — куркыныч эзе бар.
Йомшак суда тончыктырган аузында
Шәфкать белмәс гыйсъянчылар сүзе бар.

Нинди ахмаклар ул — тын жирдә
Тәм табалар аны каргап-сүкмәктән?!
Юлчы булып юлга чыккач, иркендә
Жан бирерләр — дәһшәттән өрекмәктән!

Кара болыт күзләреннән ул күп чак
Учлап-учлап яңа көчләр аладыр.
Әй тынычта көлгәннәр, йөзегез — алчак;
Сезгә ул тик күз-кабагын саладыр...

Савытыгыз — хуржиныгызны күрсәм —
Күз яшьләре, кайгы белән тулгандыр,
Кичкән — үткән юлчылардан белешсәм,
Кулыгызда жан-егетләр үлгәндер.

Күперер су, тынгысыз ул — ташар ул,
Гүрегездән, нәгърә орып, ашар ул!

*Үзбәкчәдән* **Рәдиф ГАТАШ** *тәрҗемәләре*

# ЗАМАН ШИГЪРИЯТЕНДӘ ИЛ ГАМЕ

Чын шигърият беркайчан да халык язмышына, дөнья, ил гаменә битараф кала алмаган, димәк, шагыйрьләр дә элек-электән күбәләкләр белән куышып, гүзәлләргә һәм нәфис гөлләргә сокланып, былбыллар сайратып кына яшәмәгән. Мең еллык тарихлы татар шигъриятендә дә шул ук хәл: шагыйрь булып туганнарны һәрвакыт, Зөлфәтнең бер шигырендә әйтелгәнчә, «көтеп торган Колгалилек, Колшәрифлек тәкъдире». Төрле чорның зинданнары да татар шагыйрьләрен көтеп торганга охшый әле. Акмуллалар заманыннан бирле шулай. */ Шагыйрьләрне җырлар гына түгел, / Язмышлар да бергә кушалар... / Әнә кайдан — Акмуллаларыннан / Башланган ул мәшһүр Мусалар, — /* диелә Мөдәррис Әгъләмнең «Акмулла арбасы» поэмасында.

Колшәрифләрдән соң йөзләрчә ел узгач, яңа чор — егерменче гасыр башы шагыйрьләрен Дәрдемәндлек, Тукайлык язмышы, беренчесенең мәңгелек сәфәргә чыгарыласы «Кораб»ы, Тукайның «Милли моңнар»ы, «Көзге җилләр»е көткән. Аннары Такташларны, Җәлилләрне, Кәрим һәм Туфаннарны тудырган да байтагын җисми юк иткән авыр чор — тагын шул ук әйтәсен әйтми, язасын язып бетерми китеп барган шагыйрьләр заманы. */ Шигъриятнең хәле беркайчан да / Булмаган шул рәхәт, җинел дә... / Ул һәрвакыт Җәлил җыры сыман, / Яшәү белән үлем чигендә, — /* дип язды заманның иң нечкә хисле шагыйре Илдар Юзеев. Хактан хак бу сүзләрне кире кагучы табылмастыр. Алдагы көннәр шагыйрен күз алдында тотып, аларга нык ышанып, шагыйрь болай ди: *«Такташларның әйтми калган сүзен / Әйтми калмас, барыбер әйтер ул!»* Бервакыт үзен әдәбият белгече санаучы тар күңелле бер түрә «язучы халкы артык күбәйде» диебрәк сөйләп ташлады, әмма моның чын сәбәбе хакында фикер йөртеп тормады. Тукайларның, Такташларның халык исеменнән дөньяга әйтер сүзләре күп калганга, татарның үз алдына куйган максатлары да биниһая зур булганга, Бөек Көч безгә шагыйрьләрне дә күп бирәдер, бәлки. Күпсенмәгез, әфәнделәр, халыкка рух ныклыгы, үтемле хак сүз аеруча кирәк чакларда күбәя шагыйрьләр. Карагыз сез, иң фаҗигале, дәһшәтле чорда — нәкъ сугыш алдыннан, сугыш вакытында һәм аннан соңгы ике-өч елда татарның нинди шагыйрьләре туган: Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим, Рәдиф Гаташ, Ренат Харис, шагыйрьлеге өстенә, гамьле, тирән фикерле, хәр рухлы публицистикасы белән дә иң шәпләрдән саналучы Рәфикъ Юныс (аның әлегрәк басылган «Татарстан референдумы», әле генә дөнья күргән «Татар гаме» китапларын күз алдында тотам), Гарифҗан Мөхәммәтшин, Рәшит Әхмәтҗанов, Харрас Әюп, Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәт, Илдус Гыйлаҗев! Кемгә дип һәм кайсы халык исеменнән язганнарын анык белгән, холык-фигыльләре дә күркәм булган шагыйрьләрнең кыскача гына исемлеге әле бу! Дәһшәтле еллар авырлыгын үзләре кичеп, халык белән бергә күргән-кичергәннәрен сүзләр ярдәмендә сурәтләп, тарихка калдырсыннар өчен, Табигать шулай күп итеп тудыргандыр аларны. *«Әшәкелек басып дөньяны, / Яхшылыкка кеше зарыкса, / Күңелләргә якты иңдереп, / Пәйгамбәрләр килгән халыкка»,* — диелә Илдус Гыйлаҗевның бер шигырендә.

Харрас Әюп иҗатында халык, ил гаме аның Такташны, Фатих Кәримне, Муса Җәлилне, Шамил Усмановны, Зөлфәтне күз алдында тотып, күңеленнән алар белән фикерләшеп язылган шигырьләрендә аеруча калку гәүдәләнә. Ул «киңәшкә чакырган» милләт асылзатлары, бер яктан, Харрасны шагыйрь буларак

югарыга, үз биеклекләренә күтәрсәләр, икенчедән, шигырьләрдәге милли гамь аерым бер шагыйрьнеке генә булып калмыйча, фидакарь затлар аша, бөтен халыкныкы булып әверелә. Шагыйрьгә ияреп уйлана башласаң, хәйраннар калырлык: халкыбызның катлаулы, чал тарихында «яшәү белән үлем чикләре» шулкадәр еш кабатланган, ул чикләрне кичкәндә авыр югалтулар шулкадәр күп, бу хәлләр әллә ничә буын каләм ияләренең җанын сыкратырлык. Ә бит халык уллары булмастайны, бүтәннәрнекеннән артыкны дауламады, аларга татарның Кояш астында, Ходай тәгаенләгән урында үз ирке, үз дәүләте, үз дине белән, алдауларсыз, гадел һәм имин яши алуы гына кирәк иде. Шамил Усманов, ялган беркетмәгә кул куймас өчен, үз күзләрен үзе каләм белән чәнечкән. Ә ул беркетмәдә кемнәргә генә яла ягылмагандыр да, уйдырма, пычрак гаеп ташланмагандыр. Халык улларын үз-үзенә кул салыр хәлгә җиткерүчеләр дә кешеләр дип аталганнар бит. Иблискә хезмәт итүләре белән масаеп, үзләрен бүтәннәрдән өстен тоеп яшәгәннәрдер әле. Шуңа күрә беркем беркемнән вәхшәтле еллар өчен гафу сорамады, фаҗигаләрнең бүтән кабатланмаячагына өмет тудырмады, аларның оятын да күтәрсә шул шагыйрь күтәрәсе. / *Күзләр харам безгә,* / *Усмановның* / *Күзендәге канлы каләмне* / *Тартып алып язалмыйбыз икән* / *Ул каләмгә мәгълүм хәлләрне.* / *Халык дошманына тиеш исем* / *Халык улларына тагылган.* / *Юасы бар әле чорыбызны* / *Ахыргача алар канында*, — / дип язды Харрас Әюп «Шамил Усманов» исемле шигырендә. Берхаксызга халык кичергә дучар ителгән җан өшеткеч хәлләрне сурәтләү бу шигырьдә башлана гына кебек әле. Алар шагыйрьнең «Сибгат Хәким төше», «Калка Туфан...», «Такташка хат» кебек шигырьләрендә дәвам иттерелә. Сибгат Хәким төшендә Хәсән Туфан белән Фатих Кәримнең төрмәдә очрашуын күргән һәм шул хакта шигырь язган. Харрас шуны бәян итә: / *Әллә каян кермиләрдер төшләр...* / *Туфан авызыннан ишетеп,* / *Зирәк шагыйрь өндә булган хәлне* / *Язган икән бары төш итеп.* / *Тарих өчен теркәп куйган шулай,* / *Хәтәр чорда хәтәр заманны* / *Язып калдырган ул төшләрендә* / *Күрергә дә ярамаганны.* /

*«Туфаннарны суккан кара яшен* / *Тими калмас иде Сезгә дә...»* — дип яза ул «Такташка хат»ында. Тими кала диме соң, шагыйрь кебек хөр рухлылар башыннан йөргәнгә дә кара яшен бит ул. Ләкин Харрасның Такташка әйтер сүзләре болар гына түгел. Шигырьдә Такташның киләчәккә язган хатлары, ул хатларда бәян ителгән хыял-өметләре хакында сүз бара. Бездә кайберәүләр, «Киләчәккә хатлар» поэмасындагы хыяллары чынга ашмауны сылтау итеп, Такташны ялган көрәзәлектә гаепләмәкче булалар. Ә бит, мантыйк буенча, халыкның күп михнәтләр, җәберзолым кичеп яуланган яңа тормышы нәкъ Такташлар өметләнгәнчә барырга тиеш иде. «Корыч бабай» атлы дәҗҗалның юлыбызга каршы чыгып, иң яхшы ул-кызларны җисми юк итәсен, зинданнарга куып кертеп, күпләренең рухын сындырасын, шагыйрьләрен хак сүзеннән, якты хыялларыннан мәхрүм итәсен, кайсыдыр шигырьдә әйтелгәнчә, «бер шагыйрьгә унлап Шаһгали» туры киләсен Такташ каян белсен! Бу бит мантыйк белән дә, акыл белән дә аңлап булмый торган ил. Харрас Әюп «Такташ абый» шигырендә болай борчыла: / *Сезнең хыялдагы матурлыклар* / *Алдадыр ул, алда, күрәсен...* / *Тик ул чорлар Сезгә ничек итеп,* / *Кайсы телдә хәбәр җибәрсен?* / *Үз телендә уку хокукыннан* / *Бүгеннән үк мәхрүм ич алар!* / *Ни гаебе бардыр милләтләрнең* — / *Ирексезләп телен кисәләр...* /

Харрас Әюпнең «Көй эзләү» поэмасында да халыкның үз көеннән, моңыннан, теленнән язуы милли фаҗига буларак сурәтләнә. Ә бит, күпме генә сылтасак та, һәммәсенә явыз хакимнәр генә гаепле түгел, үз битарафлыгыбыз да чиктән ашкан. Хаталарыбызның көенечле йомгагы да иң элек шагыйрьләрне борчый.

Илдус Гыйлаҗев шигырьләрендә дәүләтледән дәүләтсез калган халык гаме тагын да ачыграк гәүдәләндерелә, бу шагыйрьгә кискенлек, күнелендәгеп ахыргача ачып салырга омтылу хас. Сурәтләүләрендә буяуларның да куерагын куллана. Татар халкының Хәтер көнендәге Казанны ул болай сурәтли: / *Монда... тынлык.* / *Нинди битарафлык* / *Тутырды сон җирне, күгемне?* / *Хәтер көнендә дә кымшанмагач...* / *Шомлы уйлар баса күнелне.* / («Әй башкала, башкала...»)

Әйе, халыкның йокы халәте — бөек Тукай заманнарыннан ук килеп, чын шагыйрьләрне гел борчый, әрнетә торган күренеш. Бәлки ул динебез өйрәткән сабырлык-күндәмлектән дә киләдер, шуңа күрә бөтенләй үк тискәре сыйфат та түгелдер? Әмма хакимнәрен, иблисләнеп, синең Ходай биргән ирегеңне тартып алырга, телеңне тыярга, динеңнән яздырырга, төшемле урынга утыртып, халкыңны җәберләттерергә тели, үзенең һәм ишләренең исәпсез харам байлыгын саклап җаныңны бирергә өнди икән, бу очракларда да күндәмлек акланамы?

Халкының ирекккә, явызлар җимергән дәүләтен кире кайтаруга, хак сүз әйтүгә, үз газиз телендә белем алуга хокукын яклап язганда, Илдус Гыйлажев үзенең кайда, нинди илдә яшәвен бер мизгелгә дә исеннән чыгармый, билгеле. */ Рәсәй бу... / Каршы әйтсәң — таптарлар. / Нәселеңне корытырлар; / Еллар уткәч ...акларлар, / Бетергәнче вакларлар /* («Халләр шундый, татарлар...»), — дип мөрәҗәгать итә ул җәяләр эчендәге (ирексез!) милләттәшләргә. Әйе, милли хокукларының һәммәсе диярлек хәйлә-мәкер белән тартып алына барганда да мона әлләни исе китмәгән, күпчелеге «татар теле белән кая барып була» дип, баласын мәктәпнең рус сыйныфына илтеп биргән, оныкларының чит милләтле булып үсүенә үтә ваемсыз караган халыкка хак сүзне бүтән беркем түгел, шул халыкны ихлас яраткан, *«Кулга каләм алган кеше / Күк каршында җаваплы»* дип санаган шагыйрь генә әйтә ала. Һәм әйтә дә: */ Бүтән Иван килер иде, / Явыз Иван килмәсә. / Дошман керә... Акыл гына / Керми ул бер кермәсә, — /* дип ярып сала Илдус Гыйлажев. «Атадан калган хата»лар зур шул. Инде татарны дошман күрүчеләр дә «Булган дәүләтегезне сакларга кирәк иде!» дип ычкындыргалый икән, үкенечле уен шагыйрь ничек белдерми кала алсын? *«Үткәннәрдән сабак алмау / Төп чиреде татарның»* дигән сүзләр белән тәмамлана бу шигырь. «Татар моның аңлар өчен» шигыре дә югарыдагыларга аваздаш: */ ...Монаймаска юк шул чара, / Бәйсезлеккә ерак ара. / Дүрт йөз кырык катлам аша / Үтеп чыгып яшәп кара. /*

Бу шигырь язылганнан соң, катламнар тагын да калынайды, чөнки халык та, халык ышанып таянган җитәкчеләр дә мөстәкыйль дәүләтчелегебезне кайтару өчен гасырларга бер генә була алган мөмкинлекне кабат кулдан ычкындырдылар. Бу хәлгә җаны әрнүчеләр дә — милли көчләрнең бәләкәй төркеме һәм аз санлы шагыйрьләр генә бугай. Ә ул чактагы җитәкчеләр үзләре «йота алган кадәр» ирекккә тиенеп калдылар кебек, үкенеч-фәлән белдергәннәре юк. Кайберләре, киресенчә, Мәскәү матбугатына әңгәмәләрендә, горур кыяфәттә, «Татарстанның тулы бәйсезлеген таләп итүчеләр дә бар иде, без андыйларга каршы тора алдык», — дип тә белдерәләр. Көч-кодрәтләрен менә кемнәргә каршы көрәшкә, ә кемнәрнең хезмәтенә сарыф иткәннәр, көрәшләренең ахыр максаты менә нидә булган икән! Якты юл сабучы дигәнебез кара юлсызлыкта адаштыручы икән, ләбаса. Милләт җанлылар ярдәме белән яулап алынган хокукларын һәм эләктергән байлыкларын кулларында саклап калу бәрабәренә кылынды микән бу гамәлләр? *«Бәрәм-бәрәм җен-паригә / Сатылыгыз, сатыл»*, — дип яза Илдус Гыйлажев «Замана хакимнәренә» дип исемләнгән шигырендә. «Син...» дигән шигыре дә шундыйларның берсенә атап язылгандыр: */ Тәхет саклап вөҗлан таплау / Синдәйләргә үз нәрсә. / ...Тәре дә тагарсың әле, / Заманалар үзгәрсә... /*

Тагарга уйласалар, тәре эзләп йөрергә дә кирәкми бит аларга — байтагының Мәскәү бүләк иткән тәреле орден-медале әзер тора. Бүләкләнгәннәр икән, Мәскәү өнәмәгән кемнәрнедер җиңгәннәр, ниндидер «батырлык» кылганнар, димәк. Горур йөрергә хаклары бар, дигән сүз. Дәүләт Думасында татарның һәм башка «нацмен»нарның теленә, милли мәгарифенә, тарихына, Төп Законнарында билгеләнгән «президент» атамасына каршы тавыш бирүчеләребезне дә, хуплап, депутатлыкка кабат-кабат сайлаталар. Фикерләре килешә, «безнекеләр»гә нәкъ шундый депутатлар кирәк, күрәсең. Гел үсендергәнебезгә күрәдер, бәлки, милләтнең ирекле дәүләт торгызу хыяллары тагын бер кат җимерелгәннән соңгы елларда сәнсәтче-түрәләр һәм милләтсез, карун байлар сафы, отыры ишәя һәм куәтләнә генә бара, тавышлары да бөердәнрәк чыга, халыкка аларны тоту да кыйммәткәрәк

төшә, ә шул чорда татар кебек зур халыкта гына күпләп туа алган иң талантлы, иң нәфис һәм халыкчан иҗатлы шагыйрьләребезнең күпмесе якты дөнья белән хушлашты: Фәннур Сафин, Рәшит Әхмәтҗан, Илдар Юзи, Наис Гамбәр, Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәт, Харрас Әюп, Роберт Әхмәтҗан, Шәүкәт Галиев... Яшәү-көрәштән дә, иҗаттан да туймаган иде әле берсе дә. Аларның да өзелгән сүзен әйтеп җиткерү исән шагыйрьләргә, аларның дәвамчыларына йөкләнеп калды. Үзләре исеменнән генә түгел, мәрхүм каләмдәшләре өчен дә әйткәнгә, кайчак сүзләре кискенрәк ишетелсә дә гаҗәп булмас.

Мөдәррис Әгъләм үз иҗатында җимерелгән дәүләтчелегебезне торгызу, азатлык-бәйсезлек кебек төшенчәләрне үтә сирәк кулланса да, шигырьләренең һәрберсеннән рухи хөрлек, кешелеклелек, киңлеккә, иреккә омтылу хисләре бөркелеп, кыя бөркетләре авазы ишетелеп тора. Кайбер шигырьләрен ул галәмдә торып язгандыр һәм бөтен кешелеккә юнәлткәндер кебек тоела. Аның һәръяктан камил «Бердәнбер» исемле шигыре генә дә Мөдәррисне галәм шагыйре бөеклегенә күтәрде, дәүләтсез милләте генә шагыйрьгә лаек булган урынын тәэмин итә алмый һаман. Бу шигырьдә — якты хыялы, чәчәктәй яшьлеге җимерелгән, үпкәсеннән кара кан килерлек имгәтелгән, идәндә үрмәләүче сабыен кулына алырга тилмереп, күзләре мәңгелеккә йомылган миллионнарча Аналар язмышы. Ананың бу хәлгә калуына ил башларының үзләренә байлык һәм дан-дәрәҗә яулау өчен башлаган сугышлары сәбәпчеме, моңа акылсыз хакимнәр яисә тәкәббер кавемнәр гаепләме — нәтиҗәсе бер үк. Халыкларга каршы кылынган явызлык, инде тәмамланган кебек булса да, үтеп китми, миллионнар йөрәгенә чир булып сеңеп кала, җәрәхәте әллә ничә буынга җитә. */ Идәндә сабые үрмәли, / Алырга иде бер кулына! / Бу соңгы теләге үтәлми, / Чем-кара күзләре йомыла. / Ә аның шикелле илемдә / Меңләгән хатыннар үлгәндер. / Онытма, кешелек, / Ул минем / Әнием иде бит, / Бердәнбер! /*

Көенечебезгә күрә, әдәбиятыбызда зур казаныш саналырлык бу Шигырь турында фәнни докладлар язылганы да ишетелми, аңа багышлап әдәби укулар да үткәрелми. Инде без дә Шагыйрь һәм Шигырь бөеклеген аңламаслык булып рухи имгәнә барабыз микән әллә? Алла сакласын берүк!

Тумышыннан ук Тукайлык тәкъдире көтеп торган, яшәү рәвеше белән дә башкалардан үзгә, беркадәр Тукайчарак булган Мөдәррис Әгъләм — шагыйрьлекнең халык каршындагы җаваплылыгын бар вөҗүде белән аңлап эш итүчеләрнең берседер. */ Җырны чикләмәгән вакыт, / Ә гомерне чикләгән... / Рәнҗеп туктамасын / Сина / Халкың тапшырган каләм! — /* дип язды ул «Синең кулда каләм...» шигырендә.

Бөек Тукайга багышлап шигырь-поэма язмаса, шигъри сүзен Тукай бизмәненә салып үлчәмәсә, ул шагыйрь Мөдәррис Әгъләм дә булмас иде. Аның поэмасы «Тукайдан хатлар» дип исемләнгән. Тукайның Фатих Әмирханга язган хатыннан «Мин әле кая барам?» дигән сүзләр Мөдәррисне бигрәк тә уйландырганга охшый. */ — Кая барам? — Бирсәм шул сорауны, / Дөнья белән дөнья бәрелгәндә, / Ярар микән? / Ә Тукай бит биргән / Миннән авырырак хәлендә дә... /*

Бу тирән мәгънәле сорау хакимнәребезне дә уйландыргаласа ни әйтер идең дә бит... Мисалга, хәтәр референдум чорын Ходай ярдәме белән имин һәм җиңүле кичеп, хөр дәүләтчелекне торгызу юлына баскач та, ниндидер Шартнамә, аның да зәгыйфь туган кыска гомерлесе белән язмыш дилбегәсен кача-поса гына Мәскәүләр кулына илтеп бирүченең уенда ни булган, нигә ул үз-үзеннән «Мин әле кая барам?» дип сорамаган? Референдум алды көннәрендә халык арасыннан чыкмаган түрәләр-җитәкчеләр Шартнамә алдыннан ник халык һәм милли җәмәгатьчелек белән киңәшмәделәр? Нәтиҗәдә нәрсә килеп чыкты? */ Без каядыр бармак булган идек, / Азат булмак булган идек әле... / Алла бәндәләре булмак булдык, / Ә һаман да — Мәскәү бәндәләре, — /* ди Мөдәррис «Син дә әкиятмени?» шигырендә. Ә Казанның чигенүе ерак тарихта да күп халыклар өчен фаҗигале һәм гыйбрәтле булган, чөнки татар артыннан аларны да җиңелү тәкъдире көтеп торган.

Шигырьдәшләреннән берсе — Равил Фәйзуллин тарафыннан «ил тарихы, халык

язмышы, аның бүгенгесе һәм киләчәге турында борчылып, әрнеп иҗат итүче шагыйрь» дип бәяләнгән, үзе дә бер шигырендә «Алтын-көмешләргә алданмадык, / Чиксез байлыгыбыз – ил гаме!» дип язган Рәшит Әхмәтҗановның «Ачлык мәйданы» исемле бәйләмен укысаң, «шушындый шигырьләрнең иҗатчысы да мәрхүменнән соң тиз-тиз онытыла барыр икән, Ходаем!» дип гаҗәпләнүдән тыела алмыйсың. Бу кадәресе хакимияттәгеләрдән генә дә тормый югыйсә. Әлеге шигырьләрне радио-телевидениедән укуны, исәпсез концертларда яңгыратуны әлегә кем тыя? Әнә ТНВ телеканалы зур бер төркем кәмитченең мәгънәсезлек чигендәге «иҗат җимеше»н көнгә берничә тапкыр күрсәтеп тора. Андый тапшыруларның продюсеры да мәгънәле ханым, халыкка озын гомерле бик матур җырлар язып калдырган ата кызы югыйсә. Сәхнәләштерсеннәр иде әнә шул тук егет-кызлар Рәшитнең «Ачлык мәйданы»н, Харрасның «Көй эзләү» поэмасын, Илдус, Мөдәррис, Газинур, Рүзәл шигырьләрен! Рольсез торып тилмергән чакларында бүтән актёрлар да концерт төркемнәренә катнашып шигырь укый аладыр? (Түбәнлек түгелдер бу, мәшһүр Василий Лановой да вакыт-вакыт концертта шигырь укып йөргән, дип сөйләделәр.) Уйнаган рольләреннән генә түгел, тулы спектакльләрнең бер әйбәт шигырьгә тормаганнары аз мәллә? Күптән түгел ТНВның бер тапшыруында мәшһүр Ренат Таҗетдинов та «вак-төяк уйныйбыз» дип әйтеп салды, җаны әрнеп, кат-кат әйтте. Әйтер дә шул, күпме фаҗигалар кичергән татарның Ренат һәм Әзһәрләре, Равилләре, мәрхүм Наил һәм Хәлилләре кинәнеп уйнарлык, рольләре аша халыкка үз сүзләрен әйтерлек заманча трагедияләре, шундыйны яза торган драматурглары булмасын әле! Референдумның, Татарстан Конституциясе кабул итүнең фәлән-фәлән еллыклары авылларда гына түгел, район үзәкләрендә дә бер мәдәни чарасыз узып тора. «Ачлык мәйданы»ндагыдай шигырьләрдән шәп-шәп кичәләр үткәреп буладыр, ләбаса? Халыкның туксанынчы еллардагы хөр рухын уяу тоту өчен дә кирәк болар. Рәшит Әхмәтҗановның һәм башка фидакарь җаннарның милли хокукларыбызны, гаделлекне, халыкларның тигезлеген даулап эссе кояш астында ачлык тоткан урыннарына һәйкәл утыртып кую да артык булмас иде дә бит, кая инде ул безгә! Һәйкәл куеласы изге урыннар аяк асларында таптала һаман. */ Ялган булып су төбенә батасы бар, / Әгәр хаклык өскә калкып чыкмаса. / Дошман таптар каберләрдә ятасы бар, / Халкым болай бер-ике ел йокласа, – /* дип язган Рәшит Әхмәтҗанов. Ни хәл итик соң, һәммәбезгә диярлек «җинел» тормыш кирәк бит. Халыкка түгел, иң элек үзебезгә кирәк, бүген кирәк. */ Кол булу бик җиңел – җаныңның / Ил түгел икәнен белдер дә, / Кер, утыр ятларның түрендә – / Тамагың тук булыр бүгенгә. /*

Болай турыдан бәреп Рәшит Әхмәтҗанов кебекләр генә яза аладыр һәм шулай язарга халкының ирегең, тигезләр арасында тигез яшәргә хокукын яклап ачлык мәйданнарында көйгән фидаи җаннар гына хаклыдыр, бәлки. Аз санлы каләмдәшләре белән бергә шул мәйданда күргән-кичергәннәре генә дә әрнеп-сызланып язу өчен берничә шагыйрь гомеренә җитәрлек булгандыр аның. Ә безгә бер шагыйрьнең кыска гомерендә язганнарын укып һәм һәр шигъри юлыннан диярлек үзебезне танып офтанасы хәзер (шуңа күрә бик укымыйбыз да).

Халыкның тормышын беләсең килсә, ул халыкта балаларның һәм өлкәннәрнең ничек яшәвенә кара, дигән бер акыллы зат. Аларның ничек яшәве дә ил-халыкның ниндилеген сөйли ала. Үзе бай, үзе әхлаксыз һәм шәфкатьсез дәүләтнең аналары һәм балалары хәле шагыйрьләрне һәрвакыт борчып торган. Рәшит Әхмәтҗановның «Карга каргышы» поэмасыннан менә бу юллар Мөдәррис Әгъләмнең «Бердәнбер»енә аваздаш: */ Мондый вәхшилекне белми тарих, / Яши торгач, шундый көн килде: / Балалары исән бар әнкәләр / Ач үлемгә хөкем ителде. / Соңгы кабымнарын әйлар бүе / Безгә бирә-бирә үлделәр. / Ә алар бит сөргеннәрдә түгел, / Үз илләренә кырларында иделәр. /*

Ямьсез шаяру белән әйтсәк, хәзер бездә балалар, түрә-чиновниклар кебек үк, өстен сыйныф санала үзе, чөнки икесе дә, авырсалар, чит илләрнең дәрәҗәле хастаханәләрендә дәвалана. Аерма шунда гына, балалар гади халыктан тиенләп

жыелган хәйрия акчасына, ә түрәләр шул ук халыктан хөкүмәт һәм бай хуҗалар сыгып алган миллионнарга дәвалана. Без укыган чордагы бер китапта язылганча, берәүләргә – клиндер, икенчеләргә анын уртасы.

Рәшит Әхмәтжановнын «Җавап» шигырен укыйм. Алар утырган Ачлык мәйданына Рифкатьнең авылдашы килгән, янәсе, хәл белешә: */ Үләсез бит инде, туктагыз, – ди. / Ул әйткәнне гүя бу белми. / Егетебез тыныч. Тынлап тора. / Сынар керфеге дә селкенми. / «Качып кына бераз ашагыз сез...» / Катып кала Рифкать бер мәлгә. / – Безгә ашау – үз халкынны ашау, / Кеше ашаганың бар мәллә?! /*

Рәшитнен Ачлык мәйданындагы көрәштәше, шигърияттәге туганы Газинур Морат та үзенен «Ачлык» поэмасында әлеге «авылдаш» кебекләрне якыннан белеп сурәтли. */ Улымны телсез калудан / И Тәнрем, үзең сакла. / Сакла хәтерсез калудан, / Сакла Иделен, йортын. / Сакла берук – / Хәтеребез / Болай да ярым-йорты. /*

Тарихи хәтеребезнен ярым-йортылыгы Газинур Моратның байтак шигырьләрендә үзәккә алып бәян ителә. Чөнки вәзгыять шундый: исәпләмәсәң – түзәрлек, исәпләсәң – үләрлек, шуна күрә исәпсез-уйсыз гына яшәргә маташабыз да. Хәтеребезне буташтыру, телебезне бетерү, татарны бүтән милләтләр арасында «эретү» дигәндә безнен бик үк федераль булмаган үзәкнең Сталинчы-Столыпинчы чиновниклары һәм галимнәре әллә нинди нечкә алымнар уйлап таба, өстәвенә, байтагыбыз аларга ярдәм итә. Милли сәясәтчеләребез исә гел азая. Хәер, соңыннан анлашылганча, аларнын байтагына Татарстан мөстәкыйльлеге дә хосусый байлык, балаларына зур мөлкәтле урын йолкып калу өчен генә кирәк булган бит. Андыйларга милләтең ни дә, телен ни? Кайберләре каләм иясенә дә «Бик акыллы булгач, ник бай түгел сон син?» дип кенә җиффәрә. (Каләм иясенен «ник бай түгел»леген Рәшит Әхмәтжанов бер кыска шигырендә болай анлата: */ И пәйгамбәр шагыйрь, кичер Илне, / Хәбәр килде менә әле генә: / Сонгы китабынның әҗеренә / Таш та куеп булмый каберенә...) /*

«Ачлык» поэмасы безне үткәнебезгә дә, бүгенгебезгә дә ачыграк күз белән карарга чакыра, чөнки киләчәгебез шуна бәйләнгән. Ваемсызлыктан изрәп никадәр озак йокласак, уяну шулкадәр кыен, милләт үтәсе ачлык мәйданнары күп булачак. Оттырышлар болай да хәттин ашкан. Татар да күп «ачлык»ларга күнде-күнекте. Аз санлы милләттәшләребезгә бирелгән хокукларны һәм бинибая зур матди байлыкны безнеке дә дип хис итә алсак, ярыйсы яшибез булып күренәчәк. Шуннан еракракк карарга да кирәкмидер, бәлки? Газинур Морат бу турыда болай уйлана: */ Танк белән таптарга да була, / Атарга да була безләрне. / Буй кыскара, уй кыскара бара, / Яши икән халкын тезләнеп. /*

Татар җаныннан алып язылган, хөрлеккә чакырган, телсез-монсыз яшәүләрне кимлек санаган шигырьләрен онытмасак, бу даулы елларның шагыйрь Рәшитләрен, Әюпләрен, Мөдәррис һәм Зөлфәтләрен чынлап та халык арасында, исән каләмдәшләре Равилләр, Илдуслар, Газинурлар янында калгандай хис итәрбез, иншалла.

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ**

# РУХЛАНДЫРУЧЫ

МАРСЕЛЬ СӘЛИМҖАНОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Кин җәмәгатьчелек бакый дөньяга күчкәннәрдән бик сирәкләрен генә юксынып, сүнмәс-сүрелмәс сагыну белән искә ала, тормыш мәйданына кабат шундый ук рухландыручының килүен өмет итә.

Равил Фәйзуллинның «Аһ, тау юклыклар!» дигән шигырь юллары бар. Халыкның: «Татарстанда таулар юк, Чечня белән Грузиядә ул чын таулар», — дип сөйләүләре дә искә төшә. Әмма шуны онытмаска иде: халкыбыз тау кадәр эшләр эшләп дан казанган шәхесләргә бай. Бүген безгә шундыйларның берсе, моннан унике ел элек арабыздан китсә дә, хәтер түребездә әле дә балкып торган Марсель Сәлимҗанов турында сүз әйтү җае чыкты. Исән чагында хезмәтенә күрә кадер-хөрмәтен дә күргән иде, шуннан башласак, дөресрәк кебек.

РСФСР һәм Татарстан Республикасының күпсанлы Дәүләт премияләре лауреаты, Россиянең «Дуслык ордены» иясе, Татарстан, Россия һәм СССРның халык артисты, Төркиянең Истанбул шәһәрендә 1999 елда үткәрелгән төрки театрларның беренче фестивалендә Лион клубы тарафыннан «Иң яхшы сәхнә куелышы» өчен бирелә торган мактаулы бүләкне яулаган режиссёр, берсеннән-берсе талантлырак булган шәкертләр үстергән профессор һәм инде килеп Россия Дәүләте һәм аның театр җәмәгатьчелеге бик үлчәп кенә бирә торган Алтын битлек иясе! Аның да әле иң-иң мәртәбәлесе булган «Намус һәм абруй» номинациясендәгесен тапшырдылар аңа.

«Милли театрны Марсель кебек 36 ел буе җитәкләү берәүнең дә кулыннан килгәне юк», — дигән иде төрки театр һәм Россия театр дөньясының талантлы вәкиле Рифкать Исрафилов. Милли театрның, гадәти театрлардан аермалы буларак, мең-мең проблемасы була. Әнә шуларны бербөтен итеп чишә белүче, барсын да аллан күрүче шәхес кенә театр бөтенлеген саклап, киләчәген ышанычлы итә ала. Шушы юнәлештә зур уңышларга ирешкән бөек остазыбыз турында том-том китаплар язсаң да, аз булыр кебек.

Ринат Таҗетдин белән очрашканда, нишләптер гел Марсель Сәлимҗановны искә алабыз:

— Марсельгә: бүген аншлаг, урамда бер көтү кеше артык билетың юкмы, дип сорап тора анда дисәң, Марсель тәмам үзгәреп китәр иде... «Тамашачы аз-маз йөрсә дә, миңа җиткән», — димәс иде... Әйе! «Теге әсәрне дә бәлкем куеп булыр», — дип фаразларга тотынып, иҗат уты яңа башлаган күзләре, кырыслыгын югалтып, эчке бер җылылык чәчә башлар иде.

Ринат Таҗетдиновны аңларга була. Марсель абыйның иң ышанган артистларыннан берсе иде бит. Директор Шамил Закиров Марсель абыйга: «Синең берничә бик яраткан артистың бар, син һаман да шуларны гына үстерәсең», — дигәч, ул: «Миндә артистларны аеру юк, аларны тигез яратам, әмма ишеткәнең юкмыни кыйммәтле авыр йөкне тарта алган атка гына салалар»,— дигән иде.

Марсель Сәлимҗанов — үз тамашачысы булган режиссёр. Һәм аның тамашачылары шулчаклы күп иде, театрыбызның баш режиссёры булып торган, ягъни 36 ел буе (гади еллар димәс идем мин аларны: «Җепшеклек чоры» дигән дәвердән Торгынлыкка, аннан Яңарышка килү, СССР таркалу, социаль строй үзгәрү) аның артистларына ярым-йорты залларга уйнау хет кеше исәбе булса да булыр дип ялынып чакырып китерелгән тәртипсез карчыклар төркеменә уйнарга туры килмәде.

Нечкә тавышлы артистның, табигать биргән тавышын калынайтып сөйләп, тавышын бозуын яки күп нәрсәдән мәхрүм режиссёрның, биек котурннарга басып,



мәһабәтле күренергә азаплануларын да күргән бар безнең. Ә минә театрның тоткан юлы милләтнең куәтен арттыру икәнен сиземләгән, үзе исә Ходай Тәгалә тарафыннан пәһлеван режиссёр булып яратылган Сәлимжановка мондый кыланып маташулар һич кирәкмәде. Бу урында аның остазларын искә төшерү дә артык булмас. Сәлимжановның курс житәкчесе Андрей Гончаров (Андрей Александрович безнең Югары курсны да житәкләде, шуңа белгәнемне сөйлим) Станиславский системасын изге итеп күрә иде, чөнки ул Станиславскийның шәкерте бөек Лобановта тәпле белем алган. Марсель Хәкимовичка аларның икесендә дә укырга туры килгән. Станиславскийның үлемсез системасына мәхәббәт алардан килә, һәм ижаты дәверендәге тәжрибәсе дә аны шуна инандырган (аның 1999 елны «Театральная жизнь» журналында чыккан «Корни Мхатовской школы – наши корни» дигән мәкаләсендә дә чагыла бу фикер). Марсель Сәлимжанов та Гончаров кебек театр дөньясын баса башлаган сектант режиссёрларның, ягъни бар нәрсәнең эчен тышка әйләндерү юлы белән «яңа сүз» әйтүчеләрне бик өнәмәде. Ни өчен Гончаров әлеге режиссёрларны (ә бит алар арасында искиткеч талантлы шәхесләр дә бар) сектантлар гына дип атый иде соң? Аның уенча, әлеге шаккатристларга үз трюклары кадерлерәк һәм алар Станиславскийны урыныннан йолкып ташлап, шунда үзләре менеп утырмакчы булалар икән. Марсель абыйга, инде әйткәнемчә, сектант режиссерлар кебек ниндидер ясалма дөньялар ясап, шунда тар интересларын тормышка ашырып яту кирәк булмады. Аның көч-куәте, зиһене житкәнгә, ул, һәрвакыт театрны үзәк юлдан алып бара алды. Театрны татар мәдәниятенең бер алтын баганасы итеп эш йөртте. Сектант режиссерлар театр драматургларддан башка да яши ала, әнә Библиядан бер бит текст алам да өч сәгатьлек спектакль куям, чөнки театрда сүз беренче түгел, иң мөһиме хәрәкәт (чөнки хәрәкәтләрне режиссёр уйлап чыгара бит, димәк, театрның Алласы режиссёрлар) дип торганда, Марсель абый, Станиславский шәкертләрен куәтләп: «Театр сәнгате драматургиядән башлана, без, Станиславский системасына йөз тотучы режиссёрлар, драматургның идеясенә, әсәренә кан өстибез, артистлар аркылы жан өрәбез, төп бурычыбызны кеше рухының тормышы турында (ә туалетта ничек утыруын күрсәтү түгел), кешеләр өчен, кешеләр ярдәмендә сөйләү», — дип әйтә килде. «Тамашачыга авторның сүзен һәм фикерен тиешле югарылыкта житкерә алмагач, ни кала соң аларга?! Сектант режиссёрлар эзләнү дигән мөһим бурычның формаль ягы белән генә эш итәләр. Артистта көчле холыклы ижат рухы тәрбияләү урынына, аннарын бутап, болганчык суда әллә ниләр бар дип женләнәләр, күз буалар».

Чыннан да, сүз милли театрда икеләтә мөһим роль башкара бит. Мәдәниятебезнең иң зур казанышларыннан берсе булган сүзнең дәрәжәсен белер-белмәс түбән төшерү ахмаклык икән. Телебездән генә аерылыйк, без шундук милләтебезне дә, соңгы дәүләтебезне дә югалтачакбыз.

Бик игътибарга лаек факт: Марсель абый, мактаулы Америкага барып, егерме ел күрешмәгән Галилә апасы янында ике атна буе искиткеч дәрәжәдә кунак булып кайтты. «Америкада каласыгыз килмәдеме соң?» — дигәч: «Анда калсам, бер елдан соң ук үләр идем», — диде. Бу да аның үз халкын, үз илен яратуы турында сөйли. Һәм аның феноменаль көче дә шуннан иде – татар театрының элек-электән килгән традицияләренә таянды, яңартты һәм туктаусыз үстерә алды. Рус булмаган милләтләрнең мәктәпләре ябылып беткән, милли культураларын Рәсәй туфрагыннан төбе-тамыры белән йолкып ташлау башланып киткән шомлы бер чорда да, Камал театрына үз йөзен югалтмаска булышып, милли тамырларда яшәтү, яшәртү һәм үстерү

юлында фидакарь көрәшеп, дөньяда бәһасе булмаган тәҗрибә туплады. Ул тәҗрибә безгә бүген дә бик кирәк.

М.Сәлимҗанов белән бергә эшләү һәркайсыбызга да җинел булды кебек. Театрда әдәби бүлекнең мөмкинлекләрен чикләп, үзе белгәнчә, үзе теләгәнчә ваклап, тураклап бетерә торган кешеләр бар иде. Бу хәлдән гарык булып, эшемнән китәргә дә омтылып карадым. Шунда Марсель абый: «Китсәң, бер әсәрең дә безнең сәхнәдә куелмаячак», — дип калырга мәҗбүр итте. Һәм ни гаҗәп, «Идегәй» дастаны буенча сәхнә әсәре язарга алынган драматургларның кульязмаларын оштамый, авторларына кире кайтаргач, «Идегәй» трагедиясен миннән яздырды. Һәм, әлбәттә, Марсель абый режиссёр булганга гына яза алдым. Аны миннән тагы Дамир Сиражиев дигән режиссёр яздыра алган иде, әлбәттә, ансы Дамирча бөтенләй үзгә әсәр булып дөньяга килгән иде. Шуны да өстәү мөһим дип уйлыйм: «Идегәй» Марсель Сәлимҗанов тарафыннан үзе куйган иң мөһим ун спектакль исемлегенә кертелгән булса да, инде ул үлгәч, театрның 100 еллыгы уңае белән чыккан 100 спектакль дигән видео-спектакльләр җыентыгына кертелмәде. Һәм, гомумән, зыялыларыбыз тарафыннан күтәреп алынган «Идегәй» нишләптер тиешле бәясен алалмады. Бу хакта миңа соңрак Минтимер Шәриповичтан да ишетергә туры килде: «Хәзерге чорда вакыт ягы җитәрлек булып, бик күп укыганлыктан: «Идегәй»не теге чакта бөтен зурлыгы белән аңламаган булуыбызга төшендем, аны хәзер кабат сәхнәгә кайтарырга вакыт җитте», — диде. Бу сүзләр күбрәк Ринат абый белән миңа төбәп әйтелсә дә, аларны бик күпләр ишетте. «Мөгаен, куймаслар», — дип җаваплаганымны да ишеттеләр кебек.

«Сәлимҗанов мәйданга чыгып, «азатлык» дип кычкырмый», — диюче провокаторлар да табылган иде вакытында. Рус һәм чит ил драматургиясен куя дип тә гаеп тактылар. Ә бит без репертуарга рус драматургиясенең алтын өлгеләрен генә ала идек. Марсель абый аларны татар театрына хезмәт иттерде ләбаса. Драма сәнгатебез үсеше өчен дә, театрыбыз рус театр дөньясы кинлекләрендә хәрәкәт иткәндә дә, алар безнең өчен ифрат файдалы иде. Әйтик, Островскийның «Бирнәсез кыз»ы. Бу әсәр шулчаклы да камил язылган ки, аның янәшәсенә дөнья даһилары иҗат иткән бик сирәк сәхнә әсәрләрен генә куеп була. Әнә шуның героинясын уйнаган артисткаларыбыз, мин монда Лариса — Алсу Гайнуллинаны гына түгел, бик хаксыз рәвештә искә алынмый торган Лариса — Рузия Мотыйгуллинаны да мисалга китерәм, алар Островский — Сәлимҗанов тандемында туган образ гәүдәләндерү тәҗрибәсен татар сәхнә әсәрләрендә дә кулланып, татар пьесаларының искиткеч зур уңышларга ирешүенә булыштылар. Шулай ук «Бирнәсез кыз»ның берничә театр сезоны дәвамында, кая гына барса да, Рәсәйне шаулаткан спектакль булуын онытмыйк. Дистәләгән театр тәнкыйтьчеләренең, шул исәптән М.Ульянов, Б.Поюровскийларның: «Россиядә бу дәрәҗәдәге Лариса Огудалова да, мона тиң спектакль дә юк, татарча куелган бу спектакль таң калырлык», — дип Рәсәй халкына татар театры турында дан җырлаулары начар була аламы? Ә Б.Горбатовның «Бер төн»е куелгач: «СССРда Биктимеров Кривохатскиена тиң торырлык Кривохатский иҗат ителмәде», — диюләре дә безнең милләт казанына су койды бит. Мисалларны тагы күп китерергә булыр иде, әмма Марсель Хәким улы режиссурасы ирешкән башка мөһимрәк казанышларны да онытмыйк. «Миркәй белән Айсылу», «Кыю кызлар», «Казан сөлгесе», «Сүнгән йолдызлар», «Американ» кебек, татарның элекке тормышын тасвирлаганда, чиләк-чиләк тискәре буяулар кулланып язылган бу пьесалар башка режиссёрлар куйганда, бик кыска гомерле спектакльләргә әверелгән. Ә менә Сәлимҗанов аларга бөтенләй башка яңгыраш һәм башка язмыш бүләк итте. Әнә, Марсель абый куелышында сүнгән йолдыздан сүнмәс йолдызга әверелгән спектакльне генә алыгыз. Татар сәхнәсендә бер генә спектакльнең дә тоташтан 700 тапкыр аншлаг белән баруын хәтерләүче юк. «Әни килде» дә, «Әлдермештән Әлмәндәр» дә, хәтта артык киң катлау тамашачыны үзенә тартучы «Зәңгәр шәл» белән «Хуҗа Насретдин» дә тәнәфесләр аша, яна куелышлар аша гына бу саңга якыная алдылар. Туганлаш халыкларның күпме әсәрен сәхнәбезгә күтәрде ул тагы. Татар артистлары башкорт режиссёрларыбыздан тыш, әле үзбәк, әле казах, әле азәрбайҗан режиссёрлары белән аңлашып, тагын да туганлаша төшеп спектакльләр чыгара тордылар. Бездә хәтта француз режиссёры — француз әсәрен,



Латин Америкасыннан килгән режиссер испан әсәрен куйды Оста үзе дә гарәп, кыргыз, башкорт, рус, итальян халыкларының сәхнә әсәрләренә еш мөрәҗәгать итә иде.


Сәлимжанов үләренә бер ел кала: «Мин бу театрга тагы биш ел буе бик кирәк», — дип йөри башлады. Биш ел түгел, тагы унбиш ел да бик кирәк булганын менә хәзер генә аңлый башладык кебек. «Марсель Сәлимжанов бытописатель генә», диючеләргә: «Ә сез аның «Качаклар», «Портфельле кияү», «Әлдермештән Әлмәндәр», «Өч аршын жир», «Американ», «Ябырылу», «Бер төн», «Бирнәсез кыз», «Идегәй», «Баскетболист» кебек бер-береннән ут белән су шикелле аерыла торган спектакльләрен карадыгызмы соң?» — диясе килә. Бөек оста үлгәч, театрга кайгы уртаклашкан йөзләрчә телеграмма яуды. Аның җәсады белән саубуллашырга татар гына түгел, руслар, казахлар, башкортлар, чувашлар, үзбәкләр, азәрбайҗаннар агылды. Безгә берәү белән саубуллашырга да бу кадәр күп халыкның килгәне булмады. Чөнки ул каты авыру белән авырганда да, фәрештәдәй Гөлнары: «Марсель, тыңла сүземне, калдырып тор репетицияңне, зинһар, Германиягә барып дәвалан», — дип каршына тезләнеп ялварганда да, оста татар милләте үзенә ышанып тапшырган театрын кайгыртты — Мансур Гыйләҗевның сәхнәләштерер өчен ифрат авыр булган «Баскетболист» әсәрен (сөйләшә алмый, бугазын тотып утырса да, каны агулана башлаганын белсә дә) куеп бетерде.

Соңгы дәвердә драматургиягә һәм режиссурага яшьләрне күбрәк тартырга тырышуы да театр киләчәген кайгыртудан иде. Хәер, ул гомере буе, нәкъ Станиславский системасы кушканча, театрның драматурглар өчен дә туган йортка әверелүен кайгыртып яшәде. Шәриф Хөсәенов, Аяз Гыйләҗев, Туфан Миңнуллиннар белән булган иҗади дуслыгын һәркем белә. Хәй Вахит һәм Сәет Шәкүровны да читкә какмады ул. Диас Вәлиев, Нурихан Фәттах, Фәнис Яруллин, Ризван Хәмид, Зөлфәт Хәкимне дә сәхнәләштерде. Батулла, Рөстәм Мингалимов, Мансур Гыйләҗевлар да театр репертуарында урын алды. Разил Вәлиев, Марсель Галиевлар белән дә яратып эшләде ул. Дөрес, Разилне Дамир Сиражиев үз театрына алып китте, Галиевны исә Минзәлә театры куйды. Ркаил Зәйдулланы инде мин 1985 елдан ук театрга килергә кодалап йөри башлаган идем. Безгә бу яшь егет белән Казан — Канаш поездында бергә кайтырга насыйп булган сәгатьләрдән башлап. Әмма Ркаилне театр белән кызыксындыруларым бик күп еллардан соң гына үз эшен эшләде. Ниһаять, Марсель абый аның «Саташкан сандугач»ын Камал сәхнәсенә күтәрде. Бүген инде театрлар белән уртак тел табучы, «Үлеп яратты»сы кайнар алкышлар астында барган Ркаил сәхнәдә нык басып тора кебек. Димәк, Марсель Сәлимжановның тырышлыгы монда да бушка китмәгән.

Читтән карачуыга күбрәк күренә, диләр. Мәскәүнең иң затлы театр белгечләре: «Чын милли сәнгать кенә дөнья халкына кызыклы. Менә сез шуна ирешкәнсез. Сезнең шушы югарылыктан төшәргә хакыгыз юк», — дип, Марсель Сәлижанов житәкләгән театрны зурлый иделәр. Марсель абый турындагы хәтер исә бу сүзләргә икеләтә җаваплы карарга, татар театры ирешкән югарылыкны сакларга, үстерергә чакыра.

**Юныс САФИУЛЛИН,**
*Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе*

# УЛ ҺАМАН БЕЗНЕҢ БЕЛӘН



Шулкадәр тиз үтә икән бу гомер. Театрның эче-тышы халык белән тулы, бик күп тамашачыларның күзләрендә яшь, артистларыбыз башларын аска игән, шушы коточкыч авыр көн әле генә булган шикелле, ә инде унике еллап вакыт үткән дә киткән.

Ә Хәкимич (без аны яратып «Хәкимич» дип йөртә идек) онытылмый!.. Аның тавышы, репетицияләр вакытында, артистларга аңлатырга дип, йөгереп сәхнәгә менүләре... Онытылмый!..

Сүземне бик ерактан, институт елларыннан башлыйсым килә. Без аның белән әле ныклап таныш та түгел, ә Мәскәүдә узган декада көннәрендә, «Король Лир» спектаклендә, шпагада сугышканын күреп, шаккаткан идек. Ул инде спорт мастеры, Татарстан чемпионы иде шикелле.

Бу аның, университетның юридик факультетын ташлап, ГИТИСка укырга кергән вакытлары... Безнең исә Мәскәүнең Кече театр каршындагы Щепкин исемендәге Югары театр училищесында укыган вакытыбыз.

Һаман да әле аңлап житә алмыйм, ни өчен ул чакта ук без аның белән ныклап аралашмадык икән?..

Аның да, безнең дә вакытыбыз аз иде шул, кичләрен спектакльләр карыйбыз, музейларга йөрибез, Малый театр спектакльләрендә, массовкаларда катнашабыз, китаплар укыйбыз, көндез инде үзебезнең дәресләр, ул еллар, әлбәттә, һич кенә дә онытылмый.

Мин аның белән бер тапкыр гына очраштым, ул вакытта кайбер спорт төрләре буенча институтлар арасында ярышлар оештырыла иде. Безгә ГИТИС белән очрашырга туры килде, фехтование буенча, үзебездә фехтование белән шөгыльләнә башлаган идем. Шуңа күрә мин дә катнаштым. Шунда миңа беренче мәртәбә Марсель белән очрашырга туры килде, шуңа да ул күңелемә ныклап кереп калды. Әлбәттә, бирелдә мин оттырдым, дөресен генә әйткәндә, нык кына кыйналдым.

Марсель Хәкимич спортта гына түгел, сәнгатьтә дә бик зур уңышларга иреште, ул татар театрын шундый югарылыкка күтәрде ки, милли театрлар арасында беренчеләрдән санала иде. Буш сүзләр генә түгел бу.

Безне, яшь артистларны (үзе дә бездән әллә ни олы түгел иде), нәрсәсе белән җәлеп итте соң? Үзенең, спектакльләр куйганда, бик тә әзерләнеп килүе белән. Репетициягә килгәч, ул нәрсә эшлибез соң әле хәзер дип вакыт уздырмый, җигелеп безне эшләтә башлый. Теләсә нинди пьесаны куйса да, ул безгә, иң беренче, без бу әсәр белән халыкка нәрсә әйтергә тиешлегебезне аңлата һәм шуны уйната да белә.

Мин шактый еллар Театр әһелләре берлеге рәисе булып эшләдем. Марсель Хәкимич белән Мәскәүдә конференцияләрдә булырга туры килә иде. Анда бөтен Рәсәй театрларыннан режиссёрлар, зур артистлар җыела. Тәнәфес вакытында бер читтә басып торабыз, мине яныннан җибәрми. Шакката идем, зур артистлар, режиссёрлар аның белән үзләре килеп исәнләшәләр, чөнки аны беләләр иде. Без бик күп гастрольләргә йөри идек бит, шуңа күрә аның нинди режиссёр икәнен яхшы белгәннәр. Ул беркайчан үзен түбән итеп тотмады, аны шуңа да нык ихтирам итәләр иде. Чыгыш ясаганда, шундый итеп сөйли, тыңлап туя алмыйсың.

Чынлап та онытылмый Хәкимич...



Ул балыкка йөрергә ярата иде, хатыны Гөлнар анардан калмый. Ял йортларына йөрергә яратмый иде ул, үзебезнең Татарстан төбәген бик ярата иде. Берничә ел алар, бер төркем артистлар белән, Мамадыш ягына, Вяткага балыкка йөрделәр. Салих Сәйдәшев Идел буенда Кызыл байракта ял итсә, Марсель Вятка елгасын үз итте. Вяткада зур булмаган утраулар бар, алар шунда кереп урнаша, палаткалар коралар, хатын-кызлар йөгереп тәртип урнаштыра, ә ирләр балыкка китә.

Марсель балыктан кайткач, анын үзбәк халатына охшаган бер бик матур халаты бар иде, шуны киеп, палаткалар янына урындыкка утыра, хатын-кызлар ашарга пешерә, ә ирләр балык чистарта, чынлап әйткәндә, мәш киләләр.

Вятка елгасы Идел кебек киң түгел, каршы яктагы авылдан барысы да күренеп тора, авыл халкы бик кызыксынучан бит инде ул. «Әнә, үткән елны килгән үзбәк тагын хатыннары белән килде. Аларны ул бик каты эшләтә, гел чабып кына йөриләр, ә үзе утырып кына тора», — дип әйтәләр икән.

Марсель Хәкимич бөтен йөрәге белән Татарстаныбызны ярата иде. Үзенең тамашачыларын, Казанны, артистларын яратты, хөрмәт итте. Әнисе Америкада яши иде, бер елны Гөлнар белән кунакка бардылар.

«Анамнарда утырабыз, фатирлары әйбәт, бер эш, бер кайгы юк. Ашарга-эчәргә муеннан, бик матур шәһәр, Сан-Франциско шәһәре... Бер ун көннән шулкадәр туйдым, үләм, кайтасым килә, Казанымны, артистларымны, өемне сагындым», — дип сөйләгән иде.

«Артистларымны яратам», — дип әйтүенә мин ышана идем.

Безнең артистларыбызга, Студенец дигән жирдән урын алдылар, шунда йортлар төзи башладылар, ләкин Марсель аннан түгел, башка жирдән алды.

Вакыт үтте, бераздан ишетәм: Марселебез, бакчасын сатып, Студенецка килеп, артистларыбызныкы яныннан йорт сатып алган. Шуны ишеткәч, шаккаткан идем, тагын артистларын сагынып, алар янына күчкән. Менә шундый иде ул безнең Марселебез! Шуна күрә ул һич кенә дә онытылмый, һаман безнең күз алдыбызда!

**Ринат ТАЖЕТДИНОВ,**
*Татарстанның һәм Россиянең халык артисты*

# ТАЛАНТЛЫ ТАРИХЧЫ–РОМАНТИК ЯДКАРЕ

## МИХАИЛ ХУДЯКОВНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

*Күренекле тарихчы-археолог, энциклопедик белемле, Идел буе һәм бу төбәктә яшәүче халыкларның борынгы һәм урта гасырлар тарихы буенча зур мирас калдырган, 1894 елда Малмыж шәһәрендә сәүдәгәр гаиләсендә дөньяга килгән, 1936 елда 42 яшендә «халык дошманы» буларак үтерелеп, соныннан акланган Михаил Георгиевич Худяковның тууына быелның 3 сентябрендә 120 ел тулды.*

### Ни өчен Михаил Худяковны сатлыкҗан диләр?



«Халык дошманы» дигән тамга алып ташланып, ябык архивлар ачылгач һәм фәнни әйләнешкә яңа чыганаклар кергәч, М.Г.Худяков турында гыйльми даирәдә ике төрле караш калыплашты. Күренекле удмурт галимәсе М.В.Гришкина аның турында: «Ул якты идеалларны тормышка ашырырга мөмкин булуына, Россиядә кешеләр һәм халыклар арасында чын мәгънәсендә тигезлек һәм туганлык булырга мөмкинлегенә ышанган үз заманы баласы, тарихчы-романтик булды. Шашынып ышануының бөтен көчен ул үзенең хезмәтләренә салды, шул исәптән Нократ-Чулман төбәге тарихына багышланган хезмәтләренә дә. Идеаллары тормышка ашсын өчен ул үзен дә, хезмәттәшләрен дә кызганмады, ахыр чиктә, шулар өчен тормышын бирде», – дип яза[1].

М.Худяковның гражданлык позициясен гаепләп бәяләүчеләр галимне совет системасына артык нык яраклашуда, куркуыннан иптәшләрен, хезмәттәшләрен, шул исәптән заманында үзе баш игән, хөрмәт иткән, тормышының кыен мизгелләрендә ярдәм кулы сузган коллегаларын, остазларын соңгы хезмәтләрендә нигезсез тәнкыйтьләүдә, аларны «буржуаз мәдәният вәкилләре», «буржуаз фән вәкилләре» буларак күрсәтеп, совет дәүләте дошманнары исемлегенә кертүдә гаеплиләр, икейөзле шәхес иде дигән фикерне алга сөрәләр[2].

Чыннан да, галимнең Ленинград чоры (1925-1936) эшчәнлегендә, бигрәк тә 1931 елдан, ул эшләгән Матди мәдәният тарихы дәүләт академиясенә «марксистик совет фәнен» яклау бурычы йөкләнгәч, буржуаз фән вәкилләрен тәнкыйтьләү ачык чагыла. М.Худяковның «Казан чоры» (1918-1925 еллар) гомеренең бер мизгеле дә бу яктан галимнәр игътибарын җәлеп итте. Билгеле булганча, Идел-Урал төбәге тарихчыларын берләштерүче үзәк ролен озак еллар Казан университеты каршындагы Археология, этнография һәм тарих җәмгыяте үти. 1920 елларда аның утырышларына империя чорында югары уку йортларында эшләгән галимнәр җыела. Советлар илендә алар үзләренең гыйльми эшчәнлекләрен төрле оешмаларда (Казан университеты, музей, дәүләт оешмалары һ.б.) дәвам итәләр. 1919-1921 елларда җәмгыятьнең эшчәнлегендә М.Худяков та актив катнаша, аның журналы булган «Хәбәрләре»ндә («Известия»)

---

[1] Гришкина М.В. М.Г.Худяков — историк Вятско-Камского края // Материалы краеведческих чтений, посвящённых 135-летию Общества естествоиспытателей при КГУ, 110-летию со дня рождения М.Г.Худякова. – 24-25 марта 2004 г. – Казань: Школа, 2004. – С.16-18.

[2] Руденко А.К. В плену у времени // Казань. – 2004. — №3. – С.41-45; Куликов К. Распятая честь. О трагической гибели М.Г.Худякова // Казань. – 2004. — №3. – С.46-55.

мәкаләләр дә бастыра («Борынгы Казанның күренешләре», «Казан татарларының агач архитектурасы» һ.б.).

Археология, этнография һәм тарих җәмгыяте әгъзалары арасында фикер каршылыклары килеп чыккалый. Шундый зур каршылыкларның берсе — күпчелеге земство һәм иганәчеләр хисабына 1917 елда илнең төньяк-көнчыгышы халыкларының тарихын-көнкүрешен һәм археологиясен өйрәнү һәм фәнни кадрлар әзерләү максатында Казанда ачылган Төньяк–көнчыгыш археология һәм этнография институтын Көнчыгыш академиясенә әверелдерү буенча бәхәс була. Бу хактагы проектны 1920 елның 30 октябрендә ТАССРның Халык мәгарифе комиссариаты утырышында Б.Н.Вишневский, Г.Ш.Шәрәф, А.Максудов, М.В.Бречкевич һәм М.Г.Худяков кул куя. Республика Халык комиссарлары советы бу карарны раслый. Татар югары уку йорты дип уйланылган Көнчыгыш академиясенең ректоры итеп профессор Н.Н.Фирсов билгеләнә[3]. 1922 елның сентябрендә академия Казан университетының иҗтимагый фәннәре факультеты, Халык мәгарифе югары институты (элекке Казан педагогия институты) белән кушылып, беренче чиратта укытучылар әзерләргә тиеш булган Көнчыгыш педагогия институты итеп үзгәртелә. Шушы юл белән совет властен «кайнар» якламаган галимнәр укытудан читләштерелә.

1920-1921 елларда Археология, этнография һәм тарих җәмгыятенең эшчәнлеге төрле сәбәпләр аркасында туктап кала. 1922 елның апрелендә Җәмгыятьнең яңа рәисе сайлана (К.В.Харлампович), ләкин Җәмгыятьнең Советын сайлаганда Совет хөкүмәте яклы булган галимнәрнең күбесе үтмиләр. Шулай итеп, җитәкчелеккә сайлаулар галимнәрнең профессиональ сыйфатлары буенча түгел, ә сәяси карашларыннан чыгып уздырыла. Казан университетының гуманитар факультетлары ябылгач, университет укытучылары Көнчыгыш педагогия институтына, ТАССРның Үзәк музеена, архив һәм статистика идарәләренә эшкә урнашырга мәҗбүр булалар.

Бу вакытта Җәмгыятьнең җитәкчелеге, совет дәүләтенең фән һәм фәнни хезмәткәрләргә карата уздырыла торган сәясәте белән килешмичә, аңа пассив һәм эчкерле каршылык күрсәтү юлына баса. Мондый позиция сәяси максатларны күздә тотмый, ә фәннең киләчәге турында борчылуга бәйле була[4]. Җәмгыятьнең 1923 елның гыйнварыннан 1924 елның мартына кадәрге вакыт аралыгы хисабында «Хәбәрләр»нең XXXIII томының 1нче чыгарылышы, марксистик әдәбият бастырырга кирәк булу сәбәпле, дөнья күрми калды дип әйтелә. Нәтиҗәдә Совет хакимияте тарафыннан Җәмгыятьнең эшчәнлегенә күзәтү көчәйтелә, ОГПУның Татарстан бүлеге 1924 елның сентябрендә рәис К.В.Харлампович һәм тагын алты галим – Җәмгыятьнең Совет әгъзалары И.И.Сатрапинский, С.П.Шестаков, В.Ф.Смолин, С.И.Порфирьев, Н.В.Никольский һәм И.М.Покровский өстеннән тикшерү башлый. Алар карагрухчылыкта, иске фикерләр белән сугарылган «чиста фән» белән шөгыльләнүдә, контрреволюцион һәм миссионерлыкта, халык арасында христианлык, искелек, консерватизм фикерләрен таратуда, шулай ук борынгылыкны һәм сәнгатьне саклауны сылтау итеп чиркәүнең байлыгын алуга каршы чыгуда гаепләнә[5].

Тикшерү эшләре буенча сорау алуга Җәмгыять әгъзалары В.Егерев, А.М.Миронов, Г.С.Гобәйдуллин, Н.М.Троицкий, Н.И.Воробьев, Г.М.Худяков и Н.Н.Фирсов чакырыла, күбесе гаепләнүчеләрнең сәяси карашлары турында фикерләрен белдермиләр. Ахыр чиктә, М.Худяков күрсәтүләре нигезендә Җәмгыять христиан идеяләрен таратуда, миссионерлык белән шөгыльләнүдә гаепле дип табыла. Академик К.В.Харлампович өч елга ТАССРдан сөрелә, башка гаепләнүчеләр, тискәре характеристикалар алып, иректә кала. 1924 елның октябрь аенда Җәмгыятьнең

---

[3] Кабирова А.Ш. Историография советского периода истории Татарстана (1917-1950-е гг.). – Казань, 2008. – С.20-21.

[4] Там же.

[5] Сидорова И. Поступают «сведения о группировке черносотенного элемента в Обществе археологии, истории и этнографии при Казанском университете...» (ОАИЭ в первые годы Советской власти, 1917-1924 гг.) // Гасырлар авазы—Эхо веков. – 2003. – №3/4. – С.70-71.

[6] Там же. – С.72-73.

чираттан тыш утырышында рәис итеп профессор Н.Н.Фирсов, аның урынбасары итеп Г.С.Гобәйдуллин сайлана[6].

М.Худяков 1925 елда Ленинградка күченә, хезмәт юлын хәзерге Россия милли китапханәсендә фәнни хезмәткәр буларак башлый. 1926-1929 елларда Тарих һәм матди мәдәният тарихы дәүләт академиясе аспиранты: Идел буе төбәге тарихының таш һәм бакыр чорларын өйрәнә. 1931-1936 елларда ул эшләгән Ленинградтагы Матди мәдәният тарихы дәүләт академиясенә Совет хөкүмәте археология фәненә марксистик методологияне кертү, «буржуаз-дворян археологиясен һәм историографиясен» тәнкыйтьләү һәм шушы тәнкыйтьнең һәм чыганакларны анализлауның яңа методларын эшләү бурычын йөкли[7]. М.Худяковның шушы бурычны үтәү йөзеннән һәм яңа идеологик таләпләрне күздә тотып 1933 елда басылган «Дореволюционная русская археология на судьбе эксплуататорских классов» хезмәте методологик әһәмияткә ия була. Галим Россия археология фәнен сыйнфый күзлектән чыгып бәяли, «марксистик совет фәнен» яклап, «буржуаз фән вәкилләрен» тәнкыйтьли, тискәре мисаллар төсендә үзе яхшы белгән хезмәттәшләренең биографияләреннән китерә һәм аларны аерым очракларда урынсызга кимсетә. Шунысы кызык, соңрак М.Худяков эшләгән Россия тарих фәне этаплары барлык совет югары уку йортлары өчен тарих фәне дәреслекләрендә, авторның исеме аталмыйча гына, урын ала. Шулай итеп, М.Худяков историографиядә партиялелек принцибы методологиясен эшли[8]. Талантлы шәхесләргә һәр сәяси режим мохтаҗ: совет хөкүмәте тарих фәнендә марксистик принципларны эшләүдә күренекле тарихчы М.Худяковның гыйлемен файдалана.

Аның 1932 елда басылган «Великодержавный шовинизм в русской этнографии» исемле хезмәте дә шушы рухта язылган. Инкыйлабка кадәрге фәнни мирасны бәяләгәндә М.Худяков Россия империясендәге барлык уку йортлары, фәнни җәмгыятьләр, галимнәр самодержавиене ныгытуга хезмәт иттеләр, хөкүмәт тарафыннан финансландылар, шовинистик идеологияне булдырдылар дигән фикергә таяна.

Ул этнографларның ил халыкларын русларга һәм инородецларга бүлеп карауларын ассызыклый. Европаның бүгенге көндә күренекле галиме А.Каппелер фикеренчә, киң кулланылышта булган «инородец» термины фундаменталистик, хәтта расистик потенциалга ия һәм XIX гасырның икенче яртысындагы рус җәмгыятендә күзәтелгән сәяси һәм рухи агымнарга тәңгәл килә[9]. Бүген инде шунысын да ассызыкларга мөмкин: Н.И.Ильминский, В.В.Григорьев, Н.П.Остроумов кебек ислам һәм төрки дөнья белгечләре, хакимият органнарына эшкә урнашып, югары даирәдәге чиновникларга хатлар язып, яки үзләренең хезмәтләре белән самодержавиенең ил халыкларына карата уздырыла торган милли сәясәтенә нык йогынты ясадылар.

М.Худяков империя чоры рус этнографларын өч төркемгә бүлә. Мондый бүленешнең төп билгеләреннән берсе булып галимнәрнең нинди сословие вәкиле булуы тора. Шуңа да карамастан, барысы өчен дә уртак сыйфат — рус булмаган халыкларга карата шовинистик караш һәм аны пропагандалау. Шушы карашны таратучылардан беренчесе итеп ул Россия тарих мәктәбе концепциясенә нигез салучыларның берсе Н.М.Карамзинны һәм славянофилларны атый. Аларның икенче уртак сыйфаты дип галим миссионерлык белән бәйлелекне күрсәтә (Н.И.Ильминский, Н.А.Бобровников, Н.Ф.Катанов, Н.А.Ашмарин, А.И.Емельянов һ.б.). Чыннан да, рус зыялылары, галимнәре арасында рус булмаган халыклар киләчәктә ассимиляцияләнеп, тәмам урыслашачаклар, тик моның өчен вакыт кирәк дигән карашлар өстенлек итә, бу мәсьәләдә аларның күпчелегенең карашлары хакимиятнекеннән аерылмый.

[7] Гришкина М.В., Кузьминых С.В. Михаил Георгиевич Худяков как историк // Михаил Худяков. Тарихи-документаль җыентык. – Казан: «Җыен» нәшрияты, 2011. – Б.642.

[8] Мельникова О.М. М.Г.Худяков как историк науки // Материалы краеведческих чтений, посвящённых 135-летию Общества естествоиспытателей при КГУ, 110-летию со дня рождения М.Г.Худякова. – 24-25 марта 2004 г. – Казань: Школа, 2004. – С.133-137.

[9] Каппелер Андреас. Как классифицировали русские источники XVI – середины XIX вв. этнорелигиозные группы Волго-Уральского региона // Исповеди в зеркале: Межконфессиональные отношения в центре Евразии (на примере Волго-Уральского региона – XVIII–XXI вв. / сост. и отв. ред. Стефан А.Дюдуаньон, Ксавье Ле Торривеллек, Ольга Н.Сенюткина. – Н.Новгород, 2012. – С.32-33.

М.Худяков, ун – консерватив – лагерьдан тыш, сул – либерал – группа вәкилләрен аерып чыгара (Д.А.Золотарев, С.И.Руденко, С.А.Теплоухов һ.б.). Буржуаз зыялыларның өченче группасына «дворян булмаган» төрле катлам вәкилләре гаиләләреннән чыккан зыялылар кертелә (алар күбесе земство оешмаларында хезмәт куючылар – этнографлар Д.А.Клеменц, Л.Я.Штернберг, Б.Г.Богораз һ.б.). Сыйнфый принципка нигезләнеп, М.Худяков 1886 елда Рус география җәмгыяте рәисе итеп сайланган һәм 23 ел бу вазифаны башкарган В.И.Ламанскийның эшчәнлеген тискәре бәяли. М.Худяков үз фикерләрен раслау өчен этнографларның хезмәтләреннән рус булмаган халыкларны кимсетеп язган өзекләр китерә.

Хезмәтнең икенче, «Революциягә кадәрге провинция» исемле бүлегендә Казан этнографларына зур урын бирелгән. Автор «шовинистлар» исемлегенә чувашлар, марилар, удмуртлар турында китаплар язган, «Мултан эшендә» гаепләүче эксперт-галим сыйфатында катнашкан, «Обрусение инородцев и задачи обрусительной политики» (1892) исемле мәкалә авторы И.Н.Смирновны кертә, Катановны, Ашмаринны, Емельяновны татарларга каршы шовинистлар дип атый, Н.И.Ильминскийның Синод обер-прокуроры Победоносцевка язган хатларын «сәяси донос» дип бәяли һәм үз фикерләрен дәлилләп бара. Археология, этнография һәм тарих җәмгыяте үзенең эшчәнлеген Ильминскийның урыслаштыру системасы белән бергә алып барды дип белдерә, М.М.Хвостовны, Б.Ф.Адлерны, С.П.Покровскийны гаепли.

Хезмәтнең соңгы, өченче «После октября» дип аталган бүлеге, әлбәттә, бүгенге көн югарылыгында тискәре тәэсир калдыра. Биредә автор большевиклар манарасыннан катлаулы күчеш чорына эләккән күренекле галимнәрне, шовинистик карашлары өчен, нигезле-нигезсез нык кына тәнкыйтьли. (Әйтик, А.А.Шахматовны рус телен рус, украин, белорус «наречийларыннан» һәм рус халкын великоруслардан, украиннардан һәм белоруслардан тора дип санауда, фин халыкларын өйрәнүче Д.А.Золотарёвны Идел буе халыклары картасын төзегәндә төбәктә нинди халык яшәгәнлеге төгәл билгеле булмаса, аларны руслар дип күрсәтүдә һәм русларның санын ясалма арттыруда гаепли һ.б.). Гомумән, М.Худяков бер галимгә дә уңай бәя бирми. «20нче елларның икенче яртысында академик оешмаларның составында реакцион элементларның артуы күзәтелде, һәм бу хәл, билгеле булганча, Академия дивары эчендә 1929 елда ачылган контрреволюцион группа оешуга китерде», дигән нәтиҗә ясый[10], ул «уңай үзгәрешләрне» 1928 елдан, Тарихчы марксистларның беренче конференциясеннән башлап кына «күрә башлый».

Китерелгән мисалларда катлаулы чорда яшәгән талантлы шәхеснең Совет системасы белән мөнәсәбәтләре дә шактый ачык күренә.

Яңа ачылган фактлар нигезендә урынлы сорау туа: М.Худяковның Казан чорында иҗат иткән фәнни хезмәтләре шулай ук совет хөкүмәтенә ярашып язылганмы яки бу әсәрләрдә галимнең үз карашы, ышанулары чагылыш тапканмы? Инде «Казан ханлыгы тарихыннан очерклар» китабы социаль заказ буенча язылган дигән фикер дә яңгырады. «Михаил Григорьевич объектив тарихчы булмаган (гомумән, башка тарихчылар кебек үк). Ул үз заманының сәяси ситуация һәм идеология нюанслары кушуы буенча тарихны ничек кирәк шулай язучы нык конъюнктур уңышлы эзләнүче галим иде. Алыш-биреш эшләрендә уңышка ирешкән Малмыж сәүдәгәренең улы булган бу кеше император Николай II вакытында да, «гениаль сәясәтче Сталин» вакытында да үзен начар хис итмәгән»[11]. Шул ук хезмәттә «Казан ханлыгы тарихыннан очерклар» хезмәтенең 1920-нче еллар фәнни конъюнктурасыннан чыгып (Казан ханлыгы буенча монография булмау) һәм аның 1930 еллардагы карашлары нигезендә хакимиятнең югары эшелоннарыннан килгән социаль заказ буенча (татар халкы тарихын яңача яктыртучы китап язарга) хәзерләнүе билгеләнә, бу фаразның дөреслеген

[10] Худяков М.Г. Великодержавный шовинизм в русской этнографии // Михаил Худяков. Тарихи-документаль җыентык. – Казан: «Җыен» нәшрияты, 2011. – Б.484.

[11] Рахимзянов Б.Р. Концептуальные воззрения М.Г.Худякова в 1930-е гг. // Материалы краеведческих чтений, посвящённых 135-летию Общества естествоиспытателей при КГУ, 110-летию со дня рождения М.Г.Худякова. – 24-25 марта 2004 г. – Казань: Школа, 2004. – С.70.

раслаучы дәлил итеп М.Худяковның китапны язганчы күбрәк археология, бигрәк тә борынгы җәмгыять чоры археологиясе белән шөгыльләнүе, Урта Идел буе төбәгенең урта гасыр тарихын яктыртуда тенденциозлыгы күрсәтелә. Моның шулай булуын раслаучы тагын бер дәлил бар кебек: М.Г.Худяков китабын 1922 елда язып тәмамлый, кульязма өчен ТАССРның Халык мәгарифе комиссариаты коллегиясе президиумы 1922 елның 19 октябрендә булган утырышында галимгә 20 мең сум гонорар түләү турында карар кабул итә һәм Академүзәктән бу хезмәт турында бәяләмә сорау мәсьәләсен куя[12].

Китап басылып чыккач, галимнәр тарафыннан төрле фикерләр әйтелә. Күренекле шәрык белгече В.В.Бартольд, М.Худяков хезмәтен күздә тотып һәм Ф.В.Баллодның ашыгычрак нәтиҗәләр ясалган «Идел буе Помпейлары» исемле басмасы белән чагыштырып, болай дип белдерә: «Элек, мәгълүм булганча, татарларга карата гел тискәре мөнәсәбәт күрсәтелеп, аларда купмедер мәдәният булу фикере бөтенләй инкарь ителә иде... Хәзер без моның киресен күрәбез... Элекеге кебек, монысы да ялгыш, һәм ул да, бер кырыйдан икенче читкә ташлану буларак, беренчесе кебек үк гыйльми белемгә күп файда бирми»[13]. Әйтергә кирәк, археолог Ф.В.Баллодның казу эшләре нигезендә ясалган Яңа һәм Иске Сарай шәһәрләрендә югары житештеру булган дигән нәтиҗәләрен соңрак күренекле совет археологы Г.А.Фёдоров-Давыдов раслады...[14]

## Михаил Худяков – рус булмаган халыклар тарихын өйрәнүче киң эрудицияле галим

М.Худяков Идел-Чулман төбәгендә иҗат иткән күпчелек рус тарихчыларытөбәкне өйрәнүчеләреннән аермалы буларак, җирле халыкларның телләрен белгән: татарча, чувашча, марича, удмуртча аралашкан һәм укыган. Беренче карашка телләр өйрәнүгә хирыслык дип бәяләнергә тиеш бу сыйфат булачак галимнең үз һөнәренә җаваплы карашы турында сөйли. Ул заман гуманитар фәннәр өлкәсендә язылмаган канун яшәгән: галим үзе өйрәнгән халыкның телен, гореф-гадәтләрен, мәдәниятен, менталитетын белергә тиеш. Телләр белү башка милләт вәкилләре, бигрәк тә фән һәм мәдәнияткә мөнәсәбәте булган яшьләр, зыялылар белән аралашу, алар аша туплаган мәгълүматны баетырга һәм хезмәтләрдә файдаланырга мөмкинлек бирә. Алгарак китеп, М.Худяков 1920 елларда Казанда татар зыялылары белән якыннан аралашкан ике-өч рус галименең берсе дисәк, хакыйкатьтән ерак булмас.

Төбәктә көн күргән халыкларның тормыш-көнкүреше, тарихы белән белән кызыксыну М.Худяковның гимназист, студент елларында ныгып, соңрак фәнни эшчәнлеген алып бару өчен нигез булган, күрәсең. Әйтик, туган шәһәре Малмыжда шәһәр тормышына кысылмыйча, үзенең социаль тормышын милли һәм дини традицияләр нигезендә корып көн итүче татар җәмгыятенә игътибар итми мөмкин булмый. 1897 елда биредә татарлар (409 кеше) шәһәр халкының 12,9% тәшкил иткәннәр. Малмыжга күченеп утырган дин кардәшләре хисабына бик тиз арткан (саны 1910 елда мең кешедән арта һәм шәһәр халкының 30% тәшкил итә) җәмгыять өяз шәһәрләре арасында бердәм рухлы һәм икътисади яктан үзен-үзе тулысынча тәэмин итүче көчле шәһәр татар бердәмлеге буларак танылу ала.

1906-1913 елларда, Казанның 1нче гимназиясендә укыганда, яшүсмер Михаил әти-әнисе йортына Себер тракты буенча, юл өстендәге күпсанлы татар авыллары аша үтеп, төн кунып кайтып-китеп йөри. Казанда яшәгән чорда исә Иске һәм Яңа татар бистәләрендә үз җайларына яшәп, европалашып баручы, Россиядәге иң күпсанлы татар җәмгыяте белән таныша. Гимназист һәм студент елларында һәр елны «Казан бәйрәмендә» – 4 октябрьдә – башка укучылар белән ял итә. Император

[12] Шарангина Н.А. Документы Центрального архива РТ об историке, археологе, этнографе М.Г.Худякове // Материалы краеведческих чтений, посвящённых 135-летию Общества естествоиспытателей при КГУ, 110-летию со дня рождения М.Г.Худякова. – 24-25 марта 2004 г. – Казань: Школа, 2004. – С.407-408.
[13] Там же.
[14] Госманов М.Г. Галимнең гыйбрәтле язмышы. (М.Г.Худяковның тууына 100 ел) // Михаил Худяков. Тарихи-документаль җыентык. – Казан: «Җыен» нәшрияты, 2011. – Б.12.

Николай IIнең 1854 ел 12 апрель Указы нигезендә патша Иван IVнең 1552 елның 4 октябрендә җимерелгән һәм таланган ханлык башкаласына тантаналы рәвештә, тәре йөреше белән керүе һәм Казан епархиясенең беренче миссионерлары Гурий һәм Варсонофийны искә алу көне – Казан губернасында яшәүчеләр өчен бәйрәм һәм ял көне дип игълан ителгән була.

Биредә яшүсмер Михаилның татарлар белән генә түгел, башка җирле халык зыялылары белән дә аралашуын әйтеп үтү зарур. Аның бу гадәте олы тормыш юлына аяк баскач та дәвам итә. 1918 елда ул Малмыжда удмурт шагыйре һәм галиме, ул вакытта Малмыж өяз мәгариф бүлегенең удмурт бүлеген җитәкләгән К.П.Чайников (Кузебай Герд) белән якыннан аралаша, үзе нигез салган Малмыж шәһәре Тарих җәмгыятенә әгъзалыкка кабул итә. Иң мөһиме, Михаил Худяков Кузебай Герд тәэсирендә удмурт этносының борынгы һәм урта гасырлар тарихы белән тагын да ныграк кызыксына башлый. Алай гына да түгел, удмурт халкы тарихы һәм мәдәнияте темасы М.Худяковның иҗатында аерым бер юнәлеш булып формалаша[15].

Биредә М.Худяковның Урта Идел төбәгендәге рус булмаган халыклар зыялыларына, төбәкне өйрәнүчеләргә атап язылган һәм археологик чыганакларны өйрәнү буенча методик хезмәт ролен үтәгән, 1920 елда совет Россиясендә музей эше буенча беренче фәнни журнал – «Казанские музейные ведомости» журналында дөнья күргән «Старое — юно!» исемле мәкаләсен искә алып үтү зарур. Автор, удмурт, мари, чуваш һәм татар төбәк тарихларын өйрәнүчеләргә мөрәҗәгать итеп, милли тарихка бәйле әйберләрнең барысын да өйрәнергә чакыра: борынгы бабайлар нәрсә белән яшәгәннәрен белү, риваятьләрне, гадәтләрне, ритуалларны, җырларны җыю, бабаларыннан ишеткән борынгы риваятьләрне язып алу кирәклеген искәртә. «Тизрәк эшләргә ашыгыгыз!» дигән лозунг ташлый. Бу халыклар вәкилләреннән тиз арада милли даһилар үсеп чыгачагына ышанычын, төбәк халыкларының мәдәниятен һәм мәгарифен үстерүне үзенең рухи бурычы итеп санавын белдерә[16].

Мин М.Худяковны рус булмаган халыкларның тарихларын өйрәнүче галим буларак бәяләүдә М.Госманов фикерен хаклы табам. Ул болай дип язды: «Худяков элекке һәм хәзерге чор империячел тарихи фикер, халыкларны үзара каршы куючы, элгәре конфликтларның дәвамын бүгенге чорга, хәттә киләчәккә дә күчерергә теләүче омтылыш вәкилләреннән, бигрәк тә татарларга карата тискәре мөнәсәбәтләрдән нык аерылып торган икән. Ул тарих белемендә элементар гаделлек, узган чор вакыйгаларына мөнәсәбәттә объективлык тарафдары булган. Бу сыйфатларда галимнең кеше буларак олы җанлылыгын, затлылыгын күрү кыен түгел» [17].

М.Худяков студент елларында ук әзлекле кызыксынган берничә теманы атап үтү зарур. Алар турында студент М.Худяковның басылып чыккан мәкаләләре буенча фикер йөртәбез. Икенче курста укыганда, туган шәһәре һәм Малмыж өязе тарихының кайбер сәхифәләренә багышланган кечкенә мәкаләләр (сообщение) сериясе әзерли, алар «Вятка гыйльми архив комиссиясе хезмәтләрендә» 1915-1916 елларда дөнья күрә[18]. Күренекле удмурт галимәсе М.В.Гришкина бик төгәл билгеләп үткәнчә, бу беренче мәкаләләрдә М.Худяковның эзләнүчән галимлек сыйфатлары анык күренә: автор тарихи фактларга һәм чыганакларга, аларның эчтәлегенә гаять зур игътибар итә, яктыртыла торган тема буенча барлык басылган хезмәтләрдән хәбәрдар була, ягъни историографияне яхшы белә[19]. Университетны тәмамлагач, бу сыйфатлар яна дәрәҗәдә чагыла – галиҗәнап Тарих фәненә хезмәт итү анын тормыш мәгънәсенә әверелә.

---

[15] Гришкина М.В. М.Г.Худяков — историк Вятско-Камского края // Материалы краеведческих чтений, посвящённых 135-летию Общества естествоиспытателей при КГУ, 110-летию со дня рождения М.Г.Худякова. – 24-25 марта 2004 г. – Казань: Школа, 2004. – С.16-18.

[16] Гришкина М.В., Кузьминых С.В. Михаил Георгиевич Худяков как историк // Михаил Худяков. Тарихи-документаль җыентык. – Казан: «Җыен» нәшрияты, 2011. – Б.598.

[17] Госманов М.Г. Галимнең гыйбрәтле язмышы. (М.Г.Худяковның тууына 100 ел) // Михаил Худяков. Тарихи-документаль җыентык. – Казан: «Җыен» нәшрияты, 2011. – Б.14.

[18] Худяков М.Г. К истории поместного землевладения в Малмыжском уезде. Аныкы ук. Предания о разбойниках в г.Малмыже. Аныкы ук. Сторожилы города Малмыжа. Аныкы ук. Материалы по истории города Малмыжа. Аныкы ук. Материалы по истории татар Малмыжского уезда. Аныкы ук. Хронологические сведения о церквях города Малмыжа.

[19] Руденко А.К. В плену у времени // Казань. – 2004.- №3. – С.42.

Студент елларында М.Худяков даими шөгыльләнгән икенче зур тема археология фәне һәм археологик экспедицияләр белән бәйле. Беренче карашка, 1914 елда Пономарёв житәкчегендә Болгар шәһәрлегенә казу эшләре алып барачак группага М.Худяков фотограф буларак, очраклы гына эләгә. Чынлыкта исә ана беренче елны ук казу эшләре буенча хисап язуны – катлаулы һәм махсус белем сорый торган эшне – ышанып тапшыралар. 1915 һәм 1916 елларда Биләр һәм Болгар шәһәрлекләрендә казу нәтижәләре белән М.Худяков мәкаләләрендә уртаклаша. Археологик эзләнүләр Михаилнын фәнни карашлары формалашуда мөһим урын тоткан, күрәсен, ул еш кына «мин археолог» дип белдерергә яраткан.

Беренче Бөтендөнья сугышы елларында армиягә алыну һәм 1916-1917 елларда хәрби хезмәттә булу ана университетны 1918 елда гына тәмамларга мөмкинлек бирә. Университетны тәмамлагач, М.Худяков Казанда чыгучы күпсанлы журналларда редактор һәм автор, төрле жәмгыятьләрдә оештыручы һәм сәркатиб төсендә, дәүләт оешмаларында компетентлы галим, югары уку йортларында кин эрудицияле укытучы буларак таныла.

М.Худяков 1918 елнын 1 ноябреннән 1919 елнын 1 февраленә кадәр Казан 4-нче номерлы икенче баскыч мәктәбендә укыта, аннан 1925 елнын 1 февраленә кадәр Казан губернасы (1920 елдан – Татар республикасы Үзәк музее) музеенда тарих-археология бүлеге музее мөдире булып эшли башлый. Бу елларда Үзәк музейда бер төркем галимнәр туплана: Б.В.Адлер (директор), П.М.Дульский, Н.И.Воробьев, Г.С.Гобәйдуллин, М.Е.Евсевьев һ.б. Музейнын М.Худяков житәкләгән бүлек фонды Ф.В.Баллод казыган Иске һәм Яна Сарай шәһәрлекләре табылдыклары, археолог В.Ф.Смолин тапкан материаллар, Казан коллекционерлары Н.В.Высоцкий, В.И.Заусайлов варисларыннан сатып алынган әйберләр хисабына байый. Аларны системалаштыру, теркәү белән бүлек мөдире шөгыльләнә. М.Худяков, галим буларак, биредә тупланган материалларны өйрәнә, яна табышлар төбәкнен һәм Казаннын борынгы һәм урта гасыр чорларын чагылдырган яна экспозицияләргә дә урнаштырыла. М.Худяков, шулай ук, Казан һәм шәһәрнен тирә-ягына тарихи-мәдәни һәм археологик эчтәлекле экскурсияләр планнарын эшләүдә катнаша, 1921-1922 елларда шушы юнәлеш белән шөгыльләнүче Казан экскурсия базасынын уку-укыту бүлеге мөдире булып та тора. Гражданнар сугышыннан сонгы чорда советча яшәү рәвеше күп кенә урта гасыр һәм империя чоры тарихи-мәдәни һәйкәлләрен кирәксезгә чыгара. М.Худяков аларнын бер өлешен музей-архивларга туплау буенча гаять кирәкле эш алып барган галимнәр сафында була[20].

1920 елларда ул фәнни даирәдә борынгы һәм урта гасыр Казан төбәге тарихы буенча хәбәрдар һәм ин күп белүче галим буларак таныла һәм 1923 елда зур фәнни хезмәт – ТАССРнын археологик картасын тәмамлый. Дөрес, М.Худяков Татарстанны аркылыга-буйга йөрми (кин масштабта археологик эзләнүләр үткәрү катлаулы финанс шартларында мөмкин дә булмый), фәкать Чулман һәм Нократ буйларына бернича тапкыр сәяхәт белән чикләнә[21]. Бүгенгә кадәр табылмаган бу хезмәт анын өлгергән археолог-тарихчы булуын раслый. Чөнки археологик карта төзү – археологик табылдыклардан тыш барлык булган чыганакларны да файдалануны таләп итә, гажәеп зур көч һәм күп вакыт сорый торган фәнни хезмәт.

Ленинградта эшләгән елларда М.Худяков фин халыкларынын һәм Чулман-Нократ төбәгенен борынгы тарихы белән шөгыльләнүен дәвам итә. Ул «Очерки истории первобытного общества на территории Марийской области» *(«Известия государственной академии истории материальной культуры имени И.Я.Марра». Вып.141. – М., Л., 1935. – 132 с.)* дигән хезмәт яза. Галимнен әлегә кадәр басылмаган «Культ деревьев народа мари» (7 басма табак), «Религиозные верования в Поволжье в эпоху родового общества» (10 басма табак), «Древнее Поволжье (до V в.н.э.); Среднее Поволжье (до V в.н.э.)» (15 басма табак) кульязмалары саклана. 2008 елда «История вотского народа», «Общественный строй вотяков в VII-XIV столетиях» исемле күләмле хезмәтләре, ниһаять, дөнья күрде – укучыларга барып иреште.

[20] Шарангина Н.А. Документы Центрального архива РТ об историке, археологе, этнографе М.Г.Худякове // Материалы краеведческих чтений, посвящённых 135-летию Общества естествоиспытателей при КГУ, 110-летию со дня рождения М.Г.Худякова. – 24-25 марта 2004 г. – Казань: Школа, 2004. – С.406-409.

[21] Гришкина М.В., Кузьминых С.В. Михаил Георгиевич Худяков как историк // Михаил Худяков. Тарихи-документаль жыентык. – Казан: «Җыен» нәшрияты, 2011. – Б.621.

М.Г.Худяковның хезмәтләре аның энциклопедик белемле галим булганлыгын раслый. Аның дөнья күргән күпсанлы китап-мәкаләләренең бер өлеше һәм төрле архивларда сакланган кулъязмаларының исемлеге белән танышкач, әле һаман да М.Худяковның фәнгә керткән өлеше тиешенчә бәяләнмәгән дигән фикер кала. Хезмәтләре гуманитар фәннең шулкадәр төрле өлкәләренә карый, аның турында фикер әйтүчеләр (тарихчылар, этнографлар, халык авыз иҗатын өйрәнүчеләр, археологлар, сәнгать белгечләре, Идел буе халыкларының борынгы диннәрен өйрәнүчеләр, тел белгечләре, архитекторлар, төбәк тарихын өйрәнүчеләр h.б.), гадәттә, үзләре шөгыльләнә торган өлкәгә, фәннең аерым бер тармагына керткән өлеше турында сүз алып баралар. Идел буеның милли республикалары галимнәре бу мирас хакында беренче гомумиләштерүләрне М.Худяковның аерым этнос (татар, рус, мари, удмурт, мордва) тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүгә караган мирасын барлаудан башладылар. Чынлыкта, бу тикшеренүләр дә бик еш кына өстәмәләр һәм төзәтүне сорый. Чөнки М.Худяков үз мәкаләләрендә төрле чыганакларны комплекслы файдаланып, төрле фән гыйлемнәренә мөрәҗәгать итеп язган. Күрәсең, М.Худяковның аерым этнос тарихы һәм мәдәниятен өйрәнүгә караган мирасы хакында берничә галим — үз фән тармаклары осталары — бергәләшеп язарга тиештер! М.Худяковның гыйльми масштабы шуны таләп итә!

## «Казан ханлыгы тарихы буенча очерклар» китабына социаль заказ булганмы?

1920 елда ТАССР оешкач, әле дүрт-биш ел элек кенә «инородец» дип аталып, түбән статуслы крестьян катламына кергән татар зыялыларының зур максатлар куеп эшли башлаулары күзгә ташлана. 1921 елда Фәнни коллегия нигезендә (ул, үз чиратында, 1918 елда оешкан була) Академүзәккә нигез салына. Аның беренче рәисе булып Гаяз Максудов (1920-1921 елларда Үзәк музейда М.Худяков белән бергә эшли)[22] тора[23]. Яна буын татар галимнәре, илдә барган үзгәрешләргә ышаныч белән караган хәлдә, яна зур проектларга алыналар. 1922 елда Газиз Гобәйдуллин һәм Гали Рәхим авторлыгында бүгенгә кадәр тиңе булмаган, татар әдәбиятының күпгасырлык тарихын колачлаган фундаменталь хезмәт дөнья күрә. *(Татар әдәбияты тарихы. 1нче җилд: Борынгы дәвер. — Казан: Татарстан Җөмһүрияте нәшрияты, елы күрсәтелмәгән. — 240 б.; Татар әдәбияты тарихы: Борынгы дәвер. XVII, XVIII һәм XIX гасырларда иске әдәбият. 1нче җилд. Казан: Татарстан Җөмһүрияте нәшрияты, 1922. — 184 б.; Татар әдәбияты тарихы: Борынгы дәвер. 2нче бүлек. 1нче җилд. — Казан: Татарстан Җөмһүрияте нәшрияты, 1922. — 240 б.).* Шул ук елны Газиз Гобәйдуллин «Татар тарихы» *(Казан: Татарстан Социалистик Совет Җөмһүриятенең дәүләт нәшр., 1922. — 126 б.)* исемле фундаменталь хезмәтен бастыра. Мәшһүр галим борынгы кешелек җәмгыятен, татарларның тарихын һуннардан, хәзәрләрдән, болгарлардан алып, Алтын Урда, Казан, Әстерхан, Себер ханлыклары, Нугай Урдасы, Россия составындагы дәверенең XVIII гасыр азагына кадәрге тормышын эзлекле һәм системалы рәвештә яктырта. Г.Гобәйдуллин беренче тапкыр, Европа тарих фәне традицияләренә нигезләнеп, татар халкы тарихын язып чыга. Бу хезмәтләрнең 1922 елда басылуы, М.Худяковның шул ук елны китабын тәмамлау һич кенә дә очраклы күренеш түгел.

«Казан ханлыгы тарихы буенча очерклар» китабының «Кереш»ендә автор «китапның дөньяга чыгуына сәбәпче булган» Гаяз Максудовка һәм Газиз Гобәйдуллинга рәхмәтләрен җиткерә. Ул шулай ук профессор Н.Н.Фирсовка «үзенең хезмәтләренә игътибарлы булган өчен», мәрхүм М.И.Лопатинга «үз китапханәсен тәкъдим иткән өчен», археограф С.Г.Вахидовка «үзе тапкан Сәхибгәрәй ярлыгының асыл текстыннан файдаланырга мөмкинлек биргән өчен» рәхмәт әйтә. Автор «Хезмәтне язган чорда авыр матди хәлен җиңеләйткән өчен И.В. һәм П.Д.Петровлар гаиләсенә» дә тирән рәхмәтен белдерә[24].

[22] Айнутдинова Р.А. Гаяз Максудов // Татарская энциклопедия. Т.4. М-П. – Казань, 2008. – С.35.
[23] Гарипова З.Г. Казань: общество, политика, культура. – Казань, 2004. – С.104.
[24] Худяков М. Казан тарихы буенча очерклар // Михаил Худяков. Тарихи-документаль җыентык. – Казан: «Җыен» нәшрияты, 2011. – Б.21.

Күрәбез, хезмәтне язганда аның беренче фикердәшләре булып татар тарихчысы Газиз Гобәйдуллин һәм Гаяз Максудов торган. Алар бергә Үзәк музейда эшләгәннәр. М.Худяковның китабы Академүзәкнең яшь галимнәрне туплап, бер юнәлештә эшләү нәтиҗәсе дип уйларга нигез бар. Китап язу идеясе, бәлки, Газиз Гобәйдуллин белән аралашу барышында, бәлки, бу фикер М.Худяковта Үзәк музейда борынгы һәм урта гасыр Казаны һәм Урта Идел төбәге тарихы экспозицияләрен эшләү барышында тугандыр. Төрлечә фаразларга мөмкин. Шунысы бәхәссез: М.Худяковның китабы ул заман иҗтимагый тормышының йогынтысында, татар тарихына һәм мәдәниятенә игътибарны арттырырга кирәклеге турында фикерләшүләр һәм гамәлләр тәэсирендә язылган.

Гаяз Максудов, белгечлеге буенча математик, яшь галимне хезмәтнең республика өчен кирәклеге турында искәртеп, рухландырып торган булырга мөмкин. Ләкин ниндидер матди ярдәм турында сүз алып барылмаган. Чөнки әле бу омтылышның нинди нәтиҗә белән тәмамланасы билгеле булмаган. Бу нәүбәттән, М.Худяковның китапны язган вакытта матди хәле бик начар булып, ачлык елларында ана рус гаиләсенең ярдәм итүе игътибарга лаек.

Китапның керешендә автор үзе белдергәнчә, «Әлеге хезмәтне язарга тотынганда, без, әлбәттә, Казан ханлыгы тарихын бөтен тулылыгы белән сурәтләп бирү ниятеннән ерак тордык. Бу, бәлки, ерак киләчәк эше, һәм аны башкару аерым кешенең генә көченнән килмәс, ул бер төркем галимнәрнең уртак хезмәтеннән тәшкил булыр. Казан ханлыгы тарихын тарихчыларның, архивчыларның, этнографларның, хокук өйрәнүчеләрнең һәм башка галимнәрнең уртак казанышыннан башка тулы килеш дөньяга чыгарып булмас. Билгеле, без ниндидер кыю дәгъваларлан да ерак торабыз. Күп чыганаклар безнең күз уңыннан читтә калды һәм шушы хәл хезмәтнең сыйфатына хилафлык китерми калмагандыр. Монарчы аз тикшерелгән, югыйсә җентекләп өйрәнелергә хакы булган әлеге тарихка белгечләрнең игътибарын юнәлтү максаты белән генә автор кулына каләм алырга мәҗбүр булды». Минемчә, монда барысы да ачык әйтелгән!

ТАССРның Халык мәгарифе комиссариаты коллегиясе президиумының (1922 елның 19 октябре) китапның кулъязмасына Академүзәктән рәсми бәяләмә дә алмыйча авторга 20 мең сум гонорар түләү турында карар кабул итүе, бер яктан монда Гаяз Максудовның «кулы уйнавына» һәм аның шәхсән яки аның ышанычлы кешесенең инде кулъязма тексты белән таныш булуына ишарәли. Икенче яктан, мондый гамәл, минемчә, финанс елы азагында бюджет акчасын бүлеп калдырырга омтылудан килеп чыккан.

28 яшьлек М.Худяковның хезмәте Россия фәнендә гасыр дәвамында урнашкан стереотипларны җимерүгә хезмәт итә. «Социаль заказ» дип әйтүнең икенче ягы авторның татар дәүләтчелек тарихын һәм мәдәниятен бик югары күтәреп, бөекдержавачылыкны инкарь иткән нигезгә куеп язылуда. Әлбәттә, авторның йөгерек каләме, кыю фикерләве, галимлек таланты, чыганакларны яхшы белүе һәм оста анализлавы күп мәсьәләләрне дәлилле итеп яктыртырга мөмкинлек биргән. М.Худяков рус булмаган халыклар тарихын, рус дәүләт тарихы мәктәбе традицияләреннән өстен булып, төбәк халыклары турында тирән ихтирам белән яза. Ләкин китапның концепциясе авторы М.Худяков түгел. (Аның исемен китабының «Кереш»ендә автор атап та китә:«Мәсьәләнең икътисади ягы исә яңарак кына М.Н.Покровский һәм Н.Н.Фирсов кебек галимнәрнең хезмәтләрендә чагылды»)[25].

В.И.Ленин элекке Россия империясе территориясен рус булмаган халыкларга милли үзбилгеләнү вәгъдә итеп саклап калгач, яшь совет дәүләтенең рәсми тарих фәнендә марксистик идеологияне эшләүче итеп рус тарихчысы М.Н.Покровский һәм аның хезмәтләрен сайлый. 1918 елның маенда галим совет хөкүмәте әгъзасы, РСФСР Халык мәгарифе комиссариаты җитәкчесенең урынбасары итеп билгеләнә. Югары уку йорларын яңача үзгәртеп кору, архив, музей, китапханәләр эшен җайга салу, тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне саклау кебек өлкәләрдә зур эшләр башкара.

[25] Худяков М. Казан тарихы буенча очерклар // Михаил Худяков. Тарихи-документаль җыентык. – Казан: «Җыен» нәшрияты, 2011. – Б.17.

Шул ук вакытта иске профессорларны уку-укыту эшеннән читләштерү буенча зур тырышлык куя. Ул Россия дәүләт эшлекләләре, шул исәптән патшалар да мөстәкыйль булмыйча «сәүдә капиталы» кушканны үтәгәннәр дигән фикер уздыра. Марксист тарихчы М.Н.Покровскийның «милли мәсьәлә» буенча фикерләре игътибарга лаек. Аның хезмәтләре интернационализм рухында язылган һәм рус тарих фәненә хас булган империячел һәм шовинистик карашларны көчле тәнкыйтьлиләр[26]. Шул исәптән, ул рус булмаган халыкларны «мәдәни яктан артта калуда» гаепләүгә һәм башка кимсетүләргә каршы чыга. Кайбер халыкларны Россиягә кушу прогрессив күренеш түгел, кушуның сәбәбе царизмның агрессив тышкы сәясәте дип атый[27]. Ул, шулай ук, монархчы Россия империясе тарих фәне мәктәбе вәкилләре язарга ярамый дип санаган рус милли тарихының караңгы якларына зур игътибар итә, шулар аркылы дәүләтнең тышкы һәм эчке сәясәтен каты тәнкыйтьли. Тарихи материализм күзлегеннән галим Россиядәге сыйнфый изү хакында, империянең агрессив тышкы сәясәт уздыруы, күрше дәүләтләрне һәм халыкларны яулап алу өчен сугышуы, буйсындырылган халыкларны талау сәясәте уздырылу турында яза.

Әйтик, М.Н.Покровский Алтын Урданың рус кенәзлекләренә уңай йогынтысын билгеләде. Ул, җан исәбен алуга нигезләнгән яңа салым системасы керүне күрсәтеп: татарлар борынгы рус финансларына техник янарыш гына алып килмәделәр: алар, читтән тәэсир итү көченә хас булганча, социаль мөнәсәбәтләргә дә тирән үзгәрешләр керттеләр, һәм бу үзгәрешләр үсеш алды дип белдерә[28]. М.Н.Покровский Мәскәү үзәкләштерелгән дәүләте оешуда Бөек мәскәү кенәзе үзенең байлыгына, татарларга, чиркәү ярдәменә таянды һәм акрынлап барлык рус кенәзләренең башлыгына әйләнде, дигән фикер уздыра[29]. «Русская история в самом сжатом очерке» китабының кинәйтелеп язылган вариантында автор тагын да төгәлрәк итеп: "Урда, ахыр чиктә Мәскәү самодержавиесен булдырды", — дип ассызыклады[30], бер үк вакытта Алтын Урдага каршы көрәшнең рус дәүләтен берләштерүдә уңай ролен дә таныды[31].

М.Н.Покровский XVI гасыр уртасында боярларның Бөек Идел юлын – Казан һәм Хаҗитарханны – алу сәясәте «сәүдәгәрләр сыйныфы»ның ихтыяҗына туры килә иде дип санады[32]. Г.И.Перетяткович, Казан ханлыгындагы элитаны ике төркемгә – «Мәскәү яклы» һәм «Ногай яклы» фиркаләргә бүленүе турында язса[33], М.Худяков, аның фикерен «заманчалатып», Мәскәү белән дустанә мөнәсәбәтләрне кору ягындагыларны «рус базарына тыгыз бәйлелектә булган сәүдә капиталы» вәкилләре дип атады. Аларга каршы төркем исә Урта Азия базарына тартылучы, ногайлар белән дус булып, кулга төшергән рус әсирләрен Көнчыгыш базарларында сатучылар – Россия белән сугышырга, русларга дошмани мөнәсәбәттә булучылар, дип күрсәтте[34]. Гомумән әйткәндә, М.Худяковның күп хезмәтләре, Газиз Гобәйдуллинның да югарыда телгә алынган «Татар тарихы» китабы кебек үк, М.Н.Покровский концепциясенә нигезләнгән.

Шунысы мөһим: 1920 елларның беренче яртысындагы сүз иреге һәм милли күтәрелеш шартларында М.Н.Покровский концепциясе рус булмаган халыкларның милли тарихларын язарга юл ача. Бу мөмкинлектән Академүзәк җитәкчелеге,

[26] Госманов М.Г. Галимнең гыйбрәтле язмышы. (М.Г.Худяковның тууына 100 ел) // Михаил Худяков. Тарихи-документаль җыентык. – Казан: «Җыен» нәшрияты, 2011. – Б.10.
[27] Соколов О.Д. М.Н.Покровский и советская историческая наука. – М., 1976. – С.114.
[28] Покровский М.Н. Русская история с древнейших времён (тома I и II) // Избранные произведения. Книга 1. – М., 1966. – С.177.
[29] Покровский М.Н. Русская история в самом сжатом очерке // Избранные произведения. Книга 3. – М., 1967. – С.43.
[30] Покровский М.Н. Русская история с древнейших времён (тома I и II) // Избранные произведения. Книга 1. – М., 1966. – С.180.
[31] Соколов О.Д. М.Н.Покровский и советская историческая наука. – М., 1976. – С.180.
[32] Покровский М.Н. Русская история с древнейших времён (тома I и II) // Избранные произведения. Книга 1. – М., 1966. – С.291.
[33] Перетяткович Г. Поволжье в XV-XVI веках (очерки истории края и его колонизации). – М., 1877. – С.151.
[34] Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. Репринтное издание. – Казань. – С.44-45.

М.Худяков, Газиз Гобәйдуллин, Гали Рәхим, Жамал Вәлиди унышлы файдалана. Татар милли тарихының һәм мәдәнияте тарихының матур үрнәкләре шушы галимнәр тарафыннан языла һәм алар киләчәк буын галимнәре өчен нигез ташына әверелә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә: М.Худяковның Казан ханлыгы турында җитди хезмәт язарга алынуы Академүзәкнең татар тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүне активлаштыру һәм Казандагы фәнни көчләрне шушы максатка туплау өчен оештыру чаралары чорына туры килә. Авторның татарларга зур хөрмәт белән каравы һәм югары бәяләп язуы ул елларда киң таралган М.Н.Покровский концепциясе нигезендә башкарылган. М.Худяковны «хакимиятнең югары эшелоннарыннан килгән социаль заказ буенча (татар халкы тарихын яңача яктыртучы китап язарга)» язуда гаепләргә нигез юк.

***

1936 елда «халык дошманы» буларак гаепләнүе галимнең мирасына «табу» салды. Фәкать соңгы чирек гасырда хезмәтләре кабат фәнни әйләнешкә керә, китап-мәкаләләре һәм кульязмалары киң җәмәгатьчелеккә кайта башлады. «Очерки по истории Казанского ханства» монографиясе «Җыен» фонды *(Казан, 1990)*, Мәскәүдәге «Инсан» нәшрияте *(Мәскәү, 1992)*, Татарстан китап нәшрияты *(Казан, 2004)* тарафыннан зур тиражлар белән басылды, әсәрдән өзекләр «Идел» *(1989, №1; 1990, №2 h.б.)*, «Мирас» *(1993, №11; 2001, №10; 2007, №11)* журналларында дөнья күрде, 2011 елда «Җыен» фонды авторның бу китабын, «Татар сәнгате», «Казан татарларының агач архитектурасы» исемле мәкаләләрен татарчага тәрҗемә итеп, шулай ук «Великодержавный шовинизм в русской этнографии» исемле күләмле мәкаләсен кабат бастырды[35]. Ф.Бәйрәмова күпсанлы мәкаләләр, 2003 елда «Худяков и история татарского народа» исемле китап бастырып, 2006 елда «Роль М.Г.Худякова в исследовании истории и культуры народов Среднего Поволжья» исемле темага кандидатлык диссертациясен унышлы яклап, галимнең татар тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүгә керткән өлешен ачыклау һәм таныту, мирасын пропагандалау өлкәсендә гаять зур эш башкарды, беренче булып аның дөнья күргән һәм кульязма хәлендә саклаучы әсәрләренең исемлеген төзеде.

М.Г.Худяковның 110 еллыгы уңаеннан, 2004 елда Татарстанның Милли музее конференция уздырды һәм аның материалларын бастырып чыгарды[36]. Заманында М.Худяков туплаган, русча төзегән удмурт халык героик эпосы русча һәм удмурт теленә тәрҗемә ителеп дөнья күрде[37].

Удмурт Тарих, тел һәм әдәбият институты 2008 елда «Худяков М.Г. История Камско-Вятского края. Избранные труды» *(Ижевск: Удмуртия, 2008. – 416 с.)* исемле китапта аның мирасыннан удмурт һәм мари халыклары тарихына кагылышлы егермедән артык исемдәге мәкаләләрен, кульязмаларын бастырды. Күрәбез, һәр милли республика галимнәре М.Худяков мирасыннан үзләренә кирәклесен «аралап алып» бастыра башлады.

Кызганычка каршы, бу эш бик сүлпән бара. Безнең алда галимнең татар халкы тарихына кагылышлы хезмәтләрен җыеп бастыру бурычы тора. Ташларны җыярга, галим алдында бурычны кайтарырга күптән вакыт.

**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,**
*тарих фәннәре докторы*

---

[35] Михаил Худяков. Тарихи-документаль җыентык. – Казан: «Җыен» нәшрияты, 2011.

[36] Материалы краеведческих чтений, посвящённых 135-летию Общества естествоиспытателей при КГУ, 110-летию со дня рождения М.Г.Худякова. – 24-25 марта 2004 г. – Казань: Школа, 2004. – 484 с.

[37] Ванюшев В.М. Михаил Георгиевич Худяков и удмуртский героический эпос // Материалы краеведческих чтений, посвящённых 135-летию Общества естествоиспытателей при КГУ, 110-летию со дня рождения М.Г.Худякова. – 24-25 марта 2004 г. – Казань: Школа, 2004. – С.470-479.

# ТРАДИЦИЯЛӘРГӘ ТУГРЫ КАЛЫП...

Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, татар филологиясе һәм сәнгать белеме өлкәсендә җитди тикшеренүләр алып бара торган бердәнбер академик оешма, бу көннәрдә 75 яшен тутырды. Ул СССРдагы милли республикалар халыкларының тарихын, мәдәниятен, әдәбиятын өйрәнү максатында төбәкләрдә фәнни институтлар ачылган чорда – XX гасырның утызынчы еллары азагында оеша.

Юбилей, аерым шәхеснеке булсынмы ул, зур оешманыкымы – һәрвакыт үткәннәрне барларга һәм киләчәккә планнарны билгеләргә, максатларны ачыкларга кулай вакыт. Шул уңайдан «Казан утлары» журналы институт галимнәре белән «түгәрәк өстәл» янында фикер алышты.

*Белешмә: 1939 елның 7 октябрендә Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институты ачу турындагы карар кабул ителә. 1941 елның февраленнән ул Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшерү институты статусын ала. 1946 елдан СССР Фәннәр академиясенең яңа ачылган Казан филиалы составына кертелә. Институтта татар гуманитар белемнәренең барлык өлкәләрендә – тел белеме, лексикография, әдәбият белеме, текстология, фольклор фәне, театр сәнгате, музыка сәнгате, сынлы сәнгать, тарих, археология, этнография, иҗтимагый фикер һәм ислам дине буенча җитди теоретик һәм гамәли тикшеренүләр алып барыла.*

*Институтның структурасы фәнни максатларына ярашлы рәвештә, эшне нәтиҗәлерәк итү өчен һәм заман таләпләренә җавап рәвешендә үзгәрешләр кичерә. Мәсәлән, тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге барлыкка килә, сүзлекләргә ихтыяҗ артуына бәйле рәвештә тел галимнәре лексикография бүлегенә берләшә. Халкыбызның гаять бай кулъязма мирасын өйрәнү һәм тиз арада фәнни әйләнешкә кертүне тизләтү максатыннан 2009 елда «Казан Кремле» биләмәсендә «Мирасханә»нең яңа бинасы ишекләрен ача. ТӘҺСИдә канат ныгытып «башка чыккан» институтлар да аз түгел. Мәсәлән, 1990 елда оештырылган татар энциклопедиясе төркеме Татар энциклопедиясе институты булып җитешә. 1996 елда институтның тарих, этнография, археология, иҗтимагый фикер һәм ислам тарихы бүлекләре нигезендә Татарстан һәм татар тарихы буенча җитди тикшеренүләр алып бара алырлык Тарих институты оеша. Институт күренекле татар галиме Шиһабетдин Мәрҗани исемен йөртә. Әлеге институттан А.Халиков исемендәге Археология институты да аерылып чыга.*

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ, журналның бүлек мөхәррире:**



*— 75 ел дәвамында татар халкының тарихы, теле, әдәбияты, фольклоры һәм иҗтимагый фикере буенча җитди тикшеренүләр алып барган институтның тарихы, әлбәттә, халкыбыз язмышы белән тыгыз бәйләнгән. Бүген без бу хакта институт директоры, филология фәннәре докторы, ТФАның мөхбир әгъзасы Ким Мөгаллимович Миңнуллин, филология фәннәре докторы, профессор, ТФАның мөхбир әгъзасы Фуат Әшрафович Ганиев, филология фәннәре докторы, профессор Зөфәр Зәйниевич Рәмиев, сәнгать фәннәре кандидаты, тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге җитәкчесе Рауза Рифкатевна Солтанова, филология фәннәре кандидаты, халык авыз иҗаты бүлеге җитәкчесе Илмир Илдарович Ямалтдинов белән әңгәмә корабыз. Сөйләшүебезне иң гади, традицион сораудан башлыйк әле: институт үз тарихын, бәлки тарихын гына да түгел, ә институт ачылырга сәбәп булган алшартларны да, ныклап өйрәнә алдымы?*

**Ким МИҢНУЛЛИН:**



— Өйрәнелеп бетерелде дип әйтә алмыйм. Әле менә 75 еллык унаеннан да хезмәткәрләребез, архивларда утырып, шактый гына кызыклы документлар таптылар. Аларны өйрәнеп, эшкәртеп, саллы гына китап итеп бастыру хыялы бар. Шунысын да онытмыйк: институт буш урында барлыкка килә алмый. Аның бит бай тарихи җирлеге булган. Идел-Урал буенда яшәүче халыкларның, шул исәптән татарларның мәдәнияте, тормыш-көнкүреше белән кызыксыну шактый күптәннән башлана. Казан император университетында 1829 елда ачылган Көнчыгыш разряды, 1855 елда Санкт-Петербургка күчерелгәнгә кадәр, шәрык халыкларын, аеруча, төркиләрне өйрәнү үзәге булып тора. Сонрак мондый эшчәнлекне 1878 елда Казан университеты каршында төзелгән «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» дәвам итә. Җәмгыятьнең үз журналы да булдырыла һәм 1929 елга кадәр актив эшләп килә. Анда Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Х.Фәезханов, Г.Әхмәров, Һ.Атласи кебек татар галимнәре хезмәттәшлек итә. Татарстан АССР төзелгәч, 1921 елның 3 декабрендә Академик үзәк төзелә. Аның составында фәнни-сәяси, фәнни-техник, фәнни-педагогик, сәнгать комиссияләре эшли. Үзәкнең беренче рәисе Г.Максудов булып, күпмедер вакыттан соң бу вазифаны Галимҗан Ибраһимов башкара. Бирелә татар әдәбияты тарихы, татар теле, халык иҗатын җыю һәм бастыру, төбәк тарихын өйрәнү, терминология, орфография сүзлекләре төзү, мәктәпләр өчен дәреслекләр һәм программалар язу буенча эшчәнлек җәелдерелә. ВКП(б)ның Татарстан Өлкә комитеты карары белән 1934 елның 4 июлендә Татар марксизм-ленинизм фәнни-тикшеренү институты төзелә. Андагы галимнәрнең бер төркеме профессор М.Корбангалиев һәм Ш.Рамазанов җитәкчелегендә татар башлангыч һәм урта мәктәпләре өчен уку әсбаплары язу, ә С.Атнагулов җитәкчелегендәге тәрҗемә бюросы сүзлекләр төзү белән шөгыльләнә. Ягъни, бүген институтыбыз 75 еллыгын билгеләп үтсә дә, аның нигез ташлары күпкә элегрәк салынган: ул тикшерә торган проблемалар буенча актив эшчәнлек 1921 елда ук барлыкка килгән Гыйльми үзәктә һәм аннан соңгы фәнни оешмаларда башлана. Алга таба аларда эшләгән гыйльми көчләрнең байтагы институтыбызда хезмәт итә. Ниһаять, 1939 елның 7 октябрендә ТАССРның Халык Мәгарифе комиссариаты Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институты төзү турында карар кабул итә, 1941 елның февраленнән Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты статусын ала. 1946 елдан СССР Фәннәр академиясенең яңа ачылган Казан филиалы составына кертелеп, ярты гасырдан артык Татарстанда татар гуманитар фәннәрен өйрәнүче бердәнбер академик институт булып кала. 1993 елдан ул Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе канаты астында. Бүгенге көндә институтта

тугыз фәнни бүлек бар. Аларда 80гә якын фәнни хезмәткәр, шулардан 20дән артык фән докторы, 50ләп фән кандидаты хезмәт куя.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ:**

*— Ким Мөгаллимович, төрле елларда институт белән җитәкчелек иткән шәхесләрне дә бүген җылы сүз белән искә алу бик урынлы булыр иде.*

**Ким МИҢНУЛЛИН:**

— Шушы дәвер эчендә институтны 10 кеше җитәкләгән. Аларның һәрберсе институтның үсеше өчен үз өлешен керткән шәхесләр. Кызганыч, институтыбызның беренче директоры, бу вазифада нибары бер ай гына эшләп өлгергән Миргали Нигъмәтуллин турында без әле бик аз беләбез. Хәсән Шабанов балалар шагыйре һәм мәктәп дәреслекләре төзүче буларак билгеле, ул Бөек Ватан сугышында катнашып, Берлинга кадәр барып җиткән. Фольклорчы, филология фәннәре докторы Хәмит Ярми, әдәбиятчы, филология фәннәре докторы, профессор Мөхәммәт Гайнуллин, әдәбиятчы, тәнкыйтьче Хәсән Хәйри, дәүләт эшлеклесе, фәлсәфә фәннәре докторы, профессор Камил Фасиев, тарихчы, тарих фәннәре докторы, профессор Мидхәт Мөхәррәмов, фәлсәфә фәннәре докторы, профессор Яхъя Абдуллиннарның исемнәрен тирән хөрмәт белән искә алабыз. Алар – милли фәнебез үсешенә зур өлеш керткән, халкыбыз тарихында якты сәхифә булып калган олпат шәхесләр. Институтыбызны озак кына еллар җитәкләгән ике директорыбыз әле безнен арада. Филология фәннәре докторлары, профессорлар Мирфатыйх Зәкиев белән Нурмөхәммәт Хисамовлар читтән күзәтеп торучылар гына түгел, ә балки, әле дә актив тормыш алып баралар – конференцияләрдә катнашалар, матбугат битләрендә чыгышлар ясыйлар, җәмгыятебездәге үзгәрешләргә карата һәрдаим үзләренең гражданлык позициясен белдереп торалар. Нурмөхәммәт ага Хисамовның «Йосыф китабы»на нигезләнеп язган «Йосыф-Зөләйха» әсәренең сәхнәдә куелуы шулай ук уртак шатлыгыбыз. Шунысы да игътибарга лаек: директорларның тәрҗемәи хәленә күз салсак, аларның татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә туып-үскән, фәнгә-гыйлемгә сусап Казанга тартылган шәхесләр икәнлеген күрербез: беренче директорыбыз – Уфа губернасыннан, икенчесе – Пенза якларыннан, өченчесе – Себердән…

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ:**

*— Фуат Әшрафович, сез институт аксакалларының берсе, сез тел белеме бүлегенә аспирантурага укырга кергәннән бирле ярты гасырдан артык – төгәлрәк әйтсәк, нәкъ 55 ел узган. Афәрин! Фәннең гомерегез буе сез тугрылыклы булган юнәлеше, лексикография бүлеге белән хәзер институтта сезнең аспирантыгыз — филология фәннәре докторы Айнур Тимерханов җитәкчелек итә. Институттагы барлык үзгәрешләр, фән йортының уңышлары да, проблемалары да күз алдында булгандыр. Әйдәгез, сезнең хатирәләр буенча беркадәр тарихны яңартып, фаразларыгыз буенча киләчәген күзаллап карыйк әле.*



**Фуат ГАНИЕВ:**

— Татар теле белеме, башка төрки телләр белән чагыштырганда, революциягә кадәр дә, аннан соң да, иң нык өйрәнелгән тел белеме дип саналды. Беренчедән, татар тел белемендә электән үк бик көчле галимнәр эшләгән – Гиганов, Троянский, Казимбеклар миссионерлык мәктәбендә татар телен укытканнар. Тел белеме буенча үз «мәктәпләрен» булдырган галимнәребез бар. Әйтик, татар әдәби теленең тарихы буенча эшләүчеләр – Латыйф Җәләй шәкертләре, лексикография буенча галимнәребезнең остазы – Риза Газизов, грамматика буенча – Вәли Хангилдин. Институтның күтәрелеш еллары дигәндә, ул Бөек Ватан сугышыннан соң башлана, ул чакта фәнни-тикшеренү эшләре бермә-бер көчәеп китә. Сугыштан соң тыныч тормышка сусаудан шулай булгандыр, дим. Без төрки дөньяда беренчеләрдән булып «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н төзергә алындык. Аны тел галиме Гаян Әмиров башлап җибәргән иде. Без – яшьләр, тел белеме буенча фәнни хезмәткәрләр,

татарлар яшәгән төбәкләргә чыгып, татар классиклары әсәрләре буенча 3 миллионнан артык сүзгә картотека төзедек. Шуның нигезендә өч томлык «Аңлатмалы сүзлек» төзелде, ул язучы телennән алынган мисаллар нигезендә әзерләнгән чын сүзлек иде. Үзбәк, казакъ галимнәре үз сүзлекләрен төзегәндә безнен сүзлекне үрнәк буларак кулландылар. Татар теле белеменә иң зур өлеш кертүчеләрнең берсе иде ул Гаян Суфиянович! Ә Мирфатыйх Зәкиев җитәкчелек иткән елларда «Татар теленең академик грамматикасы»н бастырып чыгара алдык. Аның төп авторларына Дәүләт премиясе бирелде. Андый дәрәҗәдәге фәнни басма төрки телләрнең бер өлешендә әле дә юк. Башкортстанда, мәсәлән, яна гына әзерләнеп тапшырылды.

Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының барлык бүлекләре, аеруча тел белеме бүлеге «Татарстан Республикасы халыкларының телләре турындагы» Законын эшләүгә зур өлеш кертте. Әлеге Закон кабул ителгәннән соң, аны тормышка ашыру буенча Программа эшләүдә, аның теоретик һәм гамәли якларын ачыклауда безнең институт галимнәре башлап йөрде.

Бүгенге көндә институт капиталь сүзлекләр белән бергә массакүләм сүзлекләр дә әзерли. Хәзер «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» алты томлык итеп төзелә. Татар теле – фигыльләргә бай тел, япон яки һинд телендәге кебек тезмә фигыльләребез бар. Төп фигыльгә ярдәмче фигыль кушылып ясалган тезмә фигыльләр саны дистәләрчә меңнән артып китә. «Тезмә фигыльләрнең аңлатмалы сүзлеге»н әзерләп бастырган идем, хәзер алар яна аңлатмалы сүзлекләргә дә кертеләчәк. Күп кенә сүзлекләребез «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» ТР Законы һәм аның программасы нигезендә басылып чыкты. Әйтик, бер томлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (2005), ике томлык «Татарча-русча сүзлек» (2007), «Татарча-русча кеше исемнәре һәм фамилияләре» (2006), «Диалектологик сүзлек» (2009), «Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге» (2013), «Татарча-русча-инглизчә мәктәп сүзлеге» (2014) ... Ә менә хәзер, татар гуманитар фәненә игътибар кими төшкәннән диимме икән, «Татар теленең академик орфоэпия сүзлеге» һәм «Татар теленең академик орфография сүзлеге»н бастырып чыгара алган юк әле.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ:**

*— Зөфәр Зәйниевич, туксанынчы елларда галимнәр тарафыннан бик актив рәвештә Гаяз Исхакый иҗаты өйрәнелде, хәзер сездән Габдулла Тукайның академик басмаларын көтәбез. Татар әдәбиятына караш җәмгыятьтәге үзгәрешләр белән ни дәрәҗәдә бәйле? Татар әдәбиятында иҗаты җентекләп өйрәнелергә тиешле әдипләребез дип тагын кемнәрне атап үтәр идегез?*

**Зөфәр РӘМИЕВ:**



— XX гасыр башы – татар әдәбиятының алтын чоры, чын мәгънәсендә янаруы дибез. Ул көнчыгыштан гына түгел, көнбатыштан да килгән традицияләрне синтезлау юлы белән үсеш алган. Яна чорга туры килә торган образлар, идеяләр, мотивлар табылган. Татар халкы яшәгәндә, аның милли рухы булганда, минемчә, классикларны читкә тибәрү беркайчан да булмаячак, чөнки ул безнең тарих, анда һәр чорга янгырашлы фикерләр чагылыш тапкан. XX гасыр башы дибез икән, сүз дә юк, иң элек Тукай күз алдыбызга килеп баса. Революциядән соңгы чорда Тукайга артык кагылмасалар да, тәнкыйди моментлар бар иде. Ә инде утызынчы елларда ул фәнни дөньяда халык шагыйре буларак расланды. 1938 елда хөкүмәтнең Тукай иҗатына кагылышлы, ялгышмасам, беренче карары бар: Тукайның фәнни басмасын әзерләргә диелгән анда, һәйкәлен куярга дигән фикер дә була. 1939 елда безнең институт ачылгач та, әдәбиятчы галимнәр алдына ике бурыч куела: әдәбиятның тарихын язу һәм классикларыбызны халыкка кайтару. Әдәбиятчылар беренче эш итеп Тукайның ике томлык академик басмасын әзерләү эшенә керешәләр. Академик басма дип аталса да, ул әле шактый гына аксый, чөнки күп шәхесләр оныттырылганга күрә, Тукайның әсәрләрен шактый сайларга, аңлатмалар язганда сак булырга туры килгән. Тукай иҗатын халыкка якынайтуга зур

өлеш керткән галимнәребез – Хәй Хисмәтуллин, Якуб Агишев, Рашат Гайнанов, Нил Юзиевлар. Ниһаять, Тукайның 125 еллыгы якынайган елларда житәкчелек Тукайның академик басмасын әзерләүне институт планына кертте. Ул алты томда булачак. Анда нинди дә кыскартылуларга юл куелмыйча, Тукай ничек язган – шулай биреләчәк. Галимнәребез Тукайның яна әсәрләрен таптылар – бүген аның 65ләп псевдонимы билгеле. Академик басманың 1-2нче томнары инде басылып чыкты, 3-4нче томнары нәшриятка тапшырылган, 5-6нчы томнары буенча да эш төгәлләнеп килә. Жиренә житкерелеп, фәнни принциплар кулланып эшләнгән Тукай басмасы алдагы юбилеена дөнья күрер дип ышанабыз. Тукайның 130 еллыгына безнең текстология бүлеге томнарны халыкка житкереп зур эш башкара. Тукай энциклопедиясен әзерләү буенча да актив эш бара. Моннан 20 ел элек Нил Юзиев инициативасы белән инде аның беренче адымнары ясалган иде. Ул бик күләмле итеп уйланылган, Нил Гафурович аны Лермонтов энциклопедиясе рәвешендә эшләүне хуп күргән иде. Юнәлешләрен, тематикасын да ул билгеләп калдырды. Нил ага вафат булгач, бу эшне житәкләү минем жилкәгә йөкләнде. Анда 2800 мәкалә урын алырга тиеш, бүгенге көндә 2400е әзер. Аны да Тукайның 2016 елгы юбилеена бастырып чыгару бурычы куелган. Эш жинел бармый. Беренчедән, әлегә бездә аерым шәхескә багышланган персональ энциклопедия төзү тәжрибәсе юк. Совет чорында татарның үз энциклопедиясе дә юк иде бит. Бирелә Тукайның 770ләп тексты һәрберсе берәмтекләп тикшерелә, туганнары, дуслары һәм замандашлары белән мөнәсәбәтләре чагылыш таба, ижатына Тукай тәэсир иткән әдипләр, Тукайны төрле телләргә тәржемә итүчеләр, Тукай образын тудырган язучылар, артистлар, рәссамнар, Тукай белән бәйле урыннар...

Сорауга жавап буларак, институтның тагын бер зур хезмәтен күрсәтеп үтми мөмкин түгел. Үзгәртеп кору чорлары житеп, тыелган темалар ачылганнан сон, чит илдә яшәп, совет чорын тәнкыйтьләп торган, халык дошманы дип игълан ителгән язучыларның ижатын өйрәнү мөмкинлеге туды. Беренче чиратта, Гаяз Исхакый әсәрләрен халыкка кайтару кирәк иде. Башта ул бер том булып кына чыкты. Аннары хөкүмәтебез язучының 15 томлыгын әзерләү турында карар кабул итте һәм бу эшне Татарстан Фәннәр академиясенә тапшырды. Әлбәттә, аны әзерләү эше безнең институтның текстология бүлегенә йөкләнде. Эш жинел бармады. Чөнки Исхакыйның библиографиясе, язучы каләменнән төшкән текстлар бездә юк иде – табарга кирәк булды. Беренче биш томын галимә Лена Гайнанова төзегән иде, башка томнарын текстология бүлеге хезмәткәрләре әзерләде. Бу 15 томлык хезмәт – татар әдәбияты, татар гуманитар фәне өчен зур вакыйга, чөнки бер генә татар классигының да ижади мирасы фәнни аңлатмалар, эшкәртмәләр белән шушындый күләмдә басылып чыкканы юк.

Татар әдәбиятында ижаты жентекләп өйрәнелергә тиешле әдипләребез бик күп. Ачылырга тиешле әсәрләр дә бар. Күренекле язучы һәм галим Галимжан Ибраһимов ижатының 12 томлык тулы басмасы әзерләнә. Фатыйх Әмирхан, Шәриф Камал, Һади Такташларның ижатын да тулысынча кайтарып бетерә алганыбыз юк. Киләчәктә бу текстологларның зур бурычы булып тора.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ:**

*— Институтның иң яшь, әмма иң актив бүлекләренең берсе – Тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге. Әлеге бүлек хезмәткәрләре катнашкан проектлар дисеңме, конференцияләр, чыгышлармы... Рауза ханым, бу бүлек эшчәнлеге белән кыскача таныштырып үтсәгез иде. Бүгенге көндә нинди җитди эшчәнлек алып барыла? Гомумән, сәнгать бүлегенең татар милли сәнгатенә тәэсире бармы? Әллә ул гамәли сәнгатьнең, милли театр сәнгатенең үсешен читтән күзәтеп, анализлап торучы гынамы?*

**Рауза СОЛТАНОВА:**

— Татарстанның тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать тарихы белән кызыксыну соңгы елларда аеруча активлашып киткән иде. Шушы активлыкның да тәэсире булгандыр, 2007 елда институтның сәнгать бүлегеннән Тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге мөстәкыйльлек алып чыкты. Ул яна фәнни концепция нигезендә, комплекслы тарихи-сәнгати тикшеренүләр ысулына таянып эш итә. Төп темабыз – «Тарихи-мәдәни контекстта татар халкының милли-сәнгати фикерләү формалары». Бүлекнең үсеш концепциясе тасвирый материалны фәлсәфи, эстетик һәм мәдәни анализның теоретик



идеяләре белән ныгытуны күздә тота. Милли-сәнгати фикерләү төрле контекстларда – тарихи яки мәдәни яктан күзәтелә. Куелган максатыбызга ирешергә безгә тарих, фәлсәфә, культорология һәм социология белгечләреннән төзелгән консультатив совет ярдәм итә. Бүлекнен үсеш концепциясенә ярашлы рәвештә берничә юнәлештә эш алып барыла. Сәнгать фәннәре кандидаты Динә Вәлиева «Алтын Урда чорында Идел Болгарстанының сәнгате», «XX гасырда Татарстан сәнгате» исемле китапларында рәсем сәнгатенең тарихын һәм бүгенгесен чагылдырган. Татар шамаилләрен һәм каллиграфиясен өйрәнүче галимебез, сәнгать фәннәре кандидаты Рөстәм Шәмсутовның Урта Идел һәм Урал буе татар-мөселманнарының гыйбадәтханәләре бизәлеше турындагы эзләнүләре дә игътибарга лаек. Татарстанның графика сәнгатен борынгы заманнардан алып бүгенгәчә өйрәнү – шулай ук төп юнәлешләребезнең берсе. Бу тема Ольга Улемнованың «1920-1930 елларда Татарстанда графика сәнгате» исемле диссертациясендә чагылыш тапты. Фирдәвес Вәһапова революциягә кадәрге чорда китап бизәлешен, гарәп графикасы булган илләрдә татар китабының тоткан урынын өйрәнә. Өлкән фәнни хезмәткәребез Лариса Донинаның татар театрында милли киемнәр буенча тикшеренүләре сәнгать белеме, эстетика, этнография, филология фәннәренең киселешендә карала, ә монарчы бу тема тарихи-этнографик аспектта гына өйрәнелгән иде. Минем үземнең фәнни эзләнүләрем татар театры тарихында сәхнә бизәлешен (сценография) күп сәнгать төрләрен үз эченә алган феномен буларак күрсәтүгә юнәлдерелгән. Сәнгать фәннәре кандидаты Гөлчәчәк Ногманова бүлекнең яна юнәлешләре булган архитектура һәм шәһәр төзелеше тарихын өйрәнде. Аның хезмәте Россия империясе шартларында Идел-Кама төбәгенең архитектура үзенчәлекләрен чагылдыру ягыннан гына түгел, заман архитектурасы һәм реставрация эше үсеше өчен гамәли яктан да гаять зур әһәмияткә ия. Динә Әхмәтованың «Стилевое многообразие в ситуации современной художественной культуры» дигән монографиясендә тасвирый сәнгатьтә стиль үзенчәлекләре теоретик яктан бүгенге проблемалар белән бәйләп тикшерелә. Безнең бүлеккә 1970 елларда нигез салган, татар сәнгать белемен үстерүгә зур хезмәт куйган Фоат Вәлиевнең эзеннән баручы яшь галимнәребез бар. Мәсәлән, Наилә Халитова Алтын Урда чоры архитектурасындагы милли бизәкләрнең үзенчәлекләрен өйрәнә. Илдар Муллин сәнгать әсәре буларак, татар кабер ташлары эволюциясен барлый. Людмила Шкляева татар дөньясындагы агачны сәнгатьле эшкәртү проблемаларын карый. Фәнни хезмәткәрләребез Динә Хисамова һәм аспирантка Татьяна Кривошеева скульптура сәнгатен өйрәнәләр. Белгәнебезчә, безнең скульптура сәнгатебез борынгы төркиләрнең һәм кыпчакларның балбалларына, Идел Болгарстаны гамәли сәнгате предметларына, Казан ханлыгындагы ташка уелган бизәкләргә һәм сәнгать төре буларак каралган каберташларга барып тоташа. Кривошееваның быел нәшер ителгән татар скульптурасының үсеш юлларына багышланган китабы зур кызыксыну уятыр дип ышанасы килә.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ:**

*— Рауза ханым, скульптура дигәннән, быел гаҗәеп кызыклы проект тормышка ашырылды. Ялгышмасам, идея авторы да, башлап йөрүче дә сез идегез. «Казан – төрки дөньяның 2014 елгы мәдәни башкаласы» программасына кертелгән «Таш моңы» халыкара симпозиумы турында әйтүем.*

**Рауза СОЛТАНОВА:**

— «Таш моңы» дигән халыкара скульптура симпозиумы Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм ТӨРЕКСОЙ халыкара оешмасы ярдәмендә быел беренче мәртәбә «Казан Кремле» музей-тыюлыгында уздырылды. Цифрлы технологияләр киң кулланылган, алга киткән мәдәниятләр үз тәэсирен көчәйткән заманда этник берлек билгеләрен саклау зарурлыгы үзен аеруча ачык сиздерә. Скульптурага бәйле симпозиумнар этник һәм милли традицияләрне саклап калуга һәм яклауга ярдәм итәләр, милли сынлы сәнгатьтә яңа мөмкинлекләр ачып, үсеш юлларын күрсәтәләр. Бирегә Россиянең төрле төбәкләреннән

һәм чит илләрдән вәкилләр чакырылган иде — осталар 20 көн эчендә ачык һавада сыннар ясадылар. Әлеге чара шулай ук сынлы сәнгатьне популярлаштыруга, шәһәр урамнарын, биналарын, парк-бакчаларын милли үзенчәлекле һәм халыкның бай мәдәниятен чагылдыручы югары кимәлдәге сәнгать әсәрләре белән бизәүгә юнәлдерелгән.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ:**

*— Ким Мөгаллимович, элек тә шулай булдымы икән, соңгы елларда галимнәребезнең төрки дөнья белән бигрәк тә активлашкан элемтәсен билгеләп үтми мөмкин түгел. Әйтик, сезнең институт шушы көннәрдә генә Казан дәүләт консерваториясе белән берлектә «Төрки халыклар әдәбияты һәм музыка сәнгатенең тамырлары һәм үсеше» исемле халыкара конференция үткәрде. ТӘһСИнең төрле республика, аеруча төрки дәүләтләр белән бәйләнешләре турында да сөйләшик әле.*

**Ким МИҢНУЛЛИН:**

— Рухи мирасыбызны милли-мәдәни бәйләнешләр яссылыгында өйрәнү төрки дөнья күләмендә зур әһәмияткә ия. Шул унайдан Казанга Төркия, Казакъстан, Азәрбайҗан, Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Иран кебек илләрдән мөхтәрәм галимнәр килде. Болар барысы да кардәш халыклар арасындагы мәдәни бәйләнешләрне ныгыту һәм үстерү, төрки мәдәниятне киң җәмәгатьчелеккә таныту максатыннан чыгып эшләнә. Бөтен дөньяга танылган төркиләрнең мәдәнияте, сәнгате һәм әдәбиятының күпгасырлык тарихы бар: төрек, татар, казакъ, үзбәк, азәрбайҗан, якут, чуваш һәм башка төрки халыклар рухи мирасының беренче яралгылары моннан мең еллар элек барлыкка килгән. Уртак тамырларга ия бу мирас бүгенге дөнья мәдәниятендә зур урын тота. Аны фәнни өйрәнү һәм киләчәк буыннарга җиткерү эше — барлык төрки кавемнәрнең мөһим бурычы дип саныйм. Шунысы да игътибарга лаек: ТӨРЕКСОЙ быелгы елны төрки илләрдә төрекмән шагыйре һәм философы Мәхтүмколый елы дип игълан итте. Мәхтүмколыйның шигъри мирасы төрекмән милләтенең генә түгел, бөтен төрки халыкларның мәдәни байлыгы дияр идем. Шуна күрә конференциянең бер секциясе Мәхтүмколый иҗатына багышланды. Әлеге фәнни чарага Төрекмәнстаннан да белгечләр килде. Мондый уртак чаралар, һичшиксез, ике туганлаш халыкның бәйләнешләрен ныгыта.

Бөтен бәйләнешләрнең максаты бер — уртак проектларга омтылу. Без тарихта эзе, үз йөзе, реаль көче булган халыклар белән аралашабыз. Әйтик, азәрбайҗаннар, үзбәкләр, казакълар... Заманында алар — союздаш, без автономияле республика булсак та, безнең абруебыз бар, нигезебез нык, фәнни потенциалыбыз шактый зур иде. Соңгы елларда, мөстәкыйль дәүләтләр буларак, аларның көче күзгә күренеп арта, башкарган эшләре киң колач ала бара.

Без — икътисад өлкәсендә, химия, машина төзү тармакларында, спортта алга киткән локомотив-республика. Ә бит үзебезнең фән, мәдәният, сәнгатьтә дә алдынгы була алуыбызны күрсәтү зарур. Шуна күрә конференцияләрне, симпозиумнарны якын һәм ерак чит илләрдән күп кунаклар чакырып зурлап үткәрергә тырышабыз. Бу үзен аклый: килсеннәр, күрсеннәр — институтыбызның эшен дә, Казаныбызны да...

**Рауза СОЛТАНОВА:**

— Ким Мөгаллимович фикеренә кушылып, шуны да өстисем килә: сәнгать белеме өлкәсендә эзләнүләрнең заманча этабына милли һәм мәдәни тәңгәллек проблемаларына бәйле методологик карашларны эзләү активлыгы һәм сәнгать үсешенең традицион булмаган формаларын ачыклау хас. Бу яктан караганда төрки сәнгать белеме хәзерге сәнгать үсеше юнәлешләреннән иң үзенчәлеклесе булып санала. Ул элекке Советлар Союзының төрки республикаларында соңгы ике дистә елда аеруча активлашты. Тарихи вакыйгаларның үзенчәлекле үсеш кичерүенә, мәдәни процессларның үзгәлегенә карамастан, төрки халыкларның хәзерге сәнгатендә тирәнтен өйрәнүне таләп итә торган уртак проблемалар шактый дияр идем. Шуна күрә дә без 2009 елда төрки дөньяда иң борынгы һәм иң киң таралган киез сәнгатенә багышлаган халыкара симпозиумны үткәреп, күп уртак проблемаларны күтәрдек. Быел май аенда институтның бер төркем хезмәткәрләре Алматыда булып кайттык. Казакъстан сәнгать белгечләре белән фикер алышканда төрки халыкларның

сәнгати культурасын теоретик, методологик яктан, дөньяга караш проблематикасы югарылыгыннан өйрәнүнең яңа ракурслары ачыкланды; ирешелгән казанышларны бергәләп бәяләү, идеяләр белән уртаклашу һәм хезмәттәшлеккә тагын да тирәнәйтү зарурлыгы билгеләнде. Әйтик, Казакъстан галимнәренең дә игътибар үзәгендә, бездәге кебек үк, төрле аспектларда чагылыш тапкан милли традицияләр проблемасы тора.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ:**

*— Инде әкренләп халкыбыз мирасы темасына күчик. Халкыбыз үз көйләрен, җырларын, әкиятләрен, риваятьләрен, йомры сүзләрен буыннан-буынга күчереп кадерләп саклап килә. Хәзер ул буыннар чылбыры өзелмиме? Яшь буын фольклор белән ни дәрәҗәдә кызыксына? Илмир, бу сорау сезгә адресланды, институтның фольклор юнәлешендә алып барган эшчәнлеге турында кыскача гына әйтеп китсәгез иде?*

**Илмир ЯМАЛТДИНОВ:**



— Институтның юбилей елы фольклор юнәлеше өчен дә истәлекле ел, чөнки безнең мәшһүр фольклорчы галимебез Хәмит Ярминең тууына 110 ел тулды. Ул милләтебезнең йөзек кашы саналган институтның үсешенә зур өлеш керткән кеше, аның директоры да булган. 1939 елда институт оешуга, бу шәхеснең тырышлыгы белән фольклор секторы оештырыла һәм халык иҗатын өйрәнү мөһим юнәлеш итеп билгеләнә. Беренчедән, халык җәүһәрләрен җыю өчен фәнни экспедицияләр оештыру, икенчедән, фольклор текстларын әзерләп бастырып кабат халыкка кайтару һәм халык иҗаты белән бәйле проблемаларны фәнни өйрәнү эшчәнлеге – бүлектә 75 ел дәвамында, дөнья күләмендә фольклористикада кабул ителгәнчә, шушы өч юнәлеш буенча нәтиҗәле эш алып барыла. Милли фольклорны комплекслы һәм максатчан өйрәнү Хәмит Ярми, Нәкый Исәнбәт, Халидә Гатина, Илбарис Надиров, Фатыйх Урманчеев, Флора Әхмәтова, Тәлгат Галиуллин, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Ленар Җамалетдинов, Рәшит Ягъфәров, аннан килеп Айсылу Садекова, Ким Миннуллин, Илсөяр Закирова, Лилия Мөхәммәтҗановаларның исемнәре белән бәйле. Бүгенге көндә инде өч-дүрт буынны берләштергән академик татар фольклорчылар мәктәбе бар. Без барыбыз да Хәмит Ярминең фольклор мәктәбе шәкертләре дисәм килә.

Институт оешканнан бирле максатчан, планлы рәвештә фәнни экспедицияләр оештырылып килենә. Институтның бай фольклор фонды булдырылып, төрле типтагы җыентыклар дөнья күрә башлый. Алтмышынчы еллар азагына уникe томлык «Татар халык иҗаты» җыентыгын төзү проекты туа. Әлеге зур хезмәт дөнья күреп, Тукай исемендәге премиягә лаек була. Хәзерге вакытта да фольклористиканың мөһим проблемалары өлкәсендә төрле тикшеренүләр алып барыла: фәнни монографияләр дөнья күрә, диссертацияләр яклана. Фольклористикада бүгенге көн таләпләреннән чыгып, үз вакытында чорга, идеологиягә бәйле рәвештә җыентыкларга кертелми калган халык җәүһәрләре белән тулыландырылган «Татар халык иҗаты»ның 25 томлык җыентыгын төзү буенча эш бара. Русчасы 15 томнан тора, бүгенге көндә дүрт томы басылып чыкты, икесе нәшриятка тапшырылды. 2009 елдан бирле Институтта экспедицияләр комплекслы итеп оештырыла, ягъни, телчеләр, фольклорчылар, сәнгатьмузыка белгечләре, археографлар бер төркем булып җәй айларында халкыбызның милли-мәдәни мирасын барлау, җыю һәм өйрәнү максатыннан кыр тикшеренүләре үткәрәбез. Шул вакыт эчендә Татарстан районнары һәм милләттәшләребез яшәгән Россия төбәкләренә, аерым чыгуларны исәпкә алмаганда, 15 комплекслы экспедиция оештырылган. Бу елына 2-3 экспедиция дигән сүз. Әлеге тикшеренүләрнең нәтиҗәсе буларак «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә китаплар дөнья күрә. Инде басылып чыкканнары Татарстанның Актаныш, Апас районнарында, Россиянең Түбән Новгород өлкәсе, Марий Эл, Удмуртия республикаларында яшәүче милләттәшләребез, аларның көнкүреше, гореф-гадәтләре, тел үзенчәлекләре турында бай мәгълүмат бирә һәм борынгы ташбилгеләр, шәҗәрәләр, төбәкләрнең халык авыз иҗаты, җыр-моңнары, җирле осталарның кул эшләре һ.б. белән таныштыра. Боларга өстәп Чүпрәле, Кукмара,

Мамадыш районнары, Пермь, Омск, Самара өлкәләрендә яшәүче татарларның мирасын өйрәнүгә багышланган китаплар да басмага әзер инде. Нәшер итү өчен матди чыгымнар мәсьәләсе хәл ителгәндә, алар да тиздән дөнья күрер дип уйларга кирәк.

Үткән чорларда яшьләрдән дә, балалардан да кызыклы мәгълүмат язып алынган булса, хәзер күпчелек очракта өлкән буын гына безгә ярдәм итә. Хәер, соңгы ике елдагы экспедицияләребезнең берсендә – Мамадыш районында информантларыбыз арасында урта буын вәкилләре дә бар иде. Бу апалар, кызу җәйге көндә печән чабып кайтып кергәч тә, әниләреннән-әбиләреннән отып алган, өйрәнгән 15-20 халык җырын рәхәтләнеп җырлап күрсәтә алдылар – рәхмәт аларга! Әлеге җырлар аларның балаларына күчәрме – анысын әйтүе кыен. Шунысы кызганыч: халыкта әкиятләр сөйләү традициясе югала бара. Экспедицияләргә алты-җиде ел катнашып килэм – быел Самара өлкәсендә беренче тапкыр әкият язып алынды. Хәтта әкиятчеләр ягы дип дан алган Апас төбәгендә дә халык иҗатының әлеге жанрына караган әсәрләре очрамый инде. Ә иң еш очраганы – җырлар. Халкыбыз җырлаган һәм әле дә җырлый. Аеруча Пермь өлкәсе Барда районында мөнәҗәтләр әйтелә – актив кулланылышта, традицион рәвештә буыннан-буынга тапшырылып килә, төргәк-капчыкларда сакланган мөнәҗәт дәфтәрләре моңа дәлил булып тора. Аларны милләттәшләребез бик кадерләп саклыйлар, күчереп алырга гына рөхсәт итәләр. Арада яшәү һәм үлем турында, Ана һәм бала, Туган ил, бәйрәм мөнәҗәтләре, бигрәк тә Мәүлид бәйрәменә мөнәсәбәтлеләре зур урын алып тора. Монда инде мин еш очраган янсә очрамаган халык иҗаты жанрларын гына атадым. Ә гомумән, нинди генә төбәкне алып карасак та, анда яшәүче милләттәшләребезнең күңелләрендә, бигрәк тә өлкән буында, телдән-телгә, буыннан-буынга күчеп килгән халкыбыз мирасы саклана. Алга таба да әлеге эшне дәвам итеп, аларны язып алу, өйрәнү һәм системага салып янадан халыкка кайтару безнең бурыч булып тора.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ:**

*— Юбилей көннәрендә проблемалар турында сөйләшү бик үк урынлы да түгелдер. Шулай да, «түгәрәк өстәл» тирәсенә җыелганбыз икән, кайбер проблемаларны уртага салып сөйләшәсе иде. Әйтик, буыннар арасындагы өзеклек. Урта буын булмау проблемасы театрларда да бар, әдәбиятта да. Өлкән буын белән яшьләр арасында буыннар чылбыры өзеклеге сизеләме?*

**Ким МИҢНУЛЛИН:**

— Әйе, әлеге проблема, кызганычка каршы, безнең институтны да читләтеп үтмәде. Бу – туксанынчы елларда фәнгә булган мөнәсәбәткә дә бәйле булды инде. Ул чакта, хәтерлисезме, шактый гына уку йортлары ачылды, аларга кадрлар күп кирәк иде. Акча күбрәк түләнгәч, яшьрәк буын хезмәткәрләрнең бер өлеше институттан Югары уку йортларына киттеләр. Академик фән, әлбәттә, укытудан нык аерыла, җаваплылыгы да зуррак, чөнки ул үз продукциясен бөтен җәмәгатьчелек алдына «өстәлгә» сала. Эшебезнең нәтиҗәсе – күз алдында. Мәсьәләнең тагын бер ягы шунда ки, туксанынчы елларда татар гимназияләрен тәмамлаган укучыларыбызны зур өметләр баглап чит илләргә укырга җибәрдек. Аларның күбесе биргә кайтып яки чит илләрдә калып тормышта үз урыннарын тапканнардыр да. Тик белемле бу яшьләребез белән татар гуманитар фәне генә артык баемады. Инде бүген бу юнәлештә дә максатчан эш алып баруыбызның нәтиҗәсе сизелә башлады дияргә мөмкин. Институт структурасында аспирантура бүлеге һәм Диссертация советы унышлы гына эшләп килә. Аспирантларыбызның бер өлеше үзебездә эшкә дә кала.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ:**

*— Димәк, өлкән буын галимнәребез эшен дәвам итәрлек яшьләребез бар һәм булачак? Илмир, институтта яшьләр фән йөген өлкән буын җилкәсеннән үз җилкәсенә күчерерлек көчкә иямe?*

**Илмир ЯМАЛТДИНОВ:**

— Соңгы елларда килгән яшь буын бай тарихлы институт коллективына әкренләп кереп бара. Институтка яшьләр килә, алар шушы фәнни атмосферага күнегеп, коллективта үз урынын тапсын өчен бөтен мөмкинлекләр тудырыла. Институтка яшьләрнең килүе, аспирантура тәмамлап биредә эшкә калулары фәнни

житәкчеләрнен дә, институт житәкчелегенен дә максатчан эшләвеннәндер дип уйлыйм. Яшьләргә өлкән буын белән аралашып, аларнын ярдәмен тоеп эшләргә, алар тәжрибәсен алып калырга кирәк, беркем дә бөтенесен белеп тумый.

Хәзер институтта 35 яшькә кадәрле 20гә якын хезмәткәр эшли. Аларнын зур күпчелеге үзебездә аспирантура узып, кандидатлык диссертациясен яклап эшкә тотынган кешеләр. Институтта Яшь галимнәр һәм аспирантлар советынын актив эшләп килүе дә мона этәргеч биргәндер.

**Әлфәт ЗАКИРЖАНОВ:**

*— Ким Мөгаллимович, әңгәмәгә нәтиҗә ясап, институтның үсеш перспективаларын билгеләп, киләчәген фаразлап карыйк әле.*

**Ким МИҢНУЛЛИН:**

— Һичшиксез, институтларнын милләтләрне саклау максатында роле гаять зур. Безнең галимнәрнең алга зур максатлар куеп, зур проектларны тормышка ашырырлык потенциалы бар дип уйлыйм. Әйтик, соңгы биш елда институт хезмәткәрләре тырышлыгы белән 200дән артык китап һәм монография, шул исәптән, төрле сүзлекләр, каталоглар, жыентыклар бастырылган, 2600ләп фәнни һәм фәнни-популяр мәкалә дөнья күргән. Быелдан башлап институт көче белән татар телендә «Фәнни Татарстан» исемле журнал чыга башлады. Хезмәткәрләребез дәүләт грантларында да катнашалар. Бүгенге фән таләпләренә ярашлы рәвештә алдыбызга зур бурычлар куела. Бу беренче чиратта яна технологияләрне кулланып телләрне фәнни өйрәнү, институт компьютер лингвистикасы, корпуслы лингвистика, интернет-сүзлекләр төзү һәм башкалар. Алдыбызда торган зур эшләребезнең берсе — Институтнын «Мирасханә» үзәгендәге гаять бай архив материалларын электрон формаларга күчереп, аларны фәнни әйләнешкә кертү, зур музыкаль фондыбызны эшкәртеп җәмәгатьчелеккә тәкъдим итү. Үзебез өчен чагыштырмача янарак саналган кино, бию сәнгате кебек юнәлешләрдә дә тирәнтен фәнни эзләнүләр алып бару безнең алдагы бурычларыбызнын бер өлеше.

Кайбер кардәш халыкларда төрки мирасны өйрәнү дәүләт сәясәте дәрәҗәсенә куелган. Әйтик, казакъ галимнәре эзлекле рәвештә үз халкынын рухи байлыгын жыеп, бөтен илләрнен архивларында йөриләр, нәтижәдә, «Бабалар сүзе» дип аталган йөзтомлыклары дөнья күрде. Азәрбайжаннарда һәр фәнни юнәлеш буенча 150-200әр фәнни хезмәткәре булган аерым институтлар эшли. Алар үзләрен таныту өчен зур халыкара гуманитар форумнар үткәрәләр — дөнья галимнәренең төрки халыклар белән кызыксынуы көчле, әлеге форумнар Европа илләре өчен дә кызыклы. Мондый зур чаралар, бер яктан, милли республикалар арасында фәнни бәйләнешләр булдырырга ярдәм итсә, икенче яктан, ул бүгенге чор галимнәренә шәхси элемтәләр урнаштыру, аларнын дөньяга карашларын киңәйтү өчен кирәк. Югыйсә, СССР дигән илнең таркалып, анын составындагы республикаларнын мөстәкыйльлек алуы галимнәрнең аралашу даирәсен шактый тарайткан иде. Галимнәрне хәзер Мәскәү һәм Санкт-Петербург үзенә жыеп, элеккеге кебек еш аралаштырып тормый. Дөресен әйткәндә, Россиядәге республикаларнын кайберләрендә ул милли институтларнын хәлләре дә төрлечәрәк. Менә бу сөйләгәннәрнең барысын да истә тотып, институтнын 75 еллык юбилее көннәрендә гуманитар юнәлештәге фәнни-эзләнү институтлары житәкчеләре форумын уздырырга жыенабыз. Шул уңайдан XX гасырның утызынчы елларында төзелгән барлык милли институтларнын кыскача тарихы һәм бүгенгесе турында мәгълүмат бирә торган китап-белешмәлек төзергә дигән теләгебез бар. Чөнки барыбызнын да юнәлеше, максатлары уртак, проблемаларыбыз да бер үк — аларны уртага салып сөйләшәсе иде.

**Әлфәт ЗАКИРЖАНОВ:**

— Фикер алышуга бәйле рәвештә, институт үзенен 75 еллык юбилеен күркәм казанышлар белән каршы ала дип, нәтижә ясый алабыз. Ул, һичшиксез, төрки дөнья фән үсешендә күренекле урын алып тора, төрки дөнья белән бәйләнешләрне ныгыту юнәлешендә максатчан эш алып бара. Әйе, институтны алда яңа үрләр көтә. Аны яулау өчен фән йортынын потенциалы зур, бөтен мөмкинлекләре бар. Тагын бер кат юбилеегыз белән котлыйм! Уңышлар сезгә!

**Рузилә МӨХӘММӘТОВА** *язып алды.*



*Камал театры бинасында драматург Таҗи Гыйззәт белән хушлашу. Сулдан уңга: Латыйф Җәләй, Җәүдәт Фәйзи, Гамир Насрый, Әхмәт Фәйзи, Фатих Хөсни, Гариф Гобәй, Максуд Сөндекле, Гомәр Бәширов, Афзал Шамов, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Гази Кашшаф, Рәисә Ишморатова, Габдрахман Әпсәләмов, Мөхәммәд Садри, Шәрәф Мөдәррис, Абдулла Әхмәт, Мөнир Мазунов. 1955 ел.*



*Шагыйрь Зөлфәт һәм журналист Эльвира Кудрецкая Сибгат Хәким белән әңгәмәләшә. 1979 ел.*



*1963-1965 елларда «Казан утлары» журналының баш мөхәррире булып эшләгән язучы Газиз Мөхәммәтшин (1932-1972).*



*Аксакал әдипкә киңәш-фатихалар бирә. Гомәр Бәширов һәм Әхәт Гаффар. 1993 ел.*



*Татарстанның халык язучы Гәрәй Рәхим һәм Төрки дөньяны өйрәнү фонды президенты Туран Язган Сөләйман мәчете китапханәсендә. Истанбул. 1996 ел.*

*Рубриканы* **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** алып бара.

# МИЛЛӘТНЕҢ ЙӨЗ АКЛЫГЫ САГЫНДА

Россиядә яшәүче төрки милләтләр арасында басма китап чыгару эшенә иң әүвәл безнең татарлар керешә. Әлбәттә, татарларга бу эштә патша хакимияте дә күпмедер этәргеч биргән диярлек. Дөресрәге, ул хакимият Казан каласының Россия империясендәге дәрәҗәсен танырга мәҗбүр булып, 1804 елда анда университет оештыру карарын чыгарган. Һәм шуңа бәйле рәвештә монда Россия биләмәсендәге иң тәүге «азиатский басмаханә» дә ачылган. Икенче-өченче нәүбәттә китап басу эшенә керешүчеләр азәрбайҗаннар («Кавказ татарлары») белән үзбәк кардәшләребез булган. Ташкентта төрки телдәге беренче басма хәрефле газета 1870 елда дөнья күрә. Аны оештырып чыгаручы милләттәшебез — Оренбург төбәге морзаларыннан булган Шаһимәрдән Ибраһимов. Шунда ук аның фарсы теленнән тәрҗемәдә «Мең дә бер кичә» әсәре дә, атлы казаклар тарихын чагылдырган үз китаплары да, үзбәк телендә еллык календарьлар да нәшер ителә. Бакуда да милли телдә газета һәм китап басу эшенә шул ук XIX гасырның җитмешенче елларында керешәләр.

XX гасыр башында татар телендә китап нәшер итүче басмаханәләр һәм аерым нәшриятлар Россиядәге күпчелек губерна башкалаларында эшләп килә. Совет хакимиятенең беренче көннәреннән үк мондый таркаулыкка чик куярга теләк белдерелә. РКП(б) Үзәк комитеты 1918 елда ук барлык шәхси басмаханәләрне берләштерү, үзәкләштерү буенча беренче талпынышын ясый. Әйтик, шул ук елның февралендә Оренбургта Рәмиев һәм Хөсәенев байларның басмаханәләре хуҗаларыннан тартып алына, башка басмаханәләр белән берләштерелә. Ә инде бердәм Дәүләт нәшриятларын булдыру турындагы катгый карар 1919 елның июлендә чыгарыла. Утызынчы еллардагы үзгәрешләргә чаклы дәүләт нәшрияты рәвешендә оештырылган ул идарәгә шул төбәктәге барлык басмаханәләр дә буйсындырыла, китап сәүдәсен оештыру бурычлары да аңа йөкләнә. Газета-журналлар да шул нәшрият карамагында дөнья күрә. Мәсәлән, «Казан утлары»ның элгәреләре дә, башка барлык журналлар да 1958 елга чаклы Татарстан китап нәшрияты канаты астында яшәп килә. Ул мәҗмугаларның баш мөхәррирләре дә, Татарстан Язучылар берлеге белән киңәшеп, нәшрият җитәкчелеге карары белән билгеләнә.

Егерменче еллар урталарына чаклы РСФСР дәүләт нәшриятының Казан губернасы бүлегенә чуаш, мари телләрендә матбугат нәшер итүче бүлекчәләр дә беркетелгән була. Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы оештырылганнан соң, 1920 елның ноябреннән, Казан губернасы бүлеге Татарстан дәүләт нәшрияты (Татгосиздат) итеп үзгәртелә. Хуҗалык, исәп-хисап эшләре буенча ул Татарстан совнархозына буйсындырыла. Ә нинди китаплар нәшер итүне планлаштыру, нинди газета-журналлар чыгаруны билгеләү бурычы Халык мәгарифе комиссариаты һәм аңа буйсынган Гыйльми үзәк карамагына калдырыла. Һәм шушы тәртип 1945 елга кадәр саклана диярлек. Дөрес, китап сатуны оештыру йөген 1936 елда ук махсус карар белән сәүдә оешмаларына тапшырган булалар. Ә 1945 елда элеккеге Татгосиздат җирлегендә Нәшрият һәм полиграфия сәнәгате идарәсе оештырыла. Шул рәвешле басмаханәләр дә нәшрияттан аерыла. 1949 елда шушы идарәгә китап сәүдәсе оешмасы (Таткниготорг) да килеп кушыла. Матбугат һәм полиграфия сәнәгате идарәсе баштарак турыдан-туры Министлар Советына буйсындырылган булса, 1953-1963 елларда исә Мәгариф министрлыгы карамагында да эшләп ала. Ә 1991-2001 еллар аралыгында бу идарә мөстәкыйль министрлык буларак яшәде. Китап нәшрияты белән турыдан-туры җитәкчелек иткән әлеге министрлыкның татар матбугаты язмышы хәл ителгән авыр еллардагы соңгы министрлары − күпләребезгә таныш, абруйлы шәхесләр Ислам Әхмәтҗанов белән Шамил Хамматовлар булды.

Казан губернасы карамагындагы тәүге Дәүләт нәшрияты бүлеге җитәкчеләре башка милләт вәкилләре булган. Хәер, үзебезнең милли шәхесләребез дә бу эштән

читтә тормаган. Мәгълүм ки, бу елларда Галимҗан Ибраһимов Россия мөселманнары эчке эшләре комиссариатында да, РКП(б) Үзәк комитеты каршындагы Шәрык халыклары оешмаларының Үзәк бюросында да матбугат эшләре өчен җаваплы булган. Димәк, Дәүләт нәшриятының Казан бүлеген оештыру эшләрендә ул турыдантуры катнашкан. 1920 елдан башлап Таттосиздат Халык мәгарифе комиссариаты белән бергә кулгакул тотынышып эшли. Ул



*Редакция советы утырышы, 2001 ел.*

еллардагы Халык мәгарифе комиссарлары Шәһит Әхмәдиев белән Исхак Рәхмәтуллин — Галимҗан Ибраһимовның иң якын фикердәшләре. Өстәвенә Г.Ибраһимов үзе дә нәкъ шул чорда шушы комиссариат карамагындагы Гыйльми үзәкне җитәкләгән иң. Ә ана чаклы бу Гыйльми үзәкнең җитәкчесе булып Төркия белән Бельгия югары уку йортларында да белем алган Гаяз Максуди эшләгән. Ул да, мөгаен, милли матбугатның һәм милли китап бастырып чыгаруның алга китүе өчен тырышкандыр. Китап нәшрияты елъязмасының 1920-1930 елларга караган өлешендә Галимҗан Ибраһимов, Исхак Рәхмәтуллин, Галимҗан Нигъмәти, Гомәр Гали исемнәре баш редактор буларак та теркәлгән. Мөгаен, бу очракта кайберәүләренең «Безнең юл», «Мәгариф», «Атака» кебек журналларның баш мөхәррире булып эшләве дә искә алынгандыр. Г.Галинең исә утызынчы еллар дәвамында (1937 дә кулга алына) китап нәшриятында даими эшләве һәм баш мөхәррир вазифасын үтәгәнлеге турында өстәмә мәгълүматлар да бар.

Ә 1922 елдан башлап татар мәдәнияте үсеше өчен бик кадерле булган ул Таттосиздат (соңрак, 1940 елларда Татиздат рәвешендә дә теркәлгән) идарәсе белән фәкать үз кешеләребез җитәкчелек иткән. Шул елда ул җитди вазифаны үтәү бурычы элекке полиграфист, яшь коммунист Нурис Мохтаровка йөкләнә. Нуристан соң Татарстан дәүләт нәшриятын (бу оешмага буйсынган басмаханәләр, басылып чыккан китапларны барлап барырга тиешле Китап палатасы һ.б.) җитәкләгән «управляющийлар» исемлегендә Вәли Шәфигуллин, Самат Шәрәфетдинов, Закир Тинчурин (ун елдан артыграк эшли), сугышта һәлак булган Шакир Арсланов, әдәбият галиме, булачак профессор Мөхәммәт Гайнуллинны да атап китәргә кирәктер. Башка иярчен оешмалардан арынып, фәкать кульязмаларны китап рәвешенә китерүче саф нәшрият вазифасын үтәүче Татарстан китап нәшрияты директорларын да санап үтик: Салих Вәлиди (1957-1963, шуннан соң ул китап сәүдәсе оешмасы директоры итеп билгеләнә), Гыймади Камалиев (1963-1973), Гарәф Шәрәфетдинов (1973-1987), Ринат Мөхәммәдиев (1987-1989), Харис Әшрәфҗанов (1989-1998 ).

Вәли Шәфигуллин белән Самат Шәрәфетдинов исемнәре Бауман урамындагы үзенчәлекле Матбугат йортын һәм шуңа өстәп салынган полиграфия комбинатын төзүне (1933-1935) оештыручылар буларак тарихка кереп калды. Камил Якуб исемен йөрткән полиграфия комбинаты, җитмеш еллар чамасы көне-төне эшләү дәверендә, меңнәрчә исемдә, дисталәгән миллион данәдә татар һәм рус телләрендә китаплар бастырып чыгарды. Хәер, ул комбинат цехларында, татар һәм рус телләрендә басылган китаплардан тыш, башка тугандаш республикалар телендә дә миллионлаган данәдә затлы-затлы китаплар нәшер ителгән. Байтак еллар минем китап киштәсендә казакъ әдәбияты классигы Сәкен Сәйфуллинның шул комбинат тамгасы белән 1935 елда чыгарылган затлы, калын «Тар жол, тайгак кичү» романы торды. Әйе, ул комбинатта байтак еллар дәвамында казакъ, каракалпак, төрекмән телләрендә дә китаплар, дәреслекләр басылган. Хәтеремдә әле,

1970-1980 елларда Төрекмәнстан, Каракалпакстан республикаларыннан китап чыгару мәшәкәте белән килеп йөрүче канкардәшләребез, кунакханәгә урнаштыруны үтенеп, ул вакытта Матбугат йорты бинасында булган Татарстан Язучылар берлегенә мөрәҗәгать итәләр иде. Ә бер таныш төрекмән язучысының үз китабын чыгаруны тизләтергә ярдәм итүемне үтенеп язган ике-өч хаты бүген дә миндә саклана.

1972 елның урталарына кадәр Матбугат йорты дигән мәһабәт бинада Татарстанда чыккан барлык газета-журнал редакцияләре эшләде. Алар аерылып чыккач та анда Татарстан китап нәшрияты коллективы, полиграфия комбинаты идарәсе, китап сәүдәсе оешмасы, Китап палатасы, чыгасы китапларның сәяси эчтәлеген тикшереп торучы цензура идарәсе, Татарстан Язучылар берлеге һ.б. бик күп оешмалар, шул исәптән 1945 елда барлыкка китерелгән Матбугат һәм полиграфия сәнәгате идарәсе дә XXI гасыр башларынача «яшәде» әле. Ә бинаның бишенче катында урнашкан Тукай исемен йөртүче клубта исә һәр атнаның җомгасында диярлек кызыклы-кызыклы әдәби-мәдәни очрашулар, ә атна дәвамында исә төрле-төрле җыелышлар үткәрелеп торыр иде. Архитектура һәйкәле буларак танылган ул бина диварына күптән инде архитектор С.С.Пен исеме белән янәшә Татиздат идарәсенең 1930 еллар башындагы идарәчесе С.Шәрәфетдинов һәм ул бина белән полиграфия комбинаты аякка бастырылган чорда партиянең Татарстан өлкә комитеты вәкиле буларак төзелешкә җитәкчелек иткән В. Шәфигуллин исемнәрен мәңгеләштерү максатында истәлек тактасы куелырга тиеш иде дип уйлыйм.

* * *

Бөек Ватан сугышына чаклы татарча вакытлы матбугат һәм татар китаплары РСФСРның кайбер башка өлкәләрендә эшләүче Дәүләт нәшриятлары тарафыннан да нәшер ителгән. Мәсәлән, Куйбышев, Оренбург, Свердловск, Чиләбе өлкәләрендә, Себер тарафларында аерым әдәби яисә иҗтимагый-сәяси эчтәлекле китапларның басылган булуы Татарстан китап палатасы хезмәтләрендә теркәлгән. Мәгълүм ки, байтак кына күренекле шәхесләребез иң әүвәл шул төбәкләрдә нәшер ителүче газета-журналларда каләм чарлаганнар. Шуннан соң гына Татарстан китап нәшрияты белән хезмәттәшлекләрен дәвам иттергәннәр. «Социалистик Татарстан» газетасының баш мөхәррире һәм берничә китап авторы Шәмси Хамматов — Свердловск өлкәсендә вакытлы матбугатта, ә әдәбият галиме Хәсән Хәйри — Себер төбәгендәге өлкәара «Азат Себер» газетасында, Шакир Абилов исә Оренбургта (ул чорда шәһәр Чкалов исемен йөртә) татарча нәшер ителүче «Коммунист» газетасында көч сынаганнан соң Казанга килгәннәр. Андый шәхесләребезнең исемлеге болар белән генә чикләнми. Әйтик, балалар әдәбиятын үстерүгә үз өлешләрен керткән Абдулла Әхмәт, Идрис Туктар һ.б. да бар әле. Ләкин утызынчы еллар ахырына табарак Татарстаннан читтә эшләп килүче, татарча китаплар чыгаручы нәшриятлар ябыла.

1930нчы елларда китап нәшриятында күренекле әдипләрнең сайланма әсәрләрен һәм күп томлыкларын чыгару омтылышлары да ясала. Татар телендә язылган әсәрләрне даими рәвештә русчага тәрҗемәдә нәшер итә башлау да шушы елларга туры килә. Мәсәлән, 1936 елда, шагыйрьнең тууына илле ел тулуга нисбәтле рәвештә, Г.Тукайның зәвыклы итеп эшләнгән «Избранные стихи» китабы дөнья күрә. Ана чаклы язучы һәм мөхәррир Фатих Сәйфи-Казанлы тырышлыгы белән аның әсәрләренең татарча өч томлыгы басылып чыккан була (1929-1931). Галимҗан Ибраһимовның алдан планлаштырылган җиде томлыгыннан өч томы шулай ук утызынчы еллар башында нәшер ителгән. Шул елларда нәшриятта өлкән мөхәррир вазифаларын үтәгән Афзал ага Шамов сүзләренә караганда, әдипнең тагын өч томы корректурасы вариантларының бер өлеше, автор тарафынннан кабат тикшерелеп, Кырымнан Казанга кайтарылган була. Г.Ибраһимовның шул көздә кулга алынуы сәбәпле, ул томнар нәшер ителмичә кала һәм юкка чыгарыла.

Бу чорда Татарстан китап нәшриятында без күренекле әдипләребездән тагын Фатих Кәрим, Нур Баян, Гомәр Бәширов, Ибраһим Гази, Госман Бакиров (балалар әдәбияты бүлеге мөдире), Гасыйм Лотфи (татар телендә чыгучы дәреслекләр өчен җаваплы мөхәррир була, соныннан байтак еллар дәвамында Мәгариф министрлыгында эшли), Гази Кашшаф, Әнәс Камал, Кәшфи Басыйров (матур әдәбият үрнәкләрен,

шул исәптән М.Лермонтовның «Безнең заман герое»н татар теленә тәрҗемә иткән автор, сугышта һәлак була), Фәтхи Бурнашларны очрата алган булыр идек. Афзал ага хәтерләвенчә, Матбугат йортының дүртенче катындагы 84 нче бүлмәдә алар дүртәү утырганнар: Ф.Бурнаш, И.Гази һәм тагын кемдер. Афзал аганың сөйләгәннәре әле дә хәтердә: «Фәтхи син утырган өстәл артында, ишектән кергәч тә ун тарафта утыра иде. (Әйе, 1980 елларда без дә дүртәү: Максим Глухов, Юныс Әминев, Альберт Тәхәвиев һәм мин шул бүлмәдә утырып эшләдек.). Фәтхине кулга алгач та, аның өстәл тартмасындагы, китап шкафындагы барлык кәгазьләрне җентекләп карап, язып чыктылар да, Гази белән икебездән кул куйдырдылар... Ул елларда нәшриятта андый хәлләр еш кабатланды. Фатих Кәримне дә безнең алда кулга алдылар. Аларны гаепләтергә теләп, безне төрмәләргә дә күп мәртәбәләр йөрттеләр. Милләт, милли тел яшәсен өчен эшләүче оешма вәкилләре булганлыктан, ул чакта без барыбыз да яшерен күзәтү астында тордык. Һәрберебезнең көнелендә «кайчан кулга алырлар икән» дигән курку хисе яшеренгән иде». Әйе, А.Шамов ул елларда «кулак малае» һәм Мәскәүдә университет тәмамлап кайткан кеше буларак аерым шик астында тора, әлбәттә. Шул елларга кагылышлы КГБ архивы документлары белән таныш булган Рафаэль Мостафин хезмәтләрендә язылганнарга караганда, А.Шамов, кайберәүләрдән аермалы буларак, каләмдәшләре язмышына бәйле эшләрдә шаһитлек итәргә туры килгәндә дә бик сак булган, аларны гаепләү юлына басмаган икән...

Әйе, замана чиренә бәйле рәвештә кадрлар еш алышынып торуга карамастан, Татарстан китап нәшрияты утызынчы еллар дәверен дә уңышлы ерып чыга алган. Матур әдәбиятны нәшер итү белән бергә СССР буйлап сибелгән татар мәктәпләре өчен дәреслекләрне җитәрлек күләмдә бастырып чыгарганнар. Нәкъ шул елларда рус һәм башка милләтләр әдәбиятлары үрнәкләрен даими рәвештә татарча тәрҗемә итеп бастыру тәртибе дә урнаштырыла. Үзара бәйләнешкә кереп, үз әдипләребезнең китапларын кайбер кардәш республикалар нәшриятларына да тәкъдим иткалиләр.

Бу елларда киң тармаклы нәшрият һәм китап басу, тарату эшенә җаваплы кешеләрнең дә исемнәрен атап үтәргә кирәктер. Алда телгә алынган Самат Шәрәфетдиновтан соң абруйлы җитәкче буларак Закир Тинчурин таныла. Бер истәлек язмасында Гомәр ага Бәширов аның турында мондый сүзләр китерә: «Акыллы, тәҗрибәле кеше. Кешене аңлый торган зат». Әйе, ул чордагы нәшрият идарәсе башлыгын әдип яхшы белә, чөнки сугыш алды елларында ул, «Совет әдәбияты» мәҗмугасының җаваплы сәркәтибе буларак та, матур әдәбият редакциясе мөхәррире вазифасын үтәгәндә дә аның белән көн саен диярлек аралашып торган.

Сугыштан соңгы елларда, Казан педагогия институтын җитәкләгән дәверДә дә Закир Тинчурин Татарстан китап нәшрияты белән тыгыз элемтәдә булган. Институтта белем алган шәкертләреннән иҗат эшенә сәләтлерәкләрен башта нәшриятта практика үтәргә кодалый, соңрак шунда эшкә билгели. Илленче еллар башында шул рәвешле нәшрият мөхәррире булып китүчеләрдән Әнисә Ибраһимова, Рәис Даутов, Таһир Нурмөхәммәтовларны беләм. Ул исемлектә әле мин аралашмаган тагын кемнәрдер бардыр. Боларның өчесе дә — соңрак язучы буларак та танылган шәхесләр. Дөрес, Әнисә ханым, күпчелек язучылар тарафыннан да яратып кабул ителгән «Томан таралганда» повестен китап итеп бастырып чыгарганнан соң (1967), никтер тукталып калды. Язучылар берлегенә дә кабул ителмәде. Нәшриятта эшләгән елларда ул табигать фәннәреннән рус телендә басылучы дәреслекләрне оста тәрҗемә итүче буларак та танылган иде шикелле. (Дөрес, нәшриятта мина аның белән бер чорда эшләргә туры килмәде.)

* * *

Ниһаять, күпләребезгә танышрак заманга, сугыштан соңгы дәвергә дә якынлаштык шикелле. Кайчандыр үзем язган «Мылтык һәм каләм берлеге» мәкаләсендә бәян ителгәнчә, ул чордагы күп профильле Татарстан китап нәшриятының фәкать китап редакцияләү һәм басмаханәгә әзерләү бүлегеннән генә дә Бөек Ватан сугышына утызлап ир-ат һәм берничә хатын-кыз мобилизацияләнә. Шулардан күпләребезгә мәгълүм исемнәрне генә санап үтик: полк комиссары, Берлин тирәләрендәге сугышта һәлак булган Нур Баян, алдарак искә алынган Кәшфи Басыйров, 1942 елда үзе теләп фронтка киткән миномет взводы командиры Госман Бакиров, сугышка

китү теләгән белдергәч төрмәдән азат ителгән пехота взводы командиры Фатих Кәрим (хәзерге Калининград шәһәре тирәсендәге сугышта һәлак була), пехота взводы командиры Сибгат Хәким, тупчы Мөхәммәт Садри, 1942 елдан үз теләкләре белән яу кырына китеп, татарча чыга башлаган фронт газеталарына билгеләнгән һәм дошманны җинеп кайткан капитан Ибраһим Гази белән капитан Афзал Шамовлар. 1941-1942 елларның зәмһәрир кышында Апас белән Тәтеш араларында тун җирне чокып окоп һәм дзот базлары казырга мобилизацияләнгән 4-5 хатын-кызны да сугышта катнашучылар исемлегендә санарга хаклыбыз.

Сугыш чорында Казанда калган хатын-кызлар да чыдам, көчле рухлы була, ачлы-туклы яшәп, суык бүлмәләрдә авыр шартларда китап һәм газета-журналлар чыгара. Сугыш елларындагы мәктәп укучысы буларак шуны әйтә алам — безнең Казакъстанга чиктәш авыл мәктәбе китапханәсенә Казаннан дәреслекләр дә, әдәби әсәрләр тупланган китаплар да өзлексез диярлек килеп торды. Шул елларда нәшер ителгән китаплардан Һ.Такташның «Караборынның дусты»н, Г.Әпсәләмовның «Төньяк балкышы»н күмәкләшеп укуыбыз хәтеремдә әле. Илнең башкаласында һәм күпчелек өлкәләрдә байтак кына газета-журналлар нәшер ителми торган елларда да Казандагы төп газеталар һәм «Совет әдәбияты» журналы чыгудан туктамаган. Шунысы да гыйбрәтле, сугышка чаклы яисә сугыш чорында эшли башлаган, авыр еллар чыныгуын узган күпчелек хатын-кызлар, китап нәшрияты коллективының төп кадрлары буларак, монда утызар-утызбишәр ел эшләде. Пенсия яшенә җиткәч тә мөхәррирлек, корректорлык вазифаларын калдырып китәргә ашыкмыйча, яшь кадрларга үрнәк буларак эшләде алар. Китап нәшриятында утыз ел дәвамында корректор да, мөхәррир дә, дәреслекләр нәшер итүче бүлек мөдире дә булган Фирдәвес Болгарская «Тылсымлы йорт» дип исемләнгән бер мәкаләсендә нәшриятта эшләү елларын искә алып мондый сүзләр яза: «Бу йортның үзенә тартып торган тылсымлы көче, килеп кергән кешене, үзенең эшенә тартып алып, бөтен күңелен, белем һәм мәхәббәтен биреп эшләргә мәҗбүр итү үзенчәлеге югалмады. Югыйсә хезмәт хакы шактый түбән иде, ә эше гаҗәеп катлаулы, четерекле, вак һәм җаваплы булды.»

Әйе, нәшриятка эшкә урнашкан кешеләрнең күпчелеге бердәм, үзара бик тату коллективта, китап бастырып чыгару эшенең халкыбызның киләчәк язмышына бәйле булганлыгын тоеп, дистә еллар дәвамында үз вазифаларын үтәүне дәвам иттерә. Дөрес, шунда эшли-эшли тәҗрибә туплаган, каләм шомарткан корректор вә мөхәррирләрне нәшрият башлыклары да үз вакытында күргән — аларны өстәмә түләүле тәрҗемә эшләре белән дә тәэмин итәргә тырышкан. Рус яисә башка телләрдән тәрҗемә итеп чыгарылган дистәләрчә әдәби әсәрнең яисә йөзләгән уку әсбапларының шушы нәшриятта күңелен, җанын биреп эшләгән сүз осталарының хезмәт җимеше булуын танырга тиешбез.

Сугыш тәмамлангач, нәшрият тормышы янадан җанланып китә. Бу дәвердә нәшриятта яңадан эшли башлаган язучыларны искә алып үтик. Госман Бакиров, Ибраһим Гази, Абдулла Әхмәт, Сибгат Хәким (икесе дә сугышка чаклы ук «Совет әдәбияты» журналы хезмәткәре булган), Сәхаб Урайский, Афзал Шамов элекке эш урыннарына кайтып утыралар. Бераз соңрак алар төркеменә янарак кына хәрби киемнәрен салып куйган Зәки Нури, Хисам Камалов, Салих Хәким, Ислам Беляев, Сафа Сабиров һ.б. кушыла.

Илленче еллар башында Казан дәүләт университетының янарак ачылган татар теле һәм әдәбияты бүлегенең беренче һәм икенче чыгарылыш студентларыннан да ишле бер төркем нәшриятка эшкә билгеләнә. Университет юлламасы белән эшкә килгән һәм гомерләрен китап нәшер итүгә багышлаганнар арасыннан Резедә Хәлиуллина-Вәлиева, Кыям Миңлебаев, Яхья Халитов, Мәхмүт Хөсәен, Фәния Гайнанова, Сания Сибгатуллина кебек фидакярь затларны атап үтәргә кирәктер. Булачак халык язучылары Гариф Ахунов белән Нурихан Фәттах та, элекке курсташларыннан калышмаска теләгәндәй, вакыт-вакыт нәшрият штатында теркәлеп, эшләп алгалаганнар.

* * *

Хуҗалык тармагында сугыштан соңгы авыр еллар дәвам итүгә, китап басарга кирәкле булган кәгазьнең тиешле күләмдә чыгарылмавына карамастан, илленче елларны китап нәшриятының чәчәк аткан дәвере дип санарга хаклыбыз. Бу чорда элек хаксыз рәвештә хөкем ителгән, әсәрләрен нәшер итү тыелган бөек каләм

ияләрен аклау хәрәкәте башлана. Китап нәшриятында бер-бер артлы Галимҗан Ибраһимов әсәрләренең өч томлыгы, Фатих Сәйфи-Казанлы әсәрләре, Хәсән Туфан шигырьләре, Фәтхи Бурнаш, Кәрим Тинчурин пьесалары тупланган җыентыклар басылып чыга. Бөек Ватан сугышы барышында әсирлеккә эләгеп, шунда җәзалап үтерелүгә карамастан, «хыянәтчеләр» тамгасы тагылу сәбәпле, иҗатлары тыелган шәхесләрдән Муса Җәлил, Абдулла Алиш әсәрләрен кабат нәшер итәргә рөхсәт бирелгән чор да бит бу. Шушы елларда аларның үз әдәби әсәрләре дә, алар батырлыгына багышланган документаль хезмәтләр белән беррәттән аерым әдәби әсәрләр дә дөнья күрә. Шундый әсәрләр рәтендә, мәсәлән, күренекле казакъ шагыйре Җобан Молдагалиевнең Муса Җәлил һәм җәлилчеләр батырлыган данлаган мәшһүр «Үлемсез җыр» поэмасын да искә төшерү урынлы булыр.

Бу үзенчәлекле күчеш дәверендә нәшрият коллективын ике шәхес – Газиз Нәбиев (1953-1957) белән Салих Вәлиди (1957-1963) җитәкләгән. Баш мөхәррир вазифасын Хәмит Мөҗәһитов башкарган (1956-1963). Шунысын да билгеләп үтәргә кирәктер, Татарстан китап нәшрияты оешкан көненнән башлап татар китапларын нәшер итү белән генә шөгыльләнмәде. Үз ана телебездә басылган китаплар саны байтак еллар дәвамында 40-50 проценттан артмагандыр.

Безнең бабайларның табигать торышына карата еш кабатлап әйтә торган бер әйтеме бар: «Илгә уныш китерә торган явым-төшемле еллардан соң корылык килүчән». Бу гыйбарә нәшриятыбыз эшенә карата да туры килә диярлек. 1950 еллар ахырында Н.С.Хрущев һәм аның тирәсендәге «кара кардиналлар» татар һәм башка кайбер милләтләрнең мәгарифе тамырына үткен кылычлары белән кизәнделәр. Март аенда булса кирәк, үзәк газеталарда басылып чыккан бер карарда «милли республикалардан читтә урнашкан милли мәктәпләр язмышын ата-аналар хәл итә», дигәнрәк сүзләр язылган иде. Ягъни милли мәктәпләрне ябу кирәклеге турында без турыдан-туры әмер бирмәдек төслерәк шома сүзләр китерелгән иде анда. Шул елларда мин әле Оренбург өлкәсендә эшли идем. Карар чыккан көздә үк күпчелек район мәгариф идарәләрендә милли мәктәпләр белән эш итүче инспекторларның эштән азат ителүен, авылларда татар мәктәпләренең бер-бер артлы ябыла башлавын хәтерлим. Ике-өч елдан соң өлкә күләмендә эшләп килүче ике милли педучилище ябылды. 60нчы еллар башында Оренбург һәм Орск педагогия институтларындагы татар-башкорт факультетлары бетерелде. Чөнки татар телен белүче, барлык фәннәрдән үз телебездә дәрес бирерлек укытучыларның кирәге калмаган иде.

Әлбәттә, ул карар тиздән Татарстан китап нәшрияты эшчәнлегенә дә «китереп суга». Татарча дәреслекләр, уку әсбаплары чыгару өчен төрле өлкәләрдән килә торган заказлар туктала . «Әлифба»лар, «Татар теле», «Татар әдәбияты», татар телендә чыгып килүче башка күп санлы дәреслекләрнең тиражлары кими башлый. Бераз соңрак нәшрият директоры булып эшләгән Гарәф Шәрәфетдинов бер мәкаләсендә, алтмышынчы еллар вакыйгаларын истә тотып, «Әлифба» дәреслекләрен нәшер итү планы икеләтә диярлек кимеде», дип яза.

Әмма бу карарның шаукымы әле ул елларда әдәби һәм җәмгыяви-сәяси китапларны бастырып чыгару тармагына зур зыян салмады. Киресенчә, Мәскәү тарафыннан ел саен бүлеп бирелә торган кәгазь фондының дәреслекләр чыгарудан янга калган өлеше күпмедер дәрәҗәдә әдәби, иҗтимагый-сәяси һәм күпмедер күләмдә тарихи-фәнни китапларның артыграк санда нәшер ителүенә китерде кебек. Элекке татар мәктәпләрен тәмамлаучылар саны да әле җитәрлек күләмдә, татар китабын укучылар бөтен ил буйлап таралган чак иде. Китап сату оешмаларыннан заказлар күп килә. Шуңа күрә проза китапларының тиражы унбиш-егерме меңнән дә ким чыкмый иде. 1970-1980 еллар аралыгында нәшрият турәләре «хәзер без һәр эш көнендә бер китап чыгарабыз», дип мактангалап та куйгалаган чор булды ул.

Бу елларда Татарстан китап нәшриятын кемнәр җитәкләде, кемнәр ана юнәлеш биреп торды соң? Шушы яңа чорга кергәндәге беренче директор Гыймади Камалиев булды (1963-1973). Мона кадәр ул берничә ел «Социалистик Татарстан» газетасында эшләгән, өч ел чамасы редактор Шәмси Хамматовның урынбасары вазифасын үтәгән кеше иде. Ләкин нәшрият эшен эчтән белгән күпчелек, шул исәптән югары оешма түрәләре дә аның эшчәнлегеннән тулаем канәгать булмадылар кебек. Татарча китапларның гомуми саны



*Ветераннар белән төшкән фоторәсем, 2004 ел. Күмәк фото.*
*Уртада утыралар: Д.Шакиров, Г.Шәрәфетдинов.*

елдан-ел артуга карамастан, һәр ел аша диярлек нәшрият үз чыгымнарын каплап, даими рәвештә табыш китерүгә ирешә алмады шикелле. Бу хәлне анын Мәскәүдәге житәкче оешмалар белән ныклы элемтәгә керә алмавыннан килә, дип юраучылар да булды бугай. Һәрхәлдә, «ул нәшрият эшен рентабельле итә алмады» дип, 1973 елның урталарында анын урынына Шәмси аганың икенче урынбасарын — Гарәф Шәрәфетдиновны билгеләделәр. «Университетта татар бүлеген тәмамлаган, колхоз рәисе дә булган, нәшрият икътисадын ул тиешле дәрәҗәгә күтәрә алыр», дигән өмет белән каршы алды аны татар зыялылары. Бу өметне ул асылда аклады. Г.Шәрәфетдинов эшли башлагач та нәшрият үз чыгымнарын үзе исәбенә каплый алу мөмкинлегенә ирешә. Г.Камалиев, гомеренең байтак өлешен дәүләт һәм партия эшлеклеләре урындагы китапларны тәрҗемә итүгә багышлаганлыктан, китап нәшриятында эшләү дәверендә дә шул юнәлешкә өстенлек бирергә тырышты, ахрысы. Ә татар халкынын үткән дәверләренә багышланган иске китапларны чыгаруга әзрәк әһәмият бирде бугай. Гарәф Шәрәфетдинов исә эшли башлаган көннәреннән үк татар галимнәре, тарихчылары белән дә уртак тел тапты. Озакламыйча китап кишгәләрендә XII гасыр шагыйре Кол Галинең «Кыйсссаи Йосыф» китабы, бөек шәхесләребез Шиһабетдин Мәрҗанига, Ризаэддин Фәхреддингә һ.б. багышланган хезмәтләр, булачак академик Әбрар Каримуллинның милли китап тарихына караган яна хезмәтләре урын алды. Өч томнан торган «Герои Советского Союза — наши земляки» китабы да көтеп алынган басма иде.

Гарәф Шәрәфетдиновның «Чорлар алышынганда» язмасының кайбер җөмләләренә игътибар итеп үтик. «Нәшрият директоры булырга ризалык биргәч, әүвәл республиканың иң олы оешмаларында вазифамның ни хәтле җаваплы буласын тукый-тукый аңлаттылар. Шуннан соң мине Мәскәүгә чакырып алдылар. Анда РСФСРның Матбугат комитетында булдым. Сонрак ул Госкомиздат дип үзгәртелде. Татарстан китап нәшриятына мине директор итеп Мәскәүнең шушы комитеты расларга тиеш икән... Комитет җитәкчеләренең үгет-нәсихәтләре Татарстанда нинди китаплар чыгарырга кирәклеген, нинди ләрен чыгарырга ярамаганлыгын аңлату иде... Баксаң, безнең нәшрият Росглавиздат белән килештермичә бер китап та чыгара алмый икән.» Әйе, Совет хакимияте дәверендә менә шундый шартларда эшли милли нәшриятлар. Чыгарыласы китап санын да, анын исемлеген дә, шул исемлеккә кергән китаплар тиражын билгеләү өчен җитәрлек күләмдәге кәгазь фондын да ул елларда бары тик Мәскәү хәл итә торган иде. Урында эшләүче җитәкченең Мәскәү түрәләре белән элемтәсе ни дәрәҗәдә нык булса — эш нәтиҗәсе дә шундый. Бу кагыйдәне кайчандыр үзем дә, СССР Литфонды бүлеге директоры булган елларда ярыйсы ук үзләштергән шикелле идем.

Гарәф Шәрәфетдинов жирле һәм Мәскәү түрәләре белән уртак тел таба белүче директорларның берсе булды. Китап нәшрияты директоры вазифасын ул 14 ел дәвамында башкарды. Ул эшләгән 1973-1987 елларда классик әдипләребездән Галимжан Ибраһимовның 8 томлык сайланма әсәрләре, Габдулла Тукайның 5 томлыгы, Мәжит Гафуриның 4 томлыгы, Һади Такташ әсәрләренең 3 томлыгы, Хәсән Туфан белән Сибгат Хәкимнең 2шәр томлыклары, Дәрдемәнд, Сагыйть Рәмиев, Нәҗип Думави, Галәл Кутуй, Гомәр Бәширов, Әхмәт Ерикәй, Гариф Ахунов һ.б. сайланма бер томлыклары һәм аерым әсәрләре басылды. Үзенчәлекле тарихи әсәрләрдән Нурихан Фәттахның 2 томлык «Сызгыра торган уклар», Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Кубрат хан» романнары да шул чор җимеше. Шул ук елларда Галисгар Камал, Шәриф Камал, Тажи Гыйззәт, Фатих Кәрим, Кави Нәҗми, Нәки Исәнбәт һ.б. әсәрләренең күптомлыкларын Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре белән бергә туплап-барлап чыгару эшенә дә керештеләр. Әдәбият галиме Ибраһим Нуруллинның ике бөек шәхесебез тормышын һәм иҗади эшчәнлеген киң чагылдырган күләмле ике әдәби-биографик эчтәлекле китабы: «Габдулла Тукай» белән «Фатих Әмирхан» да Гарәф директор булган елларда нәшер ителделәр. Бу китапларның берсен һәм алда телгә алынган китапларның кайберләрен басмага әзерләү-редакцияләү эшендә мин дә катнашкан идем. Нәшрият белән унбиш еллап хезмәттәшлек итү дәверендә йөз иллеләп кече һәм зур күләмле китап редакцияләнгән.

Нәшрият директорлары булып эшләгән соңгы ике шәхес вакытында баш мөхәррир вазифасын өч кеше башкара: журналист һәм әдәби тәржемәче Хәбибулла Гобәйдуллин (1964 — 1972), язучылар Марс Шабаев (1972 — 1977) һәм Вакыйф Нуруллин (1977 — 1989 ел башы). Баш мөхәррирләрнең урынбасарлары булып та ике эшлекле зат: Нурулла Габитов белән язучы, партия өлкә комитетында кешеләр белән аралашу тәҗрибәсе туплап килгән Әнәс Хәсәнов эшләде. 140лап кешене берләштергән коллектив әгъзаларын тулаем санап чыгып булмастыр. Шулай да кайберәүләрне искә алмыйча да мөмкин түгел. Студент елларында ук сәяси эзәрлекләүләр, кимсетелүләр кичергән Аллер Тимергалинны Татарстан китап нәшрияты коллективы үз итеп, туган күреп кабул итә. Һәм монда егерме еллап артыграк эшләү дәверендә ул зур галим булып житлегә. Хәтеремдә әле, берәр төрле сорау туса, яшьрәк буын мөхәррирләрдән тыш кайбер олырак абзый-апайлар да энциклопедик белемле Аллерга мөрәҗәгать итәрләр иде. 1984 елда университетның татар бүлеген уңышлы тәмамлап килгән Дамир Шакиров та аны беренче остазы буларак таныды. Бу елларда матур әдәбият редакцияләре мөдирләре вазифасын күренекле язучылар Шәүкәт Галиев, Фәрваз Миннуллин, балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты редакциясен Шамил Рәкыйпов житәкләде. Ижтимагый-сәяси әдәбият редакциясе башлыклары вазифасын язучылар Илдар Низамов, аннан соң Вакыйф Нуриев башкарды. Фәнни-техник әдәбият, шул исәптән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр редакциясе башында байтак еллар дәвамында Ралинә Камалова — язучы Барлас Камаловның сеңлесе торды. Аның кул астында эшләүче Аллер Тимергалин, Рәфикъ Юнысов, Дамир Шакиров нәшриятның оста мөхәррирләре исәбендә йөрделәр. Авыл хуҗалыгы редакциясен Наил Мостаев житәкләде.

«Татарстан яшьләре» газетасының элекке мөхәррире Жәүдәт Кәлимуллин житәкләгән дәреслекләр редакциясендә дә бик тәжрибәле һәм абруйлы мөхәррирләр эшләде. Алар арасында оста тәржемәчеләр дә ишле генә иде. Шул исәптән татарча матур әдәбиятны рус җәмәгатьчелеге укырдай итеп башкаручы Азалия Бадюгина кебек белгечләр дә бар иде ул бүлектә.

Язмамның бу өлешен мәрхүм Гарәф Шәрәфетдиновның: «Яхшы кешеләр янәшәсендә эшләве үзе бер бәхет!» дигән тирән эчтәлекле җөмләсе белән тәмамлыйсым килә.

***

1970-1980 елларда республиканың кайсы гына районына, янсә күрше өлкаләрнең кайсысына гына барма, китап сөючеләр сатуда татарча китапларның аз булуыннан зарлана торган иде. Ә бит ул елларда балалар өчен китаплар утызар-кырыгар мең, проза әсәрләре кимендә ун-унбиш мең данәдән дә түбән тираж белән нәшер ителмәде. Нәшрият эшчәнлегенә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында татар телендәге дәреслекләр саны кимүгә карамастан, Г.Камалиев белән Г.Шәрәфетдинов житәкчелек

иткән чорны без татар китабы нәшер ителүнең алтын чоры дип танырга тиешбездер. Гәрчә Г.Камалиев директор вазифасын үтәгән ун елда нәшриятның икътисади хәле бик үк шәптән булмаса да, татар телендә чыгучы дәреслекләргә һәм китапларга булган заказлар, еллык китап нәшер итү планнары үз вакытында үтәлгән диярлек.

* * *

Сиксәненче еллар ахырына таба үз милли республикабызда да татар мәктәпләре саны кими. Элек-электән татар рухын саклап торган авылларыбыз саны да кими бара. Аларның бер өлеше Түбән Кама сусаклагычын төзү чорында юк ителә. Бер ишеләрен елдан-ел киңәя, зурая барган шәһәрләребез «йота». Ельцин-Гайдарларның «элекке крәстиян тормышын яңадан торгызырга» хыяллануы нәтиҗәсендә колхоз вә совхозлар бетерелгәч, авылларыбызны тагын да аянычрак язмыш көтмәгәе дип борчыла күңел.

Илдәге зур үзгәрешләр чорына якынлашкан вакытта нәшрият коллективы белән ике ел чамасы язучы Ринат Мөхәммәдиев житәкчелек итте. Минем фикерләвемчә, ул Гарәф Шәрәфетдинов сызган буразнаны дәвам иттерүче булды. Нәшрият тормышына зур үзгәрешләр кертергә өлгермичә калды. Олуг канәфидә озак утырмады, 1989 елның май аенда аны Язучылар берлеге рәисе итеп сайладылар. Дөрес, ул нәшрият кадрларын беркадәр яшәртүгә керешкән иде. Баш мөхәррир итеп тә «Казан утлары» журналында бергә эшләгән каләмдәшен, яшь язучы, өметле оештыручы буласы Мөдәррис Вәлиевне билгеләде. Баш мөхәррир урынбасары итеп шагыйрь һәм журналист Рәфикъ Юнысны куйды. Актив иҗат итә башлаган яшь язучылардан Галимҗан Гыйльманов белән Зиннур Хөсниярны эшкә алды. Киләчәктә аларны бүлек мөдирләре буларак үстерү нияте дә бар иде. Әмма Ринат, шул ниятләрен гамәлгә ашыра алмыйча, нәшрияттан китәргә тиеш булды. Тагын шунысы хәтердә калган, СССРның оста шахматчылары арасында янарак күренә башлаган милләттәшебез Гата Камский Казанга килгәч, Р.Мөхәммәдиев тырышлыгы нәтиҗәсендә китап нәшрияты кешеләре белән дә таныша алды. Егермеләп кеше катнашында директор кабинетында шахмат ярышлары да уздырылды. Билгеле инде, яшүсмер Гата безнең барыбызны да диярлек отты. Фәкать элекке Матбугат бинасында уздырылгалап килгән шахмат ярышларында һәрвакыт беренчеләр сафында йөргән өлкән мөхәррир Яхья Халитов белән генә алар уртак нәтиҗәгә килештеләр...

* * *

Татарстан китап нәшрияты тормышында иң-иң авыр еллар Харис Әшрәфҗанов идарә иткән чорга туры килә. Китап нәшрияты өчен ул чорны хәтта Бөек Ватан сугышы елларыннан да авыррак булгандыр дип бәялисе килә. Бу чорны зур бер илнең «күчәре ычкынган, олавы ауган» кебегрәк итеп күз алдына китерәсең. Кәгазь кытлыгын тәэмин итеп торучы үзәк белән ара өзелгән. Яңа китаплар җибәрүне таләп итеп торучы сәүдә оешмалары таркалган. Беркем бернәрсә өчен дә җавап бирми диярлек. Ирекле, мөстәкыйль республика булып калырга теләгән Татарстаныбызга кайбер төбәкләрдән товар урынына буш вагоннар җибәрелә башлаган еллар иде бу.

Әйе, 1989 елның июнендә директор кәнәфиенә яңа килеп утырган Харис Әшрәфҗановка бик авыр булды. Моңа чаклы ул хуҗалык эшләре белән шөгыльләнмәгән, үзбаш хуҗа булып тормаган иде. Университетны тәмамлагач укытучы, газета хезмәткәре, югарырак оешмалар тарафыннан финансланган редакциядә баш мөхәррир булган. Нәшриятка эшкә билгеләнер алдыннан дүрт ел чамасы партия өлкә комитетында инструктор иде. Холкы, сабырлыгы белән ул коллективка ошады. Ләкин СССР дип йөртелгән империянең кинәт кенә таркалуы, шуның нәтиҗәсендә ил күләмендә башланган хуҗасызлык аны мөшкел хәлдә калдырды. Өстәвенә элекке татар мәктәпләрендә укыган кешеләрнең соңгы утыз елда әкренләп юкка чыга баруы, китапларның елдан-ел тиражы кимү дә нәшриятның эшчәнлеген авырайтты. Мәскәү инде нәшрият белән араны өзгән, читтән кәгазь кайтарылмый башлаган иде. Шул рәвешле, 1980 еллар урталарында елына 330-340 исемдәге китап чыгарып килгән нәшрият тәмам төп башына утырды. Ел дәвамында йөздән дә ким исемдә китап нәшер итү белән чикләнгән чаклар да булды. Китапның таралу тиражы да ике-өч меннән артмый башлады. Боларны мин 1990 еллар башында нәшриятта эшләгән кеше буларак язам. Китап чыкмагач һәм сатылмагач, акча да килми. Татарстан

хөкүмәте дә ул елларда әле нәшриятка зурдан кубып булыша алмады. Китап сәүдәсе оешмалары да тәмам таркалган иде. Харис энебез бик зур авырлык белән 1998 ел чигенә килеп житә алды. Шул елда ул, авыр камытын үз иненнән шудырып, берничә ел элек кенә урынбасар булып эшли башлаган Дамир Шакиров җилкәсенә элеп китте. Х.Әшрәфжановның шундый шартларда сигез еллап эшли алуы — зур батырлык. Бу елларда баш мөхәррир вазифасын үтәүчеләр Мөдәррис Вәлиев (1989-1992), Фәрваз Миннуллин (1992-1994, шул елда вафат була) һәм Харрас Әюпов (1994-2007) иде.

* * *

Дамир Шакиров бу хужалыкны үз хезмәте белән үз-үзен тәэмин итеп яшәтердәй мөмкинлеге чикләнгән хәлдә кабул итә. Дөрес, берничә ел дәвамында директорның урынбасары булып тору ана үз-үзенә ышаныч көчен арттыра-арттыруын. Ләкин шуңа да карамастан эш башлап җибәрү ана да җиңел бирелми. Өстәвенә, китап нәшрияты белән бер җепкә бәйләнеп, алтмыш ел чамасы бергә эшләгән Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинатының да хәлләре елдан-ел хөртиләнә бара. Аның җиһазлары искергән, балалар өчен нәшер ителүче төсле басмаларны да, затлы коленкор тышлы китапларны да ул заман таләп иткән күләмдә җитештерә алмый. Шул ук вакытта әле ул комбинатны, аның коллективын яшәтергә дә кирәк. Башлыча газета-журналлар нәшер итү өчен дип 1970 еллар башында төзелгән, заманча җиһазландырылган элекке «обком басмаханәсе» белән нәшриятка тулы килешү төзергә исә хөкүмәт рөхсәт бирми — иске басмаханәнең язмышы хәл ителеп бетмәгән була.

Китап нәшриятында Дамир Шакировның эшчәнлеге болай да авыр чорның тагын да катлауланган дәверенә туры килә. Әмма әкренләп ул катлаулы мәсьәләләрнең берсе хәл ителә — без күнеккән Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинатын ябу турында карар чыгарыла. Хөкүмәт тә әкренләп көч туплап өлгерә, үз карамагындагы нәшриятны коткарыр өчен төрле-төрле юллар эзли. Нәшрият җитәкчелеге дә тик тормый. Шәһәр үзәгендә, Бауман урамында бер зур кибет подвалын арендага алып, анда нәшрият чыгарган китапларны сатуны оештыра. Сатып алучылар күнелен тартып торырдай итеп заманча җиһазландырылган, китапларның төрлесе, шул исәптән көн дә кирәкле дәреслекләр белән дә тәэмин ителгән ул китап кибетеннән хәзер халык өзелми. Тик әлегә ул кибетнең бердәнбер җитешсезлеге — тирән подвалда урнашкан булуы. Бер мәртәбә депутатлар алдында чыгыш ясаганда Туфан Миннуллин да: «Ул кибет бит кабердән дә тирәндәрәк урнашкан. Хөкүмәт белән шәһәр советы аңа башка урын табыша алмадылар микәнни?»- дигән иде.

Шул рәвешле, ана телебезнең язмышына да күпмедер дәрәҗәдә бәйле булган, яңа яшәү куәте өстәп торган милли нәшрият әкренләп XXI гасырга аяк баса. Әдәбият тармагында зур уңышларга ирешкән, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләренә ия булган, «Халык шагыйре» яисә «Халык язучысы» дигән дәрәҗәле исемнәрне яулап алган егермеләп әдипнең күптомлыкларын дәүләт ярдәме белән нәшер итү карарына киленә. 2000 елдан башлап шул карар гамәлгә дә ашырыла башлый. Бүгенге көндә күренекле әдипләребезнең ике томнан алып ун томга җиткән сайланма әсәрләре шәхси һәм дәүләт китапханәләре киштәләренә чыгарып тезелде. Шул исәптән бу чорда Туфан Миннуллинның — 10, Роберт Миннуллинның — 7, Рабит Батулла белән Фәнис Яруллинның — 8әр (5 һәм 3 томнар итеп икегә бүлеп чыгарыла), Ренат Харисның — 7, Равил Фәйзуллинның — 6, Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, Аяз Гыйлажев, Нурихан Фәттах, Мөхәммәт Мәһдиев, Әхсән Баян, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеевләрнең — 5әр томлыклары, башка кайберәүләрнең 2дән алып 4кәчә томда сайланма әсәрләре басылып чыкты. Олуг классик әдипләребезнең томлыклары да нәшер ителә: Гаяз Исхакыйның 15 томлыгы, Габдулла Тукайның аерым-аерым 2 һәм 1, Муса Җәлилнең 5, Әхмәт Фәйзинең 1 томлыгы. Шушы ук елларда Дәрдмәнднең ана телендәге һәм русчага тәрҗемә ителгән шигырьләрен бергә туплаган затлы китабы, аның тормышын һәм иҗатын чагылдырган күләмле фотоальбом да дөнья күрде.

Бу томнарга тупланган әләби әсәрләрнең күпчелеге халыбызның бүгенге милли рухи байлыгын чагылдырган әсәрләр. Аларга киләчәк буыннар да игътибар итәр, дистә еллардан соң да аларның кыйммәте югалмас дигән өметтә калам. Шуның өчен дәүләтебез башлыкларына да, нәшриятта эшләүче һәркемгә дә рәхмәт белдерәсе килә.

Бу чорда шулай ук Татарстан китап нәшрияты рус телендә «История татар»(Татарлар тарихы) һәм «История татар в лицах» (Татарлар тарихында шәхесләр) дип аталган ике кызыклы сериягә кергән егермедән артык китап бастырып чыгарды. Бик матур, зәвыклы итеп эшләнгән, бихисап фотоматериал һәм кайбер язма вә документ күчермәләре белән дә баетылган бу китаплар рус телендә аралашучы, республикада яшәүче башка милләт вәкилләрен татарлар тарихы, аның атаклы шәхесләре белән таныштыру өчен дип нәшер ителә. Ул серияләрнең берсе татарлар тормышына бәйле тарихи һәм иҗтимагый вакыйгаларны кыскача, укучыны ялыктырмас рәвештә тасвир итүче китаплардан тора. Икенчесе татарлар дөньясында күренекле эз калдырган шәхесләр биографиясен һәм эшчәнлеген якыртуга юнәтелгән. Китап тышлыгына «История татар» яки «История татар в лицах» дигән тамга да сугылган бу серияләрне тәкъдим итүче һәм булачак китап авторлары белән бергә оештыру эшләрен башкаручы тарих фәннәре кандидаты, нәшриятның фәнни һәм иҗтимагый әдәбият редакциясенең элекке мөдире Булат Хәмидуллин була. Бу серияләрдә чыгучы басмаларның китап сөючеләр күнелендә кызыксыну уятуын «Дэрдменд» һәм «Амирхан Еники» җыентыклары авторы буларак та раслый алам.

Алда санап үтелгән һәм башка бик күп китапларны, шул исәптән балаларга багышлап иҗат ителгән, затлы рәсемнәр белән бизәлгән төрледән-төрле җыентыкларны оештырып һәм редакцияләп чыгарган кайбер мөхәррир һәм баш мөһәррирләрнең исемнәрен атап үтик. Бу елларда Дамир Шакиров белән кулга-кул тотынып эшләгән баш мөхәррирләр шактый еш алышынды. Бу очракта зәвыклы шагыйрь һәм мөхәррир Харрас Әюповның кинәт вафат булуы, Рафис Корбанның башка нәшриятка эшкә билгеләнүе кебек сәбәпләр дә бар. Соңгы еллардагы баш мөхәрриребез — балалар әдәбияты бүлеге мөхәррире буларак сыналган, шагыйрь сыйфатында Муса Җәлил исемендәге бүләккә лаек булган Ленар Шәех. Матур әдәбият редакциясен тәрҗемәче, утыз еллык мөхәррирлек тәҗрибәсе булган Люция Нәҗмиева-Гыйззәтуллина, иҗтимагый-фәнни китаплар чыгару бүлеген Илнур Сафин җитәкли. Балалар әдәбияты һәм дәреслекләр редакциясе җитәкчесе Талия Шакированың да мөхәррирлек стажы утыз елга тула. Күптән түгел ана «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

Мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен әдәби эчтәлекле китаплар, дәреслекләр һәм бала күңеленә хуш килердәй төрле-төрле әсбап-кулланмалар бастырып чыгару белән мәшгуль булган бу редакциягә карата берничә сүз әйтеп китәсе килә. Менә бу бүлек тарафыннан балаларга һәм аларның тәрбиячеләренә атап чыгарылган китаплар сериясенең исемнәре: «Нәниләргә бүләк», «Исәнме, мәктәп!», «Рәсем ясарга өйрәнәбез», «Спорт», «Туган якны өйрәнү», «Балачак энциклопедиясе». Шушындый төрле-төрле эчтәлекле китап һәм китапчыкларны чыгарудагы уңышлары өчен бу редакция белән китап нәшрияты коллективы күптән түгел мәртәбәле бүләккә — Абдулла Алиш исемендәге премиягә лаек булды.

Нәшриятның китап сәүдәсен җайга салуда «Таткниготорг» оешмасы таралганчы аның директоры булган Эльвира Вилкова тәҗрибәсе дә кулланылды. Ә нәшрият директорының уң кулы — коммерция-хуҗалык эшләре буенча урынбасары вазифасын бүген сәләтле оештыручы Илдар Хөснетдинов үти.

Нәшрият, аның киләчәк язмышын хәл итү бурычын бүген Дамир Шакиров уңышлы башкарып килә. Без аны чын мәгънәсендә бу коллективның ветераны дип танырга хаклыбыз. Китап бастырып чыгару эшен ул утыз ел буена армый-талмый дәвам иттерә. Әүвәлрәк берничә ел ул татарча нәшер ителүче китаплар мөхәррире һәм директор урынбасары булып эшләде. 1998 елдан башлап, уналты ел инде ул — нәшриятның абруйлы җитәкчесе. 95 ел дәвамында, дәүләт китап нәшрияты оешканнан бирле, болай озак эшләгән директорның булганы юк иде әле.

Киләчәктә дә хөкүмәтебез Татарстан китап нәшриятына төрлечә ярдәм итеп, үз ана телебездәге уку әсбапларын да, әдәби, тарихи һәм иҗтимагый-сәяси китапларны да даими рәвештә нәшер итүгә булышыр дигән өметтә калабыз.

**Лирон ХӘМИДУЛЛИН,**
*Г.Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе*

# ЯҢА БИЕКЛЕКЛӘР ЯУЛАРГА...

*«Мәдәнияттә нигез булып биеклекләр хезмәт итә»*
Григорий Ландау



Татарстан Республикасы, бөтендөнья җәмәгатьчелеге кебек үк, өченче меңъеллыкка глобальләшү рухы йогынтысында килеп керде. Әлеге күренешне төрлечә бәяләү милли үзенчәлекнең юкка чыга баруы, кабатланмас мәдәниятләрне саклау мәсьәләләренең кискенләшүе хакындагы тезиска кайтып кала. Безне киләчәктә нәрсә көтә? Бу тискәре процессларга ничек каршы торырга мөмкин? Безнең көчебез нәрсәдә? Бу сорауларга анык кына җавап табуы авыр булса да, бер нәрсәне ныклы ышаныч белән әйтә алабыз: илебез, республикабыз рухи яктан тулаем фәкыйрьләнүгә каршы торырлык уникаль көчкә ия. Ул көч – буыннан-буынга күчеп баручы бай мәдәни мирасыбыз, милли йөзебезне чагылдырган үзенчәлекләребез, традицияләребез, гореф-гадәтләребез. Милли кысаларда гына калмыйча, Россия һәм дөнья кинлекләренә чыккан бик күп атаклы шәхесләрнең Г.Тукай, Ф.Шаляпин, Л.Толстой, В.Аксёнов, И.Шишкин, С.Гобәйдуллина һ.б. язмышлары Татарстан белән бәйләнгән. Татарстанның мәдәнияте төрки, рус һәм фин-угыр мәдәниятләренең, ислам һәм христиан диннәренең үзара тәэсир итешеп яшәүләре ягыннан да кабатланмас үзенчәлекләргә ия. Әлеге байлыкны саклау һәм балаларыбызга калдыру бик мөһим.

2014 елның Россия Федерациясендә Мәдәният елы буларак игълан ителүе мәдәниятнең хәзерге торышына ныклы игътибар һәм киләчәк үсешенә бурычлар билгеләргә житди сәбәп булды. РФ мәдәният министры В.Р.Мединский раслаганча, бу елда үткәрелә торган чараларның төп бурычы – төбәкләрдә мәдәниятне «уяту»... Дөрес, төбәкләрдә һәм, әлбәттә, безнең республикабызда да, гаять зур мәдәни көч бар, әмма аның куәтен һәм мөмкинлекләрен әле тулысынча файдаланганыбыз юк. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары (16.12.2013; №999) белән «Татарстан Республикасы мәдәниятенең 2014-2020 елларда үсеше» исемле Дәүләт программасы кабул ителде. Аның төп максаты – халкыбызның мәдәният, сәнгать, кинематография һ.б. өлкәләрендә хәзерге ихтыяжларын канәгатьләндерү һәм киләчәккә яңаларын формалаштыру. Беренче карашка барысы гади һәм аңлаешлы кебек! Әмма боларның һәммәсе артында нинди авыр, катлаулы хезмәт торуын күз алдына да китереп бетереп булмый... Әлеге эшләрнең шактый өлешен безнең уку йортын тәмамлаучылар һәм Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетының бүгенге студентлары алып барды һәм киләчәктә дә башкарачак.

Уку йортыбызның 45 еллык юбилее Мәдәният елына туры килү символик мәгънәгә ия. 1969 елда РФ Мәдәният министрлыгы карары белән Казанда Н.К.Крупская исемендәге Ленинград дәүләт мәдәният институтының филиалы ачылганда, ярты гасырдан да азрак вакыт эчендә бу уку йортының зур бер төбәкнең мәдәният өлкәсендә мәгърифәт һәм фән үзәгенә әвереләчәген беркем дә күз алдына китермәгәндер. Ул филиал 1974 елда мөстәкыйль институтка, аннары – сәнгать һәм мәдәният институтына (1991), мәдәният һәм сәнгать академиясенә (1995) һәм, ниһаять, мәдәният һәм сәнгать университетына (2002) әверелде. Болар барысы да – вузның узган юлы, формалашу һәм үсеш этаплары.

Шушы еллар эчендә университетыбыз заманга туры килерлек һәм динамик рәвештә үсеш алган югары уку йортына әйләнде. Ул үз эченә яңа белем технологияләрен һәм классик югары мәктәп традицияләрен ала. Уку-укыту, фәнни, сәнгать күрсәткечләре буенча безнең университет үз тармагы буенча алдынгы дәүләт югары уку йортлары арасында беренче бишлектә.

Күп тапкыр КДМСУ Бөтенроссия уку йортлары арасында үткәрелә торган «Мәдәният: Россиягә тәрәзә» конкурсы лауреаты булды («культура һәм сәнгать өлкәсендә яхшы белгечләр әзерләүдә, белем, фәнни, иҗади казанышлар өчен»); ЮНЕСКОның «Дөнья пальма ботагы» истәлекле медале белән бүләкләнде; ә житәкчесенең хезмәте – РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының К.Д.Ушинский исемендәге медаленә лаек булды.

Бүгенге көндә Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты – Россиядә казанышларга ирешкән уку йорты. Монда алдынгы уку технологияләре дөньяви мәдәният, Идел буе халыкларының милли культурасы, фольклоры, халыкара мәдәнияте, театр, музыка, бию сәнгате, кино һәм телевидение, мәдәният белеме, китапханә-информатик технологияләре, икътисад һәм туризм һ.б. өлкәләрдә тикшерүләр белән бергә үрелеп бара.

Тикшерү материаллары уку-укыту практикасына кертелә; белгечләр әзерләү программалары һәм проектларында чагылыш таба. Россия Федерациясе хөкүмәтенең югары бәясе – мәгариф өлкәсендә «Методология и технологии реализации региональной системы непрерывной профессиональной подготовки специалистов социокультурной сферы и искусства Среднего Поволжья» дип аталган хезмәтләр циклы өчен Дәүләт премиясе булып тора. Бу бүләккә 2006 елда университетыбызның бер төркем белгечләре лаек булды.

Бүген университетыбызның төп бурычы – көндәшлеккә сәләтле, югары белемле, акыллы, иҗади, мәдәни кыйммәтләрне халыкка тапшыручы белгечләр тәрбияләү. Заманча югары уку йорты көчле үсеш режимында хәрәкәт итә. Әлеге шартларда житәкчелектән дә актив яңартулар сорала: яңа оештыру структуралары булдыру, яңа юнәлешләр әзерләү, яңа технологияләрне, эксперименталь һәм мәгълүмати эшчәнлекне үстерү, фән һәм тәҗрибә казанышларын актив куллану.

Мәгариф кыры кинәю факультет һәм кафедраларга да үзгәреш алып килде, аларның үсеш концепцияләре өр-яңадан әзерләнде. Яңа ачылган факультетлар (икътисад, менеджмент һәм туризм, художество культурасы һәм дизайн, кино һәм телевидение һ.б.) һәм кафедралар (татар театр эстрадасы, эстрада-джаз музыкасы, заманча һәм бал-спорт биюе, декоратив-гамәли сәнгать, дизайн, музей һәм сәнгать белеме һ.б.) үзләрен аерым, мөстәкыйль бүлекләр буларак тәкъдим иттеләр.

Уку йортында бик күп яңа белгечлекләр ачылды: «Декоратив-гамәли сәнгать һәм халык кәсепләре», «Халык сәнгате культурасы», «Икътисад, туризм предприятиесе һәм кунакханә хуҗалыгы белән идарә итү», «Нәшрият эше һәм редакцияләү», «Гамәли информатика (дизайнда)», «Киновидеоижат», «Яшьләр белән эшләүне оештыру», «Иҗтимагый педагогика», «Эстрада музыка сәнгате (эстрада-джаз жыры)», «Театр режиссурасы», «Документлар һәм архив белән эшләү», «Кинооператорлык», «Кино һәм телевидение продюсерлыгы» һ.б.

Яңа федераль дәүләт стандартларына күчү (2010/2011 уку еллары) уку процессын яңартуны таләп итте. Система-методик тәэминат структурасы уку процессының максатын, эчтәлеген, технологик һәм оештыру компонентларының бердәмлеген күз алдында тотып проектлаштырылган. Ул белем сыйфатының үсешенә юнәлтелгән

тулылык, алдан күрүчәнлек, яраклашу, динамика һәм вариативлык принципларына нигезләнеп эшләнде. Соңгы елларда вузда стратегик идарә итү мәсьәләләре һәм мәгариф сыйфаты менеджментына зур игътибар бирелде. Бу юнәлештә югары уку йортының үз эчендә сыйфат менеджменты программасы гамәлгә ашырылды, һәм аның үсеше, камилләшүе буенча чаралар уйланылган. Шушы эшчәнлек кысаларында аерым бурычлар хәл ителә: дисциплинаара, проблема һәм проект-юнәлеш технологияләрен кулланып, инновацияле уку-укытуның үсеше; киләчәкне күздә тотып, югары дәрәҗәле белгечләр әзерләү, югары уку йортының академик базасын саклап калу; мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә фундаменталь тикшеренүләрне көйләү; университетның инновацион корпоратив мәдәниятен формалаштыру, әйләнә-тирә мохит белән бәйләнеш инфраструктурасын киңәйтү һ.б. болар барысы да шәхеснең күпкырлы үсешен кайгыртучы ачык мәгариф системасы төзүгә юнәлтелгән.

КДМСУ культура һәм сәнгать өлкәсендә квалификацияле белгечләр әзерләү үзәге булып тора. Югары һәм урта белем бирү буенча укытучыларның квалификацияләрен үстерү Россия Федерациясенең Мәдәният министрлыгы һәм «Россия культурасы 2012-2018» Федераль максатчан программасы нигезендә һәм аның финанс ярдәмендә алып барыла. Студентлар, укытучылар, иҗтимагый-мәдәният өлкәсендә эшләүче белгечләр, өлкәннәр һәм балалар өчен өстәмә белем бирү дә карала. Бу эшчәнлекнең максатлары күптөрле: балалар һәм үсмерләргә җәмгыятьтә үз урынын табарга булышу һәм аларны һөнәри юнәлдерү, студентларны, яшь, тәҗрибәле иҗтимагый-гуманитар һәм иҗтимагый-мәдәни өлкәләрдә эшләүче хезмәткәрләрне профессиональләштерү. Монда социаль яклау элементлары да урын ала: стабиль булмаган икътисад шартларында һөнәри яктан мобиль, кешеләргә карата игътибарлылык һәм аралашуга мохтаҗларга кешеләргә мораль һ.б. ярдәм күрсәтү тәэмин ителә.

Традицион эш формасы булып факультетлар һәм кафедралар ярдәме белән төзелгән иҗади-белем бирү программалары, чит ил белгечләрен җәлеп итү тора. Балалар хореография һәм театраль мәктәп студияләре, «Арт-парк» һәм «Кураж» студияләре, «Балачак бәйрәме» исемле театр-аниматор мәктәбе, кече яшьтәге балалар өчен «Тылсымлы тубал» студиясе, Россия Пенсионерлар берләмлеге белән бергә (2013 елда) төзелгән өлкән кешеләр өчен «Өченче буын университеты» эшләп килә.

Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан буенча бүлеге мәгълүматларына караганда, Татарстан Республикасында пенсионерлар саны 1 млн 75 меңнән арткан. Әлеге очракта өстәмә белем бирү яңа иҗтимагый әһәмияткә ия, чөнки бу кешеләр категориясе тирән иҗтимагый-икътисади үзгәреш шартларында, көнкүрешкә яңа мәгълүмати технологияләр тирән үтеп кергән заманда заманча белемгә мохтаҗ.

Бүгенге көндә университетның өч факультетында (хореография, театр, декоратив-гамәли сәнгать) 250гә якын ирекле тыңлаучы исәпләнә. Өлкән яшьтәгеләрнең яңа белемнәр белән танышу һәм яңа күнекмәләр алуы аларның иҗтимагый активлыгын күтәрә, тормышларының сыйфатын яхшырта, иҗади сәләтләрен хәрәкәттә тота, актив социаль һәм иҗади гомерләрен озайта, тормышка карата позитив күзаллауларга китерә, физик һәм рухи сәламәтлеген ныгыта. КДМСУның өстәмә белем бирү бүлегенә соңгы биш ел эчендә 6 меңнән артык кеше мөрәҗәгать иткән.

КДМСУ югары фәнни һәм иҗади потенциалга ия квалификацияле педагогик кадрларны үз эченә ала. Урта Идел буенда: Татарстанда, Чувашстанда, Марий Элда, Мордовиядә, Удмуртиядә мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә эшләгән тугандаш югары һәм урта уку йортлары арасында ул баш вуз булып тора. Университет башлангычы буенча әлеге төбәкләрнең уку йортлары «Казан университетлы, белем бирә торган округ» ассоциациясенә берләштерелде. Әлеге кысаларда ел саен симпозиумнар, фәнни һәм методик конференцияләр, «түгәрәк өстәл»ләр һ.б. уздырыла. Шулай ук бу уку йортларының эшчәнлеген перспектив планлаштыру һәм координацияләү гамәлгә ашырыла, төрле һөнәри юнәлешләр буенча куелган стратегик вазифалар үтәлә.

Белем бирү эшчәнлегенең киң диапазоны булу университетның тигез структурасы белән тәэмин ителә. Университет составында 9 факультет (иҗтимагый-мәдәни эшчәнлек; информацион сервис һәм медиатехнологияләр; музыкаль сәнгать;



*Университетның фольклор ансамбле*

хореографик сәнгать; икътисад, менеджмент һәм туризм; сәнгать культурасы һәм дизайн; театр факультетлары; кино һәм телевидение институты, читтән торып уку факультеты) һәм төп белем алу программалары үзләштерелә торган 23 кафедра бар. Алар 26сы – бакалавр, 26сы – специалитет, 3се магистр дәрәҗәсендә булган белгечлекләрне үз эченә ала. Югары квалификацияле кадрлар әзерләүдә (аспирантура, ассистентура-стажировка) 11 юнәлеш, докторантура, докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре яклау буенча өч совет, өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруда аерым институт эшли. «Культура» мәдәни-информацион нәшрият үзәге, фәнни китапханә, укыту-методик лабораторияләр, остаханәләр, компьютерлар һәм хәзерге мультимедиа техникасы белән җиһазланган сыйныфлар, фонотека, кече театр, киноконцерт залы, видеотехникалы төшерү павильоны, монтаж бүлмәсе; 2013 елда Универсиада объектлары санына кертелгән «Итиль» спорт комплексы һ.б. студентлар һәм барлык укучылар өчен кирәкле шартлар тудыра.

Белем эшчәнлегенең модернизациясе яхшы әзерлекле һәм квалификацияле кадрлар сорый. Югары мәктәптә фәнни тикшеренүләр алып баручы хезмәткәрләр квалификациясенең дәрәҗәсе Россиядә иң югары булып кала. Иҗади уку йортларында, шулай ук КДМСУда, фәнни һәм иҗади эшчәнлек янәшә яши һәм үрелеп үсә, педагогик эшчәнлек белән кушылып, социокультур өлкә өчен белгечләр әзерләү системасының үзәге булып тора.

Соңгы елларда югары уку йортының кадрлар составы нык үзгәрешләр кичерде, боларның сәбәбе вуз үсешенең режимы белән бәйле. Яңа юнәлешләр барлыкка килүе профессор-укытучылар составында мобилизация таләп итте, аны яңартуга һәм ныгытуга китерде. Факультетларда 300гә якын фәнни-педагогик хезмәткәр эшли. Алар арасында 46 профессор һәм фән докторлары, 100дән артык доцент һәм фән кандидатлары, 108 иҗтимагый академияләрнең хакыйкый әгъзалары, атказанган фән һәм сәнгать вәкилләре, атказанган мәдәният, Россия һәм Татарстанның югары мәктәбенең мактаулы хезмәткәрләре, 46 РФ һәм ТР атказанган һәм халык артисты бар.

Коллективның нигезе югары уку йортының башлангыч чорында хезмәт итүче ветераннарыннан гыйбарәт. Алмашка беренче чыгарылыш буын, бүгенге көндә үзләре ветеран дәрәҗәсенә житүчеләр килде. Алар инде бер генә буын талантлы

яшьләр тәрбияләмәделәр. Буыннарның алмашынуы – закончалыклы процесс. Шулай итеп, кадрлар потенциалын янадан житештерү барлыкка килә, ә укыту эшчәнлегенә актив рәвештә талантлы яшьләр жәлеп ителә. Өлкән буынның файдалы тәжрибәсен үзләштереп, алар үсә һәм ныгый, үзләре турында фәнни һәм ижади казанышлары белән хәбәр итеп, университетның, республиканың һәм илнең данын арттыра.

Укыту эшчәнлегенә Татарстанның күренекле мәдәният һәм сәнгать вәкилләре жәлеп ителә. Алар арасында – В.А.Ганиева, А.И.Шутиков, Н.И.Дунаев, Ф.Р.Бикчәнтәев, С.З.Фәтхетдинов, М.Л.Айтуганова һәм башкалар. Әлеге талантлы ижади шәхесләр йолдызлыгы укытучылар коллективын бизи, уку процессын баета, студентларны тәрбияләү эшчәнлегенә зур өлеш кертә, буыннар бәйләнешен ныгыта.

Югары профессиональ белем бирүдәге модернизация профессор-укытучылар составының хезмәт хакында да чагылыш тапты. Россия Президентының 2012 елның 7 маенда 597нче номерлы Указының «Дәүләт социаль сәясәтен реализацияләү буенча чаралар турында» беренче пунктының «а» подпункты үтәлде. Профессор-укытучылар составының хезмәт хакын региондагы уртача хезмәт хакына туры китерү юлында шактый эшләр башкарылды: укытучылар санын оптимизацияләү, кафедраларны реструктуризацияләү, укыту-булышу, административ-идарә һәм хезмәт күрсәтү персоналын кыскарту, укытуда сәгать санын үзгәртү, аны елына 900 сәгатькә тутыру, аттестация үткәрү h.б. 2012 елдан университетта укытучыларның эшчәнлеген бәяләүгә бал-рейтинг системасы кертелде, нәтижәләргә карап, хезмәт хакына стимул бирә торган матди өстәмәләр тәгаенләнде.

Бүгенге көндә педагогик коллектив ижади һәм фәнни эзләнү режимында эшли, фәлсәфә, тарих, мәгариф, классик сәнгать, милли мәдәниятләр, Идел Буе халыклары этнографиясе һәм фольклоры, культурология, музей эшен оештыру (музееведение), китапханә һәм мәгълүмати эшчәнлек, социаль педагогика, нәшрият һәм китап тарату, документ һәм архив эшен алып бару, гамәли информатика өлкәләрендәге мәсьәләләр юнәлешендә эш башкарыла. Әлеге эзләнүләрнең нәтижәләре диссертацияләрдә, фәнни программалар һәм проектларда, монографияләрдә һәм укыту әдәбиятында чагылыш таба.

Университет – ул, иң элек, талантлы, креатив, киләчәккә омтылган яшьләр. Көндезге һәм читтән торып укучылар саны 3 меңгә житә. Шуларның 1600е РФ бюджеты ярдәмендә укый, алар академик һәм социаль стипендияләр, уку, фәнни эзләнү һәм ижади эшчәнлектә булган казанышлары өчен стипендия ала. Арада балкып торучылар - үзләренең ижади киләчәкләрен фәнни эзләнүләр, аспирантура, ассистентура, ә анннары докторантура белән бәйләүләр куандыра. Бүгенге көндә 7 фәнни белгечлек буенча (05.25.03 – Библиотековедение, библиографоведение, архивоведение; 05.25.02 – Документалистика, документоведение, архивоведение; 24.00.01 – Мәдәният теориясе һәм тарихы; 13.00.05 – Социаль-культура эшчәнлегенең теориясе, методикасы һәм оештыру; 22.00.06 – Мәдәният социологиясе; 13.00.01 – Гомуми педагогика, педагогика һәм мәгариф тарихы; 01.00.05 – Икътисад һәм халык хужалыгы белән идарә итү) фәнни эш алып барырга мөмкин. Университетта докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре яклау буенча өч совет бар: Д 210.005.01 фәнни белгечлек 05.25.03 – Библиотековедение, библиографоведение и книговедение; Д 210.005.02 фәнни белгечлек 24.00.01 – Мәдәният теориясе һәм тарихы; Д. 210.005.03 фәнни белгечлек 13.00.05 - Социаль-культура эшчәнлегенең теориясе, методикасы һәм оештыру. Соңгы биш ел эчендә КДМСУның диссертация советларында 120 диссертация якланды. 2014 елдан алып университетта ассистентура-стажировкада белемне төрле юнәлешләр буенча дәвам итәргә мөмкин. Бу - актёрлык сәнгате, вокаль башкару сәнгате, сәхнә сөйләме, театраль режиссура сәнгате.

КДМСУ 2003 елдан РФ Югары аттестацион комиссиясенең «Россиядә чыгарылган алдынгы фәнни журнал һәм басмалар»ы санына кертелгән «КазГУКИ хәбәрчесе» исемле теоретик һәм гамәли эзләнүләр журналы нәшер итә. Диссертацияләрнең нәтижәләре әлеге журналда үз чагылышын таба.

Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты – югары мәктәпнең классик гадәтләрен һәм яшьләрнең ижади очышларын туплаган уникаль вуз. Республикада

һәм анын чикләреннән тыш университетның иҗади коллективлары үзләренең житәкчеләре, Татарстан һәм Россиянен мактаулы хезмәткәрләре ярдәмендә зур танылуга лаек. «Сәйдәш» бию ансамбле (житәкчесе Т.М.Латыйфуллин), «Жыр театры», «Кызыл Тау» (А.В.Самойлова), А.А. Василевский житәкчелегендәге эстрада оркестры, Ш.С.Шамгунов житәкчелегендәге халык уен кораллары оркестры, Л.П.Минһажева житәкчелегендәге «Нурлай» вокаль ансамбле, татар академия хоры (житәкчесе доцент М.Г.Яхъяев), «Жомга көн» татар фольклор ансамбле (А.Р.Еникеева житәкчелегендә) шундыйлардан.

Университетның алдынгы коллективлары республика һәм илебезнең абруйлы концерт биналарында чыгыш ясый. Россия масштабларында күренекле мәдәни вакыйгалар, тантаналы чаралар, зур милли бәйрәмнәр алар катнашыннан башка узмый.

Университетыбыз үзендә белем алган, бүген күренекле шәхесләр булып киткән студентлары белән горурлана. М.З.Васютин – Марий Элнын мәдәният, матбугат һәм милли эшләр министры, Г.А.Нигъмәтуллина – Татарстанның мәдәният министры урынбасары, А.Ф.Хәйруллин – Татарстанның Республика фәнни-методик үзәге директоры, Н.Камбеев – ТР Милли китапханәсе директоры, С.З.Фәтхетдинов – РФнең атказанган артисты, Татарстаннын халык артисты, Б.М.Бәдретдинов – Муниципаль дәүләт театрының баш режиссёры, К.Н.Нуруллин – Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең директоры, Д.М.Шәрифуллин – Казан дәүләт циркы директоры, В.Н.Подшивалов – Удмурт дәүләт филармониясенең баш режиссёры; татар эстрадасы йолдызлары З.Фәрхетдинова, З.Билалов, Мәликә, М.Рахмаев, В.Захаров һ.б. әнә шундыйлардан.

Вузның төп юнәлешләреннән берсе булып халыкара эшчәнлек тора. Ул - укуукыту мохитен кинәйтүдә, фән үсешенең стратегик ресурсларын баетуда, дөньядагы уку йортлары белән социомәдәни бәйләнешларда торуда мөһим чара. КДМСУ Франция, Нидерланды, АКШ, Кытай, Төркия, Латвия, Украина, Казакъстан, Үзбәкстан, Тажикстан, Азәрбайжан, Беларусь һ.б. илләрнең төрле укыту һәм иҗади берләшмәләре белән шартнамәләр төзеде. 2011 елда университет нигезендә МГИМО ЮНЕСКО Мәскәү дәүләт халыкара мөнәсәбәтләр институтының кеше хокуклары һәм демократия кафедрасы филиалы һәм мәдәният буенча Евроклуб секциясе оештырылды. ЮНЕСКО кафедрасынын Идел буе бүлеге архитектура һәм һәйкәлләрне саклау буенча зур эш алып бара. 2013 елда Болгар тарихи-археологик комплексынын универсаль кыйммәте булуы исбатланды, ә 2014 елда ул ЮНЕСКО хәзинәсе исемлегенә кертелде. Россиянең 27нче объекты, ә дөньяви мәдәни мирасның 1002нче объекты булып исәпкә алынды. Әлбәттә, бу проектның фәнниметодик нигезе алда әйтеп узган кафедрада эшләнде.

Бүген университетыбыз «2011-2015 елларга үсеш Концепциясе»ндәге төп кагыйдәләрне тормышка ашыру юнәлешендә эшли. Параллель рәвештә 2015-2020 елларга караган үсеш Концепциясен формалаштыру эшен дә актив алып бара. Ижтимагый-икътисади, технологик һәм иҗади янарышлар монда үз урынын таба. Үзенең 45 еллыгын ул фәнни һәм иҗади үсештә, алга таба зур планнар һәм өметләр белән каршы ала!

**Ривкат ЮСУПОВ,**
*Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать*
*университеты ректоры,*
*тарих фәннәре докторы*

# ИЗГЕ СӘФӘР ҖИҢЕЛ ГАМӘЛ ТҮГЕЛ

ХАҖНАМӘ

## Шәйехтә – кунакта

Бер кичне үзебез яши торган кунакханәдән ерак булмаган мәчеткә ястү намазына бардык. Анда Мәккәдә укучы –Чаллының күренекле дин эшлеклесе, «Тәүбә» мәчете имам-хатыйбы Галәветдин хәзрәтнең улы Габдерахман шәкертнең вәгазь сөйләячәген дә әйттеләр. Менә көтеп алган минутлар житте. Габдерахманның йөзеннән нур бөркелә, татарчасы соклангыч дәрәҗәдә камил, Коръәннән гарәпчә сүрәләр китергәндә теле телгә йокмый. Кыскасы, эреп тыңладык без аны.

– Мөселманнар өчен ел әйләнәсендәге иң хәерле көн Гарәфәдер. Бу – дога вакыты. Фәкать ихластан сорагыз. Һидаять, иман байлыгы, үзегезгә, балаларыгызга, оныкларыгызга, нәселегезгә хәерле гомерләр, тән сәламәтлеге, җан тынычлыгы теләгез. Ахирәткә күчкән әби-бабай, әти-әни рухына дога кылыгыз. Гомер буе кылган гамәл-гыйбадәтләр дә, гөнаһларыбыз булу сәбәпле, кабул булмаска мөмкин. Ә Гарәфәдә дога кайтарылмый, һичшиксез кабул була. Гомер буе хаталар ясаган кеше Гарәфәдә ихлас тәүбә итсә, Аллаһы Тәгалә аны кичерә, хаҗи-хаҗияләр гөнаһтан пакьләнә, – дип сөйли-сөйли безне олы Хаҗга әзерләде Габдерахман.

...Бүлмәдәшләрем – озак еллар Чаллыда яшәүче бертуган Фәрит белән Наил Бәгытдиновлар. Галәветдин хәзрәтнең үзе һәм аның Мәккәдә гыйлем эстәүче улы Габдерахман белән якыннан танышлар икән. Аларны Габдерахман шушы мәчетнең һәм мәхәлләнең имамы Шәйех Атнәгә (шәйех – гарәпчә аксакал дигәнне аңлата, хөрмәтле исем буларак, ислам дине әһелләренә бирелә) кунакка дәшкән. Алар, ни сәбәпледер, бармаска ниятләделәр.

– Тәлгат абый, безнең өчен кунак булып кайт! – диде Фәрит Минсәгыйть улы.

Мин ике уйлап тормадым. Шунда ук риза булдым.

– Барам, барам, минем язылачак хаҗнамәгә бер бизәк булачак ул. Исемен «Шәйехтә – кунакта» дип куячакмын. Аллаһы кушып, исән-сау кайтып житеп булса,– дидем.

Мөхтәрәм Шәйехнең офисы да ерак түгел икән. Беренче катта гаражлары, көнкүреш бүлмәләре, шунда ук намаз залы урнашкан, калган катларда үзләре яши торган бүлмәләр һәм Хаҗ чорында арендага бирелә торган кунакханәләредер инде.

Безне Шәйех Атнә үзе каршы алды. Намаз бүлмәсенә кереп, дүрт дивар буйлап тезелгән йомшак кәнәфиләргә чумдык. Башта гарәп имамнарының вәгазьләрен тыңладык, аларны татарчага Габдерахман әйләндереп торды. Аның тавышының аһәңлеген тагын бер ассызыклыйм әле, менә хәзер дә колак төбемдә яңгырап тора ул, билләһи.

Гарәпләрдә кунак сыйлау аштан, русча әйтсәк, первый-второйдан түгел, төрле савaплы эчемлекләрдән башлана икән. Иң беренче бер генә йотым су чыгардылар. Богълайныкымы, борайныкымы, диделәр. Янәшәмдә утырган Кукмара районының Тумбаш авылы егете Илшаттан сорамакчы идем, ул фикердән кире кайттым. Шуны да белми дип уйлавы бар бит. Аннары хөрмәт йөзеннән сап-салкын зәмзәм суы, татлы ашамлыклар, чикләвекләр, җимешләр, шул исәптән төрле сорттагы сусыл, татлы, баллы хөрмәләр китерелде. Катылыгы белән бездәге татлы кызыл борычка охшаган, шытырдатып ашый торган ямь-яшел хөрмә бик ошады кунакларга. Шуннан

*Ахыры. Башы узган санда*

соң бөтнек чәе, яшел яисә кара чәй, яки каһвә (кофе) тәкъдим иттелә. Аларыннан кәнәфиләребезгә утырган килеш авыз иттек.

Ике сәгать чамасы вакыт үткәч, идәндәге келәмнәр өстенә эскәтер җәелде һәм олы подносլар белән төрле тәмләткечләр салып әзерләнгән дөге, зур-зур кисәкле тавык һәм дөя итләре чыкты. Әмма кашык-мазар күренмәде. Көндез үзебез яши торган урамдагы бер кафе-ашханәдә сәке шикелле җирдә аяк бөкләп утырып, кул белән пешкән дөге ашаганнарын күргән идем. Гарәп кардәшләр майлы дөгене учларында кыса-кыса, ваграк тавык йомыркасы кадәр итеп йомарлыйлар да, авыз эченә шудыралар башта, аннары тавык ите белән бастырып куялар. Безгә дә шулай ашыйсы буладыр дип борчылып утырганда, бер тапкыр кулланыла торган калаклар тезеп куелды. Шуннан соң без, кунаклар, идәнгә төшеп утырып, гарәпләрнең милли ризыгын ашый башладык. Искиткеч тәмле иде ул.

Менә саубулашу минутлары җитте. Шәйех килгәнебез өчен рәхмәт әйтеп, зур форматлы икешәр Коръән китабы бүләк итте һәм: «Берсе — үзегезгә, икенчесен авылыгыз мәчетенә тапшырырсыз»,— диде. Без, хөрмәт йөзеннән, йөрәкләребез турына уң кулыбызны куеп, башларыбызны түбән иеп таралыштык.

Бүлмәбезгә кайтып керүгә, бүләкнең берсен Фәрит әфәндегә тапшырдым. «Авылыгыз мәчетенә куярсыз»,—дидем. Үземнекен исән-сау Сабага кайткач, 175 еллык юбилеен каршыларга җыенучы Аллаһ йортыбызга бирергә ниятләп куйдым.

Коръән дигәннән, торган җиребез коридорларында да, хәтта лифт эченә дә Согуд Гарәбстаныннан дини әдәбият алып чыгу тыелуын, таможняда күңелсезлекләр килеп туачагын кисәткән игъланнар рус телендә язылып ябыштырылган иде. Коръән китабының да кайбер басмалары тыела диделәр. Шуңа күрә кайберәүләр бүләкләрен калдырып ук кайттылар. Мин Аллага тапшырып, самолётка үзем белән керәсе кул сумкасына изге китапларны биш данә тыктым. Тагын берне Җиддә аэропортында таможня тикшерүләре үткәч, һәр хаҗига бүләк итеп бирделәр. Алдан кисәткән төпченү-бәйләнүләр өч аэропортның берсендә дә булмады. Алты данә Коръән китабы исән-сау Сабага кайтып җитте. Аларны Лесхоз, туган авылым Байлангар, Сеҗе (җәмәгатем авылы) мәчетләренә тапшырдым. Берсен Коръән укый торган Арчадагы дустым Мөзакир хаҗига бирдем. Кесәгә сыя торган күн футлярдагы бүләкне ул бик яратып кабул итте. «Безгә мондыйлар очрамаган иде, Аллаһының рәхмәте булсын,» — диде.

Мондый алдан кисәтүләрнең төп сәбәбе аңлашыладыр. Согуд Гарәбстаны Корольлегендә төп дәүләт дине — вәһһабчылык. Ана нигезне Мөхәммәд ибне әл-Вәһһаб (1703–1792) салган. Ул тарихи һәм дини һәйкәлләрне җимереп, мөселманнарны үзе «беренче принциплары» дип саналган нәрсәләргә кайтарырга омтылган. Вәһһабчыларның кызган чагына бик күп тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр эләккән, алар моны ширек (күпаллалык) тарату чыганагы дип тапканнар. Моның нәтиҗәсендә Согуд Гарәбстанында бик күп изге мираслар аяусыз җимерелә. Шул исәптән, Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.в.) белән бәйле урыннар зыян күрә. Аның туган йорты юкка чыгарыла. Мондый ямьсез мисалларны тагын да китереп булыр иде...

2012 ел ахырында Согуд Гарәбстаны Корольлеге оешуга 80 ел тулган. Король Габдулла ибн Габдел Газиз әс-Согуд тәхеттә утыра, аңа 88 яшь икән (булачак корольгә, ягъни энесе принц Нәҗефкә 77 яшь тулган) Ил хуҗасы үз Корольлегеннән сигез елга олы булып чыга. Галиҗәнап Король үз Ватанының юбилеен суперзаманча поездда каршы ала. Түшәмнәре чиста алтыннан коелган унөч вагоннан гыйбарәт әлеге могҗизалы техника Король заказы буенча Испаниядә эшләнгән. Поездның тизлеге сәгатенә 320 чакрым тәшкил итә, ул монархка мөселманнар өчен изге саналган шәһәрләр — Мәккә белән Мәдинә арасын 2,5 сәгатьтә узарга мөмкинлек биргән. Ә безгә ике тапкыр күбрәк вакыт кирәк булды. Түбәбез дә алтыннан түгел иде. Гомумән, Согуд монархының 7000ләп туганы бар икән, министрлыкларны һәм сәнәгать тармакларын принцлар һәм принцессалар контрольдә тота, барысы да дәүләттән пособие ала ди. Король белән туганлык дәрәҗәсенә карап бирелгән ярдәм акчасы аена бер меңнән башлап йөз мең долларга җитәргә мөмкинлеген әйттеләр. Кыскасы, корольлекнең икътисады гаилә бизнесы принцибы буенча төзелгән — вазифалар мирас буенча күчә.

Ә менә, рәсми чыганакларга караганда, гади халыкның яшәү шартлары гаять авыр, һәр өченче кеше — эшсез, хезмәт урыны табу бәхетенә ирешкәннәргә түләү дә елдан-ел кими икән.

Согуд Гарәбстанында алга сөрелгән шәригать кануннары хатын-кызларның хокукларын чикләвен, ир-атлар белән аралашуны (туганнарыннан башка) тыюын, шуна күрә биредә гүзәл затлар җәмәгать транспортыннан, лифтлардан файдалана алмауларын, аларга кафеларга керергә ярамавын, иреннән, абыйсыннан яки әтисеннән башка берүзе генә чыгарга тиеш түгеллеген, урамда никабтан йөрү мәҗбүри (күзләр генә күренерлек итеп йөзне каплап торган баш киеме) икәнлеген белдек.

Әлеге чикләүләргә карата канәгатьсезлек белдерүчеләр дә булгалап тора икән.

Без, Россия мөселманнары да, утыз ике көнгә сузылган сәфәребез вакытында шәригатьчәрәк яшәргә омтылдык. Ирләр һәм хатын-кызлар бер залда намаз укыла торган Әл-Хәрам мәчетендә без алгы сафларга, асыл затлар арткарак урнашты. Үзебез яши торган кунакханәнең вәгазьләр бүлмәсендә дә ир-атлар утырып бетергәч кенә, хатын-кызлар урын алды. Автобусларга да хаҗилар алдан узды.

Совет илендә тигез хокукка ия булып, иң алдан кызыл флаг тотып йөргән әби-апалар вакыты-вакыты белән онытылып китеп, беренчелекне алырга омтылып карамадылар түгел. Аларны өлкән яшьтәге имамнар:

— Монда булса да, шәригатьчә яшик инде, үзебездә дә баштан йөрисез бит, — дип тиз шиндерделәр.

Ә минем күнелемдә сугыш бара торган мөселман илләренең бер шәһәрендә булган кызык хәл янарды.

...Урамнан башта хатыны, аннан 100—150 метр арттанрак ире бара икән. Боларны мулла абзый карап-карап торган да:

— Габдулла, шәригать законы буенча хатын-кыз алдан йөрергә тиеш түгел бит, —дигән.

— Хәзрәт, беләсең килсә, — дигән Габдулла, — шәригать кануннары язылганда урамнар миналанган булмаган!

Шул мизгелдә боларның сөйләшкәнен тегенең хатыны да туктап, колак салып тора башлаган. Шуннан ана ире:

— Патыйма! Атлавынны бел! — дип бөердән чыккан тавыш белән команда биргән...

## Олы Хаҗ

...Санаулы көннәр үтә торды. Корбан бәйрәме якынлашты. Сигезенче зөлхиҗҗә көнне (13 октябрь) олуг Хаҗга ниятләп, госелләр коендык, аннары ихрамнар киеп (алда әйтелгән ике кисәк ак тукыма), Мәккәдән җиде чакрым булган Мина үзәнлегенә киттек. Автобус тәрәзәсеннән карап барабыз: транспортның иге-чиге, очы-кырые юк. 6—7 миллион кешене күчереп бетерергә кирәк бит шул изге үзәнлеккә.

Автобуслар гына түгел, вагон кадәр махсус фуралар да очрый. Алар өчәр-дүртәр кат итеп сарыклар төягәннәр. «Мина» сүзе «агарга» дигәнне аңлатып, Корбан бәйрәме көнне монда корбанлык хайваннарның каннары аккан өчен шулай аталган икән. Шушында ук Муәссәйм дигән урында корбан чалу заводы урнашкан. Мина үзәнендә йөзәр кешелек чатырларга (палаткалар) урнаштырдылар. Матраслар җиргә җәелгән, шунда ук намазлар да укылды, догалар да кылынды. Төп гыйбадәт нәкъ шушы урында була икән бит. Хәвеф-хәтәр генә була күрмәсен дип теләдек. Чөнки 1978 елда Минада янгын чыгып, 1800 хаҗиның үлгәнен әйткәннәр иде...

9нчы зөлхиҗҗә көнне (14 октябрь) Гарәфә үзәнлегенә кузгалдык. Монда да кечкенәрәк чатырларга урнаштырдылар, һәркемгә бер намазлык кадәр урын тиде.

...Гарәфәт тавы ташлы-комлы башка җирләрдән аермалы буларак, яшеллеккә бай икән. Бирегә су сиптергечләре урнаштырылган, алар коры, эссе атмосфераны йомшартып һәм суытып, сәгать саен 140 литр су бөрки торган итеп көйләгәннәр. Хаҗиларга күләгә булсын өчен якынча йөз мең төп агач утыртылган.

Менә шулай итеп, Исламны үзләренең диннәре итеп санап, аның сафлыгы өчен көрәшүчеләр намазлар һәм догалар укыйлар, елый-елый тәүбә итәләр, кылган гөнаһларыннан арындыруны сорыйлар. Хажилар, буш ара булганда, үзара танышуларын да дәвам итәләр бирердә.

## Гарәфәттәге чатырыбызда...

Бездән өч-дүрт рәт арттарак урнашкан ике ир-ат сөйләшә, шуларның сүзләре колакны бораулап керә бит.

– Син туган жиреңне пропагандалый белмисең. Муса Җәлил туган авыл – Мостафа дисәң, Россиядәге бөтен кеше белер иде,– дип кинәш бирә берсе.

– Муса Җәлилнең Мостафасы безнең авылдан соң бит әле ул. Мин бит Татар Каргалысыныкы, – дип каршы төшә әңгәмәдәше.

Татар Каргалысы дигән исемне ишеткәч, колак үрә торды. Бу авылны Байлар Сабасы тумасы Сәгыйть Хәялин житәкчелегендә Татарстаннан киткән йөзләгән гаилә – кулларыннан эш килә торган эшмәкәр-сәүдәгәрләр нигезләгән бит. Шушы буынның дәвамчысы Равил Хәялин Хажга китәр алдыннан гына миңа хат юллап, Татар Каргалысы, аның кешеләре турында кызык хәлләр тупланмасы җибәргән иде. Шуларның берсен – Согуд Гарәбстаны белән бәйле булганын шушы урынга кертеп җибәреп, аннары фикеремне йомгаклап куярмын.

Равил Рәхмәтулла улы болайрак дип язган иде. «1990 елларда мәчетләребезгә Төркия, Согуд Гарәбстаны кебек илләрдән дәгъвәтчеләр еш килә иде. Шул вакытта Мөхәммәди дигән кешебез (кушаматы – Каракаш) бер гарәп эшмәкәре белән танышып, тегенең телефон номерын алып калган. Һәм, ике-өч ай үткәч, теге яңа танышына өеннән шалтыраткан булган икән. Бервакыт жирле власть хуҗасын күргәч, Каракаш абзый болай дигән:

– Карале, Равил, ул чүл гарәбе миңа нәрсәләремә кирәк булды икән? Элемтәгә кергәч, тегенең нәрсә сөйләгәненә дә төшенә алмадым. Мин аңлаган «Бисмилләһи, Аллаһу әкбәр!», «Әссәламәгаләйкум», «Иншалла» кебек биш-алты сүз өчен элемтә бүлегеннән 2200 сумлык халыкара счет килде. Кычытмаган жиреңне кашысаң, менә шулай була ул, Рәхмәтуллович!

Бу язма минем хәтеремә ап-ачык кереп калган иде. Чөнки Мөхәммәди абзыйның кушаматы «Каракаш» «Каракош»ка да охшаган , Равил кардәшнең кулъязмасында ул сүз танылып бетмәгәч, янадан телефоннан элемтәгә кереп, ачыклаган идем...

Хөрмәтле укучым, без Гарәфәт тавында идек бит әле, әйеме? Оренбург өлкәсендәге туган авыллары турындагы ике сәфәрдәшнең әңгәмәләре тәмамлангач, киттем мин Татар Каргалысы кешесе янына.

– Сез Каргалыныкымы? Равил Хәялинны беләсезме? – дип сүземне башладым.

– Ничек белмәскә, авылның главасы бит ул!!! – диде яңа танышым.

– Менә хажи булып, исән-сау кайткач, Равилгә Татарстандагы Саба кешесе Тәлгат Нәҗмиевтән сәлам әйтерсез,– дидем.– Әгәр дә исемемне онытсагыз, Тәлгат Таҗетдинны искә төшерерсез,– дип тә өстәдем. Аннары әңгәмәдәшемнең исемен сорадым.

– Мөхәммәди булам мин! – диде ул үзенә күрә горурлык белән.

– Каракашмыни! – дип әйтеп салганымны сизми дә калганмын бит , әй.

Менә шул мизгелдә Мөхәммәди абзыйның каш урыннары маңгай түбәсенә үк менеп утырды.

– Мине каян беләсен?– дип сорады башта. Берничә секундтан: «Кушаматны кем әйтте?» – дип тә кайтарып сорады аннары.

Мин дә югалып калмадым.

– Изге жирдә Ходай Тәгалә үзе индерде, – дип, күккә төртеп күрсәттем.

Шуннан соң дуслашып киттек Мөхәммәди абзый белән. Ул җәмәгате белән килгән икән.

– Энем, әйбәтләп кара әле, абыенның кашы бөтенләй юк бит,– диде хажия бер очрашкач.

Дөрестән дә, кашсыз икән милләттәшем.

– Нишлисең, кашы юкка чыкса да, кушаматы калган,– диярге мәжбүр булдым. Саубуллашканда телефон номерларын алыштык.

Беркөнне өйдә телефон шалтырады.

– Каракаш әле бу! – диде Мөхәммәди хажи. Бик жылы итеп Мәүлед бәйрәме белән котлады.

Менә шулай итеп, Аллаһы Тәгалә мине алдагы китапка керәчәк язмам герое белән Мәккәдә очраштырды.

...Хәзер төп темага кайтыйк. Безне тагын бер сынау көтә икән әле. Мөздәлифә дигән үзәндә, коры жиргә – эреле-ваклы ташлар өстенә фәкать чыпта жәелгән жирдә, догалар укып төнне чыгасын. Монда инде чатырлар да, агач-куаклар да юк. Фәкать бәдрәф һәм тәһарәт алу корылмалары гына бар. Төнне Мөздәлифәдә үткәрү хажның важиб, ягъни тиешле гамәлләреннән санала. Монда ахшам белән ястү намазларын берләштереп, ястүне ике рәкәгатькә калдырып укыла һәм иртәнге намаздан кояш күтәрелгәнчегә кадәр – доганың шиксез кабул итү вакыты санала икән. Шуна күрә күз яшьләре күп коела: үкенү, тәүбә итү, елый-елый гамал кылулар. Мөздәлифәдә, кыямәт көнендәге кебек, бөтен кеше – байлар да, ярлылар да, түрәләр дә, гади халык та – бертигез. Ир-атлар – ихрамнан, асыл затлар махсус хаж күлмәкләреннән, яшәү шартлары да бертөрле (текәләр өчен кыйммәтле кунакханә номерлары юк) – аста чыпта, гранит-таш кисәкләре, тирә-якта – кара кыялар.

Черем итәргә ниятләп, ятып карадым. Йокы алмый. Кабыргаларым каты жиргә күнекмәгән шул. Торып, шайтанга ату өчен вак таш жыярга киттем. Борчак зурлыгында 49 данә кирәк алар. Бу хакта алга таба язылыр әле.

Бүген – 15 октябрь (10нчы зөлхиҗҗә) – Корбан бәйрәме. Иртәнге намаздан соң, автобусларда Миналагы зур палаткаларыбызга кире кайтып, ял иттек һәм өйлә намазын укыгач, бездән өч чакрым чамасы булган шайтанга таш ата торган жиргә жәяүләп киттек.

## Җәмәратта таш ату

Бу урын «жәмәрат» дип атала, вак ташны белдерүче «жәмәра» сүзенең күплек саны икән. Алар – өчәү, кече, уртача һәм олы жәмәрат. Шуларга таш ату – хаж йолаларына керүче мәжбүри гамәл. Элек жәмәратлар таштан өелгән багана формасында гына булган. Шуна күрә монда хажилар даими рәвештә тапталып үлгән. Соңгы елларда зур үзгәртү-төзекләндерү эшләре алып барылган. Баганалар киңәйтелгән. Шушы 2,9 чакрым арада өч туннель үтәргә кирәк. Аның берсе 1000 метр чамасы озынлыкта. Элек хажилар шул туннельләрнең бер ягыннан барганнар, икенче ягыннан кайтканнар. Хәзер кайту өчен аерым туннельләр эшләнгән.

Сүзнең дөресен әйтергә кирәк, беренче көнне бару жиңел булмады. Чөнки бөтен халык чын мәгънәсендә кубарылган иде. Без, татарстанлылардан берничә төркем, рәтләргә тезелдек, алдан яшь имамнарыбыз атлый, жөмһүриятебез байрагы да жилферди. Мин тыным кысылып артка кала башладым. Ярый әле районыбыз мөхтәсибе (ул бездән берничә көннән соң арттан икенче бер төркемнең житәкчесе булып килгән иде) Айнур хәзрәт Әхмәтов күз уңында тота икән. Ул уртада эскалатор барлыгын әйтте. Мин: «Бүген исән-сау әйләнеп кайтсам, иртәгә коляскалы негр малаен яллармын»,– дип уйлап куйган идем. Безнең акча белән бер мең сумга андый мөмкинлектән файдаланып булуын белешкән идем. Айнур Гыйльфан улының киңәше ярап куйды. Эскалаторга кердем дә, Вьетнамда эшләнгән, һәрвакыт үзем белән йөртә торган жыелма агач урындыгымны жәеп утырдым. Бераз хәл кереп китте. Әмма ул эскалатор йөз метр чамасы гына бара икән, аннан бераз жәяү атлыйсың да, яңадан эскалаторга керәсең. Менә шулай Аллаһ Тәгалә гел ярдәм итеп тора икән ул. Әмма барыбер күңелгә шөбһәле уйлар килә. Моннан берничә ел элек шушы туннельләрнең берсендә ут сүнү аркасында һава бетеп, берничә йөз хажиның паникага бирелә-бирелә тапталып-изелеп үлгәнен матбугат чаралары киң яктырткан иде.

Беренче көнне без шайтанга жиде таш атарга тиеш. Өч көн дәвам итә торган әлеге

мөһим чараның үз тәртипләре, үз догалары бар. Әгәр ташлар символик шайтаннарга тиешле дәрәҗәдә атылмаса, Хаҗның кабул булмаска мөмкин. Элек Хаҗда иң авыры таш ату саналган. Хәзер инде, әйткәнемчә, унай шартлар тудырылган. Алдагы елларда «Җәмәрат» бер генә катта торса, хәзер анда бара торган юлны 25—30 метрга киңәйтеп, стеналарын тагын да озынайтып, өч катлы итеп эшләгәннәр. Димәк, һәр каттан таш атып була. Алар багана-стеналар төбенә җыелмыйча, махсус тишекләр аша аска китеп торалар. Без дә беренче көнне — 7, икенче-өченче баруда һәр баганага 7шәр, барысы 21әр таш аттык. Өч көндә тиешле 49 таш атылып, үзебездә җиңеллек сиздек. Мин алты ташны артыграк, ягъни запас белән җыйган идем. Аларын Сабага — истәлек итеп алып кайттым.

Бу урында тагын бер чигенеш ясамыйча булмый әле. Таш атарга соңгы тапкыр барганда, һич көтмәгәндә коточкыч хәлгә тап булдык. Туннельнең иң озынына керергә әзерләнгәндә, күзләре акайган хаҗи-хаҗияләр ташкыны кирегә агыла башлады. Алар берни уйламыйча гына догалар укый-укый алга баручыларны таптарга тотындылар. Ярый әле, олырак гәүдәле бүлмәдәш ир-атларыбыз җәмәгатьләрен һәм мине түгәрәк эченә алып өлгерделәр. «Бетүем шушы икән», — дигән куркыныч уй икенче мәртәбә күңелемә килде һәм иреннәрем үзеннән-үзе: «Ләә иләһа иллә Аллаһу Мөхәммәдүр расүлуллаһи» дип кабатлый башлады. Аның мәгънәсен белмәгән кеше бик аздыр: «Аллаһтан башка илаһ юк, Мөхәммәд аның рәсүле», ягъни илчесе. Бу җан биргәндә дә әйтә торган кәлимә.

Аптырап, сүзсез-телсез, селкенмичә дә басып торабыз. Әйтерсең лә, мәхшәр көн булып, ап-ак киемле әрвахлар дәррәү кузгалып чыккан. Халык ташкыны «ә» дигәнче, бара һәм кайта торган туннельләр арасындагы тимер торбалар утыртып тотылган сетка койманы җимереп, каршы якка сикерә башлады. Максатлары — таш атып кайтучылар туннеленә кереп, юлны шуннан дәвам итү. Исән калу нияте белән без дә тегеләр артыннан сикердек. «Сикердек» дип язуым юкка түгел. Ул сетка-койманың аскы бер метры кирпеч стена иде. Әмма... Бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, без туннель авызына җитүгә, кайдан килеп чыкканнардыр шул арада, полицейскийлар тезелеп, дивар кебек каршыбызга бастылар. Артка чигенеп, кирегә, элек барган юлыбызга чыгарга мәҗбүр булдык. Без борылып килгәндә, ыгы-зыгы кими төшеп, кешеләр әкрен генә янадан керә башлаган иде туннельгә, бүлмәдәшләрем белән мин дә аларга ияръдем.

Кыямәт көненә охшаган бу хәл нәрсәдән килеп чыккан соң? Ул хәбәр безгә икенче көнне генә килеп иреште. Баксаң, бер озын итәкле хаҗиянең күлмәге эскалаторга кысылып калган. Шуны «әсирлектән» азат итү өчен эскалаторны кирегә әйләндерергә мәҗбүр булганнар. Шул сәбәпле, андагы кешеләр дә кирегә чыга башлаган, аларга, паникага бирелеп, билгеле, ян-яктагы халык та ияргән. Баш бетәрлек бернәрсә дә булмаган икән югыйсә... Менә шулай, әҗәлең җитсә, үз тәкерегенә тончыгып үләрсең, ди.

Таш атуның авырлыгын «символик шайтан»нарга якынайган саен ныграк тоясың икән. Сине халык дулкыны бөтерә-бөтерә йөртә. Аяк астында сандаллар, махсус сатыла торган ап-ак зонтиклар, зәмзәм суыннан бушаган полиэтилен шешәләр шытыр-шытыр килә. Аларны беркем дә иелеп алырга уйламый, бөгелсәң — таптап китәләр. Артык хискә бирелгән, битләрен тырный-тырный «Аллаһ, Аллаһ!» дип елаган-ялварган негрларга, кечкенә гәүдәле мөселманнарга да күз салып аласың да, бу кыямәт көненең репетицияседер дип уйлыйсың. Менә без шушындый коточкыч шартларда фарыз гамәлебезне — таш ату йоласын да үтәдек, аннары читкәрәк чыгып, тиешле догаларны укыдык һәм гәүдәбездә-калебебездәниндидер җиңеллек һәм канәгатьләнү сизеп, җәяүләп кайту юлына чыктык. Кая карама кеше, җаймәләр җәеп, гаиләләре белән ашап утыручы, йоклаучылар да бар. Алары кунакханәгә түләргә акчалары булмаган ярлы мөселманнар, Хаҗ гамәлләрен кояш астында яшәп үтәүчеләр икән.

Шул ук Корбан бәйрәме көнне Әл-Хәрам мәчетенә кайтып, фарызларның да фарызы булган тәваф кылырга, ягъни Кәгъбәтулланы тагын җиде тапкыр әйләнергә, Сафа һәм Мәрва таулары арасында сәгый кылырга тиеш булабыз. Элек хаҗилар Мәккәгә җәяүләп барганнар, соңгы елларда автобус белән бара торган

итеп көйләгәннәр икән, Аллага шөкер, анысы җайланган хәзер. Тәваф кылу да беренчесе кебек авыр булмады. Дөрес, Кара ташка якын килә торган түгел иде. Ул тирәдә хискә бирелеп, ягъни, чама югалтып ычкынган фанатлар кайнаша. Шулай да, мина, Байлангарның Самат малаена – Нәҗметдин оныгына Мәкам Ибраһимны (г-м) каплаучы алтын төсендәге гөмбәзне өч әйләнгәндә, ягъни өч тапкыр кулларым белән кагылырга насыйп булды. «Анысы нәрсә тагы?» – дип уйлаучылар да булырга мөмкин. Ул – Кәгъбәтулланың диварын өйгәндә басып тору өчен Исмәгыйль пәйгамбәр (г-м) әтисе Ибраһимгә (г-м) китергән мөбарәк таш.

Диварлар күтәрелгән саен, Ибраһим (г-м) торган таш һаман биекләнә барган. Анда аның аяк эзләре уелып калган. Элек Мәкам Ибраһим (г-м) кечкенә генә корылма эчендә булган. Ләкин хаҗилар саны арту белән, ул тәваф кылуда зур авырлыклар тудырган. Шуннан соң корылма сүтелгән, аяк эзләре баткан таш 1967 елда нык пыяла савыт эченә куелган. Мәкам Ибраһим (г-м) Кара таштан 14,5 метр ераклыкта урнашкан. Аллаһы Тәгалә Үзе мөселманнарга аның янында намаз укырга боера. Ул хакта, Коръәндә «Мәкам Ибраһимны намаз уку урыны итеп алыгыз» («Бәкара», 125) дигән аять тә бар. Олы хаҗ вакытында аның янында намаз уку мөмкин түгел, билгеле... Бу гамәл халык азрак чакларда тормышка ашырыла икән.

...Бәйрәм көнне үк корбаннарыбыз чалынуын да әйттеләр. Кичкә таба шул иттән пешерелгән аштан авыз иттек. Миллионлаган халыкка ничекләр итеп өештырып бетерәләрдер аны, рәхмәт яугырлары. Гомумән, Минада да, Гарәфәттә дә эчәргә зәмзәм сулары, соклар, кайнар ризыкларны даими рәвештә китереп тордылар.

12нче зөлхиҗҗә көнне (17 октябрь) Мәккәгә кайттык, торган бүлмәбез, бигрәк тә караватларыбыз сагындырган икән. Безнең әле Мәдинәгә киткәнче ун көнебез бар иде. Вакытны бушка уздырмадык, Әл-Хәрамгә йөрдек. Иртәнге намаз иртәнге биштә иде. Без урын алу өчен сәгать икедә кузгала торган булдык. Мәчеткә бер миллионнан артык кына кешe (ишегаллары мәйданы –88000, мәчетнеке 322000 квадрат метр икән) сыя, рәсми килгән хаҗилар алты тапкыр артык бит. Әл-Хәрамгә халык күп йөри, чөнки биредә укылган бер намаз 100 меңгә исәпләнә диелгән.

Мәккәдән китәр алдыннан без үзләре исән чакларында кыла алмаган әти-әниләргә багышлап гомрә Хаҗ гамәлләрен дә үтәдек. Алар вакытында да Әл-Хәрам мәчетендә җидешәр тапкыр тәваф һәм сәгый кылу фарыз булган бит.

Әмма иң элек унбиш мең кешене үзенә сыйдыра ала торган Гайшә мәчетендә намаз укырга кирәк. Ул Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) Гайшә атлы җәмәгатенең (Рәсүлебез вафаты алдыннан унөч көн авырый, бу көннәрдә чират буенча хатыннары өендә яши, хәле начарлангач, Гайшә өендә калырга рөхсәт сорый һәм һиҗринең 11нче елында рабигуль әүвәлнең уникесендә, дүшәмбе көнне алтмыш өч яшендә өзелә. Бу милади буенча 634 елның 8 июненә туры килә) саубуллашу хаҗы вакытында ихрам кигән урында төзелгән. Гайшә мәчетенә үзебез такси яллап бардык, шофёрыбыз безнең намаз укып чыкканны көтеп торды да, Әл-Хәрамгә илтеп куйды. Алдан сөйләшү шулай иде.

## Кызыклы очрашулар

...Чираттагы җомга көн иде. Иртәнге намазны Әл-Хәрамдә укып кайттык. Кайнар кояш асфальтны эссе ташы хәленә китергән. Шуңа күрә җомгага үзебезнең яндагы Тәкъва мәчетенә барырга ниятләгән идем башта. Бүлмәдәшләр китеп беткәч, башыма: «Нишләп әле син Аллаһ биргән мөмкинлектән файдаланмыйсың! Кәгъбәтуллага бармаска маташасың! Мәккәгә тәүге һәм соңгы килүеңдер, бәлки?– дигән уйлар килде. Тиз генә әзерләндем дә, автобуска чыгып утырдым. Барып җиткәч, мәчетнең төп ишегеннән кереп, эскалатор белән ремонт бара торган өченче катка күтәрелдем. Дөрестән дә, анда урын иркен иде. Шушы каттан Әл-Хәрам мәчетендәге биш вакыт намаз спутник каналлары аша күп илләргә телетрансляцияләнүен күрдем. Аллаһы йортында чираттагы киңәйтү эшләре (соңгысы 1996 елда булган) бара икән. Намазга килгәндә Әл-Хәрам тирәсендәге күккә ашкан 100дән артык төзелеш краны санаган идек. Шуннан соң Хаҗ кылу өчен квота ун миллионнан артып китәчәген

искәрттеләр. Диннән аерылып тормаган Төркия, Индонезия кебек мөселман илләрендә Хажга бару өчен 15–20 ел чират торалар, бәясе дә ун мең долларга (безнең акча белән 350 мең сум) төшә икән.

Ярар, безгә насыйп булган тагын бер җомга намазы укылды. Адашмас өчен, кергән юлны карый-карый, мәчет ишегалдына чыктым. Мәхшәр мәйданыннан бер дә ким түгел, кем әйтмешли, борын тыгар урын юк. 60 градус эсседә тагын һава җитми башлады. Як-якка карыйм: әфлисүн төсендәге җилкә сумкасы аскан якташларның берсе дә күренми. «Һушны җуйсам, тиз генә таба да алмаслар инде, – дип, күнелсез уйга чумып барганда, Татарстанның кызыл сарылы сумкалы бер хаҗие күзгә чалынды бит, рәхмәт яугыры.

– Әссәламөгаләйкүм, вә рәхмәтуллаһ, хәзрәт, бергәрәк атлыйк әле. Кәеф шәптән түгел,– дия-дия зәмзәм суы йотам. – Кайсы районнан сез?

– Арчадан. Тимерьюл станциясендә торам.

– Мин дә Арча кияве бит. Җәмәгатем Сеҗенеке.

– Тумышым белән Иске Кишеттән мин. Исемем – Дамир, фамилиям – Галиев.

– Ә мин кырык елдан артык Сабада яшим.

– Минем бертуган сеңлем Венера да сездә эшли бит.

– Кайда?

– Больницада медсестра ул. Хирургия бүлегендә. Ире теш врачы – Делюс. Беләсездер бит?

– Ничек белмәскә инде. Бер тирәдә – Үзбәк Закиров урамында торабыз.

– Ярар, исән-сау кайткач, сәлам тапшырырсыз.

– Әлбәттә, тапшырырмын. Сезнең якташыгыз, яраткан язучыбыз Мөхәммәт абый Мәһдиев әйтмешли, «кайтулар едва ли» бит әле монда.

– Андый шик кертмәгез. Шайтан максаты ул. Аллаһы Тәгалә кушса, әйбәт кенә кайтырбыз. Сез үзегез кайда эшләдегез соң?

– Редакциядә. Утыз елга якын Саба газетен чыгардым мин.

– Ник, Тәлгат абый Нәҗмиев буласызмыни сез?

– Әйе шул...

...Икенче бер кичне Әл-Хәрамнән чыктым да, кунакханәгә кайта торган автобуска кереп урнаштым. Бераздан, әллә күземә күренәме дип торам, туган авылым Байлангар имамы Габделфәрт хәзрәт пәйда булды. Исәнләштек, куаныштык, серләшеп тә алырга өлгердек. Күрше кунакханәдә – ашханәле корпуста тора икән ул. Авылыбыз турындагы хәлләр белән дә таныштырып алды хәзрәт. – Мин күп вакытымны Әл-Хәрамдә үткәрәм, кунып та калам. Бүген кайтырга ниятләдем. Шушы очрашу тарткандыр инде, – диде урамдашым Габделфәрт.

Дин кайтарылган туксанынчы еллардан соң авылдашыбыз Маһирауза апаның Хаж кылып кайтканын белә идем. Менә Габделфәрт хәзрәт белән без дә булдык изге җирләрдә. Тагын шунысы куанычлы: өчебез дә –Таубашы урамыннан.

Гомумән, Кукмара районында иманлы халык яши. Мәдрәсә гөрләп эшләп тора. Байтак авылларда хәмер бөтенләй сатылмый. Кайбер елларда хаҗга берьюлы кырыклап кеше барган. Быел да байтак иде якташларым. Мәсәлән, атаклы металл савыт-саба заводында гади токарь булып эшләүче Илнур Мөхтәров башта үзе генә барган Хаҗга. Бу юлы намаздагы әтисен – Зиннур абзыйны алып килгән. Менә шундый мөселман җанлы яшьләр күп Кукмарада.

Очрашулар... очрашулар. Күп булды инде алар. Менә шуларның тагын берсен Мина үзәнлегендә – чатырлар шәһәрлегендә булганын язмыйча кала алмыйм. Моннан ун-унбиш ел чамасы элек, «Бәкер» курортында Сәгъдәтулла Төхбәтуллин дигән шәхес белән очрашкан идек. Аның әнисе Хөббениса халык телендә Чиратнай дип йөртелә торган Урта Нырты авылыннан булган. Алар, Азнакай районының Югары Әстәрле егете Рәхмәтулла белән өйләнешеп, унбер бала үстерәләр. Сәгъдәтулла төпчек, әмма бик зирәк була. Армиядән соң Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый. Агроном, колхоз рәисе, Азнакайда – ун ел авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы, Питрәчтә – КПСС райкомының икенче секретаре, Чүпрәледә алты ел беренче секретарь, Ютазыда районны яңадан оештыручы хакимият башлыгы була.

Теге вакытта әңгәмә корып утырганнан соң, кабат очрашырга туры килмәде. Әмма аның, коммунист житәкченең: «Бүген улым килгән иде, өйлә намазын бергә укыдык», – дигән җөмләсе күңелдә мәңгелеккә уелып калган. Менә, Аллаһ Тәгалә безне кабат кайда очраштырды!

Сәгъдәтулла Рәхмәтулла улы, сигезенче дистәне вакласа да, хезмәтен ташламаган. Һаман да Ютазы районы хакимияте башлыгы киңәшчесе итеп файдаланалар икән әле аны. Әнисе ягыннан якташыбызның Хажга беренче генә килүе түгел икән инде.

– Бу юлы малай белән мин. Казанда яши ул, үзенең бизнесы бар. Әнә ул – кара сакаллы,– дип, уртача гәүдәлеләрдән бер метрга озынрак булган мәһабәт хажига күрсәтте.

## Хуш, сау бул, Мәккә!

Бик озак тоелса да, санаулы көннәр үтә торды. «Иртәгә Мәдинә шәһәренә кузгалабыз», – дигән хәбәр килеп ирешү белән хәстәрлек чаралары күрә башладык. 26 октябрь көнне Кәгъбәтуллага барып, саубуллашу тәвафы кылдык, ягъни Изге ташны тагын җиде тапкыр әйләндек һәм кат-кат хажыбызның кабул булуын теләдек. Кунакханәгә кайткач, һәр кешегә унар литрлы шешәгә тутырылган зәмзәм суы бирделәр. Аның кәгазь тартмасының почмакларын, таралып китмәсен өчен, берничә тапкыр скотч белән урадык. Бу изге хәзинә үзебездән аерым, олы сумкаларыбыз белән багаж бүлегендә кайтырга тиеш иде.

Икенче көнне Мәдинә шәһәренә – Мөхәммәд (с.г.в.) мөшрикләр тарафыннан таш ата-ата Мәккәдән куылгач, аны үзенә сыендырган, Ислам динен тарату үзәгенә әйләнгән, Пәйгамбәребез җәсәден үз жирендә саклаучы изге калага юл алдык. Мәккә белән аерылышканда күзләребез яшь белән тулды. Ике ара 500 чакрым чамасы икән. Юл буенда элмә такталар күп очрый. Гарәп телен белүчеләр аларга «Сүбханаллаһ!», «Әлхәмдүлилләһ!» кебек зикерләр язылганын аңлаттылар. Юллар киң, ике яклы. Автобусыбыз 140 километр тизлек белән элдертә. Кыскасы, атыбыз симез, юлыбыз тигез. Яшеренеп торган жирләреннән полицейскийлар да атылып чыкмый. Аларның Мәккә каласында да юкка-барга бәйләнгәннәрен күрмәдек. Бәлки, Хаж вакытында гына шулай миһербанлыдыр погонлы кешеләр. Мәккәдә юл хәрәкәтенең артуы Әл-Харам мәчетенә керү юлын жиңеләйтү һәм жәяүлеләр куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен туннельләр системасын төзергә мәжбүр иткән. Аларның саны йөзгә житә диделәр. Туннельләр Король Габделгазиз капкасы каршына килеп чыга. Әмма юлларның, аеруча мәчет алдындагыларның кирәкле инфраструктурасы юк, асылмалы күперләр дә корылмаган, жир асты юллары да салынмаган. Менә шуңа күрә дә автобус тукталышыннан соң Әл-Харамга кадәр арада жәяүлеләр, ягъни миллионлаган хажилар транспорт белән кушылып йөри. Шунда ук су ташу, чүп түгү машиналары, мотоцикллар, скутерлар һәм хәер сорanып утыручылар.

Без шәһәрнең кыл үзәгендә тордык. Буш вакытта тирә-юньне күзәтә идек. Менә кунакханәбез каршында яшәүче бай гарәп офисының баштa беренче катындагы гараж ишеге ачылды. Аннан «текә» жиңел машина чыкты. Аның алгы утыргычына жәмәгате кереп урнашты. Шул мизгелдә бер-бер артлы биш-алты бала пәйда булды. Берсенә урын житмәде. Ул алгы утыргычлар арасына кереп кысылды. «Боларда балалар креслосы юк икән», – дип уйлап бетерә алмадым, янадан дүрт гарәп күренде. Алар машина өстендәге йөк йөртү өчен ясалган әржә шикелле жиргә менеп утырдылар да, аякларын машинаның ян тәрәзәләренә таба асылындырып, бернәрсә булмагандай китеп тә бардылар. Алай итеп йөрүчеләрне элегрәк тә күргәләгән идек.

## Мөбарәк Мәдинә каласы!

Автобусыбыз Мәдинә урамнарыннан бара. Нурлы кала безне күз яшьләре кебек яңгыр тамчылары белән каршы алды. Шәһәрнең чисталыгы, яшеллеге, гомумән, матурлыгы әсир итте хажиларны. Әледән-әле төрле зурлыктагы Аллаһ йортлары янынннан үтәбез. Менә ун манаралы Пәйгамбәр (с.г.в.) мәчетенә якынлашабыз. Ул әһәмияте ягыннан Әл-Харамнән кала икенче урында торганын искәрткән идем. Бу

Изге Йорт турындагы мәгълүмат белән янәшәмдәге Рамазан хәзрәт таныштырып бара. Аның икенче килүе булгач, барысын да чамалый. Пәйгамбәр мәчете тугыз тапкыр үзгәртелгән, соңгысында мәйданы 82 мең квадрат метрга киңәйтелеп, 167 мең кеше сыйдырышлы ителгән, хәтта түбәгә 90 мең урынлы намаз бүлмәсе өстәлгән, ишегалды ак мәрмәр белән капланып, 190 мең квадрат метр намаз укый торган мәйдан булдырылган. Шулай итеп, хәзер биредә барысы 535 мең кеше намазга баса ала. Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.в.) үзе исән вакытта ук әйткән: «Әлеге мәчеттә укылган бер намаз Әл-Хәрам мәчетеннән кала, башка мәчеттә укылган мең намаздан хәерлерәк» (Бохари, 1190 хәдис). Мәчетнең ишегалды асты да кечкенә бер шәһәрчекне хәтерләтә. Биредәге ике этажда 4444 машинага исәпләнгән 22 автопарковка төзелгән. 6000 госел-тәһарәт алу урыннары һәм 2000 бәдрәф тә җир астына көйләнгән.

Иң күзгә чалынганы — хәрәкәт итүче гөмбәзләр. Аларның саны 27гә җитә, бу гөмбәзләрне бизәү өчен 68 кило чын алтын тотылган. Алар тавышсыз гына ачыла һәм ябыла да икән. Мәчетнең тышында фонарьлар урнашкан колонналар бар. Алар да зонт рәвешендә ачылалар. Мәчет эчендәге чисталыкны, матурлыкны сөйләп бетерә торган түгел. Идәндә — затлы келәмнәр, түшәмнәрдә — шәрыкъ бизәкләре, рәт араларында зәмзәм суы салынган савытлар. Биредә ирләр һәм хатын-кызларның намаз заллары аерым, бик уңайлы.

Кунакханәбез дә өч йөз метр гына ераклыкта булып чыкты. Шуңа күрә биш вакыт намазның күбесен биредә укыдык.

Экскурсияләргә дә йөрттеләр. Пәйгамбәребез (с.г.в.) Мәдинәгә килгәч, иң беренче төзегән Куба мәчетенә бардык. «Кем дә булса, Куба мәчетендә ике рәкәгать намаз укыса, гомрә Хаҗы кылган әҗер савабын алыр»,— дигән хәдисе дә бар икән. Әлеге мәчет соңгы тапкыр 1986 елда киңәйтелгән, 20000 намаз укучыны сыйдырышлы ителгән.

Тагын Кыйблатәйн дип аталган ике кыйблалы мәчеттә дә булдык. Монда михраб (имам намаз уку өчен билгеләнгән махсус урын) икәү. Башта Мөхәммәд (с.г.в.) мөселманнар белән намазны Иерусалимдагы Әл-Әкъса мәчетенә карап укыган. Әмма Пәйгамбәребез (с.г.в.) күңеле белән атабыз Ибраһим (г-м) торгызган Кәгъбәтулланың кыйбла булуын теләгән. Һиҗрәтнең икенче елында, ягъни 623 елда, шәгъбән аеның унбишенче көнендә өйлә намазының 2 рәкәгатен укыгач, Аллаһы Тәгалә Мөхәммәднең (с.г.в.) теләген канәгатьләндереп, «Бәкарә» сүрәсенең 144нче аятен индерә. «Менә хәзер йөзеңне юнәлдер мәсҗид Әл-Хәрам эчендәге Кәгъбәтуллаһка!»— диелә ул аятьтә. Пәйгамбәребез (с.г.в.) намаз вакытында ук кыйбласын үзгәртә.

Без шулай ук сугышлар булган Өхед тавын да зиярәт кылдык. Монда бәрелеш тәмамлангач, Пәйгамбәребез (с.г.в.) шәһитләрне яу кырында җирләргә боерган. Бер каберлә ике-өч мәет ята икән. Пәйгамбәребез (с.г.в.) үзе дә еш кына Өхед тавына барган, димәк, аны зиярәт кылу — сөннәт.

Мәдинә шәһәрендәге иң җаваплы һәм саваплы гамәл - Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) иң якын һәм тугрылыклы сәхабәләре Әбү-Бәкернең (р.г.), Гомәрнең (р.г.) каберләре янына кереп, аларны сәламләү, рухлары шат булсын, дип дога кылу. Мөхәммәд (с.г.в.) үзе исән чагында ук: «Мине вафатымнан соң зиярәт иткән кеше, әйтерсең, саулыгымда зиярәт иткән кеше кебектер»,— дип әйтеп калдырган. Аның: «Каберемне зиярәт иткән кешегә шәфәгатем ваҗиб булыр»,— дигән хәдисе дә бар. Аларның каберләре хәзер мәчет комплексы эчендә калган. Дөресрәге, Пәйгамбәребез (с.г.в.) үзенең югарыда телгә алынган ике сәхабәсе белән җәмәгате Гайшә (р.а.г.) бүлмәсендә, ягъни вафат булган урынында җирләнгән. Чөнки Мөхәммәд (с.г.в.): «Пәйгамбәрләрне үлгән урыннарыннан башка урында күммиләр»,— дип әйткән булган.

Без гарәп иленә төн иңгәч, сәгать уникедән соң киттек Пәйгамбәрне (с.г.в.) зиярәт кылырга. Янәсе, халык әз булмасмы? Кая ул! Тагын мәхшәр көне күз алдына килде. Хаҗилар ыгы-зыгы килә, берсен-берсе этә-төртә, каберлеккә омтылалар, күзләреннән мөлдерәп яшьләре аккан дин әһелләрен дә күрергә мөмкин. Полицейскийлар төркемләп-төркемләп кенә үткәрә Раудага, ягъни Пәйгамбәребезнең кабере һәм аның мөнбәре арасындагы урынга. Аны җәннәт

бакчасы дип тә йөртәләр. Бу мәйдан җәелгән келәмнәрнең төсе белән аерылып тора икән. Алар мәчетнең башка өлешендә кызыл булса, биредәгеләр яшел төстә. Келәмнәрнең төсе әһәмиятле, чөнки Рауда белән мәчет мәйданы арасында стена да, пәрдә-мазар да юк.

Мөнә без, кысыла-кысыла, изге Раудага үттек. Мөнбәр янында, Аллаһының Илчесе торган урында намаз укырга тиеш булабыз. Халык мичкәдәге балык кебек, хәтта гәүдәне кыйблага таба бору мөмкин түгел. Шундый шартларда, ничек кирәк алай, тиешле тәхиятүл-мәсҗид намазын укыдык, теләкләребезне ирештердек. Аннары Пәйгамбәребез (с.г.в.), аның сәхабәләре Әбү-Бәкер һәм Гомәр (р.А.г.) каберләре алдына килеп, артык кычкырмыйча һәм бик шыпырт та итмичә, тыйнаклык белән сәламнәребезне җиткердек. Сәламнәр тексты утызга якын. Аларның барысын да истә калдыру яки укып чыгу мөмкин түгел. Шуна күрә без, диндә башлангыч белемлеләр, кат-кат «Әс-Сәламү галәйкә йә Расүл Аллаһ, әс-Сәламү галәйкүм йә Нәби-Аллаһ» («Сәлам сина, әй Аллаһының илчесе, сәлам сина, әй Аллаһының Пәйгамбәре») дип кабатладык.

Мөнә шулай, Аллаһының Илчесен зиярәт кылып, күңелдәге хисләрне сөйләргә сүзләр таба алмыйча кунакханәбезгә кайттык.

Әмма икенче көнне күңел тынычлыгы бозылды.

– Тәлгат абый, – диде тумышы белән Чирмешән районының Утыз Имәни авылыннан булган, хәзер Чаллыда гомер итүче бүлмәдәшем Хәмит туган,– кичә син, намаз укыганда, кыйблага борылып бетә алмаган идең. Дөрес булып бетмәде шикелле, күңелдә ниндидер төер калды. Бүген янадан барып, бергәләп зиярәт кылыйк,– диде.

Җавапка рәхмәттән башка сүз таба алмадым. «Кешенең кем икәнен беләсең килсә, өч көнлек сәфәргә чык»,– дип бик белеп әйткәннәр шул. Икенче юлы таң алдыннан киттек Пәйгамбәребез (с.г.в.) каберенә һәм зиярәтне җиренә җиткереп кылып, җанны-калебне тынычландырып кайттык. Чөнки гамәлләр ихлас күңелдән һәм дөрес итеп үтәлсә генә, хаҗи яки хаҗия буласың диелгән бит. Аллаһының Илчесе Пәйгамбәребезгә (с.г.в.) һиҗрәт кылу (Мөхәммәднең Мәккәдән Мәдинәгә күчеп килүе – 622 елның 16 июле – мөселманнарның ел исәбе башланган көн) һәм яшәү өчен сайлап алынган һәм шушында мәңгелеккә калган мөбарәк шәһәрдә без өч кенә көн булдык. Шуна күрә барлык намазларга да мәчеткә йөрдек. Җеназа намазы да бик еш укылды (мәетләр күп булгандыр инде). Сәҗдәгә китеп торыла торган тынлык вакытында тагын шуңа игътибар иттем: барлык хаҗилар да диярлек йөткерә. Ныклап авыручылар күбәйде. Чөнки мәчетләр эчендә зур кондиционерлар урнаштырылган, бина эчендә һәрвакыт үтәли җил йөри. Кунакханәләрдә, автобусларда да шундый ук хәл. Тирләгән-пешкән кешегә болай да салкын тиз тия. Хаҗның башыннан ахырына кадәр чирләп йөрүчеләр, кайткач та авыручылар булды. Кыскасы, һәркайсыбыз бу кизүне кичердек.

Төркемебез җитәкчесе Рамазан хаҗи белән Пәйгамбәребез (с.г.в.) мәчете янындагы зур зиратка да кереп чыгарга ниятләдек. Ул ике метр биеклектәге таш коймa белән әйләндереп алынган, тимер капканы полицейский саклый. Кыскасы, бездәге кебек теләсә ничек кереп-чыгып булмый икән болар зиратына. Бераз гарәпчә белгән Рамазан хәзрәт сакчыга аңлатып та, үтенеп тә карады. Әмма тегe сынмады.

Күңелең дөрес булса, Аллаһ барыбер ярдәм итә, җаең китерә ул. Икенче бервакыт, шул тирәдә йөргәндә, зиратка мәет алып кереп барганнарын күрдем һәм җайлап кына әлеге төркемгә иярдем. Шәригать кануннары тулысынча саклана икән бирелә: бернинди чардуган да, аларга эленгән ясалма яисә утыртылган чәчәкләр дә, язулы яки чокып ясалган портретлы һәм фотосурәтле кабер ташлары да, бюст-һәйкәлләр дә, утыра торган эскәмияләр дә күренмәде. Комлы-ташлы, гранитлы җирне чоку да җиңел түгелдер, билгеле. Кабер казучылар эшләрен бетереп киләләр иде инде. Мәрхүмнең җәсәден тәфсилләп урнаштырдылар, бездән аермалы буларак, ләхет кебек җирне яндырылмаган чи кирпеч белән капладылар. Соңыннан кабер өстенә ярты метр биеклектә ком-таш өелеп, баш һәм аяк очына берничә гади таш куйдылар. Башка каберләргә дә күз салдым, алар да нәкъ шундый иде. Кайда кем күмелгәнен сан белән

билгеләнгән махсус белешмәләрдән беләләрдер. Авырып яки башка бәхетсезлеккә очрап үлүче хажи һәм хажияләр дә бирелә жирләнә икән. Шуна күрә изге сәфәргә чыгучыларга алдан ук якыннары белән бәхилләшү киңәш ителә.

...Менә Ислам динен тарату үзәгенә әйләнгән, Пәйгамбәребез Мөхәммәдне (с.г.в.) авыр вакытта үзенә сыендырган һәм җәсәден үз жирендә саклаучы изге һәм игелекле кала Мәдинә-Мөнәвәрәдән китү сәгатьләре сукты. Зәмзәм суларыбызны һәм сумкаларыбызны кабат кунакханә алдына чыгарып тездек, аларны йөкче егетләр автобус төбәсендәге махсус урынга менгереп төйиләр, төшеп калмаслык итеп бәйлиләр. Килгәндә бер автобустагы багажлар таралып, юл буена чәчелә башлаган, андый хәлләр дә булгалый икән.

Без, Аллага тапшырып, кайту ягына юл алабыз. Автобусыбыз кешелекнең, ягъни мөселманнарның гына түгел, барлык дин кешеләренең дә анасы Хәваның (р.) кабере урнашкан Жиддә шәһәренә кузгалды. Шунын аэропортыннан башта Дубайга, аннары Казанга очачакбыз.

Туган якны сагыну көчле булса да, күнелдә монсу хисләр. Үз гомеремдә күп жирләрдә, шактый илләрдә, шәһәрләрдә булдым, елга-дингезләр гиздем, хәтта Үле дингездә дә коендым, әмма дөньяда рухи азык бирүче, җанга рәхәтлек өстәүче бердәнбер урын — шушы изге шәһәрләр Мәккә белән Мәдинә икән. Кичерешләремне язып та, сөйләп тә анлата торган түгел. Болай дигәч, елмаеп куючылар да булыр. Анысы да табигый. Чөнки бу жирләрне үз күзең белән күрергә, жаның-тәнең, калебең белән тоярга кирәк.

Әлбәттә, бер ай дәвамында күнелдә юшкын калдырган тәэсирләр дә булмады түгел. Юшкын турында сүз чыккач, сәфәрдәшем Фәрит Минсәгыйть улы кыска гына, чын бер хәл турында сөйләп алган иде.

...Яһүд милләтеннән булган ике гаилә кунак-кунак уйнарга ярата икән. Чираттагы сыйланыштан соң, икенче көнне табын хуҗасы:

— Авраам, карале, кичә сез кайтып киткәннән соң бер алтын кашыкның юкка чыгуы ачыкланды бит әле,— дигән.

Авраам шунда ук рәнжи-рәнжи аклана башлаган:

— Син нәрсә! Ничек оялмыйча миңа шундый нахак бәла ягасың! Ничә еллар буе дус булып йөрибез, житмәсә! Кеше түгел икәнсең! Бүтән сөйләшмим дә мин синең белән!

— Алай бик чәпчемә әле, Авраам дус, — дигән тегесе. — Соңрак алтын кашык табылды ул табылуын. Юганда читкә төшеп киткән булган. Әмма барыбер күнелдә сиңа карата «осадок» калды,— дигән.

Гарәбстан ярымутравында булган андый «осадок»лар да олы һәм тирән кичерешләр янәшәсендә бик тә бәләкәйләнеп, хәтта мәгънәсезләнеп кала. Чөнки бирелә син күбрәк үткән хаталарың һәм киләчәк яшәешең өчен җаваплылык тоясың. Ничектер, Аллага якынайгандай, турыдан-туры әңгәмәгә кергәндәй буласың. Кылган гөнаһлы адымнарың искә төшеп, уңайсызланып китәсең. Шуңа күрә юкбар юшкыннарны язарга да, сөйләргә дә жыенмыйм. Сер булып эчемдә калсыннар да, үзем белән бергә бакыйлыкка китсен алар.

## Юлдагы уйланулар

Янадан унбер меӊ чакрым биеклеккә күтәрелдек. Бу минутларда барлык хажи-хажияләр дә күнелләреннән иминлек һәм саулык сорыйлардыр, ата-аналары, җәмәгатьләре, балалары-оныклары, якыннары, күршеләре, хезмәттәшләре, гомумән, халкыбыз, илебез, Татарстаныбыз, туган-яшәгән жиребез өчен дога кылалардыр. Изге жир белән аерылышу җинел булмады, билгеле. Шушы бер ай эчендә бирелдәге мохиткә шулкадәр ияләштек ки, әйтерсең, гомер буе матур, моңлы азан астында, биш вакыт намаз белән мөселман кешесенә хас гамәлләргә буйсынып яшәгәнбез...

Хаж кылу саулык, сабырлык, игътибарлылык, чыдамлык сораучы бик четерекле сәфәр икән. Ул ял йорты да, курорт та, турист сәфәре дә түгел. Дөм сәламәт булмаган кешегә Хаж кылу аеруча авыр бирелә. Шуна да янадан барсам иде дигән теләк белән кайтмадым, төрле ырым-йолаларга да мөрәжәгать итмәдем. Кайберәүләр



*Татарстан хаҗҗилары байрагы Т.Нәҗмиев кулында*

дингез белән саубуллашканда янадан күрешүне сорап акча ташлый бит. 2013 елның җәендә, олы сәфәргә чыкканчы, Сочида ял итәргә насыйп булды. XXII Кышкы Олимпия уеннары узачак объектларда, төрле паркларда, И.В.Сталинның Сочидагы дачасында, Красная Поляна авылында булу, канат юл белән «Роза Хутор» тау очына күтәрелү, Абхазиягә чыгып, Рица күленә менү күңелләрдә мәңге онытылмас хисләр калдырган иде. Болары сүз уңаеннан гына саналып кителде, төп фикерем башка – дингез белән саубуллашу иде бит...

...Пляж буйлап, суга таба бер ханым атлый. Күзендә – монсулык. Үзе гел: «Полтинник булмады, полтинник булмады»,– дип кабатлый. Диңгезгә ташларга илле тиенлек – бакыр акча таба алмаган икән ул. Авыррак тормышта яшәп, очын очка чак кына ялгап баручы булгандыр инде бу ханым. Эченнән нәрсәдер укып, кулларын өскә суза-суза нидер сорады да, бер сумлык тимер акчаны дингезгә «чупылдатты» һәм кирегә таба борылып, ярга таба атлый башлады. Шул мизгелдә комлыкта нәрсәдер күреп, аска иелде ул. Илле тиенлек акча тапкан икән. Шуннан соң әлеге ханым бөтен яр буена ишетерлек итеп:

– Ходай Тәгалә сдача бирде, – дип, сөенеченнән кычкырып җибәрде.

...Мин үземнең менә шундый уйларым белән бергә күкнең җиленче катында очам. Алдагы пассажирның кәнәфие артына урнаштырылган компьютерлашкан мәгълүмат экранына күз салгалыйм. Аңа күктәге һава температурасы, очкычның күпме биеклектә булуы, үтелгән һәм кайтасы юл вакыты күрсәтелеп бара, Аллаһ рәхмәте. Күңелгә шикле уйлар да килеп китә. Зәмзәм суы Ватаныма барып ирешерме? Күпме якыннарым, дусларым, хөрмәт иткән кешеләрем көтә бит аны. Кечкенә йотымнар белән булса да авыз иттерәсе бар. Сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в): «Җир өстендә булган суларның иң хәерлесе – зәмзәм суы. Ул ачыккан кешегә ризык, авыртуга шифадыр», – дигән үзенең бер хәдисендә. Бөерләрем авыртканга, дөресрәге, операциядән соң бер ел буе бандаж кимичә йөри алмадым. 17 миллиметр озынлыгындагы сулы шеш (киста) барлыкка килүен күрсәтте соңгы томография. Мәккәгә килеп, ике-өч көн зәмзәм суы эчкәч, бөер борчуы бетте бит, әй. Бандажны салып куйдым һәм бүтән кимәдем. «Исән-сау кайтып житсәм, янадан УЗИга барып тикшертермен әле, нинди тылсымлы хикмәт булгандыр», – дип тә уйлап куйдым. Ә багаж бүлегендә кайта торган зәмзәм суы өчен борчылуым юкка гына түгел, элек барган хаҗиларның әлеге кучтәнәчләренең югалу-буталу очраклары булмаган түгел. Зур сумкадагы бүләкләрнең дә кайтып җитүе кирәк. Мин үзем әллә ни күп әйбер җыймадым. Дөресен әйткәндә, чүпрәк-чапрак ала белмим. Шуңа күрә нигездә сувенирлар – түбәтәйләр, баш яулыклары, дисбеләр, мәчет күренешләре, хаҗ ислемайлары кебек истәлекле әйберләр алгаладым. Үч иткәндәй, кесә телефоным эшләми башлады шунда. Мәккә төсе булсын дип, заманчаракны сайладым. Әйе, әйбер сайларга мөмкинлекләр зур гарәп илендә. Шәһәр гел кибетләрдән генә тора диярсең. Тышта чыдамаслык эссе булганда да, биредә гел җилләп торган салкынча һавалы, ялап алырлык ак мәрмәр ташлар җәелгән әллә ничә катлы, эче алтын-көмеш, башка төрледән-төрле товарлар белән тулган европача байлар кибетләре

бихисап. Сатучылары ир-атлар. Шәп итеп киенгән сәүдә комплекслары хуҗалары үз кадерләрен үзләре белеп, вәкарь белән, горур кыяфәттә йөри.

Гади итеп әйткәндә, урам кибетләре бихисап икән. Бөтен кеше сату итә. Җиргә бер чүпрәк җәеп куялар да, өстенә вак-төяк товарларын тезәләр. Шул тирәдә үк бер көтү балалары уйныйлар, йоклыйлар, ашыйлар. Кыскасы, кайда куыш-буш урын бар, бөтенесе сәүдә ноктасына әйләнгән. Сатыласы әйберләр барысы да аяк астында. Монда да Кытай товарлары басып алган. Хәтта намазлыклар, Әл-Хәрам, Пәйгамбәр (с.г.в.) мәчетләре тукылган келәмнәр дә шунда эшләнгән, түбәтәй, дисбеләрне әйтеп тә торасы юк. Сатулашу мөмкинлеге зур. Биш-ун риалга (бер риал безнең акча белән 8–10 сум) төшәләр дә. Берәү егерме риаллык нәрсәнедер унбишкә сорады. Сатучынын киметәсе килмәде. Теге унбиш риалын калдырып, товарны алып китә башлаган иде, сатучы: «Харам, харам»,— дип кычкырды артыннан.

Урамдагы, хәтта куышкарак кереп урнашкан үзәктәге һәм базарлардагы кибетләр төнгә бикләнми, пленка белән генә каплана, йә бау гына тарттырыла. Ә менә биш вакыт намаз вакытында, азан янгырый башлауга, сәүдә бөтенләй туктый. Мин, үтеп барганда, урамда сатып утыручы негр хатыныннан төгәл акча белән бер түбәтәй сораган идем, бирмәде. «Намаз, намаз», — дип мәчеткә таба күрсәтте. Гомумән, намаз вакытында сатылган товар акчасы хәрәмгә керә, мөселман кешесе бу сүздән бик курка икән.

## Иң мөһиме – аклау һәм саклау

Менә шулай Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.в.) эзләренә басып йөреп, анын һәм сәхабәләренең каберләрен зиярәт кылып, башка барлык тиешле сынауларны үтеп, рухи һәм җәсади яктан сәламәтлек алып кайтып киләбез. Монда ук күпләр рәнҗеткән кешеләреннән гафу үтенә, шул ук вакытта үзләре дә зыян салучыларны кичерә, гомумән, хаҗи тиешле гамәлләрне үтәүче генә түгел, үзен кулда тотарга, кемлеген, алга таба яшәү рәвешен аңлаган яки аңларга тырышучы кеше булып кайта. Мәккәгә ун-унбиш мәртәбә баручылар да бар. Әмма хаҗны әллә ничә кылсаң да, анын беренчесе фарыз, калганнары нәфел хаҗы булып санала икән. Безнең күрше төркемдә дә унынчы тапкыр килгән 85 яшьлек әби барлыгын әйткәннәр иде.

Әмма исән-сау әйләнеп кайткач, ин мөһиме – хаҗи исемен аклау һәм саклау, диделәр. Бу хакта Мәккә каласында махсус оештырылган вәгазьләрдә дә кат-кат ассызыкланды. Башкаларга «мин – хаҗи», «мин хаҗда булган кеше» , «мин хаҗда вакытта» кебек сүзләрне еш әйтүдән саклану сорала. Хаҗ телендә түгел, эшеңдә булырга, алга таба саф күңел, чиста гамәлләр белән яшәлергә тиеш икәнсен. Шулай булмаганда, күңелсез хәлләр дә килеп чыгарга бик мөмкин. Менә шушы урында кызык өчен түгел, гыйбрәт өчен кечкенә генә бер мисал да китерәм. Кайдан укыганымны теркәп куймаганмын. Эчтәлеге якынча болайрак:

...Житмеш яшьлек намаз әһеле Заһидулла карт Хаҗдан кайткач, чәчен җирән төскә – кына (хна) белән буйый (кайсыдыр ил мөселманнары Мәккәгә төркемнәре белән сакалларын шул саргылт кызылга буяп килгәннәр иде), сакал-мыегын кырып ташлый. Теш куйдырта, энәдән генә төшкән кәчтүм-чалбар, күлмәк-ыштан алып җибәрә. Кершән кебек ап-ак күлмәккә чем-кара бантик та эләктерә. «Житмеш яшьлек егет чак дип, бабай йөри тансыга»,— дип җырлыйлармы әле? 45 яшьлек тол хатын белән танышып ала Заһидулла карт. Парлап ресторанга китә болар. Рәхәтләнеп күңел ачалар. Әмма... Кич кайтып, балконына чыккач, картны яшен суга...

## Туган җирем – җәннәтем

...2 ноябрь көнне көндезге өченче яртыда барыбыз да исән-сау Казан аэропортына төшеп утырдык. Без бик тә бәхетле идек. Чөнки бу изге сәфәр вакытында тимер очкычлар белән дүрт тапкыр күтәрелеп, дүрт тапкыр җиргә кабат орындык. Дөнья булгач, үкенечле хәлләр дә очраштыргалап куйгалый бит. Жиддә аэропортыннан самолёт өскә күтәрелгән вакытта бер хаҗиебыз – өлкән яшьтәге бабай җан биргән. Анын җәсәден җиргә – мәңгелеккә калдыру өчен кире төшергәннәр. Чөнки изге җирдә фани дөнья белән хушлашу саваплы үлемнән санала.

Мәккәгә быел да Мәскәү туры белән баручылар булган. Узган гасырның сиксәненче елларыннан берле республикабызның «Татсельхозхимия» тармагын җитәкләүче Салихҗан хаҗи Кәлимуллин утырган самолётның Казан күгендә шассилары ачылмаган. Очкычны Идел елгасына – су өстенә төшерү варианты да уйланыла башлаган була тиешле хезмәтләр тарафыннан. Хаҗилар, Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорап, бердәм рәвештә дога кылырга тотынганнар. Һәм, Ходайның рәхмәте беләндер инде, шассилар ачылып киткән...

...Каршы алучы улым һәм каениш белән зәмзәм сулы тартмабызны һәм багажыбызны алып, һавага чыктык. Ноябрьнең шыксыз көзге көне иде. Әмма шундый ямьле булып тоелды ул минутлар. Башта туган җиребезнең – кечкенә генә җәннәтебезнең саф һавасын туйганчы суладым. Күзнең пычраклары да матур булып күренде. Дөрестән дә, дүрт фасыллы оҗмахта яшибез икән! Үз табигатебезгә җитми, билгеле, беренче кардан атлап китүләр генә дә ни тора?! Кыштан соң яшәргә көч бирә торган язны, аннары чәчәкле-җиләкле җәйне көтә башлый бит күңел...

## Йомгак

Туган җиргә кайтып, бераз ял иткәч, ерак сәфәрдә бергә булган бүлмәдәшләр юксындыра башлады. Хәзер алар белән элемтәдә торабыз, дини бәйрәмнәр, туган көннәр белән котлашабыз. Ярар, юлдашлар белән телефоннан хәбәрләшеп тә була, ә менә илаһи җир – бормалы Мәккә урамнарын, азан эчендә талгын гына тибрәлүче Мәдинә каласын, сусыз, такыр, мәһабәт таулар илендәге Әл-Хәрам, Пәйгамбәребез (с.г.в.) мәчетләрен күңел генә түгел, җан сагына икән. Аларны да күз алдына китерү җае табылды. Сихри Мәдинә шәһәреннән (монда этләр дә өрми, кешеләр дә сүгенми диләр) китәр алдыннан түгәрәкләп төрелә торган Әл-Хәрам һәм Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.в.) мәчетләре картиналарын сатып алган идем. Исән-сау кайтып хәл алгач, менә шуларны затлырак рамга утырттырдым да, өебезнең түренә – телевизор өстенә урнаштырдым. Әлеге рәсемнәрнең аскы өлешенә 2010 елда үзебез булган Әл-Әкъса мәчете фотосын да өстәдем. Хәзер ятсам-торсам, йә язу өстәле артына утырсам, карашларым Мәккә, Мәдинә һәм Иерусалим калаларындагы дөньякүләм билгеле булган, I–II–III дәрәҗәдәге шушы өч мәчеткә юнәлә һәм, ни хикмәттер, яшен тизлеге белән, телевизор экраннарында кебек, шул изге сәфәрләр күз алдыннан үтеп, җан тетрәп, күңел язып кына аңлатып булмый торган тирән канәгатьләнү кичерә...

Бөек Хаҗ иленнән зәмзәм суы гына түгел, рида һәм изар дип аталган теге йомшак ике кисәк тукыманы да алып кайттык. Изге сәфәрдә булучыларны шул ихрам киемнәре белән җирләүләре турында ишеткәнем бар иде, бу хакта гыйлемле хәзрәтләрдән дә сорадым. Ихрамнан чыккач, рида белән изарны әйбәтләп юган идек. Өйгә кайткач, тагын бер мәртәбә кер юу машинасы аша уздырып, зәмзәм суы бөркеп куйдык. Менә шулай, мәңгелеккә китә торган ап-ак, йомшак (махер сөлге кебек) «күлмәгем» әзер. Дүрт мең чакрым җирдән кайткан ихрам киемнәре гәүдәмә генә түгел, җаныма да бик якын һәм кадерле минем, юк-юкта ун тәүлеккә якын газиз тәнемдә йөргән кәфенлек бит ул... Аллаһ безләрдән разый булып, хаҗларыбыз кабул булсын иде!..

**Талгат хаҗи НӘҖМЕТДИН,**
*Байлар Сабасы – Казан – Дубай – Җиддә – Мәккә – Мәдинә – Казан – Байлар Сабасы*

**Редакциядән:**
*Журналыбызның якын дусты, каләмдәшебез Талгат Нәҗмиев әлеге язма матбугатка әзерләнгәндә арабыздан бакыйлыкка күчте. Аның якыннарының, гаиләсенең авыр кайгысын уртаклашабыз.*

# ШУНЫҢ БЕЛӘН ШУЛ... ВОКЗАЛДАН ЯЗАМ

МЕМУАРЛАР

Иртән Виктор Гофман сугылып чыкты, почтадан мина дип сакланган газеталарны китергән (Малеевкада да матбугаттан өзелмәдем, һәрдаим язылып бардым). Каһвә (кофе) тәкъдим иттем, «Варцихи» грузин коньягын салып бирдем. Ул вакытка каһвә данынын илгә таралганына унлап ел узган булгандыр, бер банка тиз эрүчән каһвә табу сират күперен кичүгә тиң иде, моны хәзер күз алдына да китерү мөмкин түгел – ә безгә Һиндстаннан иң түбән сыйфатлы каһвә кайта иде югыйсә. Ләкин мин Малеевкага киткәнче ким дигәндә берәр атна «Пекин» кунакханәсендә яшәп алгаладым, ә анын өченче һәм алтынчы катларында гаҗәп бай буфетлар эшләде – бирегә, әлбәттә, чит-ятларга керү каттый тыела иде...

Әйе... Кыскасы, Малеевка донжуаны Гофманны «Юлиус Мейл» каһвәсе белән сыйладым. Ул рулетканы уйлап та бирмичә, йотлыгып-йотлыгып Борис Парамоновнын мин кичә тынламый калдырган тапшыруы турында сөйләп китте – фәкыйрегез өчен моннан да авыррак газап юк иде! – Виктор җан ярама тозны чеметем-чеметем генә түгел, учлап-учлап сипте; өстәвенә, бу тозны кытыршы сөлге белән яхшылап уып та куйды – бүген, иртәгә, берсекөнгә нинди кызыклы тапшырулар житкереләчәген санап узды. Дустым, әлбәттә, мине котыртырга, күңел кылларымда уйнарга теләмәгәндер – андый кеше түгел Гофман...

Хушлашканнан соң мин озак вакыт мингерәп утырдым әле, газеталарга да кагылмадым, язу өсталенә дә якынлашмадым – «Нишләргә?» дигән мәңгелек сорау бәгыремне бораулапмы-бораулый иде. Монарчы сәгать кебек төгәл барган тормышымның өч көн эчендә асты-өскә капланды. Озак утырдым шулай, ахырдан анык фикергә килдем: уенны хәзер үк ташларга кирәк, кем әйтмешли, болай яшәргә ярамый! Төшке аштан соң һава сулап кергән арада үз ниятемне Игорьга да житкерергә ниятләдем – Головановның нинди фикердә калачагы мине гомумән борчымый иде инде; артык күп нәрсәне югалта башладым, аннары, урынымны алырга теләүчеләр дә буа буарлык, ә крупье булу, беренчедән, егәремнән килми, икенчедән, теләгемдә дә юк.

Шулай итеп, иннәремнән авыр таш төшкәч, тыныч күңел белән бәянымны язып бетерергә утырдым (беркадәр гомер үткәч бу әсәрем Ташкент комсомолы премиясе белән бүләкләнде). Яхшы гына эшләп алдым, ара-тирә бүленмичә дә булмады, дөрес. Игорьга ничек кенә итеп рулеткадан бизүем турында әйтергә икән? Бик сак кыланырга кирәк – Волгинны һаман да нәрсәдер уенга бәйләп тота иде әле, ул, һичшиксез, китмәвемне үтенәчәк һәм мин аңа каршы төшә алмаячакмын.

Язучыларның төшке ашы һәрвакыт шау-шулы уза иде, мона, бәлки, шул сәгатьләрдә генә эшләгән буфет та сәбәпче булгандыр – каләм әһелләре аны сарып ала, ә аеруча сабырсызлар чиратсыз үтә – монда, телефон төбеннән аермалы буларак, андый «оятсызлык» рөхсәт ителә иде. Мин чәнечке-калакларның тәлинкәгә сак кына кагылып узган тавышын, йомшак кына башланып гүләүгә күчкән әңгәмәләрне, кемнендер кычкырып көлеп җибәрүен, тыз-быз йөгереп йөргән официант кызларны ярата идем, ул кызларны әледән-әле чакырып кына торалар – электричкага ашыгучылар бигрәк тә тынгысыз кылана. Зал кайный, гөрләп тора, ләкин – гаҗәп! – мондый хәл ни иртәнге, ни кичке ашта кабатланмый...

*Ахыры. 2014 елның 7нче саныннан басылып килә.*

Игорь залның икенче башында туклана. Ул миннән иртәрәк ашап бетерде дә, яныма килеп сорады: тамак ялгаганнан соң Глуховога кадәр сәйран кылып кайтырга теләгем юкмы, янәсе. Ризалаштым — барысы да мин уйлаганнан яхшырак оешып бара иде...

Игорь, вәгъдәсен онытмыйча, юл буе Георгий Иванов турында сөйләде, әле иртән генә Гофманнан ишеткән мәгълүматны мин янадан йотлыгып тыңладым, хәер, дөресен танырга кирәк, Волгинның хикәяләве тирәнрәк тә, баерак та иде, ул Виктор әйтмәгән бик күп мөһим детальләр өстәде — мөгаен, Борис Парамонов тапшыруында да бу фактлар телгә алынмагандыр. Мин Игорьга шулкадәр рәхмәтле идем ки — тәмам жебеп төштем һәм, нәтиҗәдә, ниятемне ачып салып, аның кәефен кырырга базмадым.

Искиткеч бәян белән сихерләнеп, төп корпуска килеп житкәнне дә сизми калганмын, арткы яктан кемнендер безгә эндәшүе генә жиргә тартып төшерде мине. Борылып карасак — туныының төймәләрен дә каптырмыйча, безнең янга Ярослав Кириллович ашыга иде, аның дулкынлануы ерактан ук күзгә ташланды. Ике ара кимеп бетте дигәндә, килеп житкәнче үк, сүз башлады ул:

— Сезгә сугылып чыккан идем әле, таба алмадым, бүген уен булмаячак...

— Ник алай? — дип күнелсез генә сорап куйды Волгин.

— Мәскәүдән шалтыраттылар. Берничә сәгатьтән мине алырга машина килергә тиеш. Американнар чакыруы буенча иртәгә Канаверал борынына барам, анда әүвәл ракеталарга багышланган конференция узачак, аннан соң яна ракета күккә күтәреләчәк. Космонавт Береговой белән бергә булачакбыз. Мондый тәкъдимнән баш тартмыйлар. Өстәвенә, элеге проблема буенча чыгыш та ясыйсым бар. Шуңа күрә, берәр атнасыз кәтмәгез...

Жаны-тәне белән якын күргән Нью-Йоркка кабат аяк басу бәхетеннән балкып тора иде ул һәм күз ачып йомган арада юкка да чыкты.

Артыннан бер сүз әйтеп өлгермәсә дә, Волгин кинәт кенә боегып калуын яшереп маташмады. Минем йөрәгем исә куанычтан хәзер күкрәк читлеген жимереп чыгар төсле иде: «Иреклемен!» — дип кычкырасым килде хәтта, әмма тыелып калдым. Язасым бар, дидем дә, Игорь белән саубуллаштым.

Кайры туныымның төймәләрен аягүрә ычкындырып, үзем эчтән нидер көйли-көйли, кышкы бакчадан очып үттем — гомеремдә беренче тапкыр яшь леди Юлия Латынина яныннан узганда, бүген нинди фолиант укыганы белән дә кызыксынып тормадым, Семен Израилевичның бүлмәсеннән чыраен сытып чыгып килүче прокурор киемле, бер капкорсак түрәне аздан гына бәреп екмадым, ишекне ачуга, әле иртән генә «Ни эшлим икән?» дип кара кайгыга батып утырган диваныма аудым.

Ничек шома гына, шәп кенә килеп чыкты бит — мина кыл да селкетергә туры килмәде, шундый зур уныштан соң ничек жырламыйсың да ничек биемисен ди, мондый сәбәп булганда бераз затлы эчемлек каплап куйсаң да гөнаһ түгел! Шулай иттем дә: бер чынаяк «Юлиус Мейл» каһвәсе пешердем, чәркәгә «Варцихи» салдым — тормыш әкренләп үз ярларына кайтты, дип куандым.

Ул кичне, максат итеп куйган биш битемне язып бетергәннән соң, куәтле «Грюндиг»ымны иң яраткан радиостанцияләр ешлыгына көйләдем — үз көенә яшәү ничек шәп икән ләбаса! Мин хәтта йоклар алдыннан һава суларга да чыкмадым — Игорьның кәефсезләгән күрергә һәм рулетка турында сүз кузгатырга мыскал да теләгем юк иде.

Ләкин Голованов Волгин белән мине генә кисәтергә өлгергән булып чыкты, шуңа күрә кичке аштан соң Себер язучылары, алтайлылар, Ярослав Кирилловичның ишекләре бикле икәнен күргәч, бергә жыйналып, бүген кайда уйныйбыз, дип, Игорьның коттеджына бәреп кергәннәр. Волгин исә крупьеның Америкага китүен, ягъни, форс-мажор аркасында казиноның бер атнага ябылуын әйткән, ләкин болар барыбер ышанмаган, күрәсең — уен минем бүлмәгә (ул иркенрәк, унайлырак иде) күчкән дип уйлапмы, ишегемне шакыдылар. Волгин әйткән сүзләрне минем авыздан тагын бер кат ишеткәч, «почвенник», «деревенщик»ларның сөмсере коелды, арада канәгатьсезлек белдерүчеләр дә табылды — имеш, рулеткасын калдырып торса, ни булыр иде инде, берәр ничек ансыз да очына чыгар идек әле. Мин сүз табалмый

кулларымны гына җәйдем, аннары, үземнең бик мәшгуль икәнлегемне белдереп, ишекне яптым.

Гаҗәп, әмма икенче көнне, өченче көнне очрашкач та Игорь ни рулетка, ни Голованов турында искә төшермәде – Аллага шөкер, тынычланган, ахры, дип уйлап куйдым мин...

Игорь рулетка хакында тиз онытса, бу мавыгу Себер язучылары белән алтайлылар хәтереннән җуелмады әле – алар бераздан безгә кырын карый башлады хәтта. Ярты-йорты сылтау тапкан булып, бер-ике тапкыр мина кереп чыкканнарыннан соң гына төшендем: баксаң, Игорь белән икебез генә качып уйный дип уйлаулары икән! Бу турыда Волгинга хәбәр иткәч, ул дәррәү көлеп җибәрде, чөнки әфәнделәр аңа да шулай сугылгалаган. Шикләнүем рас булып чыкты, ләкин без бу турыда сүз кузгатмадык: рулетка – безнең өчен кичәге көн дип үзара килешеп куйган идек гүя.

Голованов әйткән вакытыннан соң тагын ике көн узгач кына кайтты да, үзенең ак «Волга»сына киемнәрен, кирәк-яракларын тутырып, кабат китеп барды – аның чыгышы французларда зур кызыксыну уяткан, аларның Тын океанда, Куру борынындагы космик полигоннарын тәэзекләндергән чагы икән, Ярослав Кирилловичтан үзләренең Галәм академиясендә кинрәк, тирәнрәк чыгыш ясавын үтенгәннәр. Әлбәттә, ял итү, чаңгы, рулетка турында сүз дә булырга мөмкин түгел, без хушлашыр алдыннан хәтта берешәр чәркә тотып куярга да өлгерми калдык (ул безгә күчтәнәчкә монарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән сый – «Джек Дэниелс» дип аталган виски алып кайткан иде).

Голованов киткәннән соң тормыш гомумән элекке агымына кайтты һәм мин бәянымны тизрәк тәмамлау нияте белән яңа башладым, чөнки Ташкентка кайтуыма ук яңа китабымны нәшриятка тапшырырга тиеш идем – ул китап өчен аванс алынган, мин ул зур сумманы Мәскәү юлына, «Пекин»да яшәвемә, фонотекамны, китапханәмне тулыландыруга тоткан идем инде.

Социализм вакытында безнең, язучыларның, гонорарлары мул иде, бер үк хикәя өчен әһле каләм берничә урыннан акча алды – радиодан, газетадан, альманахтан, нәшрияттан... «Борынгы» серләрнең берсен ачам: республика язучылары финанс мәсьәләсендә башкала язучыларыннан өстен иде хәтта – үз төбәгеңдә дөнья күргән китап Мәскәүдә тагын бер кат басылып чыкса, ана каләмхак барыбер беренче китапка түләнгән кебек түләнде – бу, әлбәттә, үзәктәге каләмдәшләребезнең көнчелеген кузгатмый калмый иде.

Иҗат йортында вакыт гаҗәп тиз үтә – язу, чаңгы шуу, һавага чыгу, Борис Парамоновның төнге тапшырулары, татар-башкортлардан алып теләсә-нинди Мәскәү, Урта Азия, Кавказ халыклары, украиннар, молдаваннар компаниясендәге кызыклы мәҗлесләр, өстәвенә, шушы аллә кайдан пәйда булган рулетка – кыскасы, Малеевкадагы гүзәл көннәремнең ахырга якынлашуын сизми дә калганмын. Игорь исемә төшерде – берсекөнгә китәм, диде ул, юлламаны тагын бер генә атнага озайтырга да һичнинди мөмкинлек юк, инде Ярослав Кириллович бүләк иткән вискины нишләтәсе? Бу мәсьәләдә тәҗрибәм зур булганлыктан, мин аның китүен үземнең бүлмәдә «юарга» тәкъдим иттем, Озёровны да чакырсам ярыймы, дип сорадым – Лев Адольфович та Волгин белән бер көнне китәргә тиеш иде. Игорь каршы килмәде.

Ике минем өчен бик кадерле, бик якын кешене озату хатирәсе мәңге истә калырлык булды. Акыллы, тәрбияле, энциклопедик белемле шәхесләр компаниясендә вакыт уздыру ничек рәхәт, нинди шәп шөгыль, дип әйтәм икән әгәр – белегез, «Джек Дэниелс»дан башланып «Наири» әрмән коньягы белән тәмамланган шул кичәне күз уңында тотам, димәк.

Мине тагын бер кат «агартырга», гыйлем коемны тирәнәйтергә уйлаганнар диярсең – ул кичәдә Озёров белән Волгин бик озак һәм бик күп темаларга сөйләште, рәсми программа буенча укыткан университет профессорлары ике сәгатьлек егерме лекциядә дә ике мәгърифәтле кеше үзара сөйләшкәндә биргән кадәр гыйлемнең уннан бер өлешен дә житкерә алмаслар иде. Акыллы кешеләр янында күбрәк йөрегез!

Игорь китте, без аның белән ике ел күрешмәдек – бәлки, ял итү вакытлары туры килмәгәндер, бәлки, башка эшләр белән шөгыльләнгәндер – белмим, ул вакытта безнең әдәбиятта урын даулап, Валентин Дмитриевич Оскотский сүзләре белән әйтсәк, «үз йөзебезне эзләп» маташкан чак иде.

Көннәрдән бер көнне, җәй башында, кардан арынып янадан яшәргән, яшелләнгән Мәскәүнең бульварлары, мәйданнары кышкы йокыдан уянып чыккан халык белән тулы чакта, кыскасы, шундый ямьле фасылда, «Советский писатель» нәшриятына яна китабымны тапшырырга башкалага киллем мин. Һәрвакыттагыча, «Пекин»да тукталдым да җәяүләп кенә Воровский урамына таба атладым — сөекле Мәскәү төнге янгырдан сон сафланып киткән иде, мондый иртәдә сәйран кылу үзе бер ләззәт. Арнольд Тамм белән очрашуга кадәр сәгать ярым вакыт бар иде әле, шуна күрә, Әдәбиятчылар йортына кереп тамак ялгап чыгарга булдым.

Ресторанның имән залы иртәдән үк тулы инде — бер генә буш өстәл дә юк, йә парлап-парлап, йә төркем-төркем утырганнар. Араларында дәрәҗәле-дәрәҗәле язучылар да бар — алар янына барырга кыймадым, чөнки су өстенә чыккан колмак кебек, күнел төбеннән тел очыма татар мәкале күтәрелде: сыерлар су эчкәндә бозаулар боз ялый. Дөрес, бер өстәл артындагы ир-ат танып алды да куллары белән ишарәләп үз янына дәште, мин ерактан гына итагатьле итеп баш иеп исәнләштем, әмма аларга таба узмадым — гәрчә араларында минем якташым, дустым, романчы Роллан Сейсенбаев та бар иде. Иманым камил: алар өстәленә килеп «кунакладым»мы, бүген «Советский писатель»гә барып житә алмаячакмын, Ролланның күнеле кин, ул мине болай гына җибәрмәячәк, ә Арнольд Освальдович белән күрешми калу — һич ярамый торган эш, икенче шундый очрашуны бик озак көтәргә туры килергә мөмкин, чөнки, кем әйтмешли, «икмәк ашказаны артыннан йөрми». Әнгәмә дә аек баштан барса яхшы. Инде икенче залга узыйммы дигән идем, кинәт тагын кемдер эндәште, борылып карасам — Волгин, аркасы белән утырганга, аны күрмәгәнмен дә, ә минә каршында утырган гүзәл ханымга игътибар итмичә калмадым — затлы киенгән, бик чибәр — минем аны монарчы да кайдадыр күргәнем бар иде кебек. Игорь үзләре янында урын тәкъдим итте. Табыннары мул җәелгән, көмеш чиләктә «Абрау-Дюрсо» шампаны суына... Мин ризык китерергә сораган арада дустым савытларны тутырды, икесенең дә кәефе яхшы — димәк, берәр нинди мөһим, күнелле вакыйганы бәйрәм итәләр дип уйладым. Тост әйтеп торуны беркем дә кирәксенмәгәч, үзем сүз каттым: «Нәрсә өчен эчәбез?» Игорь елмаеп, хәтта ярымшаярып дияр идем, җавап бирде: «Имин генә аерылышкан өчен». Мин кинәт тәмам коелып төштем ки, гаҗәпләнүем иреннәр арасыннан яна сорау булып очып чыкты: «Кем белән?» Әнгәмәгә гүзәл ханым кушылды: «Минем белән», — диде ул. Йөрәгемне ут өттемени, анын күзенә бактым һәм танып алдым: әлбәттә, бу — Зур театрнын ин танылган балериналарының берсе бит!

Мөгаен, бигрәк мәгънәсез, хәтта көлкеле халәттә калганмындыр, шуны сизепме, Игорь дилбегәне тиз арада үз кулына алды: «Әйе, без аерылышуыбызны бәйрәм итәбез, тормышта андый хәлләр дә була — белмисенмени? Хәер, сездә, Шәрыкта, мондый очракта икенче, өченче хатын алалардыр, бәлки — динегез дә, әхлагыгыз дә рөхсәт итә бит...»

Ул шулай дигәннән сон гына күктән төштем: юк, шаярмыйлар. Мин бирелә нинди хисләр өермәсенә, нинди драмага шаһитлек итәм һәм ул драма бик якын кешемә кагыла. Күз алдымда мәхәббәт, мәнгелек мәхәббәт турында кино төшерүче теләсә нинди режиссёрны әсир итәрлек гүзәл пар утыра иде, ханзадә белән хан кызы, алар шулкадәр дә туры килгән, бер-берсен тулыландырып торалар, шулкадәр матурлар, югыйсә — тигезлекне бозып шундый куркыныч сүз атом бомбасыдай килеп төшсен әле: аерылышабыз! Ник? Нәрсәгә? Туктагыз! Ләкин минем берни сорарлык, кинәш итәрлек, юатырлык, ә бигрәк тә — бу адымнарыннан саклап калырлык мөмкинлегем юк иде...

Без берсүзсез генә шампан шәрабы эчтек — анын тәмен әллә сиздем, әллә юк. Сораган ризыкны — безнен ресторанда искитмәле була торган гөмбә жульены белән полякча пешерелгән укборын — тиз китерделәр, рәхмәт төшкере, нәтиҗәдә, өстәл бераз җанланып китте, алар да янадан тәгамгә үрелде.

Мин төрле хәлләрдә калгаладым, әмма бер сүз әйтә, берни кинәш итә, берничек тынычландыра алмый торган мондый халәткә тәүге таруым иде. Бу очракта Одесса яисә француз юморы ярап куяр иде дә бит, ләкин, үкенечкә күрә, мин һичкайчан юньле-рәтле шаяра белмәдем — шуна күрә, Малеевкада «казино» ачылган көндә

Игорь сизеп алган кебек, бүген дә тораташ катып утырырга туры килде. Дөресен генә әйткәндә, каушавым, дулкынлануым аркасында, мин ни рәвешле кузгалып китүемне дә хәтерләмим. Әлбәттә, хушлашырга онытмадым, ансы, балеринага ниндидер матур сүзләр әйтеп, кулыннан үбеп тә алдым әле...

Тамм белән күрешүгә соңга калмадым, шөкер – нәшрият ике квартал аша гына, Яна Арбаттагы XVIII гасыр чиркәве янында иде...

Аннан соң Игорь белән тагын ике ел күрешмәдек без – мәшәкатьләр, төрле мәсьәләләр, вакытны гына түгел, тулаем, гомерне үк алучы романнар... Мин элеккечә Иҗат йортларыннан кайтып кермәдем, әмма юлларыбыз беркайчан да, беркайда да – ни урманда, ни диңгездә, ни кышын, ни җәен – кисешмәде. Дөрес, аның иҗаты күз алдымнан китмәде – шигырьләрен затлы матбугатта, һәрдаим дөнья күреп барган китапларында укып бардым, аларга дәрәҗәле-дәрәҗәле тәнкыйтьчеләр бәя бирә килде, ул мәкаләләрне дә игътибардан читтә калдырмадым, куанычлы хәл – аерылышу Волгинны сындырмаган булып чыкты. Әһле каләмнәрнең, бигрәк тә шагыйрьләрнең тормышын җимерү, бетерү бик җиңел юкса...

Ләкин иҗат кешеләре, хәтта кайберләреннән күптән инде һичнинди унай яңалык көтмәсәләр дә, кинәт үсеп китәргә мөмкин, рәссамнар, көйчеләр, җырчылар, музыкантлар, артистлар, режиссёрлар белән дә шулай була, әдәбиятта исә мондый хәл аеруча еш күзәтелә.

«Юность» журналының бөтен прозасын – Василий Аксёнов, Анатолий Гладилиннан алып Дина Рубинага кадәр – үз куллары аша уздырган Мэри Озерованың сөйләгәнне истә: «А зори здесь тихие» бәянын ул почтадан ала, авторның исеме һичкемгә билгесез 52 яшьлек Борис Васильев дип язылган. Укый башлагач, уртасына да житмичә, баш мөхәррир Борис Полевойның өенә шалтырата һәм иртәгә үк редакциягә килеп менә дигән өр-яңа әсәр белән танышырга кыстый. Борис Полевой да, укып бетермәстән, автор белән телефон аша элемтәгә керә, күз ачып йомган арада Васильевны китерергә машина җибәрәләр. Өч сәгатьтән Борис Львович үзе хөрмәтенә җәелгән табынны калдырып, бик канәгать рәвештә «Юность»тан чыга («Юность» урнашкан бинаның беренче катында «София» исемле искитмәле болгар рестораны бар иде): кулында – әле азагына кадәр укылмаган да әсәр өчен иң югары исәп буенча түләнгән гонорар конверты, күнелендә – әдәби язмышының хәл ителүе куанычы.

Ниндидер әсәрләрне алып атып, бәянны әзер санга кертәләр, ә ике атнадан соң, журнал чыгуга, Борис Васильев – беренче басылуыннан! – танылган язучы булып уяна. Нигә бу турыда сөйләп тораммы? Сабыр итегез. Бераз тарихны искә төшерик...

Безнең Көмеш гасыр була, Толстой була, Достоевский, Тургенев, Гоголь, Чехов, Бунин... Шушы кешеләр аркасында мәгърифәтле Аурупада рус әдәбияты, рус мәдәнияте белән кызыксыну уяна. Совет хөкүмәте Гаребкә үзкыйммәтләр баганасын тагарга тырышты тырышуын, аурупалылар белән американнарның, хәер, бөтен дөньяның дип әйтик, зиһененә А.С.Пушкинны, Л.Н.Толстойны, аннары, исемлек буенча, М.А.Сусловны сеңдереп карады – теләгенә ирешмәде.

Кемгәдер ошыймы бу, ошамыймы, әмма җиһанда иң танылган, иң күп укылган, иң күп басылган рус язучысы – Фёдор Михайлович Достоевский булып чыкты. Ә аны, романнарында юраганы юш килеп баргангамы (бигрәк тә «Бесы»ны хәтергә алыйк), СССРда яратып бетермиләр иде... Мин белгеч түгел, гади укучы гына, ләкин дөньяда аның кадәр тирәнтен, җентекләп, кинкырлы итеп өйрәнелгән бер генә язучыны да – хәтта Нобель премиясе лауреатлары арасында да! – белмим кебек. Бу бөек каләм әһеленә багышланган хезмәтләр шулкадәр күп, ә кайберләре шулкадәр матур, эчтәлекле итеп язылган ки, аларны да авторның үзен укыган кебек яратып, ләззәтләнеп укыйсың. Сирәк очрый торган хәл бу!

**Рауль МИР-ХӘЙДӘРОВ**

# СЕЗНЕҢ ЯЗМЫШ СУГЫШ УТЫ БЕЛӘН ҮРЕЛГӘН

## Мифтах Вәдүт

*(Мифтахов Вәдүт Кәшшаф улы)*

*(1915–1942)*

Шагыйрь. 1915 елның 20 ноябрендә Татарстан Республикасының Сарман районы Яхшы Каран авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. 1931-1934 елларда Лубян урманчылык техникумында, аннан Казан дәүләт педагогия институтында укый. 1939 елдан Питрәч районы Шәле авылында татар теле һәм әдәбиятын укыта.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк М.Вәдүт гади солдат булып фронтка китә. Мәскәү тирәсендәге канкойгыч сугышларда катнаша, шәхси батырлыклар күрсәтеп, полк комсоргы-политругы дәрәҗәсенә күтәрелә. Шушы авыр сугыш шартларында ул коммунистлар партиясенә әгъзалыкка кандидат булып алына. Ул фронттан язган бер хатында, дулкынланып: «Мине хәзер партиягә кандидат итеп кабул иттеләр, кече политрук дигән хәрби дәрәҗә бирделәр. Армия мине үстерде һәм тормышның искиткеч катлаулы күренешләрен күрсәтте», — ди. Ләкин 1942 елның 30 мартында ул батырларча һәлак була. Сугышчан иптәшләре М.Вәдүтнең гәүдәсен зур хөрмәт белән Тула өлкәсе Арсеньев районы Рыдань авылындагы туганнар каберлегенә җирлиләр.

Бу хат һәлак булуына нәкъ өч көн кала химик карандаш белән язылган. Вәдүтнең адресы: 286 кыр почтасы, 1181 СП, штаб. Мифтахову В.К.

**Төхфәт Имаметдиновка**[1]

*Иптәш Имамутдинов!*

*Сезгә һәм барлык язучыларга сагыну сәламе. Мин гөрләтеп немец этләреннән Ватан җирен әрчү эшемдә. Бүген бик уңышлы операция үткәрдек. Политрук Решетняк үзенең бер отделениесе белән 50 фашист солдатын пешерде. 13 не үтерде, икене плен алды һәм раненыйлары бар, ә үзе бер кеше дә югалтмады. 5 автомат, 2 пулемёт һәм 9 винтовка – трофей. Көн саен шулай алга китеш. Күптән түгел Маннур белән очраштык, йөрәкләр бушап китте, аны күргәч, серләштек, сөйләштек. Сугыш мине бик күп нәрсәгә өйрәтте, ләкин язарга вакыт җитми. Исән кайтсак, әзрәк кыймылдарбыз инде. Үзем полк комсомол бюросының җаваплы секретаре булып эшлим. Тормыш шәп.*

*Сагыну сәламе белән: М.Вәдүт.*
*27.03.42.*

(ТР МА. Р-7083 фонд. 1 тасвирлама. 144 эш. 53 бит. Төп нөсхә)

## Касыйм Вахит

*(Вахитов Касыйм Мисбах улы)*

*(1916–1942)*

Шагыйрь. 1916 елның 16 мартында Башкортстан Республикасының Әлшәй районы Нигъмәтулла авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. 1935 елда Дәүләкән техникумын тәмамлап, Искәндәр авылында физика-математика укытучысы булып эшли. 1937 елда Казанга килә һәм Казан дәүләт педагогия институтына укырга керә. Бөек Ватан сугышы башлангач К.Вахит үзе теләп фронтка китә һәм

[1] Имаметдинов Төхфәт Минһаҗетдин улы, Татарстан Язучылар союзы идарәсенең җаваплы сәркатибе.

сугышның беренче айларыннан ук алгы сызыкта сугыша, шәхси батырлыклары өчен медальләр белән бүләкләнә.

Касыйм Вахит 1942 елның 4 октябрендә Сталинград өлкәсендә барган каты сугышларның берсендә батырларча һәлак була. Сугышчан иптәшләре К.Вахитны зур хөрмәт белән Шелемка дигән авыл янындагы туганнар каберлегенә күмәләр.

**Гази Кашшафка[2]**

*Гази Кашшаф ага!*

*Совет кешеләренең башка бер ил кешеләрендә дә булмаган бер гадәте бар, ул да булса кешеләрнең кешеләр турында кайгыртуы. Менә мине дә кешеләр исәбенә кертеп минем хакта кайгыртучы табылган һәм миңа сезнең журналның 12 номерын (41 ел) җибәргән. Билгеле, бу минем бүгенге тормышымда кечкенә вакыйга булмады. 10 айлар чамасы бертөрле китап, шигырь һәм журнал төсе (бигрәк тә татар телендә) күрми торган кешегә 5,5 табаклы журнал тоттыр әле, биредә нинди дер күз алдыма китерә алмаслык комсызлык туарга тиеш. Һәм ул шулай булды да. Журналның бер як тышыннан алып икенче тышына чаклы бер 3-4 кат укып чыктым. Билгеле, шигырьләрнең аз булуы, ә хикәяләрдән оригиналь әз булуы (бары бер) һәм хәрби эпизодлар, истәлекләрдән язучы специаль кадрларыгыз булмау журналны ярлыландыра.*

*Гази ага, әгәр турыдан-туры журналның үзенә килсәк, гомумән, журнал бүгенгенең үзе булалмый, ә бүгенгенең тонык шәүләсе генә, ә бит заман үтү белән әдәби әсәр тормышка якынаюга бара. Шулай булгач, журнал тормышның үзен үк чагылдырмаса да, аның куерак шәүләсе булсын иде.*

*Шигырьләргә килгәндә, Т.Фәттах шигырен яратып укыдым, чөнки ни генә димә, анда һәрбер сугышчының тәкъдире, киләчәге, йөрәге чагылган. Кичә лейтенант Коченов шул эшне башкарган, ә иртәгә миңа туры килмәс дисенме? Мин дә 3 граната һәм 60 патрон белән кулымда карабин йөртәм. Мин аларны соң дошман кулына бирергә йөртәмме? Менә шуларын һәр сугышчы уйлый да «бу шигырьдә минем йөрәк, миемдә рух бар», ди.*

*Мусаның шигырьләре абстрактлаша төшә. Шулай да начар әйберләр түгел. Бигрәк тә, «Окоптан хат» һәм «Госпитальдә» шигырьләрен яратып укыйм. Шигырьләренә караганда, Муса хәрәкәттәге армиядә булса кирәк?*

*Н.Баянның шигырьләр сыек чыга. Ә Исхак шулай ук, шундый Ватан өчен сугыш барганда, шундый шигырьләр белән масса каршына чыгуга батырчылык иткән. Моны бит һәрбер колхозник әйтә ала. Ә шагыйрьнең шагыйрьлеге шуларны художестволы итеп әйтеп бирә алуында. Ә художество сүзләрне рифмага салуда гына түгел.*

*Кавый Нәҗми мәкаләсе матур эшләнгән. Күләменә күрә матур материал туплаган. Сезнең Такташ турындагы материалыгызны бөтен мөмкинлекләре белән кулланырга кирәк.*

*Гадәт буенча, бәлки Хәснигә бәйләнгәннәрдер. Ләкин хикәясе уңышлы. Ахырына тагы да басым ясый төшкәндә, тагы да яхшы булыр иде.*

*Гомумән алганда, шуны әйтәсе килә. Кешеләр көяләр, көрәшәләр, батырлыклар күрсәтәләр, ә шуларны чагылдырып, массаны тәрбияләүдә аз эшлисез. Журналыгызның эчтәлегенә караганда, фронт белән аз элемтә тотасыз булса кирәк.*

*Үземнең хәлгә килгәндә менә алтынчы ай хәрәкәттәге армиядә хезмәт итәм. Шул вакыт эчендә сугышның бөтен дәһшәтләрен үз тиремдә татып үткәрергә туры килде. Язарга вакыт юк, ә материал муеннан. Буа буарга җитәрлек. Шулай да башлап сезгә «Үлем турында баллада» дигән бер нәрсә җибәргән идем. Белмим, ни эшләткәнсездер. «Фронттан хатлар» исеме астында шигырьләр эшләп ятам. 4 хатны эшләп бетердем. Ләкин материалны шигырь итеп үстереп җиткерергә вакыт юк. Шуның өчен сезгә җибәрергә тартынып торам. Ни димә, сугыш – сугыш бит, иҗат командировкасы түгел. Урманда шалашларда, землянкаларда ашыгыч туган шигырьләр сезне канәгатьләндермәсләр төсле тоела. Шулай, Гази ага, менә монда чын-чыны белән поэзия. Исән-сау йөреп кайтырга язса, барын да эшләячәкмен.*

[2] Кашшафетдинов Мингази Солтан улы (1907-1975), тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме.

*Сезнең газеталардан укып белгән хәлләрнең 70% үз күзем белән күреп, йөрәгем белән кичереп уздырам бит.*

*Ярый хушыгыз. Исән күрешүне көтеп,*
*К.Вахит.*
*Адрес: Действуюшая армия; Полевая почта 1641, ОАД-76, 3 б.*
*15/У – 42.*

***P.S.** Казан хәлләрен, язучылар дөньясыннан, театр җәмгыятеннән күп итеп хәбәрләр белән хат көтәм.*

(ТР МА. Р-7083 фонд. 1 тасвирлама. 144 эш. 21, 22 бит. Төп нөсхә)

**Төхфәт Имаметдиновка**

*14.07.42. Хәрәкәттәге армия.*

*Төхфәт ага!*

*Мин сезнең җибәргән хатыгызны 13/УП алып укыдым. Шундый зур мактавын һәм җаваплы бер эшкә миңа да катнашырга тәкъдим итүегез мине бик шатландырды. Шуның өчен сезгә бик күп итеп рәхмәт әйтүдә үземне җаваплы саныйм.*

*Билгеле, бу үткәрелә торган эшләргә, җыентыкларга әсәрләр белән катнашу гаять тә зур шатлык булыр иде. Ләкин бер нәрсә җитми, ул да булса - вакыт. Чөнки хәрби хезмәт – хәзерге сугыштагы радистлык хезмәте үзе яхшы ук җаваплы һәм һәрвакыт мәшгуль булуны сорый торган хезмәт. Шуның өстенә партийный линия буенча күп кенә эшләргә туры килә. Чөнки фронт коммунистларга күп кенә бурычлар йөкли. Гитлерны тар-мар итүне 42 елда тәэмин итүдә һәр коммунист үзен командир белән бер җаваплылыкта тотарга тиеш. Билгеле, бүгенге шул шартларны алганда әдәбият белән шөгыльләнүгә вакыт бик аз кала.*

*Шулай да минем хәзер «Совет әдәбияты»на 15 ләп шигырь җибәрелде. Беренче әдәби җыентыкка шуннан үзегез теләгән шигырьләрне сайлап алыгыз.*

*Икенче җыентыкка материал турында мондый караш: Минем хезмәт иткән частемдә андый исемне[3] алган якташлар юк. Ләкин үзенең хезмәттә курку белмәс батыр артиллеристлар бар. Каһарманнарча сугышу, билгеле, зур хезмәт. Ә бит әле ул герой дигән сүз түгел. Шундый егетләрдән Бөгелмә МТСыннан бер механик – Исхаков дигән егет бар. Фашистларны тукмауда күп кенә хезмәте бар. Әгәр кирәк тапсагыз, шундый егет хакында язарга мөмкин.*

*Өченчедән, «Совет әдәбияты»нда минем әйберләр бар. Шуның өстенә һәр буш минутымны Язу өчен файдаланырга тырышам һәм эшләнгән әйберләрне журналга җибәрә барам. Шул «Фронттан хатлар»ым йөрәк соңгы кабат типкәнгә кадәр дәвам итәргә тиешмен. Яхшымы-яманмы, соныннан күз күрер. Ә бүген алар дары, төтен астында языла барулары белән кыйммәтләр.*

*Шулай, Төхфәт ага! Тиз көндә, ихтимал, давыллы көннәр башланыр. Күп хат язырга вакыт та булмас. Ләкин хатлар язып торыгыз. Сугышта хатлар алып уку рухны күтәрә. Дәрт тудыра. Көч бирә.*

*9 айлап фронт күп кенә тәҗрибә бирде һәм йомшак якларны бетереп ныгырга ярдәм итте. Комсомол үз вазыйфасын үтәп, партиягә тапшырды. Данлыклы Ватан сугышында партиянең тоткан юлында армый-талмый хезмәт итәргә сезгә... коммунистларча сүз бирәм.*

*Исән-сау йөреп, күрешүне көтеп: К.Вахит.*

(ТР МА. Р-7083 фонд. 1 тасвирлама. 144 эш. 73 бит. Төп нөсхә)

*Хатларны һәм искәрмәләрне* **Әлфия ШАМОВА** *әзерләде.*

[3] Советлар Союзы Герое.

# СОРАУЛАРГА ҖАВАП ЭЗЛӘГӘНДӘ...

## РАШАТ НИЗАМИНЫҢ РЕНАТ ХАРИСКА ҖАВАП ХАТЫ

Хөрмәтле Ренат Мәгъсүмович!

«Казан утлары»нда басылып чыккан *(2014, № 3)*, миңа атап язылган ике хатыгыз белән дә таныштым. Татарның ике күренекле композиторы, музыкабыз тарихында тирән эз калдырган Салих Сәйдәшев һәм Фәрит Яруллин турындагы әсәрләремне укыйлармы, укыдылар микән дип борчылган чакларым булмады түгел. Рәхмәт, татар әдәбиятында һәм опера-балет сәхнәсендә ат уйнаткан кешенең вакыт табып уй-фикерләрен әйтеп салуы үзе үк күп нәрсә турында сөйли.

Минa әсәргә карата телдән дә, язмача да фикер әйтүче каләмдәшләрем байтак булды үзе. Матбугатта басылган ике генә хаттан өзек китерик. Казаннан Мансур Җәләлиев: «Күптән көткән идем бөек композиторга багышланган саллы әдәби әсәрнең язылуын һәм басылып чыгуын. Рәхмәт язучыга, рәхмәт «Казан утлары» журналы редакциясенә» *(«К. У.», 2010, № 8).* Мөслимнән Роза Хәбибуллина: «Рашат Низаминың «Сәйдәшнең соңгы елы» әсәрен укып, үзәгем өзелеп, күпме кеше бу әсәрне укып сагышланды икән дип ирексездән журналның тиражын карадым...» *(«В.Т.» газетасы, 2010, санын-көнен язып куймаганмын).*

Чеховның «на критику не реагируют» дигән сүзләрен истә тотып, баштарак мин Сезгә җавап язмаска уйлаган идем. Ләкин әзерлексез укучының (хәтта Айдар Хәлим кебек әзерлекле язучы да канатланып китеп, әнә ничекләр пафоска бирелгән бит!) Ренат Харис язганнарга йөз проценты белән ышанып куюы бар лабаса. Шунлыктан җавап язуны, кайбер аңлатмалар бирүне лазем санадым.

Сез хатларны, бигрәк тә беренчесен, яхшы ният белән язгансыз. «Кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла», дигән сүзләр белән бу ниятегезне ачык кына ныгытып та куйгансыз. Ләкин һәр ике хатта да әсәрнең әһәмиятле якларына игътибар итмичә, фәкать «житешсез» якларына гына басым ясау «нотка»лары күзгә бәрелеп тора. Хәер, жимешсез агачка таш атмыйлар, дигән Нәкый Исәнбәт бабабыз. Сәйдәш турындагы әсәрнең әһәмиятенә, аның иҗаты һәм тормыш юлындагы сикәлтәләр киң катлам укучы өчен кирәкле булуына ни өчен күз йомгансыздыр — аңлашылып бетми. Мин Сәйдәшев һәм Яруллиннар турында язганда каш ясыйм дип күз чыгармадым — чебеннән фил ясамасак иде.

Беренче хаттагы кинәш-тәкъдим-тәнкыйть фикерләре, күп булганлыктан, шактый таралып-сибелеп ята. Мин дә, чәчелеп-таралып китмәс өчен, үземә адресланган сүзләргә җавапны укып бару тәртибендә язарга булдым. Беренчесеннән башлыйк.

Сез Акмулла чичәннең Сәйдәш турындагы роман-кыйсса башына куелган, «Мескен илнең баласына сан булмас», дигән сүзләрнең туры мәгънәсен, әйләндереп салып, бөтенләй икенче төрле шәрехләгәнсез түгелме? Бу канатлы сүзләрдә «мескен халыкның сансыз уллары» дигән мәгънә юк дип саныйм. Шулай да, китапка әзерләгәндә мин ул эпиграфны төшереп калдырдым. *(Рашат Низами. «Без яшибез...» — Казан: Татар.кит.нәшр., 2011).*

Әсәрне укыган кеше автор сүзләренә ышаныр: мин Сәйдәштән төрле «гайбәт» объекты ясамадым. Сез әйткән теге «сверхзадача» әсәрнең кереш өлешендә ачык әйтелгән: «Салих Сәйдәшевнең иҗаты, бөеклеге турында галим-голәмә, музыка белгечләре тарафыннан күп санлы хезмәтләр язылган. Ә менә композиторның тормыш-көнкүреше, гаилә хәлләре, шәхси тормышындагы фаҗигасе, төрле сәбәпләр аркасында җәмгыятьнең кайбер көчләре тарафыннан кире кагылуы хакында ныклап язылмаган диярлек. Әлеге кыйссада мин төп игътибарны әнә шул катламнарга да юнәлтергә тырыштым»:

Ачык әйтелгән булса кирәк. Шул ук вакытта Сезнең белән килешәм дә: көнкүреш детальләрен, анекдот һәм мәзәк хәлләрнең күбесен, чыннан да, төшереп калдыру мәслихәт булгандыр.

Ә.Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе»н һәм үзегезнең «Сәйдәш яры» дигән поэманы уңышлы мисаллар итеп дөрес китергәнсез. Тик бер нәрсәне истән чыгармыйк: әлеге ике әсәр саф әдәби жанрда язылган. Минем язганнарым исә әдәби-документаль жанр кысаларына карый. Документальлек һәрчак чабудан тотып тора. Документаль жанрда героенны «лаклау» мантыйкка туры килмәс иде. Әнә бит Тәлгат Галиуллин да «Мәһдиев йолдызлыгы» дигән китабының кереш сүзендә болай дип яза: «Алдыма куелган максатым — бу олы затны дәреслек битләрендә урын алган «портрет» итеп түгел, аны гади кешеләр кебек ярата, көнләшә, курка, кирәк чакта күзгә төтен җибәрә белә торган, тулы тормыш белән яшәгән, гаилә, дуслык, иҗат бәхетен татыган кеше буларак сурәтләү».

Шунысын да әйтик, Ә.Еники «Сәйдәш бәхетле булганмы?» дигән мәгълүм мәкаләсендә, повестеннан аермалы буларак, каләмен бөтенләй икенче тонда йөгертә һәм фантазиясенә түгел, чынбарлыкка, Сәйдәш мохитенә, андагы каршылыкларга таянып яза.

Сез, яза торгач, бер урында: «Акылым картайгандыр, күрәсең», дип, үз-үзегезне тәнкыйтьләргә дә җөрьәт иткәнсез. Юк, акылыгыз картаймаган, Ренат Мәгъсүмович. Бу очракта, вакыт-вакыт, Сезнең, миңа калса, зур иллә бердәнбер партия яшәгән һәм идарә иткән заманнардагы идеологик шаукымга бирелүегез сизелә. Сез Туфан Миңнуллиндагы «Үзгәрү» (язма исеме) эволюциясен кичермәгәнсез бугай. Бары шул.

Без бит хәзер бүтәнчәрәк җәмгыятьтә, кемнәрдер яратмаган «гласность» пәрдәсе күтәрелгән заманда яшибез. Ленин, Сталин кебек юлбашчыларның да хаталарын, хәтта антигуманистик һәм илгә тирән яра салган гамәлләрен дә ачыктан-ачык әйтеп салган заман бу. Лермонтов 1839 елда ук инде болай дип язып калдырган: «Довольно людей кормили сластями; у них от этого испортился желудок: нужны горькие лекарства, едкие истины». Ә инде минем Н.Җиһанов турында чагыштырмача җиңел әйтелгән сүзләрдән генә бу колачлы шәхеснең орден-медальләре дә, укасы да коелып төшмәстер бит?.. Мин үземне Җиһановка карата тенденциозлык эшләдем дип уйламыйм. Сәйдәшне гомеренең соңгы чорында сигез ел буе (!) эшсез-акчасыз тотканнар икән, бу фактны беркая да яшереп куя алмыйсың инде...

Телибез-теләмибезме, танырга кирәктер: сәнгатьтә дә, тормышта да Моцарт һәм Сальери варианты һәрчак булган. Яшерен-батырын түгел ич, Сезнең дә, минем дә иҗатны һәм шәхесне өнәп бетермәүчеләр бар бит, әмма бу очракта тирәнгә кереп тормаскадыр.

Сез бер урында: Н.Җиһанов җитәкләгән чакта консерватория биргән татар композиторлар плеядасы бармы соң, дигән зур сорау куясыз. Ләкин мәгълүм ки: әдәбият-сәнгать кырында язылмаган шундый бер закончалык бар — талантлар мәйданга дулкын-дулкын булып килә. 60нчы елларда сезнең буын шагыйрьләр «бишлеге», М.Кәрим әйткәнчә, әдәбиятка «шартлау» булып килеп керде. Сәнгатьтә дә ренессанслар гел булып тормыйдыр шул. Бу күпмедер дәрәҗәдә җәмгыятьнең яшәеш пульсына да бәйле.

Әйе, Сәйдәшевнең үз заманында бер генә әсәре дә диярлек дөньяга чыкмыйча калмаган, чөнки даһилыкка киртәләр юк. Әмма фактларның мондые да бар: иҗатташ дуслары-фикердәшләре Кәрим Тинчурин һәм Фәтхи Бурнаш «халык дошманы» итеп төрмәгә ябылгач, илаһи музыка иясе Сәйдәшкә дә кара көннәр килә: кулга алыну куркынычы; әсәрләрен яңгырату кими, гонорар түләнми. Аны еш кына хәерче хәленә төшерәләр.

Шулай да... Бу уңайдан миңа Сәйдәшне машинага утыртмый киткәннәрен, Җиһанов белән гонорар мәсьәләсендә юллары кисешкәнен язмаска, вакланмаска кирәк булгандыр. Килешәм. Икенче басманы әзерләгәндә мин бу якларга, һичшиксез, игътибар итәчәкмен.

Тагын бер урында, Мәхмүт Нигъмәтҗановның уйдырма мәгълүматлары, дигәнсез. Сезнең алымга ияреп, мин дә сорау куяр идем: музыка белгече профессор М.Нигъмәтҗановның «уйдырмалар»ын кире кагардай дәлилләрегез бармы соң?

Болар бик четерекле мәсьәлә, ләкин утсыз төтен чыкмый, дигән сүзне дә онытмыйк. Заманында Рейган СССРны «империя зла» дип атаганы өчен безнекеләр ана аяк терәп каршы чыккан иде. Ә бүген ни күрәбез: Кырымның Россиягә кушылуы унаеннан АКШ һәм Көнбатыш «аннекция» дип лаф ора, Кремль исә «референдум нәтиҗәсе» ди. Ике якта да хаклык бар шикелле. Ә Татарстан референдумы карарыннан ни генә калды соң?

Сез, рәхмәт төшкере, әсәремдәге зур житешсезлекне күргәнсез һәм язып биргәнсез: «композиторны ижат ләззәте кичергән сәгатьләрдә сурәтләргә кирәктер, минемчә». Менә бу чын ихласый киңәш, яхшы ниятле тәнкыйть, ичмасам! Моны кабул итеп була. Әмма мин композиторның тормыш-көнкүрешенә һәм фажигале көннәренә барыбер күз йома алмас идем. Алда әйткәнемчә, әдәби-документаль жанр бит бу.

Ике бөек композиторыбыз арасындагы тагын бер үзенчәлеккә игътибар итәсе килә. Жиһанов, ни әйтсәк тә, рәсми зат, хакимият кешесе, депутат һ.б. Сәйдәшев, киресенчә, күбрәк халык тормышы, аның кайгы-шатлыклары белән яшәгән, гади халык һәм үзешчән композиторлар белән дә аралашырга яраткан, мәжлесләрдә уйнаудан да тартынмаган. Бу аерма аларны якынайта алмаган, күрәсең.

Аларның һәр икесе турында да матбугатта, китапларда һәм истәлекләрдә ифрат күп язылган. Мин шуларга да таяндым. Ә ташка басылган язмалар, гафу итегез, гайбәт була алмый инде. Кайберләре белән генә танышып китик әле.

Профессор Мөхәммәт Гайнуллин Жиһанов турында болай дигән: «Оештыручы һәм житәкче буларак, бу өлкәдә ул, һичшиксез, булдыклы фигура. Музыкаль таланты зур. Аның күләмле зур әсәрләре халкыбыз музыкасының алтын фондына кереп калды инде. Ләкин кирәгеннән артык орденнар, мактаулы исемнәр, рәсми титуллар аңа аю хезмәте күрсәтте бугай... Кайбер талантларның уңышларын күрмәмешкә салышты». Композитор Фасил Әхмәтов: «Әгәр зурлыгы, матурлыгы, музыкаль мирасының әһәмияте ягыннан безнең композиторларны бер сафка бастырсак, иң алда — Сәйдәш һәм Рөстәм Яхин булыр». Мәшһүр дирижер Натан Рахлин Казанга килгәч, Сәйдәш ижатының киштәдә ятуына борчылып, Мәскәүгә хат яза. Хатны Казанга төшерәләр. Рахлинны югарыга чакыртып келәмгә бастыралар. «Шулаймы? Ул чагында бигайбә! Мине болай да инде Киевка чакыралар», — дигәч, өстәгеләр авызын йома. Сез санап киткән дөньякүләм даһиларыбыздан Софья Гобәйдуллина Казанга килүләреннән берсендә, композиторлык юлына мине Сәйдәш ижаты этәрде, дигән фикер әйтә.

Шаккаткыч хәл бит бу: Жиһанов исеме дигәндә берсе дә алай ук егылып китми, Сәйдәш ижатын алга сөрәләр. Мин моның бер сәбәбен шунардан да күрәм — докладлар, фәнни мәкаләләр, диссертация темаларыннан тыш, Н.Жиһановның тормыш юлы һәм ижаты турында әдәби-популяр жанрда язылган әсәрләр юк диярлек. Мин Жиһановның бай дөньясын, музыкасын, ижтимагый зур эшләр башкарганын анламаслык, кабул итмәслек кеше түгел. Аның хакында ЖЗЛ сериясеннән, һичшиксез, китап язарга кирәк. Кем язар моны, бу турыда уйлаучы бар микән?

* * *

Инде икенче хат унаеннан.

Укучы бутала күрмәсен иде: ул хат Ренат Харис тарафыннан композитор Фәрит Яруллинның тууына 100 еллык унаеннан «Чын мирас» журналында басылып чыккан юбилей мәкаләсенә нисбәтән язылган. Ә инде Фәрит Яруллинның тууыннан алып һәлак булган көненә кадәрге гомере турында ЖЗЛ сериясеннән китабым дистә еллар элек басылган иде. Болар — икесе ике хезмәт.

Жавабымның беренче өлешендә мин ике як өчен дә принципиаль булган төп мәсьәләләргә кагылып уздым шикелле. Ә хәзер кайбер аңлатмалар бирү белән генә чикләнергә уйлыйм.

Сез бу хатта, Ренат агай, таякны кеше уйламастай якларга бигрәк тә нык бөгеп жибәргәнсез шикелле. Юбилей мәкаләсенең кирәклеген, андагы мәгълүматны, тарихи фотоларны, унай якларны да күрергә, әйтеп китәргә мөмкин булгандыр ич. Минемчә, бу очракта Сезнең тарафтан алтын урталык табылмаган. Бигрәк тә

кайбер истәлекчеләрнең исемнәре күрсәтелмәгән өчен нык «үпкәләгәнсез», алар сөйләгәнне «гайбәт» категориясенә кертергә кирәк, дигәнсез. Миндә күп алар, кыска гына мәкаләдә мин бөтенесен чыгарып селкергә теләмәгән идем. Профессорлардан — укытучысы Г.Литинский, Фәрит абыйның рота командиры Д.Самойловның миңа язган хатларыннан яисә аларның сөйләгәннәреннән мисаллар китергән булсам, картина бер дә «матур» булмас иде. Алайса, әйдәгез, бер генә хаттан өзек китерик. Ленинградның Киров театрыннан Казанга эшкә күчеп килгән балетмейстер-репетитор Петр Гусев (хәзерендә — профессор) миңа үзенең хатында болай дип яза: «Фарид был прямолинеен, с Жигановым были в недружественных отношениях». Ә инде Галия Кайбицкая, Мирсәет Яруллин, Аяз Гыйләҗев сөйләгәннәрне язудан тыелып калам. Аларын матбугат аша түгел, бер күрешкәндә колагыгызга гына әйтсәм, дөресрәк булыр.

Мәскәү һәм рус темасына тукталып, Сез нигә соң бу унайдан (дөресрәге, миннән) «бүки» ясарга булгансыздыр, бик сәер һәм күпертеп аңлату бит бу. Сез бит тарихны, Худяков һәм Гумилев хезмәтләрен миннән күпкә яхшырак беләсез дип уйлыйм. Татар халкының үткәне һәм бүгенгесе турында борчылып, ачынып, сызланып (андый сызлану Сездә дә бардыр дип уйлыйм) әйткән кайбер сүзләрдән афәткә чакыру, хәтәр юл кебек «гөнаһлар» эзләү хакыйкатьтән ерак тора. Хәтта Тукайның «Тотса Мәскәүләр якан...» дигән образлы сүзләрен дә мәкаләдә урынсыз дип тапкансыз. Публицист Рәфыйк Шәрәфиев «Тукай сыман буласың киләме?» дигән бер мәкаләсендә шагыйрьнең:

*Беләмсез, ни дияр азан:*
*Китте Касыйм,*
*Китте Казан,*

— дигән юлларын китерүе белән, ул да Тукайның сүзләрен үз контекстына яраклаштырган дип бәялик микәнни?

Татарстан җыйган салымның 70 проценты федераль казнага китүен әйтеп тә тормыйм. Минем телемне, мәгариф үсешен (309 нчы маддә) чиклиләр икән, мин моңа борчылам. «Россия — для русских!» дигән шигарьне әледән-әле калкытып торалар, тик аларны тыючы юк. Ә менә мин татарларның татарча сөйләшүен, мөстәкыйльлекне яклыйм дисәм, мине сепаратизмда гаеплиләр. Әгәр эшләр шулай барса, киләчәктә Сезнең һәм безнең китапларны укучы, ай-һай, табылыр микән?

Сез дөрес әйтәсез, безгә башка милләтләрне түгел, үз татарымызны аяусыз тәнкыйтьләргә кирәк. Казан һәм районнарыбыз мәктәпләренә Мәскәү килеп йозак салмаган ич. Укысыннар татарча, сөйләшсеннәр туган телдә, русча да яхшы белсеннәр. Күп нәрсәләр үзебездән, район башлыкларыннан, мәктәп директорларыннан да тора лабаса!

Ренат Мәгъсүмович! Сезнең икенче хатта бер парадокс очратып гаҗәпләндем. Сез «Казан утлары»нда баш мөхәррир булып эшләгән чагында Ф.Яруллин турында роман-хроника язуымны ихластан хупладыгыз һәм журналда бастырып та чыгардыгыз. Әлеге журнал вариантында ук мондый юллар бар иде: «Ләкин театр һәм композиторлар союзы яшь талантны саклап калу мәсьәләсендә тиешле кайгыртучанлык күрсәтмәгәннәр». Сез нигә әнә шул чакта ук миңа карата «уяулык» күрсәтмәдегез икән? Цензурага ышандыгызмы, әллә хәзер бу фактка карашыгыз тамырдан үзгәрдеме?

Ярый, житәр, тукталыйк. Сез һәм мин күтәргән бу темалар аерым бер трактат язарлык мәйдан сорый. Укучылар исә укысын, уйлансын һәм үзләренчә нәтиҗә ясасыннар. Шунысын яхшы беләм: үзенең белеменә карап, эрудиция һәм әхлакый-социаль биеклегеннән торып, берәүләр — Сезне, икенчеләр исә минем фикерләрне хуплаячак. Аннары... Әгәр шушы ике хат язылмаган булса, мин үземнең тырыш, эзләнүчән һәм кызыклы язучы икәнлегемне, бәлки, белмичә дә яшәп яткан булыр идем әле. Рәхмәт.

# БИЮЧЕ НӘГЫЙМӘ

ХИКӘЯ

Сабан туе. Халык гөр килә, көрәш дәрте белән мәйдан кызган, бала-чагалар да уеннарын тәмамлаган, ә бер якта гармун татарча дәртле бию көе сиптерә. Ул көйне тыңлаган бер генә кеше дә урынында басып тора алмас кебек, өздерә лә үзәкләрне бу гармун моңы. Сабантуй аланында көрәштән кала барысы да бер түгәрәккә баскан да бердәм кул чаба, ә уртада бер генә хатын-кыз бии. Җиргә аның аягыннан тып-тып кан тама.

Авыр сугыш елларында ирләр белән беррәттән гүзәл хатын-кызларыбыз да илебез өчен кан койды. Туган яктан ерак җирләрдә башларын салды. Сугыш — хатын-кызмы син, батыр ир-егетме, әллә куркак җанлы ир кисәгеме – берсен дә аямады; ул бары ялагай, сатлыкҗаннарга гына вакытлыча игътибар итте. Ә инде туган якка кайтып, мин батыр, диеп күкрәк киереп йөрүчеләрен авыл халкы хупламады, башка күзлектән карады.

Нәгыймә дә сугышка унсигезе тулыр-тулмаста китеп барды. Ак халат киеп яралылар тирәсендә кайнашасы килмәде аның, «яшен җитмәгән» дисәләр дә, фронтка – алгы сызыкка ашкынды, чөнки әтисенеке кебек кырыс холкы, тәвәккәллеге шуны таләп итә иде. Кулына корал алып, сугышның кызу җирендә ике ел ярым йөргәч, кырык сигезнең июлендә генә тимер таяк һәм агач аяклар белән туган авылына кайтып керде ул. Аның көтәрдәй кешесе дә, газиз әти-әнисе дә инде юк иде. Бары тик әтисе ягыннан туганнан-туган апасы Хәбирә генә бу нигездә җанлылык сизелә башлагач керәсе итте. Хәбирә үзен-үзе: «Туганыңның берәрсе исәндер, кереп хәлен дә белеп чыкмыйсың, Хәбирә тәресе, эчеңдә җаның юктыр!» – диеп сүгә-сүгә кереп барганда, өстәл почмагында туган энесе утырганны күреп инәлеп китте. Текә, кырыс карашлы, чыраенда сабыйлык төсмерләре сизелеп торган туганының кызы Нәгыймәне ул көч-хәл белән генә таныды. Нәкъ шул вакыт, йөрәк түрендәге бер нечкә кыл сулкылдап, туганының моңдый карашыннан куркып, сабыйларча йөзендә бернинди дә шатлык нуры булмаганлыгын сизеп, йөгереп барып аны кочагына алды. Нәгыймә бер мизгел эчендә сугышка кадәрге тормышны һәм Хәбирә апасының очраганда: «И-и, исәнме, үскәнем! Әти-әниеннәр нихәл соң?» – диеп сорашып, һәрвакыт кесәсеннән яки сумка төбеннән берәр әйбер сузганын искә төшерде. Кинәт кенә күңеле йомшарып, күзләре кызарган Хәбирә апасын кочагына алгач, озак кына кысып торды да коры гына: «Рәхмәт!» – диде.

Озын, куе чәчләрен икегә үреп салган, кайчандыр җил-җил атлап йөргән «әйбәт апа» инде бирешкән: йөрешләре авырайган, йөзен җыерчык баскан, күзләрендә мөлдерәмә тулы моң... Яулык астына зур төргәк итеп җыеп куелган теге матур куе чәчләре генә: «Мин әле шул Хәбирә апаң!» – дип әйтә кебек иде.

Күп сораулар яудырып, Хәбирә апасы, «ускәнем» диеп ялгыш ычкындырды да туганының күзенә беркавым карап торды һәм аңлады: аның каршындагы кырыс күзле бу кеше сүзгә мохтаҗ түгел иде. Үсү генә түгел, шушы ике ел ярым эчендә ул ниләр генә күрмәде һәм ниләргә генә түзмәде.

Нәгыймә авыз ачып сүз әйтмәгәч: «Ярар, икенче вакыт керермен», — дия-дия ишеккә таба атлады.

Ә Нәгыймә... аңына килеп күзен ачып җибәрсә, чалкан яткан килеш, сабый чактагы күктә төтен болытларын күрде, борынына сөрелгән җир исе белән бергә әче төтен, дары исе килеп керде. Башкалар кайда икән, дигән уй бер секунд эчендә башыннан йөгереп үтте дә торып басарга ниятләде, ләкин аяклары аны тыңламады һәм тәнендә үзәк өзгеч авырту тойды.

Күз йомылды. Госпиталь. Ыңгырашулар. Саташулар... Аңына килеп, хәлен аңлагач та, Нәгыймә: «Түзәргә!» — дигән ныклы уйны күңеленә беркетеп куйды. Бу уй ана көч өстәде, яшәргә зур өмет уятты. Ике аяк та тез төбеннән тиң юк. Ә күңелдә бары тик бер уй: «Түзәргә!»

Авыр сугыш елларында сындырганчы сыныйм дип, ачлыгын да бирде язмыш.

Култык таяклары белән монда ярамыйсың инде... туган якка кайтырга дигән приказ алды ул.

Ничек инде, ике аяксыз килеш, авылдашларына кирәкмәгән йөк булып кайта ала ул?! Яу кырыннан бер читтәге урыс авылында төпләнеп калды, «туган авылыма кайтам, ләкин үз аягым белән кайтам» дигән уй ташламады аны. Кырыс холкы, ярдәмчеллеге һәм күкрәгендәге орден-медальләре аны кайда да үзен танытты, ярдәм итте.

Нәгыймә тылда да үз-үзен иркәләмәде, аяусыз булды. Ана ат бирделәр. Ул аты белән йөк ташыды, ерак та түгел яу кырына сугышчылар өчен кирәк-ярак алып барды.

Шулай бервакыт, иртән атын җигәргә конюх килми калды. Нигәдер Нәгыймәнең күңеле җилкенә. Сугыш кырындагыларга авылдан-авылга ризык, кием-салым җыярга кирәк, чыгып китәсе дә, ат җигелмәгән. Үзе дә ике көн инде авызына тәгам ризык алмаган, ул гына түгел, башкалар да Нәгыймә хәлендә, илдә ачлык бит. Ул култык таягына таянып чыкты да көндәгечә атына саклап килгән ике шакмак шикәрен каптырды, сыйпады. Матур сүзләр белән иркәләп сөйләшеп алды да, таякларын җиргә ташлагач, атына чүгәләргә кушып, җәһәт кенә менеп атланды. «Малкай» кушаматлы аты да Нәгыймәнең уй-фикерләрен белә кебек иде, авылдан чыкканчы ул әкрен теркелдәп кенә барды, аннан соң кушаяклап яу кырына чапты. Ат өстендә барган Нәгыймә, күзен алга текәп, ләм-мим — бер сүз дәшми баруын дәвам итте. Күңеленең яу кырына ашкынуын аты да сизде, күрәсең. Шартлау-гөрселдәү тавышлары атны куркытмады да, ә Нәгыймә бу тавышны гүя ишетми дә, әйтерсең чебен-черки тавышы. Малкай хуҗасының нинди уй белән яу кырына китүен әле белми, белсә, болай ук ашкынмас та иде бәлкем.

Көн кичкә авышкач, туктап атын ял иттерергә уйлады. Тезгенне тартып, алгы ботына өч мәртәбә суккалап алды. Малкай аны иплəп кенә җиргә утыртты. Атын иркәләп, матур сүзләр белән сөйләшкәннән соң, аягына уралмасын дип, колак кырыена йөгән башын эләктереп бәйләп куйды да: «Бар, ашап ал!» — диеп атын чирәмгә җибәрде. Күрәсең, алар гомер буе бергә булганнар, бер-берсен бик тиз аңлыйлар һәм ярдәм дә итәләр иде. Нәгыймәнең үтереп ашыйсы килгәч, җиргә ятып, әле генә борын төртеп чыгып килгән тузганакның

яшь яфрагын өзеп капты һәм барыр юлны күзаллап, әзрәк хәл жыярга кирәк дигәндәй, черем итеп алырга уйлады.

Шул арада ул төш күрде, имеш, сугышның эчендә, чолганышта калган да ике фашист, автоматларын терәп, аңа усал итеп карап тора. Куркып уянып китсә - ике бүре ач күзләрен текәп, ыржаешып, аны ботарларга әзер тора иде. Ул әче итеп атына: «Малкай!» — дип кычкырып җибәрде дә кесәсеннән шырпы алып, җиңенә ут төртте һәм янган кулы белән селтәнә-селтәнә бүреләргә таба шуыша башлады. Шулвакыт аты да аңа ыргылып ярдәмгә ташланды, ләкин бар хайваннар да уттан курыкканга, Малкай да якын килергә батырчылык итмәде. Бүреләр уттан куркып бераз читкә китүгә, аты тиз генә җиргә ятты. Нәгыймә дә атының ялын икенче кулы белән чорнап тотып, ерак та түгел күл эченә каулады. Шул арада пешеп әрнегән кулы җанны көйдерде.

Җимерек, янып кара күмергә калган йортлар, басу-кырлар аша үтеп, ниһаять, алар яу кырында. Нәгыймә сугышчыларга ничек тә ярдәм итү йөзеннән, үзенең Малкаен сугышка алып килгән иде дә насыйп булмады.

1945 елның 8 маенда алар тагы да ныграк сөенделәр. Их, аяклары да булса, Малкае тирәли сикереп-сикереп биер иде дә бит, юк шул. Ләкин алар җиргә ятып ауный-ауный сөенеч уртаклаштылар. Нәгыймә үзенең якын дустын — Малкаен беркая да, беркемгә дә бирмәскә һәм аны, гомумән, ташламаска диеп ант итте.

Нәгыймә тагын аның җуйды. Госпиталь. Операцияләр. Озын юл. Туган авыл...

Малкаен ул кабат күрмәде.

Һәр Сабантуйда да шулай бии ул. Тез башына беркеткән тимерләр буынны кырып, тәнне яралый һәм кан чыга. Ә ул түзә, егылмый, бии. Йөрәктә фашистларга карата булган үч тә, Малкаеның ничә еллар көтеп-көтеп тә кайтмавы, газиз әти-әнисеннән аерылу да, чәчәк кебек яшь гомернең мәгънәсез үтүе дә, ялгыз калып, берәүгә дә файдасы тимичә яшәве дә үз-үзен аямыйча биетәдер аны. Аның кырыс холкы тагы да кырысланган, тешен кысып, түзеп яши ул. Үзенчә авылдашларына ярдәм итәргә тырышса да, аны һаман җәлләп чит итәләр. Җәлләмәсеннәр! Елга бер килә торган Сабан туенда биесен ул, ялгыз өенә кайтып тез башын бәйләр дә тагын дөньяга чыгар, тик кызгану тулы күз карашларын гына җене сөйми аның. Нигә шуны авылдашлары анламый икән?!. Җәлләмәсеннәр! Түзә ул! Биесен!

**Гөлнур ВАСЫЙЛОВА,**
*Мамадыш*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Сибгат ХӘКИМ**

## Көтелмәгән рифмалар

***

Туган якта һәр тал жырлый,
Жырлый ярга нык басып.
Монда бар да үз дигәнчә,
Монда һәр тал — Некрасов.

***

Куәте, энергиясе...
Яктысы — хисе кебек,
ГЭС — кеше, Маяковский
Красноярск ГЭСы кебек.

## Һөжүмнән соң

Таң алдыннан барган сугыш тынды кинәт,
Иптәшләрнең саны тулмый – иш ким чыга.
Исемлекне теркәп, аны тутырганда:
— Юк, үлмәдем! — дип, чокырдан Шишкин чыга.

**Рабит БАТУЛЛА**

## Чәчәкләр

Хәсән Туфанның житмеш еллык юбилее кышкы чиллэдә уза.Театр директоры Рәшидә ханым Жиһаншина бүләккә чәчәк алу хәстәрен күрә. Алып кайталар бер бәйләм чәчәк, әмма тажларына салкын бәргән булып чыга.Рәшидә ханым, бик тиз шиңәрләр бит инде, олуг шагыйребездән унайсыз,дип аптырап торганда, Туфан Миңнуллин:

— Жаен табарбыз, Рәшидә ханым,— ди. Кочагы белән чәчәкләрне сәхнәгә алып чыга да Хәсән Туфанның аяк очына сибеп-таратып жибәрә:

— Хөрмәтле Хәсән ага, сезнең чал чәчегез кебек бу ак чәчәкләрне аяк астыгызга сибәргә рөхсәт итегез! – дип, шагыйрьне котлый.

Халык аягүрә басып алкышлый. Соңыннан Нажар Нәжми сокланып болай ди:

— Шагыйрь аягы астына чәчәк сипкәннәрен тәүге тапкыр күрәм!

**Рафаэль ХӘКИМ**

## Тарих чабудан тартса

Мина, Катар дигән илдә, Көнбатыш белән ислам дөньясының үзара аңлашуына корылган зур кинәшмәдә катнашырга туры килде. Буш вакыт булдымы, кибетләргә чыгам. Хатыным мөселман дини җырлары язылган кассеталар алып кайтуымны үтенгән иде. Шуны кайгыртып йөргәндә, бер гарәп сатучысы белән инглиз телендә мондыйрак сөйләшү булып алды:

— Сез кайсы илдән?

— Россиядән.

— Үзегез рус,ә мөселман музыкасы белән кызыксынасыз?

— Татар мин. Мөселман булам.

— Та-та-арр?! Димәк, сез ул — XIV гасырда Багдадны җимерүче!

— Кичер, туган. Хата киткән. Бүтән кабатламабыз...

**Данил САЛИХОВ**

## Кем кемне елата

Гастрольдә йөреп кайткач, атаклы артистыбыз Хәлим Җәләй:

— Илһам Шакиров авырыбрак тора икән, хәлен белеп кайтыйк, — диде.

Киттек бөек җырчыбызның фатирына. Ишекне үзе ачты. Түргә уздырды.Җылы гына әңгәмә корып утырабыз. Фикеребез үткән заманнарга юл алды. Илһам ага, Тукайны искә төшереп, аның бер-ике шигырен яттан сөйләде дә тирән уйга батты. Хәлим Җәләй дә, илһамланып, Тукай шигырен сөйли башлады. Йодрыгы йомарланды. Тәэсирле сүз көченнән кинчә чырае әле җыерылып килә, әле языла.Тынлый торгач, Илһам аганың күз төбендә яшь күренде. Хәлим Җәләй сөйләп бетерде дә, мина ым кагып:

— Менә, энем, өйрәнеп кал, шигырьне шушылай сөйләргә кирәк − Илһам Шакировның үзен елатырлык итеп! − диде. Илһам ага, кинәт калкынып:

— Кит, Гармун чырай! Син укыгангамыни, Тукайны сагынып җылыйм ич мин, — диде.

**Вольдемар БАЛЯЗИН**

## Тун яки кенәз титулы

*Император Павел вакытында Ф.В.Ростопчин (1763-1826) Тышкы эшләр коллегиясен житәкли (1812 елгы сугыш чорында Мәскәүнең башкомандующие һәм генерал-губернаторы).*

Берничә кенәз арасында басып торган Ростопчинга император Павел шундый сорау бирә:

— Сез, Ростопчин, нишләп кенәз түгел?

— Минем бабам, государь, татар морзасы бит, Россиягә кыш көне килеп урнашкан.

— Ел фасылының монда ни катнашы бар? − дигән император, аптырап.

— Татар морзасы патша сараена беренче тапкыр аяк баскач, аңа тун яки кенәз дәрәҗәсе тәкъдим иткәннәр. Бик каты суыкта туңып килгән морза тунны кулайрак күргән.

## Укытучылар каян килә

Ростопчин Парижда спектакль карый. Арадан бер актёр шулкадәр начар уйный, тамашачы тибенә-тибенә сызгыра, мыскыллы сүзләр ыргыта. Бер Ростопчин гына теге актёрны олылап, басып алкышлый икән.

— Сез нәрсә? Нигә алкышлыйсыз ул мокытны?! — дип тирә-юньнән кычкыралар мона французлар.

— Мин бу бәндәне театрдан куарлар дип куркам, — ди Ростопчин. — Аннары ул Россиягә килеп укытучы булачак бит.

**Марсель ГАЛИЕВ**

## Мостай ага сүзе

Голицынодагы Ижат йортыннан Мостай Кәримне Мәскәүгә партия съездына (1986) озатып җибәргән идек, бер атнадан, 8 нче Март алдыннан кайтып төште. Җыелышып каршы алдык, бүлмәсенә озата кердек. Мостай агабыз өстәлгә әллә нинди нигъмәтләр — съезд күчтәнәчләрен таратып ташлады да, күкрәгенә таккан Алтын йолдызын балкытып, гаепле бала сыман басып тора:

— Иң кирәклесе юк бит, егетләр. Сухой закон иде съездда да, — ди.— Рәсүл Гамзатов та бик кәефсез йөрде. «Чё ты, Расул, угрюмый?» — дигән идем, «Не угрюмый, а трезвый», — ди. «Горбачёвның хәмер эчүгә каршы указы хакында ни уйлыйсың?» — дим. «Мы-то випили своё, вот дитэй жалко», — ди.

**Айдар ХӘЛИМ**

## Мәзәк әдәбият

Бүгенге татар әдәбияты дөньякүләм иң бай әдәбиятларның берсе саналырга хаклы. Аларның берсендә дә берсе икенчесе турында бу кадәр көлдерми торган,еш кына бөтенләй тозсыз мәзәк язган бөек язучылары юк. Бездә халләр икенче. Татарстан монда да үрнәк. Игътибар гына итегез:

— Рабит Батулла мәзәкләре;
— Фәнзаман Баттал мәзәкләре;
— Марсель Гали мәзәкләре;
— Тәлгат Нәҗмиев мәзәкләре;
— Камил Кәримов мәзәкләре;
— Ләбиб Лерон мәзәкләре;
— Госман Гомәр мәзәкләре...

Кемнедер онытсам, өстәрсез. Әдәбиятыгыз тоташ бер мәзәккә әйләнде. Шунысы кызганыч: көлеп кенә булмый.

**Максим ГОРЬКИЙ**

## Истәлекләрдән

Лев Толстой:

— Достоевский... Гомумән, ул сәламәт кешеләрне яратмый иде. Үзе чирле булгач, бөтен дөньяны чирле итеп күрәсе килә иде аның.

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

# МӘКАЛЬ ӨМӘСЕ

*Исәнмесез, Мәкаль өмәсен оештыручылар! Бик матур һәм фидакарь эш башлагансыз, уңышлы булсын! 9 нчы санда бирелгән, үземә ошаган мәкальләрне атап китәм (дөресен әйткәндә, барысы да ошады, барысын да китапка кертерлек – мәгънәле). Бер генә киңәш әйтер идем: мәкальләрне темаларга бүлү отышлырак булыр.*

*Үзенә сыймаган серне дустың да саклый алмас.* (Л.Гатауллина). *Бусагасыз түр булмый. Әйбере күбәйсә, йөзе кечерәя. Ир ирдә тәхетле.* (М.Мирза). *Ауган агачка түкран да кунмый. Шома тимер тиз күгәрә. Яман сүз иясеннән алда йөри. Югалган көмешне, алтыным, дип эзлисең. Ялкау байдан хәерче туа. Зур шәхеснең шәүләсе дә зур була. Үз өеңдә йокы да бушлай.* (К.Кәримов). *Хак хат та хаталан хали түгел. Хәмер капканның әмеренә капма. Башы юктан башкисәр дә курка. Моржан кыек булса да, төтене дөрес чыксын.* (В.Нуриев). *Кичке чәй – төнге йокыга тәнәфес. Куләгәнең шәүләсе булмый.* (Р.Ханнанов). *Ана телен үги иткән – анасын да үгисетер. Тарихын оныткан, телен йоткан – үз тамырын үзе корыткан. Йөргән аякка саулык ияра. Мәкаль ул – акыллы уйга тере һәйкәл.* (Р.Юныс).

*Ә хәзер үземнекеләр:*

- Язын чәчмәгәнне көзен урмыйлар.
- Яшьлек эзли күктән хыялын, картлык – җирдән үлән кыягын.
- Өскә кими йөреп авыргач, тун киеп кенә терелмәссең.

***Зимфира ИСЛАМОВА**, Тукай районы Зур Шилнә авылы*

*Кадерле редакция!*

*Иң элек 9нчы, 10нчы саннарда басылган мәкальләр турында бер-ике кәлимә сүз әйтәсе иттем. Ошбу мәкальләр күңелгә ятышлы булды: Бар кәрлә дә Наполеон түгел. Шигырь башына жыр житәр. Күләгәнең шәүләсе булмый. Кала – саланың үксез баласы.*

*Калганнары да бик күркәм,бик дөрес әйтелгән тезмәләр. Мин гомер бакый мәкаль яраттым. И, әйбәт тә эшләгәнсез, үзегез әйтмешли, изге эшне терелткәнсез, рәхмәтләр үзегезгә!*

*Беренче коймак төерле була. Мин дә җибәреп карыйм әле:*

- Көнчелек – кадак, тора йөрәкне кадап.
- Ике яклы пәке дә сынып китә.

***Рушания НИЗАМОВА**, Аксубай районы Яңа Дума авылы*

- Тел саклыйм дип ил ватма, ил саклыйм дип тел ватма!
- Сүзнең дә тәмлесен генә йотуы рәхәт.
- Төш күргәндә эш түгел, теш кенә үсә.


***Люция АБЛИЕВА***

- Ана күңеле – балада, бала күңеле – айфонда.
- Яхшы сүз җанга рәхәт, яман сүзгә бар интернет.
- Елыйсы килгән бала атасының санагы белән уйнар.
- Ике илгә бер кылыч, менә сиңа башваткыч.

***Динара ЗИННӘТОВА***

- Үткәнең белмәүчене киләчәк онытыр.
- Азгын күңел ялтыравыкка алданыр.
- Тәрбиясез кеше белеме бер тиен дә тормас.
- Эшләмичә ашаучылар эшләп ашарга кушар.

***Нурулла ГАРИФ***


16+
IPad
Төп бүләк Сезне көтә!
Газета-журналларга язылыгыз
һәм БҮЛӘК алыгыз!
Өч һәм аннан да күбрәк исемдәге басмаларга язылыгыз («ТАТМЕДИА» ААҖ газета-журналлары)
Язылган басмаларыгызның квитанция күчермәләрен җибәрегез (элемтәгә керү өчен телефоныгызны күрсәтегез)
Безнең адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт, «ТАТМЕДИА» ААҖ, – яисә – podpiska@tatmedia.ru
IPad ™ һәм өч фотоаппарат Сезне көтә!
Беренче 50 әбунәчегә – бүләкләр!
Тулы мәгълүмат www.tatmedia.ru сайтында бирелә

### СЪЕЗД

Казанда археологларның IV Бөтенроссия съезды булып узды. Анда илебезнең ин эре фәнни үзәкләре һәм чит ил белгечләре катнашты.

Съездның пленар утырышын ачып җибәргәндә Россия Фәннәр академиясенен Себер бүлеге археология һәм этнография институты директоры Анатолий Деревянко корылтай үткәрү өчен Казанны юкка гына сайлап алмаганнарын әйтте: «Барыннан да бигрәк бу Татарстан археологиясенен ирешкән уңышлары белән бәйле. Болар — Казан һәм Алабуга шәһәрләренең 1000 еллыгын фәнни дәлилләү, тарихи-мәдәни мирасны саклауга аеруча зур әһәмият бирү, республикада яна археологик экспозицияләр барлыкка килү һәм берьюлы ике эре фәнни үзәк — Фәннәр академиясе химаясендә Археология институты, Болгарда Халыкара археологик эзләнүләр үзәге ачылу».

РФ Дәүләт Думасы Рәисе Сергей Нарышкин, РФ мәдәният министры Владимир Мединский, РФ Фәннәр академиясе президенты Владимир Фортов съезд делегатларына сәламләү хатларын юллаган иде.

ТР Президенты һәм Хөкүмәте исеменнән форум кунакларын ТР Дәүләт киңәшчесе, республика тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызу фондының химаячеләр советы рәисе Минтимер Шәймиев сәламләде.

Съезд кунакларын шулай ук ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин һәм РФ Фәннәр академиясе археология институты директоры Николай Макаров котлады.

### ФЕСТИВАЛЬ

Казанда «Төрки дөнья» I халыкара музыка фестивале булды. 2013 елда Төрки халыклар композиторлары ассоциациясе оештырылгач, Азәрбайҗан, Казакъстан, Кыргызстан, Төркмәнстан, Үзбәкстан, Башкортстан һ.б. республикаларның музыка әһелләре, симфоник, камера оркестрлары катнашында шушындый чара оештыру уе туа. Казан 2014 елда төрки дөньяның мәдәни башкаласы дип игълан ителгәч, аны бездә үткәрергә булалар. Фестивальгә төрки илләрдән музыкантлар, композиторлар килгән иде.

Әлеге фестиваль кысаларында «Хәзинә» милли сәнгать галереясендә үзенчәлекле күргәзмә ачылды. Анда Татарстан һәм Россиянең халык артисты, республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Рәшит Кәлимуллин гомере буе җыйган музыка уен кораллары урын алган. Алар XVIII гасыр ахыры — XX йөз башына карый. Монда «җырлый торган» Тибет чынаягын да, Будда динендәгеләр үз гыйбадәтләрендә куллана торган төрбәне, кыңгырауларны да күрергә мөмкин. Аларның гадәти булмаган формалары хыялны Кытай, Япония, Малайзия, Сингапур, Һиндстан, Индонезия, Австралия, Көньяк Америка, Африка мәдәниятләренә алып китә. Экспозициядә тынлы, кыллы, бәрмә, үзләреннән-үзләре яңгырый торган музыка уен кораллары аерым-аерым туплап тәкъдим ителгән. Тышкы рәвешләре бер-берсеннән үзгә булса да, эчке төзелешләре охшаш аларның. Бу исә кешелек дөньясының рухи бердәмлеген күрсәтә торган фалдыр. Экспозициядә татар музыка уен коралларына да зур урын бирелгән.

Күргәзмәдә дә, фестиваль дәвамында да милли музыка уен коралларын һәм дөнья күләмендә, һәм төрки дөньяда саклау мәсьәләсе күтәрелде.

### КҮРГӘЗМӘ

«Хәзинә» милли сәнгать галереясендә II төбәкара «Идел-Арт — 2014» күргәзмәсе ачылды. Исеменнән үк күренгәнчә, ул Идел буенда яшәүче халыкларны, аларның рәссамнарын берләштерә. Күргәзмәне Татарстан Мәдәният министрлыгы, Россия Сәнгать академиясенең Идел буе бүлеге, Россия Рәссамнар берлеге һәм аның Мәскәү, Казан, Чабаксар, Самара, Саранск, Уфадагы төбәк бүлекчәләре һәм Татарстан Сынлы сәнгать музее оештырды.

«Идел-Арт» күргәзмәсенә бары тик соңгы бер-ике ел эчендә иҗат ителгән эшләрне генә кабул итәләр. Рәссамнарга жанр, өслүб, тема җәһәтеннән бернинди чикләүләр дә юк. Алардан бүгенге вакыйгаларга карата ихлас хис-кичерешләрен, хак мөнәсәбәтләрен белдерү сорала. Күргәзмәне ачу тантанасында бер төркем рәссамнарга Россия Рәссамнар берлегенең алтын, көмеш, бронза медальләре, Рәхмәт хатлары тапшырылды.

## АЛИШНЫ ИСКӘ АЛУ

Һәр елны көз башлану белән, каһарман-шагыйрь Абдулла Алишны искә алу чаралары уздыру, анын исемендәге әдәби премия тапшыру күркәм традициягә әверелде. Быел да бу тантана балалар әдәбияты классигынын туган ягында — Спас районы Көек авылында үткәрелде. Бәйрәмгә кунаклар да кайткан иде. Башта алар Алишнын музеен карадылар. Аннары Мәдәният йортында зур бәйрәм булды. Районнын барлык мәктәпләреннән килгән укучылар әдипнен шигырьләрен сөйләделәр, әкиятләрен укыдылар, җырларын җырладылар. Кичәдә катнашучыларны Спас муниципаль районы башлыгы Камил Нагаев сәламләде. Алиш якташлары алдында Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәмис Аймәт, язучылар Әнәс Хәсәнов, Фарсель Зыятдинов, Солтан Шәмси, Вакыйф Нуриев, Дания Гайнетдинова (барысы да Алиш премиясе лауреатлары), Казандагы 20нче гимназия директоры, «Алиш варислары» музеен оештыручы Рәхимә Арсланова, Алишнын туганнары Чаллыдан галим Илдар Алишев, Апастан журналист Азат Сөнкишев, Казаннан Гөлшат Сөнкишева, шушы районнан укытучы Флёра Алишева-Хәйретдинова катнашты һәм чыгыш ясады.

Бәйрәмнен ин дулкынландыргыч мизгеле Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенен Абдулла Алиш исемендәге премиясенен быелгы лауреатын игълан итү булгандыр. Ул – драматург, прозаик, шагыйрь Хәбир Ибраһимов (Ахир).

Бәйрәмнен ахырында кунаклар Алишнын бюстына чәчәкләр салды.

## СЕМИНАР

Татарстан Язучылар берлегендә республикабыздагы җирле әдәби берләшмәләр җитәкчеләренен семинары булды. Анда сүз урыннарда әдәби хәрәкәтне тагын да җанландыру, яшь язучыларны барлау, аларнын иҗади үсеше өчен мөмкинлекләр тудыру турында барды. Г.Тукай клубында үткәрелгән пленар утырышны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов ачты. Семинарда катнашучылар алдында ТР Дәүләт Советынын Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, ТР халык шагыйре Разил Вәлиев, «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры киңәшчесе, ТР халык шагыйре Равил Фәйзуллин, Татарстан Язучылар берлегенен кабул итү коллегиясе рәисе, әдәбият галиме, прозаик Тәлгат Галиуллин, ТР Министрлар Кабинетынын сектор җитәкчесе, шагыйрь, прозаик Галимҗан Гыйльманов, ТР Мәдәният министрлыгынын һөнәри сәнгать һәм сәнгать белеме бүлеге җитәкчесе Дилия Хәйретдинова чыгыш ясады. Семинарда катнашучылар Төркиядән килгән кунак, дөньякүләм танылган галим, милләттәшебез Надир Дәүләт белән очрашты.

Ин актив әдәби берләшмә җитәкчеләренә Татарстан Язучылар берлегенен Рәхмәт хатлары тапшырылды.

## ИҖАТ КИЧӘСЕ

Язучы Әмирҗан Моталлаповка 80 яшь тулу унаеннан Актанышта иҗат кичәсе булды. Юбилярны «Казан утлары» журналынын баш мөхәррире Илфак Ибраһимов, «Мәйдан» журналынын баш мөхәррире Вахит Имамов, язучылар Фәйрүзә Мөслимова, Айгөл Әхмәтгалиева тәбрик итте. Актаныш муниципаль районы башлыгы Фаил Камаев һәм Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Данил Салихов татар әдәбиятында сатира жанрын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен Әмирҗан Моталлаповка Гамил Афзал премиясен тапшырды.

## ОЧРАШУ

Минзәлә һәм Чаллы педагогия колледжларында «Казан утлары» журналынын баш мөхәррире Илфак Ибраһимов, бүлек мөхәррире Айгөл Әхмәтгалиева, шагыйрә Фәйрүзә Мөслимова белән очрашулар булды. Бүгенге көн укучысы әдәби журналдан ниләр көтә, аны нәрсәләр кызыксындыра — очрашуларда әнә шундый сораулар күтәрелде.

## ХЕЗМӘТЕНӘ КҮРӘ ХӨРМӘТЕ

Гаммәви мәгълүмат чараларын үстерүгә зур өлеш керткәне, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Тамедиа» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Шаһнәхмәтов Фәрит Илдус улы** Татарстан Республикасынын «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

2014 елнын 30 сентябрендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрә **Арсланова-Әйбәдуллова Рушания Зиннәтулла кызы (Рушания Арсланова)** 80нче яшендә вафат булды.

2014 елнын 4 октябрендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, язучы-публицист **Нәҗмиев Тәлгат Самат улы** 65нче яшендә вафат булды.

2014 елнын 29 октябрендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, театр белгече **Гыймранова Дания Әхәт кызы** 77нче яшендә вафат булды.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: Рассказы Р.ХУЗИ «Чаша цемента», Г.ВАСИЛОВОЙ «Танцовщица Нагима»; стихи Р.НИЗАМИ, С.РАХМАТУЛЛЫ, Л.ВАЛИЕВОЙ, Л.ШАЕХА.
«Конкурс на повесть малого формата»: З.ХАКИМ. «Ошалелый призывник»; Ф.АБДУЛЛИН. «Шакал».
«Рассказы из жизни»: Р.ЮСУПОВА о трагических страницах жизни С.ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ-ВОЛЖСКОЙ.
«100-я страница»: стихотворение З.МАНСУРОВА.
«Из литературы братских народов»: стихи ЧУЛПАН.
«Литературная критика»: статья Р.ШАРАФИЕВА о современной татарской поэзии.
«Юбилеи»: «Круглый стол», посвящённый 75-летию со дня основания ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова; статья Л.ХАМИДУЛЛИНА, посвящённая 95-летию ТКИ; статья Р.ЮСУПОВА, посвящённая 45-летию КГУКИ.
«Искусство»: статьи Ю.САФИУЛЛИНА, Р.ТАЗЕТДИНОВА, посвящённые 80-летию со дня рождения М.САЛИМЗЯНОВА.
«Жизнь и религия»: хаджнама Т.НАЗМЕТДИНА.
«Память»: А.ШАМОВА. «Ваши судьбы связаны с огнём войны»; Р.МИРХАЙДАРОВ. Мемуары. «Вот и всё... Я пишу вам с вокзала».
Ответное письмо Р.НИЗАМИ Р.ХАРИСУ.
«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.
Из фотоархива журнала: рубрику ведёт Р.ФАЙЗУЛЛИН.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Зимний пейзаж». Работа И.Зарипова; Казанское музыкальное училище им. И.В.Аухадеева (110 лет со дня основания). *Фото Л.Губайдуллина.*

## IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: Stories by R.HUZI «Bowl of cement», G.VASILOVA «Dancer Nagima»; poems by R.NIZAMI, S.RAHMATULLA, L.VALIEVA, L.SHAEH.
«Competition for small-format novel»: Z.HAKIM «Stunned recruit»; F.ABDULLIN «The Jackal».
«Stories of life»: R.YUSUPOVA about tragic pages of S.Gizzatullina-Volgskaya's life.
«100th page»: poem by Z.MANSUROV.
«Literature of fraternal peoples»: verses by CHULPAN.
«Literary criticism»: article by R.SHARAFIEV about modern Tatar poetry.
«Anniversaries», «Round table», dedicated to the 75th anniversary of the founding of Institute of language, literature and arts named after. G.Ibragimov; article by L.HAMIDULLIN dedicated to the 95th anniversary of TBP; article by R.YUSUPOV.
«Art»: articles by YU.SAFIULLIN, R.TAZETDINOV, dedicated to the 80th anniversary of M.SALIMZYANOV.
«Life and Religion»: hadzhnama by T.NAZMETDIN.
«Memory»: A.SHAMOVA. «Your fates are linked by war fire»; R.MIRHAYDAROV. Memoirs. «That's all ... I'm writing to you from the station».
Response letter by R.NIZAMI to R.HARIS.
«Pages of humor»: section is led by M.GALIEV.
From the photo archives of the magazine.
Diary of a social-cultural life.
On our covers: «Winter Landscape». Work by I.Zaripov; Kazan Music College named after I.V.Auhadeev (110 years since its foundation).

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Кышкы пейзаж». *Рәссам И.Зарипов эше.* Россия Федерациясенең халык рәссамы Илдар Зариповка 75 яшь.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* И.В.Әүхәдиев исемендәге Казан музыка училищесы (нигез салынуына 110 ел). *Л.Гобәйдуллин фотосы.*

# Яңа китаплар




**Халиуллин Ю.Н.**
**НА СТЫКЕ ДВУХ ТЫСЯЧЕЛЕТИЙ:** *научная публицистика дипломата. – Казань: Татар.кн.изд-во, 2014.— 542 с. Тираж – 2000 экз.*

Шәрекъне өйрәнүче галим, илче Йолдыз Хәлиуллинның унике бүлектән торган бу китабына 2008-2014 еллар аралыгында төрле газета-журналларда дөнья күргән фәнни-популяр язмалары, халыкара форумнарда ясаган чыгышлары тупланган. Әлеге язмалар хәзерге заман фәне өчен кызыклы булган микродөнья, макрокосмос, астрофизика, Арктиканың сәяси һәм икътисади проблемаларын яктырталар.
Китапта шулай ук Шәрекъ илләренең үсеше, мөселман дөньясы, төрки халыкларның әдәбияты һәм сәнгатенә караган авырлыклар да күрсәтелә. Күп илләр гизгән илче буларак, Й.Хәлиуллинның Индонезия, Пакистан, Непал кебек илләрнең үткәне һәм бүгенгесе турындагы мавыктыргыч язмалары, күренекле кешеләре белән очрашу-әңгәмәләре дә укучы өчен бай мәгълүматка ия.




**Ганиева Р.К.**
**ТРАДИЦИИ ВОСТОЧНОГО РЕНЕССАНСА В ТЮРКСКИХ ЛИТЕРАТУРАХ СРЕДНЕВЕКОВЬЯ И НОВОГО ВРЕМЕНИ.**
*– Казань: Изд-во «Фэн» АН РТ, 2014.—270 стр. Тираж – 150 экз.*

Ренессанс – французчадан татарчага «Яңарыш» дип тәрҗемә ителә. Ренессанс күренеше билгеле бер чорга гына карамый, аерым халыклар әдәбиятына һәм мәдәниятенә генә хас күренеш тә түгел. Ул — төрле дәверләрдә, формаларда яңа фикерләр белән баетылып яңарып торучы бер күренеш.
Филология фәннәре докторы Резеда Ганиеваның әлеге хезмәтендә Шәрекъ Ренессансының төрки халыклар әдәбиятындагы чагылышы өйрәнелгән. Китап берничә бүлектән тора. Автор Кол Галинең «Йосыф кыйссасы», XVI-XVIII гасырларда яшәгән Мәүлә Колый һәм Мәхтүмколый, Утыз Имәни һ.б. иҗатларында Ренессанс һәм дини-мистик мотивларны яктырта, аның мөселман гарәп-фарсы-төрки халыклар мәдәниятендә булганын да раслый. Изге китабыбыз – Коръәндәге Илаһият, Галәм, Кеше турындагы яңа дини-фәлсәфи, фәнни-дөньяви, рухи-әхлакый кыйммәтләргә таянып, ислам цивилизациясенең яңарышка таба үткән юлын чагылдыра.

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

2014
МӘДӘНИЯТ ЕЛЫ



Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)